# 2024 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эшчәнлек нәтиҗәләре турында
# ХИСАП

Казан 2025

## ЭЧТӘЛЕК

СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ТОТРЫКЛЫЛЫКНЫ ТӘЭМИН ИТҮ ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ........ 3
ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ........ 5
БЮДЖЕТ СӘЯСӘТЕ ........ 9
ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАЛАРЫ ........ 16
ТӨП СОЦИАЛЬ КҮРСӘТКЕЧЛӘР ........ 22
МӘГАРИФ ........ 24
СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ........ 33
ХЕЗМӘТ, МӘШГУЛЬЛЕК ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ ........ 40
ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ ........ 62
ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕ ........ 66
МӘДӘНИЯТ ........ 75
КОММЕРЦИЯЧЕЛ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАРГА ЯРДӘМ ИТҮ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ ........ 87
МӘДӘНИЯТ, СОЦИАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ, СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ҺӘМ МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ ОЕШМАЛАР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛГӘН ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ СЫЙФАТЫНА БӘЙСЕЗ БӘЯ БИРҮ ........ 91
ТУРИЗМ ........ 93
ЭКОЛОГИЯ ........ 96
ТӨП ИКЪТИСАДЫЙ КҮРСӘТКЕЧЛӘР ........ 107
СӘНӘГАТЬ ........ 112
АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫ ........ 126
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ ........ 131
ИНВЕСТИЦИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ........ 139
ФӘННЕ ҺӘМ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ ҮСТЕРҮ ........ 150
КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫК ........ 160
ЦИФРЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ ........ 169
КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ КӨРӘШҮ ........ 180
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында сораулар исемлеге буенча мәгълүмат ........ 184

# СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ТОТРЫКЛЫЛЫКНЫ ТӘЭМИН ИТҮ ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ

Көчле санкцияләр һәм гамәлдәге чикләүләр шартларында республиканың предприятиеләре һәм оешмалары җитештерү өлкәләрен үстерүне дәвам иттерәләр, инвестиция активлыгын киметмиләр, логистика бәйләнешләрен һәм товар сату базарларын үзгәртеп коралар, чит ил товарларын илдә җитештерелгән товарларга алмаштыру проектларын гамәлгә ашыралар.

Икътисад предприятиеләре һәм тармакларының өзлексез эшләве, федераль һәм республика ярдәм чаралары нәтиҗәсендә республикада икътисадый үсеш кимеми.

Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 29 мартындагы 125 номерлы боерыгы нигезендә төзелгән Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб (алга таба – Оператив штаб) тарафыннан предприятиеләр белән социаль-икътисадый тотрыклылыкны, соңгыларының ярдәм чараларында катнашуын тәэмин итү буенча эш оештырылды.

Оператив штаб һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы коллегиясе уртак утырышының һәм Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов катнашында Дәүләт Думасының Икътисадый сәясәт буенча комитеты күчмә утырышының 2024 елның 2 апрелендәге ПР-69 номерлы беркетмәсе нигезендә 2024 елда Татарстан Республикасы икътисадын тотрыклы нәтиҗәле үстерүне тәэмин итү буенча чаралар планы (алга таба – Чаралар планы) хупланды. Чаралар планы барышы ел әйләнәсендә даими рәвештә Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов уздырган киңәшмәләрдә каралды.

2024 елда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 18 мартындагы 96 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча эш төркеме (алга таба – эш төркеме) үз эшен дәвам итте.

Эш төркеме утырышлары кысаларында Чаралар планын үтәүгә оператив мониторинг ясала, эш күзәтчелектә тотыла, түбәндәге юнәлешләр буенча тиешле чаралар күрелә:

икътисад тармаклары оешмаларының эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру;

инвестиция активлыгын киметмәү, инвестицияләр кертүне стимуллаштыру;

инвестиция активлыгын үстерү һәм яңа технологияләрне кулланышка кертү;

кече һәм урта эшкуарлыкны сыйфатлы үстерү;

муниципаль берәмлекләрне тигезлек саклап үстерү һәм илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын нәтиҗәле гамәлгә ашыруны дәвам иттерү.

2024 елда эш төркеменең 27 утырышы уздырылды, аларда түбәндәге төп мәсьәләләр каралды:

2025 – 2027 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразларын һәм 2024 елга социаль-икътисадый үсеше фаразлары күрсәткечләре үтәлешен эшләү, икътисадый үсешне тәэмин итү өчен икътисад тармакларындагы резервларны анализлау;

республиканың тармак министрлыклары тарафыннан үзләре җитәкчелек итә

торган предприятиеләрдә система булдыручы оешмаларның финанс-икътисадый хәлен яхшырту өчен Россия ФСС «Мәгълүматларны тыштан җыю» платформасында мониторинглау нәтиҗәләренә нигезләнеп күрелә торган чаралар;

2024 елга муниципаль берәмлекләр икътисадын үстерүнең максатчан күрсәткечләрен үтәү;

республика предприятиеләре һәм оешмаларының кадрларга кагылышлы мәсьәләләре;

үзмәшгуль гражданнар белән хезмәт мөнәсәбәтләренең гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә алыштырылуын булдырмау мәсьәләләре буенча чаралар күрү;

республика предприятиеләренең һәм оешмаларының федераль һәм республика ярдәм чараларында катнашуы;

республикада илкүләм проектларны гамәлгә ашыру, аларны «Контента» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында яктырту, социаль әһәмияткә ия булган объектларга бренд бирү һәм аларга QR-кодлар урнаштыру;

Татарстанда кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү, шул исәптән кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең төп күрсәткечләренә ирешү, сәнәгать паркларын, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары башкара торган экспортны, Интернет аша сәүдә итүне, Республика маркетинг үзәге ресурсларында эшләүне үстерү, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан иминиятләштерү кертемнәрен исәпләү формасы буенча хисап тапшыруын тәэмин итү өлешендә дә;

инвестиция активлыгын үстерү;

муниципаль дәрәҗәдә норматив хокукый актларның җайга салу йогынтысын бәяләү;

Россия Федерациясе Үзәк банкы төп ставкасының икътисадка йогынтысын бәяләү;

туристлык өлкәсен үстерү;

республикада майнинг эшчәнлеген үстерү;

2024 елда республиканың тотрыклы икътисадый үсешен тәэмин итү буенча эш йомгаклары һәм 2025 елга бурычлар.

Эш төркеменең аерым бер утырышы интернет һәм мәгълүмат технологияләре өлкәсендә алдау очракларына каршы көрәшү мәсьәләләренә багышланган иде, анда Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлекчәсе – Татарстан Республикасы буенча Милли банк, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, «Саклык банкы» ГАҖ вәкилләре катнашында интернет һәм мәгълүмат технологияләре өлкәсендә алдау очракларын кисәтү буенча профилактика чаралары, алдау очракларына күзәтчелек эшчәнлеге, аларга каршы көрәшү буенча законнар базасын камилләштерү мәсьәләләре, хокук саклау органнарының кредит оешмалары белән цифрлы инструментлардан файдаланып алдау гамәлләрен профилактикалау һәм ачыклау, кредит оешмалары тарафыннан интернет һәм мәгълүмат технологияләре өлкәсендә алдауга каршы көрәшү буенча заманча инструментларны куллану өлешендә хезмәттәшлек итү мәсьәләләре каралды.

# ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ

## Илкүләм проектлар

Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары билгеләнде.

2019 елдан Татарстан Республикасы 13 илкүләм проект составындагы 50 төбәк проектын гамәлгә ашыруда катнашты. Алар түбәндәге төп юнәлешләр буенча уздырылды:

«Кеше капиталы» («Сәламәтлек саклау», «Мәгариф», «Демография», «Мәдәният», «Фән һәм университетлар»);

«Яшәү өчен уңайлы мохит» («Торак һәм шәһәр даирәсе», «Экология», «Сыйфатлы куркынычсыз юллар», «Туристлык һәм кунакчыллык»);

«Икътисадый үсеш» («Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык башлангычларына ярдәм итү», «Цифрлы нигезгә корылган икътисад», «Хезмәт җитештерүчәнлеге», «Халыкара кооперация һәм экспорт»).

Моннан тыш, 2024 елдан Татарстан Республикасында Магистраль инфраструктураны яңартып кору һәм киңәйтү комплекслы планы кысаларында чара уздырылды.

2019 – 2024 елларда республикада илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга 227,9 млрд сум бүлеп бирелде.

Бүлеп бирелгән акча хисабына 1 788 социаль әһәмияткә ия объект төзелде һәм төзекләндерелде, җиһазлар белән җиһазландырылды һәм цифрлы нигезгә корылды.

Моннан тыш, балалы гаиләләргә һәм өлкәннәргә ярдәм чаралары күрелде. Эшкуарлык һәм талантлы яшьләрне үстерү өчен өстәмә шартлар тудырылды.

2024 елда 13 илкүләм проектны һәм Магистраль инфраструктураны яңартып кору һәм киңәйтү комплекслы планын гамәлгә ашыруга 46,9 млрд сум бүлеп бирелде, шул исәптән федераль бюджеттан – 29,5 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 17,4 млрд сум. Бүлеп бирелгән акчага 311 объект төзелде һәм төзекләндерелде:

6 гомуми белем бирү мәктәбе төзелде:

1 501 урынга (Усад, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы);

1 501 урынга (Казан шәһәре, «Яз» ТК);

1 224 урынга (Биектау авылы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы);

1 224 урынга (Родина ур., Казан шәһәре);

1 224 урынга (М-14 микрорайон, Идел буе районы, Казан шәһәре);

1 224 урынга (65 микрорайон, Чаллы шәһәре);

«Алгоритм» технологияләр лицее» МБМУсенә өстәмә корпус төзелде (Көек авылы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы);

«Химиклар мәдәният сарае» яшьләр үзәгендә капиталь төзекләндерү уздырылды (Казан шәһәре);

2 спорт залында төзекләндерү эшләре уздырылды (Татарстан Республикасы Тукай һәм Ютазы муниципаль районнары);

42 җәмәгать урыны, шул исәптән парклар һәм скверлар төзекләндерелде;

Картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йорт төзелеше башланды (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы);

республиканың муниципаль районнарында 105 сәламәтлек саклау объекты, шул исәптән фельдшерлык-акушерлык пунктлары (ФАП), хастаханәләр, поликлиникалар һәм табиблык амбулаторияләре төзелде;

18 мәдәният объекты капиталь төзекләндерелде, шул исәптән: 14 авыл мәдәният йорты (Татарстан Республикасының Апас, Саба, Әтнә, Әлмәт, Буа, Алексеевск, Лениногорск, Биектау, Чүпрәле, Балтач, Минзәлә, Лаеш, Баулы, Мамадыш муниципаль районнары), балалар сәнгать мәктәбе (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы), Казан дәүләт яшь тамашачы театры (Казан шәһәре), «Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры» ТР ДАМУ, «Әлмәт татар дәүләт драма театры» ТР ДАМУ;

Биектау тимер юл станциясе поселогында биологик чистарту корылмалары һәм Биектау авылында юынтык су агызу системалары төзелде (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы);

Шыгали авыл җирлегендә (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы) юынтык су агызу һәм су белән тәэмин итү челтәрләре төзелде;

Россия Федерациясе субъектлары торак төзелеше дәүләт программаларына кертелгән торак төзү күздә тотылган торак пунктлар чикләрендә территорияләрне үстерү проекты гамәлгә ашырылды (Казан шәһәре Киров районы Ягодный урамында тоташтыру/технологик ялгау эшләре);

гражданнарны тузган торак фондыннан күчерү өчен 17 фатир сатып алынды (Казан шәһәре);

муниципаль районнарда 103 юл челтәре объектлары норматив хәлгә китерелде (төзелеш, төзекләндерү һәм реконструкцияләү);

Габдулла Тукай исемендәге «Казан халыкара аэропорты аэродром һәм аэровокзал инфраструктурасын реконструкцияләү (1 этап – перронны реконструкцияләү);

Казан шәһәренең биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү (2021 – 2024 еллар);

Казан шәһәренең биологик чистарту корылмалары елылы кырларын яңарту (2021 – 2025 еллар);

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында нефтьле матдәләр белән пычратылган җирләрне тернәкләндерү уздырылды (2024 – 2024 еллар).

Моннан тыш, 2024 елда илкүләм проектларны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә социаль әһәмияткә ия учреждениеләрнең матди-техник базасын яхшырту, шулай ук гаиләләргә һәм эшкуарларга ярдәм чаралары уздырылды.

Илкүләм проектларны гамәлгә ашыру вакытында түбәндәге күрсәткечләргә ирешелде:

балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге 100% тәшкил итте;

5 тән 18 яшькәчә 85% артыграк бала өстәмә белем ала (2024 елга план – 78,04%);

65,8% граждан системалы төстә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнә

(2024 елга план – 63,3%);

бер үк вакытта күпме кеше сыйдыра алу ягыннан чыгып караганда гражданнарның спорт корылмалары белән тәэмин ителү дәрәҗәсе – 72,5% (2024 ел планы – 71,9 %);

хезмәт яшеннән узган гражданнарга, диспансерлаштыруны да кертеп, профилактик тикшеренүләр уздыру – 70,0% тәэмин ителде (2024 ел планы – 70 %);

җәмәгатьчелек фикере буенча халыкның медицина ярдәме күрсәтүдән канәгатьлеге – 62,9% (2024 ел планы –59 %);

кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә эшләүчеләр саны, шәхси эшкуарларны да кертеп – 828,5 мең кеше (2024 ел планы – 729,9 мең кеше);

электрон рәвештә күрсәтелгән массакүләм социаль әһәмияткә ия дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өлеше – 100 % (2024 ел планы – 95 %);

торак төзелеше күләме – 3,45 млн кв. м (2024 ел планы – 2,95 млн кв. м);

355 җәмәгать урыны төзекләндерелде (2024 ел планы – 353).

Илкүләм проектларны гамәлгә ашыру барышында гражданнарның тормыш сыйфатын яхшыртуда мөһим нәтиҗәләргә ирешелүне исәпкә алып, Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин тарафыннан аларны 2025–2030 елларда да гамәлгә ашыруны дәвам иттерү турында карар кабул ителде.

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы нигезендә 2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга перспективада Россия Федерациясе үсешенең 7 илкүләм максаты билгеләнде:

халыкны саклау, кешеләрнең сәламәтлеген ныгыту һәм иминлеген арттыру, гаиләләргә ярдәм күрсәтү;

һәр кешенең мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру, аның талантларын үстерү, патриот һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү;

яшәү өчен уңайлы һәм имин мохит булдыру;

экологик куркынычсызлык;

тотрыклы һәм тиз үсештәге икътисад;

технологик алдынгылык;

дәүләт һәм муниципаль идарә системасын, икътисад һәм социаль өлкәләрне цифрлы нигезгә күчерү.

Аларга ирешү өчен 19 яңа илкүләм проект эшләнде:

«Озын һәм актив тормыш»;

«Гаилә»;

«Яшьләр һәм балалар»;

«Яшәү инфраструктурасы»;

«Нәтиҗәле транспорт системасы»;

«Экологик иминлек»;

«Нәтиҗәле һәм конкурентлыкка сәләтле икътисад»;

«Халыкара кооперация һәм экспорт»;

«Туристлык һәм кунакчыллык»;

«Кадрлар»;

«Мәгълүмат икътисады һәм дәүләтнең цифрлы нигезгә күчеше»;

«Транспорт хәрәкәтен сәнәгать ягыннан тәэмин итү»;

«Күп спутниклы орбита төркемен үстерү»;

«Яңа материаллар һәм химия»;

«Сәламәтлекне саклауның яңа технологияләре»;

«Яңа атом һәм энергетика технологияләре»;

«Җитештерү һәм автоматлаштыру чаралары»;

«Пилотсыз авиация системалары»;

«Азык-төлек ягыннан иминлекне технологик тәэмин итү».

Бүлеп бирелгән финансларны һәм декомпозиция күрсәткечләрен исәпкә алып республикада 12 илкүләм проект составына кертелгән 46 төбәк проектын гамәлгә ашыру каралган.

## БЮДЖЕТ СӘЯСӘТЕ

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре өлешендә.

2024 елда Татарстан Республикасы бюджетына салым һәм салымнан алынмаган керемнәр 499,1 млрд сум күләмендә җыелды, план күрсәткечләренең 101,8 процентын тәшкил итте, бу исә 2023 ел күрсәткечләреннән 92,0 млрд сумга яисә 22,6 процентка артыграк. Федераль бюджеттан һәм башка чыганаклардан республикага 95,1 млрд сум җәлеп ителде.

**2024 елда Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салымнан алынмаган керемнәре структурасы**




Республика бюджетына керемнәрне арттыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 30 апрелендәге 687-р номерлы карары нигезендә

Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының үз керемнәрен үстерүне тәэмин итү буенча ведомствоара комиссиясе эшли. 2024 елда комиссия расланган план кысаларында түбәндәге юнәлешләрдә эшчәнлек алып барды:

керемгә салым түләүгә ай саен мониторинг уздырылды, нәтиҗәдә алдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда түләүләре кимегән оешмалар ачыкланды. Мондый оешмаларның исемлеге квартал саен аналитик эш белән шөгыльләнүче тармак министрлыгына җиткерелеп торды, алар баланс комиссияләре эшчәнлеге кысаларында салымнар түләүнең кимүе сәбәпләрен, шулай ук барлык дәрәҗәдәге бюджетларга түләүләр буенча бурычы булган оешмалар белән бәйле вазгыятьне тикшерделәр. Уртак эш йомгаклары буенча тармак министрлыклары тарафыннан үз карамакларындагы оешмаларда җитештерү рентабельлеген арттыру һәм аларны керем алу дәрәҗәсенә чыгару, шулай ук бюджетка түләүләр буенча бурычны киметү буенча тәкъдимнәр эшләнде;

физик затларның керемнәренә салым салу өлешендә яшерен хезмәт хакын легальләштерү, «конвертта» акча түләүне һәм физик затларның керемнәренә салым түләүдән читләшүнең башка схемаларын ачыклау эшчәнлеге алып барылды; учреждение хезмәткәрләренә хезмәткә түләүнең федераль законнарда билгеләнгән

иң түбән күләменнән азрак булмаган күләмдә хезмәт хакы түләү контрольдә тотылды; шулай ук әлеге салымны түләүне алдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда киметкән салым түләүчеләргә мониторинг уздырылды;

салым түләүче физик затларның милеккә салым түләүләре үз вакытында һәм тулысынча башкарылуын тәэмин итү буенча чаралар уздырылды. Әлеге чаралар үтәлеше барышында зур предприятиеләр, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципалитетлар белән хезмәттәшлек ителде. Салым түләүчеләргә салым түләү турында хәбәрнамәләрне җиткерү, кредит оешмалары һәм почта бүлекчәләре тарафыннан түләүләрне өзлексез кабул итү эше оештырылды, шулай ук киң колачлы мәгълүмати эш, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында да, җәелдерелде;

акцизга караган продукцияне төп җитештерүчеләрнең продукция җитештерүенә һәм аны сатуына, шулай ук план күрсәткечләренә ирешүенә мониторинг уздыру буенча даими эш алып барылды;

салымнан алынмаган керемнәр өлешендә Татарстан Республикасы бюджетына һәм муниципаль районнар һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларына керә торган керемнәрне анализлау һәм фаразлана торган керемнәрне бәяләү башкарылды, керем базасын арттыру һәм түләүләр буенча бурычларны киметү максатларында салымнан алынмаган керемнәр администраторлары белән уртак эш алып барылды;

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салым бурычларын киметү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 июлендәге 1493-р номерлы карары нигезендә төзелгән Ведомствоара комиссия (штаб) эше кысаларында ай саен муниципаль районнарга һәм шәһәр округларына Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белешмәләреннән чыгып, бурычлары булган салым түләүчеләр турында мәгълүмат юлланды. Муниципаль берәмлекләрнең ведомствоара комиссияләре эшенең йомгаклары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләре катнашында видеоконференция режимында уздырылган киңәшмәләрендә каралды. Бурычлары булган затлар белән икътисадый эшчәнлек төрләре буенча эш алып барылды, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, республика башкарма хакимият органнары һәм эре предприятиеләр хезмәткәрләренең бурычларын каплауга мониторинг уздырылды.

Моннан тыш, бюджетка керемне арттыру максатларында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан республиканың зур күләмдә салым түләүчеләре белән эш уздырылды, шул исәптән:

эре предприятиеләр һәм кече нефть компанияләреннән бюджетка түләүләрне анализлау һәм фаразлана торган түләүләрне бәяләү;

компанияләрнең хисап чорында эшчәнлеге йомгаклары буенча комиссияара киңәшмәләр, аларда эшчәнлек нәтиҗәләренә бәя бирелде, түләүләр кимүе сәбәпләре ачыкланды, шулай ук бюджетка түләүләрне арттыру өчен чаралар эшләнде;

хисап чоры йомгаклары буенча эре предприятиеләр корпоратив идарә органнарының Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы катнашындагы утырышларына, кече нефть компанияләренең Татарстан Республикасы Рәисе

җитәкчелегендәге утырышларына материаллар әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фондына түләүләр планын төзү һәм аларның вакытында түләнүен тәэмин итү.

Керемгә салым һәм оешмалар милкенә салым буенча ташламалар рәвешендә дәүләт ярдәменә дәгъва кылган инвестиция эшчәнлеге субъектларының инвестиция проектларына, алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары составына кертелүгә дәгъва кылган инвестиция эшчәнлеге субъектларының инвестиция проектларына, махсус инвестиция контракты, капитал салуны куркынычсыз итү һәм аңа ярдәм күрсәтү турында килешү төзүгә дәгъва кылган оешмаларның инвестиция проектларына экспертиза ясалды. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белешмәләре нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру торышы турында хисаплар әзерләнде. Шулай ук инвестиция эшчәнлеге субъектларының республиканың берләштерелгән бюджетына инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында тиешле килешүләр гамәлдә булган чор эчендә салымнар һәм җыемнар түләүне ел саен тәэмин итү буенча йөкләмәләрен үтәүләренә бәя бирелде.

Кабул ителә торган үзгәрешләрнең Татарстан Республикасы икътисадына һәм берләштерелгән бюджетына мөмкин булган йогынтылары турында тиз арада республика җитәкчелегенә мәгълүмат бирү максатында федераль закон проектлары даими нигездә анализлана. 2024 елда салымнар һәм җыемнар турындагы законнарга үзгәрешләр кертү буенча закон инициативаларына 88 бәяләмә әзерләнде.

Республиканың салым турындагы законнарын камилләштерү буенча закон чыгару эшчәнлеге дәвам иттерелде. 2024 елда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы салым һәм җыемнар буенча 11 закон проектын әзерләүдә катнашы, алар арасында Татарстан Республикасы бюджетына керә торган салым һәм җыемнар буенча бурычны гадиләштерелгән система буенча чигерүгә, милеккә салым салуга кагылышлылары да бар.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе белән берлектә 2024 елда Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны чикләү буенча закон проектларына бәяләмәләр әзерләү тәэмин ителде.

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары өлешендә

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары 578,3 млрд сум күләмендә башкарылды, шулардан иң зур күләмдәге чыгым юнәлешләре:

юл хуҗалы – 104,5 млрд сум;

мәгариф – 87,7 млрд сум;

социаль сәясәт – 61,7 млрд сум;

сәламәтлек саклау – 58,2 млрд сум;

торак-коммуналь хуҗалык – 45,2 млрд сум;

мәдәният һәм кинематография – 26,2 млрд сум;

авыл хуҗалыгы – 15,3 млрд сум.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы муниципаль берәмлекләр белән берлектә, бюджетны үтәүнең казначылык системасын файдаланып, хезмәт хакын, социаль түләүләрне вакытында түләүне, бюджет учреждениеләре

мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүне һәм инвестиция проектларына ярдәм күрсәтүне контрольдә тотты.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты тарафыннан эчке дәүләт финанс контроле кысаларында 2024 елда 313 контроль чара уздырды. Уздырылган тикшерүләр йомгаклары буенча бюджет акчасының 130,7 млн сумга нәтиҗәсез файдаланылуы ачыкланды. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү чараларын күрү өчен учреждениеләр җитәкчеләренә кисәтүләр ясалды, алар нәтиҗәсендә җитешсезлекләрнең күбесе бетерелде. Тикшерүләр актлары прокурорлар тарафыннан чаралар күрелсен өчен Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды.

2024 елда Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы, «2012–2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә кылынган гамәлләрнең илкүләм стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы, «Ятим балаларны һәм ата-аналар тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның кайбер чаралары турында» 2012 елның 28 декабрендәге 1 688 номерлы указларын (алга таба – «май» указлары) гамәлгә ашыру эше дәвам иттерелде.

2024 ел йомгаклары буенча бюджет өлкәсенең «май указлары»нда билгеләнгән аерым категория хезмәткәрләр хезмәтенә түләүнең максатчан күрсәткечләре республикада үтәлде. Эш хакы түләү өчен акчага ихтыяҗ 2024 елда 238,8 млрд сум булды һәм финанс чыганаклары белән тулысынча тәэмин ителде, шул исәптән федераль бюджеттан – 3,9 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 170,1 млрд сум, Мәҗбүри медицина иминләштерүе фонды акчалары хисабыннан – 48,8 млрд сум, бюджеттан тыш акчалар хисабыннан – 16,0 млрд сум.

Бюджет законнары кысаларында 2024 ел дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы хисаплар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитетына, Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә даими төстә тапшырылып торды. Алар буенча кирәкле карарлар һәм бәяләмәләр кабул ителде.

Һәр квартал саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салым һәм финанслар комитеты утырышларында Татарстан Республикасы бюджетына керемнәр туплау һәм бюджет акчаларын нәтиҗәле куллану мәсьәләләре каралды. 2024 елның июнендә, сентябрендә һәм декабрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетына үзгәрешләр кертү буенча эш башкарылды.

Федераль дәүләт хакимияте органнарына Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар үтәлеше турында даими төстә аналитик материаллар юлланды. 2024 елның июнендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында 2023 елга Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисап, шулай ук «2023 елга Татарстан Республикасы бюджетын үтәү турында» 2024 елның 8 июнендәге 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы каралды һәм кабул ителде. 2024 елга бюджет үтәлеше турындагы хисапка тышкы тикшерүне һәм экспертизаны Татарстан Республикасы Хисап палатасы башкарды.

2024 елда Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетын һәм 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы бергәлектә төзегән 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты, 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминләштерүе төбәк фонды бюджеты проектларын төзегәндә эшләнгән закон проектлары, документлар һәм материаллар әзерләү графигы (аны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы бергәлектә төзеде) нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджет проектын һәм Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминләштерүе төбәк фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турында» 2008 елның 28 мартындагы 206 номерлы карарының 9 пункты нигезендә башкарылды.

Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары күләмнәре буенча 2025 – 2027 елларга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеты проектларын әзерләү өчен башлангыч мәгълүматлар әзерләнде. 2024 елның маенда 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеше фаразы нигезендә 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын формалаштыру барышында исәпкә алына торган финанслау нормативларын исәпләгәндә куллану өчен төп индекс-дефляторлар билгеләнде.

Татарстан Республикасының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджеты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның ноябрендә кабул ителде һәм аңа Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов кул куйды («Татарстан Республикасының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы). Республика башкарма хакимият органнарына чыгымнар өлешендә ул элемтә хезмәтенә, транспортны карап тотуга чыгымнарга, башка чыгымнарга билгеләнгән нормативларны исәпкә алып формалаштырылды.

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетының чыгым өлешен 2025 елга социаль-мәдәни өлкә тармаклары буенча формалаштырганда норматив планлаштыру ысулы кулланылды. Учреждениеләрне 2025 елга финанслау нормативларын раслаучы Татарстан Республикасының тиешле законнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары кабул ителде.

2024 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 31 декабрендәге 1194 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт финансларының кимчелекле якларын бетерү буенча чаралар планы чаралары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 мартындагы 788-р номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының керемнәрен арттыру, чыгымнарын киметү һәм бурыч сәясәтен камилләштерү буенча чаралар планында каралган чараларны гамәлгә ашыру дәвам

иттерелде.

Татарстан Республикасының дәүләт бурычы белән идарә итү өлешендә

2024 ел дәвамында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан йөкләмәләрне үтәү графиклары нигезендә республика дәүләт бурычын исәпкә алу, рәсмиләштерү, вакытында түләү һәм хезмәт күрсәтү мәсьәләләре белән бәйләнгән чараларның тулы бер комплексы уздырылды. Татарстан Республикасы дәүләт бурыч китабы алып барылды, Россия Федерациясе Финанс министрлыгына тапшыру өчен хисап белешмәләре әзерләнде, дәүләт бурычын киметү буенча чаралар планы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 14 гыйнварындагы 10-р номерлы боерыгы) 2023 елга үтәлде. Бу эшне башкарганда республика бюджеты дефицитын финанслау максатында коммерциячел оешмалардан акча алуга куелган чикләүләр бозылмады.

2024 елда Татарстанның инфраструктурасын үстерү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен бирү аша «Банк ДОМ.РФ» АҖ линиясе буенча «Казанның Киров районында Горький шоссесын реконструкцияләү» проектын гамәлгә ашыру өчен 12,7 млрд сум күләмендә акча алынды.

Федераль бюджетка яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашырудан алынган салым керемнәре күләмендә Татарстан Республикасының федераль бюджет алдында бюджет кредитлары буенча бурычларының бер өлешен чигерү эше дәвам иттерелде. 2024 елда 9,5 млрд сум күләмендә кредитлар буенча бурычлар чигерелде.

Дәүләт бурычына кагылышлы йөкләмәләрне үтәү эше кысаларында 2024 елда федераль бюджет кредитларыннан файдаланган өчен процентларны түләү үз вакытында һәм тулы күләмдә һәм расланган түләү графиклары буенча гомуми күләме 16,0 млрд сум тәшкил иткән төп бурычны түләү башкарылды.

«Торак», «Заманча мәктәп», «Мәдәни мохит», «Сәламәтлек саклау өлкәсенең башлангыч буынын яңартып кору», «Төбәк һәм җирле юл челтәре» федераль проектларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасының тиешле өлкәләрдә объектларны төзү һәм капиталь төзекләндерү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслар белән алдан ук тәэмин итү максатларында бюджетның бердәм хисабында калдыкка кушу өчен алынган (14,97 млн сум) бюджет кредиты тулысынча кайтарылды.

инфраструктур проектларны гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итү максатларында алынган озак вакытка исәпләнгән бюджет кредиты (1,02 млрд сум) түләнә башлады;

алдарак реструктуризацияләнгән бюджет кредитлары буенча бурычның бер өлеше түләнде (29,0 млн сум).

Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләре буенча вакыты узган түләнмәгән бурычлары юк.

2024 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт бурычының тулаем күләме (дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрне исәпкә алып) 112,1 млрд сум тәшкил итте. Татарстан Республикасы бюджетының бурыч йөкләмәсе дәрәҗәсе (салым һәм салымнан алынмаган керемнәрнең еллык күләменә дәүләт бурычы күләменең нисбәте) 22,5 процент тәшкил итте (2023 ел йомгаклары буенча – 30,9 %). Бу исә дәүләттән акча алуны башкаруга югарыда әйтелгән консерватив караш, федераль бюджет кредитлары буенча бурычларны бер өлешен түләү һәм чигерү,

Татарстан Республикасы бюджетының керем базасын эзлекле арттыруны тәэмин итү кысаларында уздырылган эш нәтиҗәсе булды.

Россиянең «Аналитика Кредит Рейтинг Агентлыгы» (АКРА) һәм «Эксперт РА» рейтинг агентлыклары Татарстан Республикасының кредит рейтингы Россия Федерациясендә иң югары дәрәҗәсенә җитте дигән бәя бирде.

## ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАЛАРЫ

Татарстан Республикасы дәүләт программалары бурычлар, аларны үтәү өчен бирелгән вакыт, башкаручылар буенча бер-берсенә бәйләнешле чаралар (нәтиҗәләр) комплексы кергән стратегик планлаштыру документлары, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы белән билгеләнгән Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына аеруча нәтиҗәле ирешүне, «Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше бурычларын хәл итүне тәэмин итә торган инструментлар комплексы булып торалар.

**Дәүләт программалары белән идарә итүнең яңа системасына күчү**

2021 елдан Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе дәүләт программалары инструментларын яңартып үзгәртү, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының яңа дәүләт программаларын эшләүне оештыру эше уздырыла.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 26 маендагы 786 номерлы карары нигезендә Россия Федерациясе дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында нигезләмә расланды, анда дәүләт программалары инструментларын тамырдан яңартып үзгәртү, аларны эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга карашны үзгәртү, аларның форматын компактлы итү, әмма бу программаларны күбрәк мәгълүмат бирерлек, камил структуралы, аңлаешлы һәм ансат итү күздә тотыла.

Дәүләт программалары инструментын яңартып үзгәртү, бюджет чыгымнарының ачыклыгы максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе тарафыннан расланган 2022 елның 30 августындагы № ММ-П6-14588 план-график нигезендә 2024 елның 1 гыйнварыннан «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итү дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында («Электрон бюджет» ДИМС) дәүләт программалары белән идарә итүнең яңа системасына күчеш булды.

Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 10 апрелендәге 16232-МР номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын электрон рәвештә гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә Татарстан Республикасы дәүләт программалары паспортларын төбәк мәгълүмат системасына күчерү эше башкарылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 2023 елның 30 маендагы 655 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2023 елның 22 декабрендәге 1667 номерлы (алга таба –

1667 номерлы карар) карарларга үзгәрешләр кертелде.

1667 номерлы карар нигезендә һәр дәүләт программасы буенча Татарстан Республикасы Премьер министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе дәрәҗәсендә кураторлар, республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре дәрәҗәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын җаваплы башкаручылар билгеләнде.

Татарстан Республикасы дәүләт программаларының җаваплы башкаручылары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт программаларын раслау турындагы карарларына проект форматында үзгәрешләр кертелде.

2024 елның 1 гыйнварыннан республикада Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм аларның структур элементларын формалаштыру һәм раслау «Дәүләт программалары белән идарә итүнең цифрлы модуле» төбәк мәгълүмат системасында (алга таба – Цифрлы модуль) алып барыла.

**Дәүләт программаларының нәтиҗәлелеген бәяләү**

Россия Федерациясе дәүләт программалары нәтиҗәлелеген бәяләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышын һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык җыелма доклад әзерләү кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм аерым актлары нигезләмәләрен үз көчен югалткан дип тану турында» 2023 елның 15 маендагы 752 номерлы карары нигезендә башкарыла.

2024 елда икътисад өлкәсенә һәм җәмгыятьнең социаль тормышына кагылышлы 34 дәүләт программасы гамәлгә ашырылды.

2024 елга Татарстан Республикасы дәүләт программаларының нәтиҗәлелеген бәяләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышын һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык җыелма доклад Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 2023 елның 30 маендагы 655 номерлы карары нигезендә әзерләнде. Бәяләүгә 34 дәүләт программасы, 81 төбәк программасы, 94 процесслы чара комплексы һәм илкүләм проектлар составында 50 төбәк проекты кертелде.

2024 елда Татарстан Республикасы программаларын гамәлгә ашыруга 570,7 млрд сум тотылды, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 511,8 млрд сум, федераль бюджет акчасы – 58,9 млрд сум.

2024 елда дәүләт программалары нәтиҗәлелеген бәяләүнең уртача күрсәткечләре дәүләт программаларының күрсәткечләренә ирешү дәрәҗәсе буенча 119,3% тәшкил итә.

2024 ел йомгаклары буенча: 33 дәүләт программасы – югары нәтиҗәлелеккә ирешкән (план күрсәткечләре 95% ка ирешелгән); 1 дәүләт программасы – нәтиҗәлелеге канәгатьләнерлек дип табылган (план күрсәткечләре 80%ка ирешелгән).

Планда билгеләнгән дәрәҗәгә тулы күләмдә – 1 657 күрсәткеч, тулы булмаган күләмдә 17 күрсәткеч буенча ирешелде, 21 е буенча күрсәткечләргә ирешелмәде.

2024 елда 1 522 чараның (нәтиҗә) 1 503 е яисә дәүләт программаларының

98,8% структур элементы үтәлде, 19 чара (1,2%) үтәлмәде.

Хисап чоры йомгаклары буенча дәүләт программалары структур элементларының 2 644 контроль ноктасыннан: 2 632 се (99,5%) – үтәлде , 12 се (0,5%) – үтәлмәде.

**Дәүләт программаларының үтәлеш дәрәҗәсе**

Дәүләт программаларының үтәлү дәрәҗәсе Цифрлы модульдә китерелгән белешмәләр нигезендә һәм дәүләт программаларын үтәү өчен җаваплы башкаручылар биргән хисап мәгълүматларының тулылыгын һәм дөреслеген бәяләүне исәпкә алып башкарылды.

Дәүләт программаларының үтәлеш дәрәҗәсе турында мәгълүмат
(2024 елның 31 декабренә)

| Т/с | Дәүләт программасының атамасы | Дәүләт программасының күрсәткечләре үтәлеш дәрәҗәсе, % |
|---|---|---|
| | **Уртача күрсәткеч** | **119,34** |
| 1. | Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше | 266,89 |
| 2. | Чит илләрдә яшәүче ватандашларга Татарстан Республикасына ирекле төстә күченүдә ярдәм күрсәтү, 2024 – 2026 елларга | 190,33 |
| 3. | Татарстан Республикасы халкы мәшгульлегенә ярдәм итү | 152,34 |
| 4. | Татарстан Республикасында архив эшен үстерү | 141,86 |
| 5. | Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базар-ларын җайга салу | 128,68 |
| 6. | Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү | 127,22 |
| 7. | Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү | 124,86 |
| 8. | Татар халкының милли тәңгәллеген саклау | 118,50 |
| 9. | Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә | 117,93 |
| 10. | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү | 114,85 |
| 11. | Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшү | 116,08 |
| 12. | Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен үстерү | 115,43 |
| 13. | Әйләнә-тирә мохитне саклау, Татарстан Республикасының табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану | 114,74 |

| Т/с | Дәүләт программасының атамасы | Дәүләт программасының күрсәткечләре үтәлеш дәрәҗәсе, % |
|---|---|---|
| 14. | Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү | 114,13 |
| 15. | Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү | 113,83 |
| 16. | Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү | 113,70 |
| 17. | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү | 111,47 |
| 18. | Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү | 111,43 |
| 19. | Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады | 111,32 |
| 20. | Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү | 108,89 |
| 21. | Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү | 108,59 |
| 22. | Цифрлы нигезгә корылган Татарстан | 107,87 |
| 23. | Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү | 107,21 |
| 24. | Татарстан Республикасы дәүләт милке белән идарә итү | 105,64 |
| 25. | Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге | 105,60 |
| 26. | Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру | 104,85 |
| 27. | Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү | 104,31 |
| 28. | Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү | 103,82 |
| 29. | Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне га-дәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэ-мин итү | 103,34 |
| 30. | Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен зарядка инфраструктурасын үстерү | 102,87 |
| 31. | Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру | 101,34 |
| 32. | Татарстан Республикасында юстицияне үстерү | 100,42 |

| Т/с | Дәүләт программасының атамасы | Дәүләт программасының күрсәткечләре үтәлеш дәрәҗәсе, % |
|---|---|---|
| 33. | Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү | 100,00 |
| 34. | Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү | 87,05 |

**Дәүләт программаларының касса үтәлеше дәрәҗәсе**

2024 елның 31 декабренә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән, шушы ук датадагы җыелма бюджет язмасында каралган Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджет акчаларының касса үтәлеше дәрәҗәсе – 560,2 млрд сум (план – 570,7 млрд сум), бу исә 98,2% тәшкил итә.

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының касса үтәлеше дәрәҗәсе 34 дәүләт программасы буенча түбәндәгечә:

6 дәүләт программасы буенча – 100% («Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү», «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге», «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше», «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен зарядка инфраструктурасын үстерү»);

25 дәүләт программасы – 90ннан 99 процентка кадәр (мәсәлән, «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшү», «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады», «Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү»);

3 дәүләт программасы буенча – 90 проценттан кимрәк («Татарстан Республикасы халкы мәшгульлегенә ярдәм итү», «Татарстан Республикасында архив эшен үстерү», «Чит илләрдә яшәүче ватандашларга Татарстан Республикасына ирекле төстә күченүдә ярдәм күрсәтү»);

Федераль бюджет акчаларының касса үтәлеше 24 дәүләт программасы буенча түбәндәгечә:

16 дәүләт программасы – 99 проценттан артыграк (әйтик, «Әйләнә-тирә мохитне саклау, Татарстан Республикасы табигать ресурсларын тергезү һәм файдалану», «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады», «Цифрлы нигезгә корылган Татарстан», «Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү», «Татарстан Республикасы дәүләт милке белән идарә итү», «Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү», «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру», «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү»);

6 дәүләт программасы — 90 ннан 99 процентка кадәр («Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү», «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин

итү», «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү», «Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү», «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү», «Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү»);

2 дәүләт программасы буенча — 90 процентган кимрәк («Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү», «Чит илләрдә яшәүче ватандашларга Татарстан Республикасына ирекле төстә күченүдә ярдәм күрсәтү, 2024 – 2026 елларга»).

# ТӨП СОЦИАЛЬ КҮРСӘТКЕЧЛӘР

## Халыкның тормыш дәрәҗәсе

Республика предприятиеләрендә һәм оешмаларында, кече эшмәкәрлек субъектларын да кертеп, уртача исәпләп чыгарылган хезмәт хакы 2024 елда 75 644,8 сум тәшкил итте һәм 2023 ел белән чагыштырганда 22,3 процентка артты. Товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә куллану бәяләре индексын исәпкә алып хисапланган реаль хезмәт хакы 112,9 % тәшкил итте.

**Татарстан Республикасында айлык уртача хезмәт хакы**




Республикада югары хезмәт хаклары икътисадый эшчәнлекнең түбәндәге төрләрендә күзәтелде:

мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек – 119,9 мең сум;

финанс һәм иминиятләштерү эшчәнлеге – 112,9 мең сум;

файдалы казылмалар чыгару – 116,2 мең сум; электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү, һава әйләнешен булдыру – 95,0 мең сум;

эшкәртү производстволары – 92,8 мең сум;

һөнәри, фәнни һәм техник эшчәнлек – 92,0 мең сум.

Мәгариф өлкәсендә хезмәткәрләрнең уртача айлык хезмәт хакы 57,8 мең сум, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә – 65,9 мең сум, мәдәният, спорт, ял һәм күңел ачуны оештыру өлкәсендә 79,2 мең сум тәшкил итте.

Бюджеттан тыш сектор оешмаларында һәм юридик зат буларак теркәлмичә генә эшләүче шәхси эшкуарлар хезмәтенә түләүнең минималь күләмен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Эшкуарлар берләшмәләренең координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында даими рәвештә айлык хезмәт хакының минималь күләме турында килешүләр (алга таба – Килешү) төзелә.

2024 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 27 декабрендәге Килешү нигезендә минималь хезмәт хакы аена 22 020 сум күләмендә билгеләнде, бу исә 2023 елның II кварталы өчен Татарстан Республикасы буенча тулаем минималь куллану бюджеты бәяләр күләменең 100 процентын тәшкил итә.

Хезмәткә түләү турындагы законнарны, шул исәптән хезмәткәрләрнең хезмәтенә вакытында һәм тулысынча түләү һәм хезмәт хакының минималь күләменә кагылышлы эш республика дәрәҗәсендә дә, муниципаль берәмлекләр дәрәҗәсендә дә, дәүләт идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары, контроль күзәтчелек органнары, республиканың һөнәр берлекләре һәм эш бирүчеләре берләшмәләре белән тыгыз хезмәттәшлектә алып барыла.

Халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшырту, хезмәт, Татарстан Республикасында чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе эшчәнлеге кысаларында бу юнәлештә чаралар комплексы күрелә. Тормыш дәрәҗәсен яхшырту һәм керемнәрне легальләштерү буенча шундый ук комиссияләр республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә эшли.

**Хезмәт базары**

Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча исәпләнгән халыкның эш белән тәэмин ителгәнлек дәрәҗәсе 2024 елда Татарстан Республикасында 62,3 процент тәшкил итте.

2024 елның 1 гыйнварыннан «Россия Федерациясе халкының эш белән тәэмин ителүе турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565 номерлы Россия Федерациясе Законының кайбер нигезләмәләре үз көченә керде. Закон тулысынча 2025 елның 1 гыйнварыннан тулысынча үз көченә керде. Федераль закон халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең хокукый, икътисадый, оештыру, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә законнарның үтәлешенә дәүләт контроле нигезләрен билгели. Законда эшсезләргә адреслы ярдәм һәм социаль булышлык күрсәтүгә, һәр гражданның шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алуга игътибар юнәлтелә.

**2024 елда эшсезлек дәрәҗәсенең динамикасы**




2024 елның декабре азагына теркәлгән эшсезләр саны республикада 3,2 мең кеше яки эшче көчләр санының 0,16 процентын тәшкил итте.

## МӘГАРИФ

Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары

Республикада 1 935 мәктәпкәчә мәгариф оешмасы эшли, аларда мәктәп яшенә җитмәгән 193 928 бала тәрбияләнә.

Балалар бакчаларының гомуми санныннан 711е татар телендә белем һәм тәрбия бирә, аларга татар милләтеннән булган 27 109 бала йөри.

653 рус-татар балалар бакчасында 1 389 татар төркеме эшли, аларда татар милләтеннән булган 24 978 бала тәрбияләнә.

Моннан тыш, республикада 51 – чуваш , 15 – удмурт, 8 – марий, 1 – мордва телләрендә белем һәм тәрбия бирә торган балалар бакчасы эшли.

Татарстан Республикасында туган телдә (рус телендә түгел) тәрбия һәм белем бирү дәрәҗәсе 55,6 % тәшкил итә.

2024 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карары нигезендә 1 560 урынлык 7 балалар бакчасы төзелде (220 урынлык – Васильево штп., Солнечная ур.; 260 урынлык – Казан шәһәрендә, «Салават күпере-2» ТК; 260 урынлык – Казан шәһәрендә, Бохар ур.; 80 урынлык – Казан шәһәрендә, Ягодинский ур.; 260 урынлык – Питрәч муниципаль районы Көек авылы, «Яшьлек» мкр.; 220 урынлык – Биектау муниципаль районы, Шыгали авылы; 260 урынлык – Лаеш муниципаль районы, Кече Кабан авылы).

Барлык яшь категориясендәге балалар мәктәпкәчә белем бирү мөмкинлеге белән 100 процентка тәэмин ителде.

Гомуми белем бирү оешмалары

2024/25 уку елында республикада 1 402 гомуми белем бирү оешмасы эшли:

1 279 гомуми белем бирү мәктәбе (шуларның 423е авылдагы урта мәктәпләр) һәм 25 мәктәп-интернат;

сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 23 мәктәп һәм 30 мәктәп-интернат;

2 шифаханә-мәктәп-интернат;

девиант тәртипле балалар өчен 1 мәктәп;

7 кичке гомуми белем бирү мәктәбе;

дәүләтнеке булмаган 27 мәктәп;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы 2 гомуми белем бирү мәктәбе;

6 федераль мәктәп.

2024/25 уку елы башында республиканың гомуми белем бирү оешмаларында 510 951 кеше (шуларның авылдагы урта мәктәпләрдә – 74 180 бала) белем алды, педагогик кадрларның саны 37 меңнән артып китте, шуларның 32 меңгә якыны – укытучылар.

2024 елда 9 478 урынга исәпләнгән 10 гомуми белем бирә торган объект төзелде (шул исәптән 888 урынга исәпләнгән инде элек төзелгән мәктәпкә өстәмә 2 корпус):

«Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында 7 898 урынга исәпләнгән 6 мәктәп һәм 618 урынга исәпләнгән инде элек төзелгән мәктәпкә өстәмә 1 корпус төзелде («Яз» ТК 1 501 урынга исәпләнгән мәктәп, Родина ур. 1 224 урынга исәпләнгән

мәктәп, Казан шәһәренең М-14 мкр. 1 224 урынга исәпләнгән мәктәп, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Усад авылында 1 501 урынга исәпләнгән мәктәп, Биектау авылында 1 224 урынга исәпләнгән мәктәп, Чаллының 65 мкр. 1 224 урынга исәпләнгән мәктәп, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Көек авылындагы «Алгоритм» технологик лицее» МБМУ 618 урынга исәпләнгән өстәмә корпус);

Татарстан Республикасы бюджеты хисабыннан 692 урынга исәпләнгән 2 мәктәп һәм инде эшли торган мәктәпкә 270 урынлык 1 өстәмә корпус (Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Кавал авылында 500 урынга исәпләнгән мәктәп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авылында 192 урынга исәпләнгән мәктәп, Казан шәһәре Мәскәү районының «Казан федераль университеты каршындагы Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 номерлы татар гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең өстәмә корпусы – 270 урынга исәпләнгән остазлык мәктәбе).

Татарстан Республикасында түбәндәгеләр эшли:

рус телендә белем бирелә торган 880 мәктәп, аларда 434 504 бала укый;

татар телендә белем бирелә һәм аерым фәннәр рус телендә өйрәтелә торган 591 (шуларның 100е – филиаллар) гомуми белем бирү оешмасы, 82 236 укучы, шулардан 57 895 бала туган телдә белем ала;

белем бирүдә этномәдәни компонентлы 124 мәктәп, шулардан:

белем бирүдә чуваш этномәдәни компоненты кулланылган, чуваш теле өйрәтелә торган 84 мәктәп (шуларның 16 сы филиаллар) (3 254 укучы);

белем бирүдә удмурт этномәдәни компоненты кулланылган, удмурт теле өйрәтелә торган 20 мәктәп (шуларның 4 се филиаллар) (1 507 укучы);

белем бирүдә мари этномәдәни компоненты кулланылган, мари теле өйрәтелә торган 16 мәктәп (шуларның 1 се филиал) (888 укучы);

мордва телләре (мокша һәм эрзя) өйрәтелә торган 3 мәктәп (шуларның 1 се филиал) (54 укучы );

яһүд теле өйрәтелә торган 1 мәктәп (777 укучы).

Күпмилләтле якшәмбе мәктәпләренең 111 бүлекчәсендә 30 милләтнең (азәрбайҗан, әрмән, таҗик, үзбәк, немец, грузин, корея, кыргыз, украин, башкорт һәм башкалар) теле һәм мәдәнияте өйрәнелә. 1 946 бала укытыла.

Сыйныф җитәкчеләренә ай саен бер сыйныфка 550 сум һәм һәрбер укучы өчен 80 сум түләнә. Федераль бюджеттан мәгариф оешмалары педагогларына сыйныф җитәкчелеге өчен өстәмә рәвештә ай саен 5 000 сум түләү каралган. 2024 елның 1 мартыннан дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы педагогларга сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү, шулай ук халык саны 100 мең кешедән артып киткән торак пунктларда (шәһәр, район үзәге, поселок, авыл) дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында урта һөнәри белем бирү мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы педагогларга сыйныф җитәкчелеге (кураторлык) өчен түләү күләме 10 мең сумга җиткерелде.

2024/25 уку елында 490 205 укучы кайнар ризык белән тәэмин ителде, шулардан 216 320 бала 1–4 сыйныф һәм 273 885 бала 5–11 сыйныф укучылары. Өстәвенә кече сыйныф укучыларының күпчелеге көненә 2 тапкыр ашатыла (туклану

белән тәэмин ителгән әлеге яшьтәге балалар санынннан 69%), урта һәм өлкән сыйныф укучыларының күпчелеге бер тапкыр туклана (туклану белән тәэмин ителгән 5–11 сыйныф укучыларының 73 %).

1–4 сыйныф укучыларын 2024 елда түләүсез туклану белән тәэмин итүгә 2 608,2 млн сум тотылды, шул исәптән федераль бюджеттан – 1 564,9 млн сум, Татарстан Республикасы һәм муниципаль бюджеттан – 1 043,3 млн сум.

2024 елда 2,47 млрд сумга 63 объект төзекләндерелде, шул исәптән:

1 137,87 млн сумга 12 муниципаль мәктәп;

227,75 млн сумга 25 дәүләт мәгариф оешмасы, шул исәптән коррекция һәм кадет оешмалары;

1 055,41 млн сумга 20 балалар бакчасы;

53,64 млн сумга – 6 дәүләт оешмасы бинасы.

Мәктәпләрне төзекләндерү федераль программасы кысаларында – 6 гомуми белем бирү оешмасы биналарында 765,54 млн сумга төзекләндерү эшләре башкарылды (459,32 млн сум – федераль бюджеттан субсидия, 306,22 млн сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары).

Гомуми белем бирү оешмаларында 1–4 сыйныф укучыларын түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру өчен кирәкле инфраструктураны яхшырту өчен, 2024 елда мәгариф оешмаларының ризык пешерү блокларын капиталь төзекләндерү программалары кысаларында, җиһаз алып, 94 мәгариф объектында 1,0 млрд сумга ризык пешерү блоклары төзекләндерелде.

2024 елда балаларга өстәмә белем бирү программаларын республиканың 2 770 мәгариф оешмасы башкарды, шуларның 153е – мәгариф системасының балаларга өстәмә белем бирү муниципаль оешмалары. Өстәмә белем бирү программалары буенча шөгыльләнгән 5 яшьтән 18 яшькәчә балаларның өлеше 85,2% тәшкил итә.

Республиканың мәгариф оешмаларында «Гаилә белеме» проекты гамәлгә ашырыла, аның максаты – укучы балаларны гаилә тормышына әзерләү, гаилә коручының шәхесен, традицион гаилә кыйммәтләренә – йортка, гаиләгә, әти-әни булуга, туганлыкка, никахта тугрылыкка һәм мәхәббәткә хөрмәт формалаштыру. «Гаилә белеме» проекты мәгариф системасына электив, факультатив яисә сыйныф сәгате буларак мәгариф оешмаларының тәрбия эше кысаларында кертелә.

2024 елның 25–26 гыйнварында Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында (ул «Гаилә белеме» проектын гамәлгә ашыру буенча республика инновация мәйданчыгы булып тора) «Гаилә: минем өемдә минем урыным» дип аталган укыту-методик семинар узды, ул Гаилә елына багышланган иде. Анда директор урынбасарлары һәм тәрбия буенча директор урынбасарлары, «Гаилә белеме» проекты укытучылары катнашты.

2024 елның 27 февралендә «ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү университеты базасында «Әтиләр һәм хәзерге җәмгыять тормышында әти кеше булу: «Гаилә белеме» программасы аша караш» дигән республика фәнни-гамәли конференциясе узды.

Казан шәһәренең Яңа Савин районы «146 нчы Лицей «Ресурс» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе Татарстанда гаилә белеме буенча педагогларның осталык дәресләре уздыруы ягыннан федераль дәрәҗәдә «Россиянең иң яхшы

мәктәбе» дип танылды.

Республикада Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларыннан килгән балалар өчен профильле тел өйрәнү лагерьлары оештырылды. 2024 елда бу лагерьларда 1 580 бала ял итте. Профильле сменалар эшчәнлеге барышында иҗат кичәләре, конкурслар, татар теле дәресләре, татар халкы тарихына багышланган дәресләр, осталык дәресләре, язучылар, республиканың талантлы яшьләре белән очрашулар оештырылды.

Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте (алга таба – Беренчеләр хәрәкәте) үзенең эшчәнлеген «Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәте турында» 261-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә һәм Күзәтчелек Советы утырышында Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин тарафыннан расланган Беренчеләр хәрәкәтенең тәрбия эше программасы нигезендә алып бара.

Татарстан Республикасында Беренчеләр хәрәкәте Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов йөкләмәсе буенча балалар бакчасыннан башлап алып барыла. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән бергәләп «Беренчеләр хәрәкәтендә мәктәпкәчә мәгариф оешмалары» сынау проекты гамәлгә ашырыла торган 160 учреждение билгеләнде. Татарстан Республикасының 1 300 гомуми белем бирү оешмаларында Беренчеләр хәрәкәтенең башлангыч бүлекчәләре ачылды.

Урта һөнәри белем бирү

Татарстан Республикасында 100 урта һөнәри белем бирү учреждениесе (88 дәүләт һәм 12 дәүләтнеке булмаган) эшли, аларда 84 193 студент белем ала.

Татарстан Республикасының төп эш бирүчеләренең кадрларга ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен төзелә торган ресурс үзәкләре биналарын, шулай ук Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары биналарын, җиһаз, инвентарь сатып алып һәм территорияләрен төзекләндереп, капиталь төзекләндерү программасы кысаларында 2024 елда 4 һөнәри белем бирү оешмасына 500,0 млн сумга төзекләндерү уздырылды.

Шулай ук һөнәри белем бирү оешмаларының тулай тораклары биналарын җиһазлар сатып алып һәм территорияләрен төзекләндереп капиталь төзекләндерү программасы кысаларында 406,46 млн сумга һөнәри белем бирү оешмаларының 15 тулай тораклары бинасы төзекләндерелде.

Республикада 49 ресурс үзәге эшли. Алар арасында «Әлмәт сәүдә-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе һәм «Н.Ш. Әхмәтшин исемендәге Түбән Кама педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында ачылганнары да бар.

Ресурс үзәкләре эшчәнлегенең төп мәсьәләләре булып аларның кыска вакытка исәпләнгән мәгариф программаларын гамәлгә ашыруы, эш бирүчеләрнең кадрлар әзерләү программаларын формалаштыруда һәм идарә эшләрендә катнашуы, укытучыларның һәм производствода эшкә өйрәтүче осталарның профильле предприятиеләрдәге стажировкаларын оештыру, мәгариф оешмаларының бюджеттан тыш эшчәнлеген үстерү, мәктәпне тәмамлаучыларны эшкә урнаштыру тора.

Республиканың һөнәри мәгариф оешмалары федераль проектларда һәм

грантларда актив катнашалар. «Һөнәри осталык» федераль проектында республиканың 16 һөнәри белем бирү оешмасы җиңүче дип табылды.

Республикада 14 укыту-производство һәм мәгариф кластерлары булдырылды, 2025 елда 2 кластер ачу планлаштырыла.

Моннан тыш, 2024 елда «Һөнәри осталык» федераль проекты кысаларында «Сәнәгать һәм инженерлык технологияләре» тармагы буенча алдан ук һөнәри әзерлек бирү үзәге төзелде. Республикада барлыгы ике алдан ук һөнәри белем бирү үзәге эшли.

Эшче һөнәренең әһәмиятен һәм абруен күтәрүгә чемпионатлар хәрәкәте ярдәм итә. Татарстан җыелма командасы ел саен «Һөнәр осталары» һәм «Абилимпикс» һөнәри осталык чемпионатларында, катнашучыларның югары һөнәри әзерлеген күрсәтеп, алдынгы урыннар ала. 2024 елда илкүләм «Абилимпикс» – 2024 чемпионатының йомгаклау өлеше гомумкоманда зачетында республика 2 нче урынны алды, 72 медаль белән бүләкләнде.

«Һөнәр осталары» чемпионат циклы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы төрле дәрәҗәдәге 180 медальгә лаек булды.

Республика мәктәпләренең 9 нчы сыйныф укучыларының 58 проценттан артыграгы укуларын дәвам иттерү өчен көллиятләрне һәм техникумнарны сайлыйлар.

Югары белем бирү

2024/25 уку елында 46 югары белем бирү мәгариф оешмасы белем бирү эшчәнлеген башкара, шул исәптән 25 төп югары белем бирү мәгариф оешмасы (16 дәүләтнеке, 9 дәүләтнеке булмаган (шуларның 3 се дини), югары белем бирү мәгариф оешмасының 21 филиалы (13 дәүләтнеке, 8 дәүләтнеке булмаган). Югары белем бирү мәгариф оешмаларында барлыгы 149 094 студент белем ала.

2024/25 уку елы кабул итү кампаниясе йомгакларына караганда, югары белем бирү программалары буенча укырга 44 079 кеше керде, шуларның 69,2 проценты – көндезге укуга.

2024 елда укуны тәмамлап чыгучыларның гомуми саны – 29 626 кеше, шул исәптән көндезге уку буенча – 20 587 кеше, кичке уку буенча – 1 179 кеше, читтән торып уку буенча – 7 860 кеше.

Республикада 14 якын һәм 110 ерак чит илдән 22 166 чит ил студенты белем ала.

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре студентларына дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2010 елның 21 декабрендәге 835-ПУ номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләре көндезге уку бүлекләрендә укучы, шул исәптән укучыларның бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларының йомгаклау этабында җиңүчеләрдән һәм бүләк алучылардан булган студентлар өчен Татарстан Республикасы Рәисе стипендияләре билгеләнә, аларның исемлеге башкарма хакимиятнең мәгариф өлкәсендәге федераль органы тарафыннан раслана. Бу орган югары белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу

функцияләрен үти. Айлык стипендиянең күләме – 10 000 сум. 2024/25 уку елында 418 студент Татарстан Республикасы Рәисе стипендиаты булды.

**«Мәгариф» илкүләм проекты**

2024 елда Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проектының төбәк өлешләре кысаларында түбәндәге чаралар гамәлгә ашырылды:

«Һәр баланың уңышы» төбәк проекты:

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Новый поселогы урта гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «3 номерлы Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең спорт заллары капиталь төзекләндерелде;

«Заманча мәктәп» төбәк проекты:

7 898 урынга исәпләнгән 6 мәктәп төзелде һәм ачылды, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Көек авылындагы «Алгоритм» технологик лицее» МБМУнең 618 урынга исәпләнгән өстәмә корпусын төзү тәмамланды, җиһазлар, инвентарь сатып алынды;

республиканың кече шәһәрләрендә һәм авыл җирлекләрендә гомуми белем бирү оешмаларында 72 «Үсеш ноктасы» үзәге төзелде;

Казан шәһәре Мәскәү районының «64 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» ДБМУ, Казан шәһәре Совет районының «174 номерлы гимназия» ДБМУ базасында ике «Кванториум» балалар технопаркы ачылды;

сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Татарстан Республикасының 9 муниципаль районында (Татарстан Республикасының Азнакай (1); Алабуга (1), Кукмара (1), Лениногорск (1), Мамадыш (1), Минзәлә (1), Менделеевск (1), Түбән Кама (1) муниципаль районнары, Чаллы (3) 11 коррекция мәктәбенең матди-техник базасы яхшыртылды. Аларга хезмәт остаханәләренә, педагог-психолог, укытучы-дефектолог, укытучы-логопед кабинетларына җиһазлар, шулай ук сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен җайлаштырылган төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен җиһазлар китертелде.

3 укытучының һәр кайсысына «Земство укытучысы» программасы кысаларында 1,0 млн сум акча түләнде.

«Цифрлы нигездә белем бирү мохите» төбәк проекты:

38 мәктәп һәм 1 һөнәри белем бирү оешмасында мәгълүмат-коммуникация җиһазлары куелды;

«Чаллы политехника техникумы» ДАҺБУ базасында балаларга цифрлы нигездә белем бирү буенча «IT-куб» үзәге ачылды;

«Россия Федерациясе гражданнарында ватанпәрвәрлек тәрбияләү» төбәк проекты:

«Ватанпәрвәрлек тәрбиясе» федераль проекты кысаларында республиканың 978 мәктәбе базасында тәрбия һәм балаларның иҗтимагый оешмалары белән хезмәттәшлек буенча 489 директор киңәшчесе ставкалары кертелде.

1 117 мәктәптә Россия Федерациясе дәүләт символлары урнаштырылды.

Әлеге максатларга 2024 елда федераль бюджеттан 3,0 млрд сум бүлеп бирелде, 0,7 млрд сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан бергәләп финансланды.

«Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектының «Илебезнең пилотсыз авиация системаларына ихтыяҗны стимуллаштыру» федераль проекты кысаларында республиканың 18 мәктәбе базасында (Казан – 6; Зеленодольск – 5; Чаллы – 2; Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы – 2; Иннополис – 1; Бөгелмә – 1; Болгар – 1) махсуслаштырылган класслар (түгәрәкләр), ГАПОУ «Лаеш техник-икътисадый техникумы» ДАҺБУ базасында – гамәли әзерлек үзәге ачылды. Әлеге мәгариф оешмаларына пилотсыз авиация системалары белән эшләүдә төп күнекмәләрне үстерү өчен махсуслаштырылган җиһазлар китертелде.

**Мәгарифне цифрлы нигезгә күчерү**

«Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы нигезгә корылган мәгариф даирәсе» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2024 елда барлык мәгариф оешмаларына җиһазлар китертелде.

2024 елда һөнәри мәгариф оешмалары укытучыларына 171,21 млн сумга 4 286 берәмлек компьютер техникасы (4 262 ноутбук һәм 24 моноблок) тапшырылды.

Татарстанда «Минем мәктәп» федераль дәүләт мәгълүмат системасын һәм «Сферум» мәгълүмат-коммуникация платформасын гамәлгә кертү һәм үзләштерү эше дәвам иттерелде. 2024 ел йомгаклары буенча республикада алардан 291 509 укучы һәм 36 426 педагогик хезмәткәр актив файдаланды.

«Киләчәк коды» федераль проекты программалары кысаларында программалаштыруның заманча «телләрен» 2023/24 уку елында 9 999 укучы өйрәнде, шул исәптән 4 725 укучы – онлайн режимда, 5 274 укучы – офлайн режимда.

2024 елда 255 укучы «Яндекс.Лицей» мәгариф проекты кысаларында программалаштыруның заманча «телләрен» өйрәнү буенча ике еллык курсны тәмамлады. Проектны гамәлгә ашыру барышында 855 укучы тулы ике еллык уку курсын тәмамлады һәм программалар төзү буенча башлангыч дәрәҗәдәге белгеч яисә стажер буларак эш башлау өчен җитәрлек күнекмәләр алды.

Ел саен көз көне республика мәгариф оешмаларында «Интернет» челтәрендә киберкуркынычсызлык дәрәҗәсен арттыруга, ата-аналар белән педагоглар җәмәгатьчелегенең «Интернет» челтәрендә балалар иминлеге проблемаларына игътибарын җәлеп итүгә һәм мәктәп укучыларында цифрлы грамоталылыкны үстерүгә юнәлдерелгән «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә куркынычсызлык буенча бердәм дәрес уздырыла.

**Төп казанышлар**

Бердәм дәүләт имтиханы йомгаклары буенча 2024 елда йөз балл җыю очраклары – 366, шулардан 2 укучы өч предметтан 300 балл, 20 укучы ике предметтан 200 балл җыйды. Математика, рус теле һәм ирекле сайлап алынган фән буенча БДИ йомгаклары республикада Россиядәге уртача күрсәткечләрдән югарырак.

Республика илебезнең олимпиада хәрәкәтендә алдынгылыкны яулый килә.

2023/24 уку елында  244 укучы бөтенроссия мәктәп укчылары олимпиадасының йомгаклау этабында җиңүчеләр дип танылды, призлы урыннар яулап алды. Дипломнар саны ягыннан Татарстан Мәскәү шәһәреннән һәм  Мәскәү өлкәсеннән соң 3 нче урынны яулады.

Казанның гомуми белем бирү оешмалары укучылары абруйлы олимпиадаларда җиңеп чыктылар.

Кытайда узган Химия буенча 58нче халыкара Менделеев олимпиадасында Казан шәһәренең Вахитов районы «131 нче лицей» укучысы Александра Ромашова алтын медаль яулады.

IOI-2024 информатика буенча Мисырда узган   халыкара олимпиадада Казан шәһәре Мәскәү районының  «2 нче лицей-интернат» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе укучысы Гыймран Абдуллин алтын медаль алды.

«Кукмара шәһәренең А.М. Булатов исемендәге күппрофильле лицее» МБМУнең яшьүсмерләр командасы Идел буе федераль округы «КЭС-БАСКЕТ» мәктәп баскетбол лигасы чемпионаты финалында 1 урынны алды. Чемпионат 2024 елның 6 мартыннан 12 мартына кадәр Киров шәһәрендә узды.

Илкүләм «Абилимпикс» чемпионатында  һәм Һөнәри осталык буенча «Һөнәр осталары» бөтенроссия чемпионат хәрәкәтендә Татарстанның җыелма командасы 2 нче урынны алды.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов ярдәме белән 2024/2025 уку елында республикада «Физика-математика өлкәсендә алгарыш» сынау проектына башлангыч бирелде. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү учреждениесе белән берлектә физика-математика белеме бирүнең сыйфатын яхшырту, балаларның математика өлкәсендәге сәләтен үстерү һәм республиканың югары белем бирү оешмаларына математика һәм физика өлкәсендә яхшы әзерлек алган абитуриентлар килүне тәэмин итү өчен чаралар комплексы әзерләде. «Физика-математика өлкәсендә алгарыш» дип исемләнгән бу  сынау проектына 5 юнәлеш керә:

1. Республика мәктәпләрендә физика-математика сыйныфларын оештыру (7 – 9 сыйныфлар).
2. 5 – 7 сыйныф укучылары өчен математика һәм физика буенча түгәрәкләр оештыру.
3. Математика һәм физиканы популярлаштыру һәм өйрәнүгә юнәлтелгән чаралар циклын уздыру.
4. Күчмә чараларда катнашу өчен укучыларга ярдәм күрсәтү (аларга премияләр бирү).
5. Мәктәпләр һәм укытучылар өчен грантлар гамәлгә кую.

Проектта республиканың 1 500 дән артык укучысы һәм 120 укытучысы катнаша.

Мәктәпне тәмамлаучылар арасыннан аеруча талантлы һәм кызыксынган яшьләрне укытучы эшенә тарту өчен республикада психология-педагогика юнәлешендәге профильле класслар челтәре үсеш алды. Боларда  6,5 мең укучы белем ала.

Аеруча ихтыяҗ булган әзерлек юнәлешләре буенча, беренче чиратта, авыл районнарында, республикада булачак укытучылар әзерләү эшенә стипендия бирү

белән ярдәм итү проекты гамәлгә ашырыла. Бу проектта «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе һәм «Чаллы дәүләт педагогика университеты» дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең 683 студенты катнаша. Шуларның 70 проценты ике теллелек һәм күп теллелек мәгариф даирәсендә эшләү программалары буенча укый.

# СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ

2024 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасындабала туганда фаразланган гомер озынлыгы 74,48 ел тәшкил итте. Әлеге күрсәткеч буенча Татарстан Россия Федерациясе субъектлары арасында 17 нче урынны, ә Идел буе федераль округы субъектлары арасында 1 нче урынны били.

| Күрсәткеч | 2024 елга күрсәткеч | Татарстан Республикасы тоткан урын | |
|---|---|---|---|
| | | Россия Федерациясендә | Идел буе федераль округында |
| Туу (1 000 кешегә) | 8,8 | 23 | 1 |
| Төрле сәбәпләрдән үлү (1 000 кешегә) | 11,3 | 22[1] | 1[1] |
| Балалар үлеме (тере туган 1 000 балага) | 2,6 | 5[1] | 2[1] |

[1] Тоткан урыннар күрсәткечне арта бару тәртибендә бүлеп исәпләнде (беренче урын – иң түбән (иң яхшы) күрсәткеч, соңгысы – иң югары (иң начар)

2024 елда төрле сәбәпләр буенча халыкның үлеме күрсәткечләре динамикасы ( 2023 ел белән чагыштырып) түбәндәгечә:

кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлү очраклары халык санынннан 100 мең кешегә исәпләгәндә 498,0 дән 453,8 очракка кадәр кимегән (8,9%);

COVID-19 китереп чыгарган коронавирус инфекциясеннән үлү очраклары халык санынннан 100 мең кешегә исәпләгәндә 3,5 тән 2,3 очракка кимегән (34,3%);

алкоголь белән очраклы агуланудан үлү очраклары халык санынннан 100 мең кешегә исәплләгәндә 1,6 дан 1,4 очракка (12,5%) кимегән;

туберкулездан үлү очраклары халык санынннан 100 мең кешегә исәплләгәндә 1,4 очрактан 1,3 очракка (7,1%) кимегән.

Тышкы сәбәпләрдән үлүчеләр (45,8%), яман шештән үлүчеләр (1,7%), сулыш органнары авыруларыннан үлүчеләр (10,7%) саны арту күзәтелә.

Аналарның бала тапканда үлү очраклары теркәлмәгән.

2024 елда бөер күчереп утырту буенча 99, бавыр күчереп утырту буенча 56 операция ясалды, йөрәк күчереп утырту буенча 17 операция, гемопоэтик кәүсә күзәнәкләрне аутологик күчереп утырту буенча 12, балага бөер күчереп утырту буенча 1 операция ясалды.

Югары технологияле 8 медицина үзәгендә 22 854 пациентка рентген-эндоваскуляр тикшеренү, 12 334 ашыгыч диагностик коронарография, 3 394 ангиография ясалды.

2024 елда мәҗбүри медицина иминиятләштерүе кысаларында1 814 экстракорпораль орлыкландыру процедурасы уздырылды.

Җан башына исәпләнгән уртача керем ала торган гаиләләрдә тәрбияләнүче ясалма катнаш ризык белән тукландырыла торган бер яше тулмаган 35,5 мең бала һәм хроник авырулары булган бала бер җан исәбенә Татарстан Республикасы

территориясендә билгеләнгән яшәү минимумыннан артып китми торган күләмдә түләүсез махсус балалар ризыгы белән тәэмин ителде.

**«Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты**

2024 елда Сәламәтлек саклау» илкүләм проектын гамәлгә ашыруга 3 622,05 млн сум бүлеп бирелде, шуларның 2 367,66 млн сумы – федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 642,94 млн сум, Татарстан Республикасының өстәмә акчалары – 611,45 млн сум.

«Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының төбәк проектлары кысаларында түбәндәге чаралар уздырылды:

«Татарстан Республикасында башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты:

халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәте белән тәэмин итү (191 очыш ясалды, 186 пациент эвакуацияләнде);

Татарстан Республикасы гражданнары профилактик тикшерүләр белән тәэмин ителде. Диспансерлаштыру уздырганда 2 973,3 мең кеше тикшерелде;

мобиль комплекслар республиканың 37 муниципаль районына чыккан (180 торак пункт), 50,0 мең кеше тикшерелгән, шуларның диспансерлаштыруның II этабы барышында – 17,9 мең кеше;

«Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү» төбәк проекты:

266,1 млн сумга 28 берәмлек медицина җиһазы белән 3 төбәк кан тамыры үзәге җиһазландырылды («Төбәкара клиника-диагностика үзәге» ДАСУ, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАСУ, Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАСУ) һәм «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ базасында башлангыч кан тамыры үзәге;

йөрәк-кан тамырлары авырулары килеп чыгуны һәм диспансерда күзәтүдә торган, сәламәтлегенә аеруча зур куркыныч янаган авыруларда йөрәк-кан тамырлары авыруларының көчәеп китүен булдырмау өчен дарулар сатып алынды (30,1 мең пациент тәэмин ителгән).

«Онкология авыруларына каршы көрәшү» төбәк проекты:

97,4 млн сумга 17 берәмлек махсуслаштырылган җиһаз алынды, шул исәптән «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә үпкәгә ясалма рәвештә һава кудыру өчен 3 аппарат;

Казан шәһәренең «20 номерлы шәһәр поликлиникасы» ДАСУ, «Буа үзәк район хастаханәсе» ДАСУ, Казан шәһәренең «21 номерлы шәһәр поликлиникасы» ДАСУ, «Буа үзәк район хастаханәсе» ДАСУ, «Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» ДАСУ, «Буа үзәк район хастаханәсе» ДАСУ, «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАСУ, «Саба үзәк район хастаханәсе» ДАСУ, «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАСУ базасында, яман шешләрнең төп төрләре буенча комплекслы һәм тиз диагноз кую өчен онкология ярдәме күрсәтү буенча 9 амбулатория, шул исәптән 2024 елның 1 октябрендә «Арча үзәк район хастаханәсе» ДАСУ базасында амбулатория шартларында онкология

ярдәме күрсәтү үзәге ачылды;

«Балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча инфраструктурасын булдыруны да кертеп, балалар сәламәтлеген саклау өлкәсен үстерү» төбәк проекты:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАСУның онкология, гематология һәм хирургия балалар үзәгендә 3 423 пациент дәваланды;

репродуктив сәламәтлекне саклау максатында 15–17 яшьтәге 102 856 балага профилактик медицина тикшеренүе уздырылды (144,9 %), уролог-андролог балалар табиблары тарафыннан 53 077 ир бала, акушер-гинеколог табиблар тарафыннан 49 779 кыз бала тикшерелде;

17 яшькә кадәр 858 917 балага профилактик тикшерүләр уздырыла (планнан 107,4%);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» ФДБМУ симуляция үзәгендә перинатология, неонатология һәм педиатрия өлкәсендә 206 белгеч өйрәтелде (планнан 100%);

бала тудыру вакытында һәм аннан соң 31 418 хатын-кызга медицина ярдәме күрсәтелде (планнан 120,8%);

«Сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» төбәк проекты:

яшь белгечләр – табибларга хуҗалык шартларын җайга салу өчен бер тапкыр бирелә торган акча һәм беренче 3 елда өзлексез эшләгән чорында айлык өстәмә түләү рәвешендә социаль ярдәм чараларын финанслауны тәэмин итү. Республиканың сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә алынган 411 яшь белгечкә (табибка) дәүләт ярдәме күрсәтелә, шуларның 141 е бер тапкыр бирелә торган 21 534 сум күләмендә компенсация түләве һәм 2 510 сум күләмендә беренче тапкыр айлык өстәмә түләү алды.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алган табиб-белгечләргә, клиника-лабораториядә диагноз куючы табибларга дәүләт ярдәме чараларын финанслауны тәэмин итү. 100,0 млн сумга 125 грант бирелде;

медицина хезмәткәрләре арасында һөнәри осталык һәм профориентация конкурсларын уздыру.

Өстәмә рәвештә «Земство табибы» һәм «Земство фельдшеры» программалары гамәлгә ашырыла. Бер табибка бер тапкыр бирелә торган түләүнең күләме 1 дән 1,5 млн.га кадәр булды, фельдшерларга – 500,0 дән 750,0 мең сумга кадәр. 2024 елда 130 медицина хезмәткәренә компенсация түләве бирелде, шул исәптән 100 табибка һәм 30 урта медицина персоналына.

«Бердәм дәүләт мәгълүмати сәламәтлек саклау системасы (ЕГИСЗ) нигезендә сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм цифрлы контур булдыру» төбәк проекты:

«Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» ДАСУга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәламәтлек саклау өлкәсенең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә сәламәтлек саклау өлкәсенең бердәм цифрлы контурын булдыру» төбәк проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 елның 30 апрелендәге 369 номерлы карары нигезендә субсидия бирелде.

Бүлеп бирелгән акча кысаларында барлыгы 97,2 млн сумга 8 дәүләт контракты

төзелде. Аларда «Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклау өлкәсе» дәүләт мәгълүмат системасын яңартып кору һәм үстерү, сервер җиһазларын һәм мәгълүмат саклау чараларын китертү күздә тотыла;

«Медицина хезмәтләре экспортын үстерү» төбәк проекты:

Татарстан Республикасы территориясендә 166 илдән килгән 111 451 чит ил гражданына медицина ярдәме күрсәтелде.

Мәскәүдә узган V юбилей Медицина хезмәтләре экспорты илкүләм конгрессында Татарстан Республикасы «Медицина хезмәтләре экспортын үстерү» проектын гамәлгә ашырган 10 иң яхшы субъектларның берсе дип танылды, Идел буе федераль округында 1 нче урын алды.

Казан шәһәрендә БРИКС саммиты кысаларында 2024 елның 20 октябреннән 26 октябренә кадәр «ТАТАРСТАНДА ЭШЛӘНГӘН» күргәзмәсе узды, анда Татарстан Республикасының түбәндәге медицина оешмаларында эшләнгән иң яңа технологияләр тәкъдим ителде:

Чаллының «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАСУ, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» ДАСУ, Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАСУ;

«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасының башлангыч звеносын яңартып кору» төбәк проекты:

8 804 берәмлек медицина җиһазы, шул исәптән маммографлар, стационар рентген-аппаратлары, ультра тавыш аппаратлары, эндоскопия системалары һәм башкалар сатып алынды;

башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтә торган медицина оешмаларына, шулай ук авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда һәм кече шәһәрләрдә урнашкан оешмаларга пациентларны медицина оешмаларына, медицина хезмәткәрләрен пациентларның яшәү урынына кадәр илтү, тикшеренүләр өчен биологик материалларны алып килү, кайбер районнарда яшәүчеләргә дарулар китерү өчен 2 автомобиль сатып алынды;

23 сәламәтлек саклау объекты төзелде (20 фельдшер-акушерлык пункты, 3 амбулатория-поликлиника учреждениесе («Түбән Кама шәһәренең Перинаталь үзәге булган балалар район хастаханәсе» ДАССУнең 3 нче балалар поликлиникасы, Казан шәһәренең «Салават Күпере» торак комплексында «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ поликлиникасы филиалы, Казан шәһәренең Борисоглебск торак комплексындагы «7 нче балалар шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУнең гомуми практика табибы һәм участок педиатрлары үзәге);

105 медицина оешмасы бинасына һәм аларның аерымланган структур бүлекчәләренә, шул исәптән авыл җирлегендә, эшчеләр поселокларында, шәһәр тибындагы поселокларда һәм халык саны 50 мең кешегә җитмәгән кече шәһәрләрдә дә, капиталь төзекләндерү уздырылды (14 поликлиника, 9 табиблык амбулаториясе һәм 82 фельдшер-акушерлык пункты).

**Сәламәтлек саклау өлкәсендә республика программалары һәм проектлары**

«Сәламәтлекне яхшырту өчен оптималь медицина тернәкләндерүе» федераль проекты төбәк программасы.

2024 елда «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» ДАСУ, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАСУ, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» ДАСУ, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАСУ өчен 134,0 млн сумга 251 берәмлек реабилитация һәм физиотерапия җиһазы сатып алынды.

Татарстан Республикасы халкына башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтүне камилләштерүгә юнәлтелгән чаралар.

2024 елда 30 объектта 330,0 млн сумга эш башкарылды, шул исәптән 28 фельдшер-акушерлык пункты төзелде, 2 объектта капиталь ремонт ясалды («Сарман үзәк район хастаханәсе» ДАСУ поликлиникасы һәм «Апас үзәк район хастаханәсе» ДАСУ балалар поликлиникасы биналарында җиһаз, инвентарь алып капиталь ремонт ясалды, яндагы территорияләре төзекләндерелде).

«Стационарларны төзү һәм капиталь төзекләндерү» республика программасы кысаларында 2024 елда 3 277,5 млн сумга 31 объектта эшләр башкарылды, «Чаллы йогышлы авырулар хастаханәсе» ДАСУның төп курпусындагы «Д» блогы төзекләндерелде, Казанның «16 нчы шәһәр клиник хастаханәсе» ДАСУ, «Буа үзәк район хастаханәсе» ДАСУ стационары, «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАСУ йогышлы чирләр бүлекчәсе, «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ хирургия корпусында һәм башкаларда капиталь төзекләндерү эшләре тәмамланды.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә медицина ярдәме күрсәтүгә юнәлтелгән чаралар.

Республиканың медицина учреждениеләрендә махсус хәрби операциядә (алга таба – МХО) катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына медицина ярдәме күрсәтелә. 2022 елның декабреннән 2024 елның декабренә кадәр 17 495 махсус хәрби операциядә катнашучыга медицина ярдәме күрсәтелде.

«Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАСУ (300 койка), Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАСУ (100 койка), Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» ДАСУ (60 койка) базасында тәүлек әйләнәсендә медицина ярдәме күрсәтү мөмкинлеге тәэмин ителгән урыннар эшли.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына медицина ярдәме күрсәтү өчен төп җаваплылык Казан һәм Чаллы шәһәрләренең сугыш ветераннары госпитальләренә йөкләнә. 2024 елда аларда 2 364 махсус хәрби операциядә катнашучы дәваланып чыкты.

Чираттан тыш тәртиптә «медицина тернәкләндерүе» профиле буенча медицина ярдәме күрсәтү оештырылды, 2324 мобилизацияләнгән гражданга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтелде.

Республикада 70 медицина-психология консультация кабинеты эшли. 2024 елда әлеге кабинетларның медицина психологлары 823 махсус хәрби операциядә

катнашучыга һәм аларның 2 013 гаилә әгъзасына, шулай ук һәлак булганнарның гаилә әгъзаларына , шул исәптән 169 балага консультация бирелде.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В.М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» ДАСУ һәм республиканың үзәк район хастаханәләре табиб-психиатрлары тарафыннан 2024 ел эчендә 114 махсус хәрби операциядә катнашучыга һәм аларның 135 гаилә әгъзасына, шул исәптән 25 балага амбулотория шартларында, 49 махсус хәрби операциядә катнашучыга һәм аларның 43 гаилә әгъзасына, шул исәптән 6 балага стационар шартларында махсуслаштырылган психиатрия һәм психотерапия ярдәме күрсәтелде.

«Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга дәүләт ярдәме фондының Татарстан Республикасы филиалында мөрәҗәгать иткән махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның туганнары, һәлак булганнарның гаилә әгъзалары белән эш алып барыла. 2024 елда медицина психологлары тарафыннан 181 махсус хәрби операциядә катнашучыга һәм аларның 644 гаилә әгъзасына 825 консультация уздырылды, шулардан 584 кеше психология профиле белгечләренә юлланды.

**Медицина ярдәме күрсәтү сыйфатын яхшырту**

Медицина ярдәме сыйфатын яхшырту юнәлешләренең берсе – медицина оешмаларында ISO 9000, JCI халыкара сыйфат менеджменты стандартларын куллануга кертү. Бу системаны куллана башлаган медицина оешмалары республиканың барлык медицина оешмаларының гомуми саныннан 51,8 % тәшкил итте. Сертификат алган медицина оешмалары өлеше – 21,1 %

Республиканың 25 сәламәтлек саклау учреждениесе Европа сыйфат менеджментына туры килү ISO сертификатына, 10 оешма Россия Федерациясе Сәламәтлек өлкәсенә күзәтчелек оешмасының «Медицина эшчәнлегенең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы» иректе сертификатлаштыру системасы таләпләренә туры килү сертификатын, 1 учреждение пациентның һәм персоналның иминлеге системасы халыкара сертификатын (JCI) алды (Чаллының «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе»).

Хәзерге вакытта 59 медицина оешмасы медицина эшчәнлегенең сыйфаты менеджменты заманча принципларын куллана башлауларын конкурсларда катнашу аша расладылар. 2024 елда 13 дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе катнашты. 10 медицина оешмасы «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсы лауреаты, 3 оешма дипломантлары булдылар.

2024 елның 21 июнендә «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов катнашында 16 нчы «Ел табибы – Ак чәчәкләр – 2024» республика конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды.

Тантананың «Ел табибы» төп номинациясендә Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАСУ баш табибының медицина часте буенча урынбасары, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең эчке авырулар кафедрасы доценты, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан

тыш төп белгеч кардиологы, Татарстан Республикасының Атказанган табибы, Россия Федерациясенең сәламәтлек саклау өлкәсе отличнигы, медицина фәннәре кандидаты З.Ф. Ким җиңеп чыкты.

«Сәламәтлек саклау өлкәсе легендасы» дип Мальцевлар гаиләсе танылды: С.В. Мальцев, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесенең академик Г.Н. Сперанский исемендәге педиатрия кафедрасы профессоры һәм Л.И. Мальцева, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең 1 нче акушерлык һәм гинекология кафедрасы профессоры.

«Уникаль очрак» номинациясендә «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар клиник хастаханәсе» ДАСУ командасы һәм «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ җиңүче булды.

2024 елда «Иң яхшы башлангыч звено командасы» номинациясе кертелде. «Иң яхшы башлангыч звено командасы (шәһәр поликлиникасы)» номинациядә Казан шәһәренең «10 нчы шәһәр поликлиникасы», «Иң яхшы башлангыч звено командасы (балалар поликлиникасы)» номинациясендә «Чистай үзәк район хастаханәсе – ДАСУ балалар шәһәр поликлиникасы, «Иң яхшы башлангыч звено командасы (үзәк район хастаханәсе)» номинациясендә «Әтнә үзәк район хастаханәсе» ДАСУ җиңеп чыкты.

«Елның иң яхшы медицина хезмәткәре» номинациясендә «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ Зәй-Каратай фельдшерлык-акушерлык пункты мөдире – фельдшеры Б.Г. Хәйруллин җиңде.

Түбәндәге махсус дипломнар белән бүләкләнделәр: «Фидакарьлек һәм һөнәргә тугрылык өчен» – «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» ДАСУ, «Фидакарьлек һәм бурычка тугрылык өчен» – «Азнакай үзәк район хастаханәсе» ДАСУ Актүбә табиблык амбулаториясе табибы-хирургы Р.Х. Габдрахманов.

# ХЕЗМӘТ, МӘШГУЛЬЛЕК ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ

## Хезмәт һәм мәшгульлек

2024 елда Татарстан Республикасында 15 тән алып шуннан өлкәнрәк яшьтәге эшчеләр саны 2 076,6 мең кеше тәшкил итте, шулардан 2 038,8 мең кеше икътисад өлкәсендә эшләде һәм 37,7 мең кешенең (яки эшче көчләрнең гомуми санынннан 1,8 %) эше булмады, әмма алар актив төстә эш эзләде (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе нигезендә алар эшсез дип таныла).

2004 ел башыннан эшкә урнаштыру хезмәте органнарына 66,0 мең кеше төрле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иткән, шул исәптән 25,4 мең кеше эш эзләүчеләр сыйфатында исәпкә алынган. Шушы чор эчендә 30,2 мең кешегә эш бирелгән, шуларның 14,1 меңе – эшсез граждан.

2025 елның 1 гыйнварына халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә эшсезләр сыйфатында 3,2 мең кеше теркәлде (2024 елның 1 гыйнварына – 4,3 мең кеше). Теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе республика эшчеләр санының 0,16 процентын тәшкил итә (2024 елның 1 гыйнварына – 0,21%).

2025 ел башы белән чагыштырганда эшсезләр составында кайбер үзгәрешләр килеп чыкты:

Түбәндәгеләрнең өлеше артты:

- хатын-кызлар – 71,07% (2024 елның 1 гыйнварына – 68,44 %);
- югары һәм урта белемле гражданнар саны – 81,05% (2024 елның 1 гыйнварына – 78,27%);
- яңадан эшкә урнашырга теләүчеләр өлеше – 8,41% (2024 елның 1 гыйнварына – 8,15%);
- урта һөнәри белем бирә торган уку йортларын тәмамлаучылар – 0,31% (2024 елның 1 гыйнварына – 0,26%);
- азат ителгән гражданнар – 12,18% (2024 елның 1 гыйнварына –8,59%).

Түбәндәгеләр өлеше кимеде:

- авылда яшәүчеләр өлеше – 19,54% (2024 елның 1 гыйнварына – 29,32%);
- пенсия яшенә җитеп килгән гражданнар өлеше – 20,37% (2024 елның 1 гыйнварына – 24,69%);
- 16–29 яшькәчә яшьләр өлеше – 7,85% (2024 елның 1 гыйнварына – 8,48%);
- балигъ булмаган балалар тәрбияләүче әти-әниләр өлеше – 33,35% (2024 елның 1 гыйнварына – 35,07%);
- инвалидлар өлеше – 7,54% (2024 елның 1 гыйнварына – 7,92%);

үз теләге белән эштән киткән гражданнар өлеше – 69,24% (2024 елның 1 гыйнварына – 75,62%).

Республика буенча эшсезлек уртача 3,4 ай дәвам итте. Республика буенча эшсезлек чорының уртача күрсәткеченнән түбәнрәк күрсәткечләр түбәндәге категорияләрдә күзәтелде: «16-29 яшьлек яшьләр» – 2,6 ай һәм «авылда яшәүчеләр» – 3,3 ай. «Хатын-кызлар» категориясендә эшсезлек республика буенча уртача күрсәткеч чикләрендә – 3,4 ай, «монопрофильле шәһәрләрдә яшәүчеләр» категориясендә – 3,4 ай. Республикада «инвалидлар» категориясендә эшсезлек вакыты уртачадан югарырак – 4,0 ай.

Эш бирүчеләр мәгълүматына караганда, 2025 елның 1 гыйнварына республикада 46,4 мең вакансия исәпләнгән.

Слесарь (төрле белгечлектәге), автомобиль йөртүче, ябыштыручы, инженер (төрле белгечлектәге), җыючы (төрле белгечлектәге), табиб (төрле белгечлектәге) кебек һөнәрләргә ихтыяҗ зур.

Хезмәт базарында киеренкелек коэффициенты 2025 елның 1 гыйнварына вакансиягә 0,07 кеше тәшкил итте.

**Кадрлар белән эшләү**

Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча эш төркеме утырышлары кысаларында Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү чараларының үтәлүенә оператив мониторинг ясала, алар контрольдә тотыла, тиешле, шул исәптән халыкны эш белән тәэмин итү буенча чаралар күрелә.

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый тотрыклылыгын тәэмин итү буенча оператив штаб (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 29 мартындагы 125 номерлы боерыгы белән расланды) тарафыннан социаль-икътисадый тотрыклылыкны саклау һәм икътисадны үстерү, аларның ярдәм чараларында катнашуын тәэмин итү буенча предприятиеләр белән килештерелгән эш оештырылды.

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Т.А. Голикова рәислегендә Хезмәт базарын торгызу мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме йөкләмәсен үтәү кысаларында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә оборона-сәнәгать комплексы (алга таба – ОСК) предприятиеләрен эшче кадрлар белән тәэмин итү буенча системалы чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру эше оештырылды. Татарстан Республикасы ОСК оешмаларында кадрларга ихтыяҗны мониторинглауны атна саен алып бару оештырылды.

2022 елның сентябреннән «Россиядә эш урыннары» порталында предприятиеләрнең кадрларга ихтыяҗы турында мәгълүматны актуальләштерү өлешендә ОСК предприятиеләре белән эш алып барыла. Вакансияләрне биләүне оештыру өчен Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсе учреждениеләре ресурслары, һөнәри мәгариф оешмалары студентлары, шулай ук студентларның хезмәт отрядлары файдаланыла. Моннан тыш, сәнәгать предприятиеләренең вакансияләр ярминкәсенең төбәк һәм бөтенроссия этапларында катнашуы тәэмин ителә.

Нәтиҗәдә 2022 елның ноябреннән (Федераль хезмәт һәм мәшгульлек хезмәте тарафыннан хисап алып барыла башлаган вакыттан алып) 2024 елның 31 декабренә кадәр 257 ОПК предприятиесендә 61 103 вакансиягә хезмәткәрләр урнаштырылган (2024 елның 1 гыйнварына – 23 233), шул исәптән:

6 330 – эшкә урнаштыру хезмәте аша, хезмәт ярминкәләрен оештыруны да кертеп (2024 елның 1 гыйнварына – 3 332);

4 806 – югары белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү учреждение студентларын җәлеп итү хисабына (2024 елның 1 гыйнварына – 1815);

601 – Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте учреждениеләре контингентын җәлеп итү хисабына (2024 елның 1 гыйнварына – 218).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән ел саен республика икътисадының өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлеге раслана. Әлеге исемлек нигезендә Татарстан Республикасының 7 елга югары һәм урта һөнәри белемле кадрларны әзерләүгә дәүләт заказы һәм киләсе елга эшчеләргә һөнәри әзерлек һәм яңадан әзерлек бирү программалары эшләнә.

Республикада урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә дәүләт заказын формалаштыруга системалы караш икътисад тармаклары ихтыяҗына карап эшкә алуның контроль саннарын билгеләргә мөмкинлек бирә.

Республика предприятиеләренең фаразланган ихтыяҗларын исәпкә алып, ел саен халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, кадрларга заказ биргән предприятиеләр, шулай ук муниципаль берәмлекләр, һөнәри мәгариф оешмалары белән тыгыз бәйләнештә эшчеләргә һөнәри әзерлек һәм яңадан әзерлек бирү программалары буенча кадрлар әзерләү ихтыяҗы формалаштырыла. Шул ук вакытта әзерлекнең күләме һәм юнәлешләре мәгариф оешмалары тарафыннан аз вакыт эчендә заказчыларның (предприятиеләр, эш белән тәэмин итү үзәкләре һ.б.) актуаль ихтыяҗларын исәпкә алып төзәтелергә мөмкин.

2024/2025, 2025/2026, 2026/2027 уку елларына эшче профессияләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча дәүләт хезмәтләре күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024/2025, 2025/2026, 2026/2027 уку елларына Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларында эшче профессияләре, хезмәткәрләр вазыйфалары, Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программаларын гамәлгә ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм аларның күләмен раслау турында» 2023 елның 8 сентябрендәге 1102 номерлы карары нигезендә 31 һөнәр буенча 23 көллият һәм техникумда 1 568 кеше күләмендә расланды.

Студентларны һәм укучы яшьләрне вакытлы, сезонлы һәм даими эш урыннарына урнаштыруны тәэмин итү, аларга Татарстан Республикасының хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган һөнәр үзләштерү мөмкинлеге бирү, эш белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан ел саен студентларны әзерләү территорияләрен, һөнәрләр исемлеген һәм күләмнәрен билгели, шулай ук студентларны һөнәри белем алуга юллауны тәэмин итә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 мартындагы 436-р номерлы боерыгы).

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә студентларны эшче һөнәрләр буенча укыту өчен мәгариф оешмаларын сайлап алуны уздыралар һәм алар белән дәүләт контрактлары төзиләр.

2024 елда студент хезмәт отрядларында катнашкан 570 студент Казан, Әлмәт, Түбән Кама, Лениногорск, Бөгелмә, Чаллы шәһәрләрендә эшче һөнәрләргә укыды.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Демография» илкүләм проектының «Эш белән тәэмин итүгә булышлык» федераль проекты кысаларында «Гражданнарның аерым категорияләренә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларын гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 21 февралендәге 201 номерлы карары нигезендә 35 яшькә кадәр яшьләр арасыннан булган аерым категория гражданнар укытыла. 2024 елда 4 385 кеше укып чыкты, шул исәптән 35 яшькә кадәр яшьләрнең аерым категорияләреннән хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган мәгариф программалары буенча 16 яшь кеше укыды.

Укытуны әлеге программаларның федераль операторы булган оешмалар башкара: «Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия Халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе, «Томск илкүләм тикшеренү дәүләт университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе, «Һөнәри белем бирүне үстерү институты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе.

2025 елда федераль бюджет хисабыннан Татарстан Республикасында аерым категория гражданнарны, шул исәптән 35 яшькәчә яшьләрнең аерым категорияләрен «Кадрлар» илкүләм проектының «Эш белән тәэмин итүнең актив чаралары» федераль проекты кысаларында укытуны оештыру дәвам итә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елда аерым категориядәге гражданнарны эш белән тәэмин итүне стимуллаштыру максатларында юридик затларга, коммерциячел булмаган оешмаларны кертеп, шәхси эшкуарларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2021 елның 13 мартындагы 362 номерлы карары (алга таба – 362 номерлы карар) нигезендә 2024 елда Татарстан Республикасында 30 яшькәчә 1 974 яшь граждан эшкә урнаштырылды. Гражданнарның аерым категорияләрен эшкә алуга субсидияләр программасы кысаларында дәүләт ярдәме эш бирүчеләргә эш тәҗрибәсе булмаган яшь гражданнарны, шул исәптән көллиятләрне һәм югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны эшкә алуга яхшы этәргеч бирде.

Шулай ук 362 номерлы карар ОСК предприятиеләре хезмәткәрләренең күченеп килүен субсидияләү өлешендә гамәлгә ашырылды. Ярдәм Россия Федерациясенең башка субъектларыннан күченеп килгән хезмәткәрләргә дә, әгәр хезмәткәр күченеп килгән муниципаль берәмлек һәм эш бирүче урнашкан муниципаль берәмлек чиктәш булмаса, аларның чикләре бер-берсеннән 50 километрдан ким булмаган ераклыкта урнашкан булса, субъект чикләреннән җәлеп ителгән хезмәткәрләргә дә күрсәтелде.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «ОСК оешмаларының җыелма реестры турында» 2004 елның 20 февралендәге 96 номерлы карары нигезендә хезмәткәрләр җәлеп итүгә ихтыяҗы булган 63 ОСК предприятиесеннән торган исемлек төзелде. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы нигезендә бу предприятиеләр ихтыяҗ кичергән 120 һөнәр (вазыйфа, белгечлек) исемлеге төзелде.

2024 елда 6 эш бирүче («КАМАЗ» ГАҖ, «Л.Я.Карпов исемендәге химия заводы» АҖ, «Казан вертолет заводы» АҖ, «Элекон» заводы» АҖ,

«Электросоединитель» АЖ, «Федерал-Могул Чаллы» ҖЧЖ) 57 кешене эшкә урнаштырды.

Эш бирүчеләр һәм Татарстан Республикасы һөнәри мәгариф оешмалары арасындагы тыгыз бәйләнеш эш урынын алдан билгеләп белем бирү турында килешүләр төзү тәҗрибәсен ел саен киңәйтергә мөмкинлек бирә. 2024 елда мондый килешүләр 2 036 кеше белән төзелгән.

Моннан тыш, һөнәри мәгариф оешмаларының беренче курсына кергән 834 кеше мондый килешүне түбәндәге предприятиеләр белән төзеде: «КАМАЗ» ГАЖ (504 кеше), «Туполев» ГАЖ филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы (215 кеше) , «Казан вертолет заводы» АЖ (73 кеше), «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» АЖ (42 кеше).

Эш урынын алдан билгеләп белем бирү турында килешүләр төзү кысаларында ярдәм чаралары буларак эш бирүче-предприятиеләр тарафыннан студентларның укуы өчен түләнә, стипендия түләнә, практика узу вакытында хезмәт хакы бирелә, укуларын тәмамлаучылар эшкә урнаштырыла. Мәгариф һәм сәнәгатьне нәтиҗәле берләштерү өчен Татарстан Республикасында предприятиеләрдә югары уку йортларының база кафедралары эшләү кебек уңай тәҗрибә бар (122 мондый кафедра эшләп килә).

«Мәгариф һәм педагогика фәннәре» белгечлеге һәм юнәлешләре буенча югары белем бирү мәгариф программалары буенча укый торган һәм арадаш аттестацияне уңышлы узган студентлар, шулай ук өстәмә гомуми белем бирү программалары юнәлешләренә туры килгән белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча югары белем бирү программалары буенча укый торган һәм арадаш аттестацияне уңышлы узган студентлар кимендә ике ел укыганнан соң гомуми белем бирү оешмаларында эшләргә хокуклы. Республиканың мәктәпләрендә һәм балалар бакчаларында 630 дан артык студент эшли.

Республиканың әйдәүче предприятиеләре белән берлектә һөнәри белем бирү учреждениеләре базасында кадрлар әзерләү ресурс үзәкләре ачу эше алып барыла. Аларда хәзерге заман югары технологияле җитештерү ихтыяҗларына туры килерлек квалификацияле кадрлар әзерләү өчен укыту-методик, кадрлар һәм матди-техник ресурслар тупланачак.

«Яшь һөнәр ияләре» һәм «Цифрлы нигездә белем бирү» федераль проектлары кысаларында 64 остаханә заманча җиһазландырылды. Алдынгы һөнәри әзерлек буенча 2 үзәк һәм «ИТ-куб» балалар өчен цифрлы нигездә белем бирү буенча 4 үзәк ачылды.

«Һөнәри осталык» федераль проектында республиканың 16 һөнәри белем бирү оешмасы җиңүче дип табылды. 14 укыту-производство һәм мәгариф кластеры булдырылды.

**Хезмәт миграциясе өлкәсендәге чаралар**

Чит ил хезмәткәрләрен эшкә җәлеп итү һәм эшче көч буларак файдалану механизмы миграция сәясәтенең барлык төп нигезләмәләре кебек үк федераль дәрәҗәдә формалаштырыла. Республикада чит илдән эшче көчләр җәлеп итү һәм аларның хезмәтеннән файдалану «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон

һәм башка закон актлары нигезендә тормышка ашырыла. Татарстанда тышкы хезмәт миграциясенә кагылышлы өлештә тормышка ашырыла торган төп юнәлешләрнең нигезен федераль норматив хокукый актлар нигезендә җайга салына торган блок тәшкил итә. Башкарма хакимият органнары тарафыннан Россия Федерациясенә виза нигезендә килгән чит гражданнарын эшче көч буларак җәлеп итүгә ихтыяҗны билгеләү һәм чит ил гражданнары тарафыннан хезмәт эшчәнлеге алып баруга квота формалаштыру буенча эш Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан чит илдән эшче көчләр җәлеп итүгә ихтыяҗны билгеләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 23 гыйнварындагы 27н номерлы карары нигезендә алып барыла.

2024 елда виза нигезендә чит ил гражданнарын эшче көч буларак җәлеп итү максатларында Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясенең 7 утырышы уздырылды.

2024 елда хезмәт эшчәнлеге алып бару максатларында виза нигезендә Россия Федерациясенә килгән чит ил гражданнарына эшкә рөхсәт һәм Россия Федерациясенә чакырулар бирүгә Татарстан өчен квота 23 илдән виза нигезендә эшкә килүче 1 502 кеше тәшкил итте. Әлеге квота эш бирүчеләрдән 55 гаризаны да үз эченә ала. Иң күпсанлы эшче көчләр Төрекмәнстан, Төркия, Кытай, Һиндстаннан килде.

«Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар Россия Федерациясенә килгән чит ил гражданнарын виза алуны таләп итмичә, патент нигезендә эшкә җәлеп итә ала.

Татарстан Республикасында ел саен хезмәт базарының үзенчәлекләрен чагылдыручы коэффициентны раслау турында закон кабул ителә. 2024 елда төбәк коэффициенты 2,163 булды, Татарстан Республикасында патентның бәясе айга 6 229 сум тәшкил итте, 2025 елда тиешенчә 2,35 һәм 7 315 сум тәшкил итәчәк.

2024 елда Үзбәкстан Республикасына эш сәфәре йомгаклары буенча 18 оешма Үзбәкстан Республикасының тышкы хезмәт миграциясе агентлыгы белән һәм ике оешма Таҗикстан Республикасы Хезмәт, миграция һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгының Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү агентлыгы белән оештырылган төстә эшчеләр җыю турында килешү төзеде. Әлеге килешүләр кысаларында 2 157 Үзбәкстан Республикасы гражданы һәм 368 Таҗикстан Республикасы гражданы эш белән тәэмин ителде.

2025 елның 1 гыйнварына 1 324 чит ил гражданына эшкә рөхсәт бирелде (2024 елның 1 гыйнварына – 709).

31 895 чит ил гражданының эшкә патенты гамәлдә, шул исәптән юридик затларда һәм шәхси эшкуарларда эшләүгә – 19 670 кешедә, физик затларда – 12 225 кеше.

**Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның ирекле рәвештә Татарстан Республикасына яшәргә күчеп килүенә булышлык итү**

Чит илләрдә яшәүче ватандашларны җәлеп итү ярдәмендә Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм демографик үсешенә булышлык итү максатларында «2024 – 2026 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның ирекле рәвештә Татарстан Республикасына яшәргә күчеп килүенә булышлык итү» дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) гамәлдә.

2024 елда программаны финанслау күләме 300,0 мең сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджеттан – 180,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан – 120,0 мең сум.

Әлеге программада катнашучылар Дәүләт программасында катнашуга дәгъва кылучы ватандашлар кандидатуралары гаризаларын карап тикшерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан һөнәри һәм квалификация таләпләрен һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең балл системасы нигезендә сайлап алына. Мәгариф, сәламәтлек саклау, авыл хуҗалыгы, спорт, мәгълүмат-коммуникация технологияләре, машина төзелеше тармаклары эшкә урнашу өчен өстенлекле өлкәләр булып тора.

Сайлап алу йомгаклары буенча 2024 елда 153 ватандаш (шул исәптән 14 ватандаш дус булмаган илләрдән) һәм аларның 418 гаилә әгъзасы Комиссиянең уңай бәяләмәсен алды.

Әлеге гражданнар төп чыгышлары белән Таҗикстан (55 кеше), Казахстан (30 кеше), Төрекмәнстан (34 кеше) һәм башка илләрдән.

Дәүләт программасында катнашуга кандидатлар Казан, Чаллы, Зеленодольск, Чистай, Лаеш һәм башка шәһәрләргә күчеп килергә планлаштыра.

**Социаль ярдәм**

2017 елдан Татарстан Республикасы ярлылык дәрәҗәсе түбән булган төбәкләр сафында. Ул халыкның гомуми саныннан 4,6 процентны тәшкил итә (2023 ел), гомумроссия буенча күрсәткече – 8,5 процент (2023 ел). Татарстан Республикасы 4 урынны алып тора (1 урын – Ямал-Ненец автономияле округы (3,6 процент), 2 урын – Санкт-Петербург (4,4 процент), 3 урын – Мәскәү (4,5 процент).

2024 ел йомгаклары буенча ярлылык дәрәҗәсенең план күрсәткече 5,5 проценттан артмады. Күрсәткечне бәяләү Россия дәүләт статистика хезмәте тарафыннан Россия Федерациясе субъектлары белән чагыштырып, 2025 елның апрелендә башкарыла.

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү халыкның социаль яклanмаган катлавына дәүләт ярдәменең нәтиҗәле коралы булып тора. Социаль контракт авыр тормыш хәлендә калган гражданга авырлыкларны җиңеп чыгарга булышуга юнәлтелгән, ягъни аңа эшкә урнашырга, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга, шәхси эшкуарлык эшчәнлеге оештыруга, үзмәшгульлек белән шөгыльләнүдә һәм башка шундый эшләрдә ярдәм күрсәтү максатында төзелә. 2024 елда 5,9 мең социаль контракт төзелде, шуларның 90 проценты гражданнарны эш белән тәэмин итүгә юнәлтелгән.

Республикада социаль контрактларның нәтиҗәлелеге югары күрсәткечкә ия.

2024 ел йомгаклары буенча социаль контрактның гамәле тәмамланганчы җан башына уртача керемен арттырган гражданның өлеше 85,1 процент тәшкил итте. Россия Федерациясе буенча бу күрсәткеч – 76,9 процент.

2024 ел йомгаклары буенча социаль контрактның гамәле тәмамланганчы җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан артып киткән гражданның өлеше 63,0 процент тәшкил итте. Россия Федерациясе буенча бу күрсәткеч – 46,2 процент.

Инвалид бала тәрбияләүче гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү

18 яшькәчә биш яисә аннан да күбрәк бала тәрбияләүче, әтисе яки әнисенең берсе яисә әтисе дә, әнисе дә инвалидлар һәм (яисә) балаларның берсе инвалид булган һәм мөлкәти тәэмин ителеше «Татарстан Республикасы халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта нигезендә билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәти тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбән булган гаиләләргә Татарстан Республикасында җан башына туры килә торган яшәү минимумы күләме (2024 елда – 13 135 сум) белән гаиләнең җан башына туры килә торган кереме арасында аермага тиңдәш күләмдә айлык пособие түләнә.

Шундый ук күләмдә өстәмә айлык акчалата түләү даими рәвештә кеше тәрбиясенә (ярдәменә, карауга) мохтаҗ инвалид балаларга түләнә.

Билгеләнгән тәртиптә наем шартнамәләре буенча социаль файдаланудагы торак фонды торак йортларында торак алуга мохтаҗ дип танылган инвалидларга, шулай ук авыр формадагы хроник авырулары булган инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләргә торак сатып алуга торак субсидиясе бирелә.

Фенилкетонурия авырулы балаларның сәламәтлеген һәм тормышын саклауга ярдәм күрсәтү максатында 2025 елның 1 гыйнварыннан инвалид балаларга (фенилкетонурия авырулы) айлык акчалата түләү рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чарасы билгеләнде. Акчалата түләү күләме балалар өчен яшәү минимумының 50 процентын тәшкил итә (2025 елда – 14 621 сум). Айлык акчалата түләү инвалид бала белән бергә яши торган әти-әнинең (законлы вәкилнең) берсенә билгеләнә.

Пенсионерларга һәм пенсия алды яшендәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү

Айлык уртача кереме 20,0 мең сумнан артмаган, мөлкәти тәэмин ителеше «Татарстан Республикасы халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта нигезендә билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәти тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбән булган, башка нигезләр буенча социаль ярдәм чаралары алуга хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшькә җиткән (тиешенчә ирләр һәм хатын-кызлар) гражданнарга транспортта йөрү өчен айлык акчалата түләү бирелә (2024 елда – 605 сум). 2024 елда әлеге түләүне 128 450 кеше алды.

Айлык уртача кереме Татарстан Республикасында пенсионерлар өчен яшәү минимумы күләменең 400 процентыннан артмаган һәм санаторий-курорт дәвалануы кирәклеге турында медицина күрсәтмәсе булган пенсионерларның сәламәтлеген ныгыту өлешендә социаль ярдәм чараларын камилләштерү максатында аларга ташламалы шартларда юллама алу хокукы бирелә (керемнә карата юлламаның

5 процентыннан алып 25 проценты күләмендә). 2024 елда 3 271 пенсионерга юллама бирелде.

Татарстан Республикасында торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплексы чаралары каралган.

Төп урынны торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен (алга таба – ТКХ) түләүгә субсидия-ташламалар алып тора, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә аерым категория гражданнарга бирелә.

2024 елда ТКХ өчен түләүгә субсидия-ташламалар 682 670 гражданга бирелде, түләнгән акчаларның гомуми суммасы 5 077 448,6 мең сум, уртача 620 сум тәшкил итә.

Моннан тыш, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә берничә адреслы социаль ярдәм чарасы да каралган.

Россия Федерациясе Торак кодексының 159 статьясы нигезендә гражданга ТКХ өчен түләүгә субсидияләр, аның тулаем гаилә кереме гражданнар тарафыннан ТКХ өчен түләүгә тотылырга мөмкин булган чыгымнарның максималь күләменнән (Татарстан Республикасында – 21 процент) артып киткән очракта, бирелә. Шулай ук республикада өстәмә рәвештә 6 төрле субсидия кертелде.

ТКХ өчен түләүгә субсидияләр алучылар саны 2024 елда 59 685 кеше тәшкил итте. Барлыгы 861 987,9 мең сум субсидия түләнде. Уртача 1 203,52 сум.

Әлеге социаль ярдәм чаралары күрсәтү җылылык бирелә торган чорда субсидия алучылар арасыннан ТКХ өчен үз акчаларын түләүче гражданнар өлешен 12 процент дәрәҗәсендә, җылылык бирелми торган чорда 7 процент дәрәҗәсендә саклап калу мөмкинлеге бирә. Шул ук вакытта тулаем гаилә керемен алганда, гражданнарның ТКХ өчен түләүләргә тотарга рөхсәт ителгән үз чыгымнарының максималь күләме 22 процент, ә Татарстан Республикасында – 21 процент тәшкил итә.

70 яшькә җиткән һәм аннан да олырак булган, ялгыз яшәүче, эшләми торган торак милекчеләренә, шулай ук 70 яшькә җиткән һәм аннан да олырак булган, гаиләләре белән бергә яшәүче, гаилә әгъзаларының берсе дә эшләми торган торак милекчеләренә, 60 һәм 55 яшьтә булган (тиешенчә ирләр һәм хатын-кызлар) һәм (яисә) I һәм II төркем эшләми торган инвалидларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен капиталь төзекләндерүгә бер айга түләүнең минималь күләменнән һәм торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр исәпләү өчен файдаланыла торган торакның норматив мәйданы төбәк стандарты чикләрендә аның милкендә булган торакның мәйданы күләменнән чыгып, күпфатирлы йортта уртак милеккә капиталь ремонт өчен түләүгә чыгымнарны каплауга компенсация (70 яшь һәм аннан өлкәнрәкләр өчен капиталь ремонт өчен түләүгә чыгымнарны каплауга компенсация – 50 процент, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәкләргә – 100 процент күләмендә) бирелә. Компенсация алучыларның саны 52,8 мең граждан тәшкил китте.

Барлык пенсионерлар һәм пенсия алды яшендәгеләр транспортта йөрү өчен социаль билет алуга хокуклы.

**Гаилә елы йомгаклары**

Гаиләне һәм гаиләгә хас рухи-әхлакый хәзинәләрне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен популярлаштыру максатында Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә Гаилә елын уздыру турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 875 номерлы Указы нигезендә 2024 ел Россия Федерациясендә Гаилә елы дип игълан ителде.

Балалы гаиләләргә федераль һәм төбәк дәрәҗәсендә социаль ярдәм чараларының тулы пакеты күрсәтелә.

Шулай итеп, кереме яшәү минимумыннан түбән булган аз keремле балалы гаиләләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә ярдәм чаралары күрсәтелә (2024 елда – 13 135 сум, 2025 елда – 15 073 сум), шул исәптән:

- күп балалы кереме аз булган гаиләләргә балалар бакчасы өчен түләүне 100 процентка компенсацияләү (2024 елда 3,9 мең балага);
- аз керемле гаиләләрдәге 3 яшенә кадәрле балаларга елына 10 мең сум күләмендә дарулар сатып алуга түләү (2024 елда – 6,2 мең балага);
- инвалид бала тәрбияләүче һәм (яисә) әтисе-әнисе инвалид булган, 5 яисә аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие, ул республикада җан башына туры килә торган яшәү минимумы белән гаиләнең җан башына туры килә торган уртача кереме арасында аермага тиңдәш күләмдә түләнә (2024 елда – 181 кешегә);
- яңа туган сабыйлары булган аз керемле гаиләләргә бала кирәк-яраклары белән бүләк комплектлар (2024 елда – 2,3 мең балага).

Авылларда яшәүче хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү – республиканың тиңдәше булмаган демографияне арттыру чарасы булып тора. Шулай итеп, 25 яшькәчә хатын-кызларга беренче баласын тапкан өчен – 50 мең сум, 29 яшькәчә хатын-кызларга өченче һәм аннан да күбрәк бала тапкан өчен 100 мең сум күләмендә акчалата түләү бирелә. 2018 елдан 14,1 мең кеше әлеге акчалата түләү алды, шул исәптән 2024 елда – 1,6 мең хатын-кыз.

Ярлы тормышта яшәүче гаиләләргә ярдәм күрсәтү буенча эшнең әһәмияте гаять зур. 2024 елда төзелгән социаль контрактларның 39 проценты (2,3 мең контракт яисә 8,2 мең кеше) балигъ булмаган балалары булган гаиләләргә бирелде (барлыгы 5,9 мең социаль контракт төзелде). Күп балалары гаиләләргә ярдәм итү дәүләт алдында торган өстенлекле бурычларның берсе.

2024 елда олы баласы 18 яшькә яисә ул көндезге уку формасында мәгариф оешмасында укыган очракта, 23 яшькә җиткәнче өч яисә аннан күбрәк балалы гаиләләргә даими нигездә күп балалы гаилә статусы (Россия Федерациясе Президентының «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы) билгеләнде һәм республикада күп балалы гаиләләргә, кеременә карамастан, социаль ярдәм чаралары күрсәтелә башлады.

Республикада 57,9 мең күп балалы гаилә бар, шул исәптән аларның саны соңгы 12 елда 2,4 тапкырга артты: 24,4 мең гаиләдән 57,9 мең гаиләгә җитте, аларда 185,0 мең бала тәрбияләнә.

2000 елдан 5 һәм аннан күбрәк бала табып, аларга лаеклы тәрбия бирүче (тәрбия биргән) хатын-кызларны югары дәрәҗәдә бәяләү билгесе буларак, дәүләт

бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале гамәлгә куелды. 2024 елдан медаль белән бүләкләнгән биш бала тәрбияләп үстергән аналарга 100 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелә, ә алты яисә аннан күбрәк бала тәрбияләп үстергән аналарга – бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләме алтынчы балага һәм аннан соң килә торган һәр балага хисаплап, бүләкләү көненә аларның өч яше тулган булу шарты үтәлгәндә, тиешенчә 20 мең сумга арта. 2000 елдан «Ана даны – Материнская слава» медале белән 1,6 мең ана (2024 елда 62 хатын-кыз) бүләкләнде.

Гаиләнең һәм ата-ана хезмәтенең абруен күтәрү максатларында 2022 елда дәүләт бүләге – «Ата-ана фидакарьлеге» медале гамәлгә куелды, ул җиде һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче яисә тәрбияләгән гаиләләргә биреләчәк. Гаиләдә бердән күбрәк балигълык яшенә җитмәгән балалар булган очракта, аларга 200 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк бирелә. 2022 елдан әлеге медаль белән 14 гаилә (26 кеше), шул исәптән 2024 елда 2 гаилә (3 кеше) бүләкләнде.

Моннан тыш, күп балалы гаиләләргә төрле яклы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:

- торак мәйданының социаль нормативлары һәм хезмәтләрдән файдалануга билгеләнгән нормативлар чикләрендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнарның 30 проценты күләмендә субсидия (әлеге түләүләрне алучылар (ата-аналар һәм балалар) – 234,8 мең кеше);
- 6 яшькә кадәрле балаларга дарулар сатып алуга субсидия. 2024 елда түләү айга 164 сум тәшкил итте (әлеге түләүне алучылар – 53,4 мең бала) (2025 елда – 171 сум);
- гомуми белем бирү оешмаларында укуларын тәмамлаганчы, ләкин 23 яшькә кадәр, укучыларга транспортта йөрүгә субсидия. 2024 елда түләү аена 369 сум тәшкил итте (түләүне алучылар саны – 69,8 мең кеше) (2025 елда – 384 сум).

Татарстан Республикасы Президентының «Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туу белән бәйле рәвештә балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2008 елның 20 августындагы ПУ-397 номерлы Указы нигезендә берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк балалар туганда гаиләләргә түбәндәге түләүләр билгеләнде:

- 10 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие (1 гаилә алды);
- берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк яшь ярым тулмаган балалар тәрбияләүче гаиләләргә айлык пособие. Аның күләме аена 1 000 сум тәшкил итә (алучылар саны – 18 бала).

2024 ел йомгаклары буенча гаиләләргә һәм балаларга күрсәтелә торган ярдәм чаралары нигезендә Татарстанда:

- гомуми халык санын алганда 1 000 кешегә туры килә торган яңа туган сабыйлар күрсәткече – 8,8, республика Идел буе федераль округында беренче урынны алып тора (7,7) һәм Россия Федерациясе белән чагыштырганда югарырак күрсәткечне саклый килә (8,4);
- барлык яңа туган сабыйларның гомуми санында беренче бала табучылар 39 процентны тәшкил итә;

- өченче һәм аннан күбрәк бала табучылар саны 2023 ел белән чагыштырганда 27 проценттан 2024 ел йомгаклары буенча 28 процентка артты.

Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан балалы гаиләләргә төрле яклы ярдәм күрсәтелә.

Бүгенге көндә республика территориясендә түбәндәгеләр эшли:

45 халыкка комплекслы ярдәм күрсәтү үзәге, аларда төрле яклы ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән гаиләләргә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәләре бар;

авыр тормыш хәлендә калган гаиләләрдә тәрбияләнә торган балалар өчен 14 социаль приют;

инвалид балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтелә торган сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен 18 тернәкләндерү үзәге.

2024 елда гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекчәләре булган халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләрендә 7,1 мең гаиләгә ярдәм күрсәтелде. Социаль приютларда 11,1 мең инвалид балага һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балага хезмәт күрсәтелде.

«Инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләргә ярдәм итү» төбәк чаралар комплексы кысаларында «Минем гаиләм» программасы буенча халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре базасында 2025 елда өйдә шөгыльләнү өчен 6 микрореабилитация үзәге, 11 тернәкләндерү җиһазларын прокатка алу пункты, 14 социаль-көнкүреш адаптация кабинеты булдырылачак.

Гаилә елы кысаларында «Гаилә кунак бүлмәсе» иҗтимагый проекты эшли башлады, ул стационар оешмаларда яши торган балаларның үз әти-әниләре (законлы вәкилләре) белән мөнәсәбәтләрен торгызуга һәм тәртипкә салуга, баланы гаиләгә кайтаруга юнәлтелгән. 16 стационар учреждение базасында балаларга әти-әниләре, башка туганнары, уллыкка (кызлыкка) алырга теләүчеләр, опекуннары (попечительләре) белән очрашулар уздыру өчен «Гаилә кунак бүлмәсе» дип аталган махсуслаштырылган бүлмәләр җиһазландырылды, ата-аналар һәм башка гаилә әгъзалары белән эшләүнең төрле формаларын үз эченә алган гаилә программалары тормышка ашырылды. Проектны эшләүгә спонсорлар һәм хәйриячеләр акчалары җәлеп ителде. Җәлеп ителгән спонсор ярдәме 2024 елда 1,2 млн сум тәшкил итте.

Гаилә тормышы формасындагы стационар оешмалардан гаиләләргә кайткан балалар санының артуы проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып тора.

Шулай ук Гаилә елы кысаларында һәр айның соңгы сишәмбесендә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү учреждениеләрендә һәм инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белгечләре катнашында «Ачык гаилә/ата-аналар көне» уздырылды, анда 2,7 меңнән артык кеше катнашты. Әлеге очрашулар вакытында анда катнашучыларга социаль интеграция, белем алу, спорт һәм мәдәният учреждениеләренә бару мәсьәләләре буенча консультацияләр бирелә, ата-аналар һәм инвалид балалар өчен мастер-класслар, спорт чаралары уздырыла.

Казан һәм Әлмәт шәһәрләренең халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре базасында ярдәмгә мохтаҗ балалы гаиләләргә комплекслы төстә социаль хезмәт күрсәтүне һәм социаль ярдәм чараларын күрсәтүне тәэмин итү максатларында Күпфункцияле гаилә үзәкләре төзеләчәк.

Татарстан Республикасында Гаилә елында төрле форматтагы 1 000 нән артык чара уздырылды.

Россия Федерациясендә Гаилә елын башлап җибәрүгә багышлап Мәскәү шәһәре «Россия» форумы халыкара күргәзмәсе мәйданында уздырылган «Кадерлеләрем – Яратканнарым» бөтенроссия гаилә форумында Татарстан Республикасын лаеклы төстә «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятеннән Гайфуллиннар-Сафиннар хезмәт династиясе тәкъдим итте, аларның предприятиедәге гомуми эш стажы 279 ел тәшкил итә. Форум кысаларында «Безнең йөрәкләр ялкыны» дигән тантаналы чара уздырылды. Гаилә учагын кабызу тантанасы чара программасының төп өлеше булды, анда тантанада катнашкан гаиләләргә үз төбәкләрендә Гаилә елын башлап җибәрү өчен символик «утлы» касә тапшырдылар. Яшь парлар – Зыятдиновлар әлеге гаилә учагын Татарстан Республикасына алып кайтты, аннары әлеге ут тантаналы рәвештә Идел буе федераль округы төбәкләренә таратылды.

2024 елның маеннан сентябренә кадәр вакыт аралыгында «Гаилә белән ял көннәре» һәм 2024 елның октябреннән ноябренә кадәр вакыт аралыгында «Гаилә көзе» иң киң колачлы чаралары дип танылды, аларда 50 меңнән артык балалы гаилә катнашты. Әлеге чаралар кысаларында гаилә спорт эстафеталары, М.Горький исемендәге паркта гаилә пикниклары, Казансу елгасы яр буенда «Гаилә ал җилкәннәре» бәйрәме, гаилә хезмәт династияләрен котлау тантаналары, җәяүле экскурсияләр, гаиләләр белән музейларга бару һәм башка чаралар уздырылды.

Гаилә елында яшь буынга тәрбия бирүдә аталарның абруен арттыруга аерым игътибар бирелде. Әтиләр, үз чиратында, үз балаларында аларга киләчәктә илебезнең лаеклы гражданы булырга этәргеч бирәчәк сыйфатлар тәрбияли ала. Татарстан Республикасының «Әтиләр берлеге» республика иҗтимагый оешмасы тарафыннан «Әти+Мин» конкурсы (ул 3 мең кешене берләштерә) оештырылды, аның финалы Түбән Кама шәһәрендә узды һәм анда республиканың барлык муниципаль берәмлекләреннән 150 кеше катнашты.

2024 елның 22 маенда республикада «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» IV республика шәҗәрәләр фестивале узды, анда 4 айдан алып 90 яшькә кадәрле 2 меңнән гаилә вәкиле катнашында 157 гаилә династиясе ярышты.

Муниципаль районнарда һәм шәһәрләрдә балалы гаиләләр өчен уздырыла торган Гаилә елына багышланган барлык чаралар муниципалитетларның интернет-сәхифәләрендә, учреждениеләрнең социаль челтәрләрендә, шулай ук республика (https://family-tatarstan.ru) һәм федераль (https://семья2024.рф) сайтларында урнаштырылып килә.

Гаилә елы чараларын гамәлгә ашыруда республика предприятиеләре һәм оешмалары актив катнашты.

Республика оешмаларында балалы гаиләләргә ярдәм итүнең корпоратив практикалары кертелде, шулардан:

- беренче сыйныфка укырга кергән һәм мәктәптә укучы балалары булган күп

балалы гаиләләргә акча сертификатлары бирү;

- предприятие хезмәткәрләренә гаилә кору, бала туу уңаеннан, шулай ук күп балалы гаиләләргә акча бүлеп бирү.

2024 елның 8 июлендә Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнендә «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медале белән 25 елдан артык бер-берсен яратып, тату яшәгән һәм балалар тәрбияләгән 70 гаилә бүләкләнде.

Татарстан Республикасы Көне алдыннан Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Рәисе һәм аның тормыш иптәше гадәттәгечә республиканың 45 гаиләсен тантаналы рәвештә котлады.

Татарстан Республикасы Көнендә «Казан» гаилә үзәгендә бер үк вакытта 45 парның гаиләсе теркәлде.

Республиканың гражданлык хәле актларын теркәү идарәләре 2 207 гаиләне котлады, шулардан 46 пар – «көмеш» юбилярлар (25 ел бергә яшәүче), 1 854 пар – «алтын» юбилярлар (50 ел), 292 пар – «бриллиант» юбилярлар (60 ел), 15 пар – «бәхетле» юбилярлар (70 ел), 16 507 гаилә теркәү тантаналары уздырылды.

Гаиләгә хас рухи-әхлакый хәзинәләрне һәм күп балалар табуны популярлаштыру максатларында республиканың барлык граждан хәле актларын теркәү органнарында «Яшь гаилә мәктәбе» проекты кысаларында гаилә коруга гариза биргән парлар белән очрашулар уздырылды. Булачак яшь парлар белән очрашуларда психологлар, дин әһелләре, табиблар катнашты; дискуссияләр, мастер-класслар, тренинглар уздырылды.

Мәктәпләр һәм урта белем бирү оешмалары өлкән сыйныф укучылары белән даими нигездә эш алып бара, аларны гаилә тормышына әзерләү, гаилә җанлы шәхесләр формалаштыру, гаиләгә хас традицион рухи-әхлакый хәзинәләргә хөрмәт тәрбияләүгә юнәлтелгән дәресләр уздырыла.

Татарстанда Гаилә елы 2024 елның 2 декабрендә «ТНВ-Татарстан» һәм «ТНВ-Планета» телеканалларында «Яңа ел белән, гаилә!» дип аталган 12 сәгатьлек телемарафон белән ябылды. Эфирда Татарстанның ватанпәрвәрлек үрнәге булган, җыр-моңга гашыйк, спорт белән шөгыльләнүче 50 актив гаилә катнашты. Телемарафонның азагында туры эфирда берьюлы берничә гаиләнең никахын теркәү тантанасы уздырылды.

2025 елда гаиләгә хас традицион рухи-әхлакый хәзинәләрне, күп балалар табуны, яшьләрдә ата-ана булуга җаваплы караш тәрбияләү, гаилә стажы зур булган парларны таныту эше дәвам иттереләчәк.

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү**

2024 елда махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү буенча системалы эш дәвам иттерелде, сәнәгать предприятиеләренең, бизнес-җәмгыятьләренең, волонтерлар хәрәкәтләренең һәм җирле үзидарә органнары арасында хезмәттәшлекнең төгәл схемасы төзелде.

Татарстан Республикасында төзелгән «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү максатыннан 360,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү каралган (Татарстан Республикасы Рәисенең

2024 елның 8 маендагы 325 номерлы Указы).

2023–2024 елларда Россия Федерациясе Кораллы Көчләре белән хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән аеруча категория хәрби хезмәткәрләргә 305 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелде. Моннан тыш, 2024 ел дәвамында хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүнең республика тарафыннан түләнә торган өлеше 205 мең сумнан 1 300 мең сумга кадәр җитте. 2025 елның башында әлеге түләү тагын 800 мең сумга артты. Нәтиҗәдә, Татарстан Республикасы территориясендә контракт төзегәндә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү 2 800 мең сумга җитте, ул республика, федераль һәм муниципаль дәрәҗәдә түләүләрдән тора.

Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итүнең түбәндәге чаралары гамәлгә ашырыла:

махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) гражданнарның 18 яшькәчә һәр баласына 20 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү;

махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына 2,0 млн сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү;

яңа туган балалары булган гаиләләрне, җан башына туры килә торган уртача керемне исәпкә алмыйча, бала кирәк-яраклары өчен бүләк комплектлары белән тәэмин итү;

гаилә әгъзалары булып торучы пенсионерларга һәм 60 һәм 55 яше тулган гражданнарга (тиешенчә ир-атларга һәм хатын-кызларга) санаторий-курорт дәвалануы өчен беренче чиратта юлламалар бирү;

олы яшьтәге гражданнарга, I һәм II төркем инвалидларга өйдә бушлай социаль хезмәтләр күрсәтү;

олылар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда, психик тайпылышлары булган гражданнар өчен интернат-йортларда, мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүгә өстенлекле хокук бирелү;

гаилә әгъзалары булып торучы инвалид балаларга мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүгә өстенлекле хокук бирелү;

тиешле эш табу максатында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләрендә теркәлеп, гариза калдырган гаилә әгъзасын, аңа туры килә торган эш табу мөмкин булмаган очракта, эшсез дип тану вакытын киметү (тиешле эш эзләүдә булышуны сорап дәүләт хезмәт күрсәтү турында гариза бирелгән көннән соң 3 көннән дә артык булмаган вакытта);

Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча көндезге уку бүлекләрендә укучы студентларга бер тапкыр кайнар ризык белән бушлай туклану мөмкинлеге бирелү;

Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының 1–11 сыйныф укучыларына көненә ике тапкыр бушлай кайнар ризык белән (иртәнге һәм көндезге аш) туклану мөмкинлеге бирелү;

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче 7 яшьтән алып

17 яшькә кадәрле балалары булган гаиләләргә ялга юлламалар алуга беренчел хокук бирелү;

18 яшькә кадәрле балаларга һәм әтисенә йә әнисенә (законлы вәкилгә) Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләрендә уздырыла торган чараларга бушлай керү хокукы бирелү;

билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре тарафыннан аларның шәхси эш ачуга бизнес-планнарын беренчел чиратта карап тикшерү;

өч һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләргә, әгәр әтисе йә әнисе хәрби хезмәткәр булган очракта, гражданнарның Татарстан Республикасында 5 ел дәвамында даими яшәргә тиешлеге таләбен исәпкә алмыйча, җир кишәрлекләре бирү;

гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан бер йорт исәбеннән йортка газ уздыру һәм өй эченә куела торган газ җиһазлары сатып алу белән бәйле чыгымнарны каплауга тотылган чыгымнар исәбеннән, ләкин 100 мең сумнан да артык булмаган күләмдә субсидия бирү;

Россия Федерациясе Президентының «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондын төзү турында» 2023 елның 3 апрелендәге 232 номерлы Указының 2 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән затларның һөнәри белем алуын һәм өстәмә һөнәри белем алуын оештыру;

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган гражданнар 2021 ел салым чорына транспорт салымыннан азат ителә;

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу шарты белән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган, ирекле формированиеләрендә хезмәт итү турында (Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ирекле рәвештә ярдәм итү турында) контракт төзегән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына бушлай юридик ярдәм күрсәтү каралган.

2023 елның ноябрендә Татарстанда «Үзебезнекеләр турында кайгырту» программы эшли башлады, анда гражданнар махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү чаралары турында мәгълүмат белән таныша ала. Программа кысаларында «Үзебезнекеләр турында кайгырту» дигән мәгълүмати ресурс (https://zabotasvo.tatar/) һәм «Үзебезнекеләр турында кайгырту» дип аталган телеграм-бот (t.me/Svoi_tatarstan_bot) эшләп килә, аларда федераль, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәдә ярдәм чаралары турында мәгълүмат урнаштырылган.

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2023 елның 24 июленнән Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашкан ятим

балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбеннән булган затларга әлеге Законның 2 статьясы нигезендә исемлеккә кертелгән башка затлар алдында торак белән тәэмин ителүгә өстенлекле хокук бирелә.

Махсус хәрби операциядә барлык катнашучыларның балаларына уку йортларына кергәндә өстенлекле хокук бирелә. 2023 елдан махсус хәрби операциядә барлык катнашучылар һәм аларның балалары өчен аерым квота кысаларында югары уку йортларына керүгә махсус хокук билгеләнде. Шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның балаларына югары уку йортларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында буш урыннар булганда һәм академик бурычлары булмаган очракта, түләүле төркемнәрдән бюджетка күчү хокукы бирелә.

Шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә хезмәт итүче, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарга, махсус хәрби операция барышында ирекле рәвештә хәрби бурыч үтәүче гражданнарга, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе куркынычсызлык федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре һәм аларның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) әлеге категория гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү тәкъдим ителә:

мәктәпкәчә белем бирү программасы нигезендә эшләүче Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмасына баланы чиратсыз урнаштыру хокукы бирелү;

мәктәпкәчә белем бирү программасы нигезендә эшләүче Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмасында баланы тәрбияләгән өчен түләүдән азат ителү;

муниципаль мәгариф оешмаларының 1–11 сыйныф укучыларына көненә ике тапкыр бушлай кайнар ризык белән (иртәнге һәм көндезге аш) туклану мөмкинлеге бирелү;

18 яшькәчә балаларга һәм әтисенә йә әнисенә (законлы вәкилгә) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль мәдәният учреждениеләрендә уздырыла торган чараларга бушлай керү хокукы бирелү.

Казан шәһәренең район администрацияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә ташламалар бирелүне раслау өчен «Батыр» пластик карталары бирелә, аның аша балалар мәдәният, спорт учреждениеләренә һәм күңел ачу паркларына бушлай керә ала.

Хәрби хәрәкәтләр инвалидлары медицина-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениесе тарафыннан эшләнгән түләүсез нигездә инвалидка реабилитация яисә абилитация уздыру индивидуаль программасында тәкъдим ителгән чаралар буенча социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар шартларында чираттан тыш социаль хезмәт күрсәтүгә хокуклы.

Социаль тернәкләндерү хезмәтләре 5 дәүләт тернәкләндерү үзәгендә,

«Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, 2 дәүләтнеке булмаган социаль хезмәт күрсәтү оешмасында күрсәтелә.

Шулай ук хәрби хәрәкәтләр инвалидларына халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре составында эшләп килүче 5 социаль-тернәкләндерү бүлекчәсендә (Татарстан Республикасының Аксубай, Балтач, Мамадыш, Түбән Кама, Сарман муниципаль районнарында) социаль хезмәт күрсәтелә.

Барлык тернәкләндерү учреждениеләре районара принцип буенча эшли, тернәкләндерү буенча барлык кирәкле заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән. Социаль тернәкләндерү алгоритмы тернәкләндерүнең төп максатларын һәм бурычларын билгеләү өчен тирәнтен комплекслы диагностика уздыруны (социаль, психологик һәм һөнәри) үз эченә ала, ул хәрби хәрәкәтләр инвалидларына, шул исәптән яраланулар һәм терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарлану (шул исәптән ампутацияләр), сулыш, периферия нерв системасы (баш сөяге-биш мие яралары һ.б.) органнары зарарлану белән бәйле авырулар буенча сыйфатлы социаль хезмәт күрсәтү мөмкинлеге бирә.

2024 елның гыйнварыннан «Идел» инвалидларны социаль тернәкләндерү республика үзәге» (Зеленодольск шәһәре) дәүләт бюджет учреждениесе базасында даими рәвештә кеше тәрбиясенә мохтаҗ булган хәрби хәрәкәтләр инвалидларына өч ай дәвамында тернәкләндерү узу өчен шартлар булдырылды.

Әлеге эшне дәвам итү максатларында Татарстан Республикасы Рәисе карары нигезендә 2025 елның май аенда Казан шәһәрендә «Восхождение» инвалидлар өчен тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе базасында хәрби хәрәкәтләр инвалидлары өчен 40 урынга исәпләнгән стационар бүлекчә ачу планлаштырыла.

Шулай итеп, 2025 елдан махсус хәрби операциядә катнашуларны социаль тернәкләндерү өчен 282 стационар урын һәм 130 ярымстационар урын булдырылачак. Тиешле җиһазлар сатып алу һәм төзекләндерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан 56,7 млн сум акча бүлеп бирелде.

Татарстан Республикасында махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә урнаштыру буенча ведомствоара эш җайга салынган, анда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, «Ватанны саклаучылар» фонды, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты һәм Татарстан Республикасы медицина-социаль экспертиза бюросы катнаша.

2025 елның 28 мартына 2024 елның 1 июненнән хәрби хезмәттән азат ителгән махсус хәрби операциядә катнашучыларның 80 проценты эш белән тәэмин ителгән, 20 проценты тернәкләндерү уза, эшләргә яраксыз дип танылган инвалидлык төркеменә карый яисә уку йортларында көндезге уку бүлекләрендә белем ала.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга эшкә урнашуда ярдәм итү өчен кайнар линия (843) 564-11-11 телефоны буенча) эшли.

Махсус хәрби операциядә катнашучылар эш бирүчеләр тарафыннан тәкъдим ителгән вакантлы урыннарга (2025 елның 28 мартына «Россиядә эш» цифрлы платформасында 37,0 мең вакансия урнаштырылган), шул исәптән инвалидлар өчен квота бирелгән урыннарга (2,8 мең эш урыны), республика бюджеты акчалары хисабыннан кеше башына аена 2 650 сум күләмендә матди ярдәм күрсәтелә торган

вакытлы эш урыннарына (ел саен Татарстан Республикасы бюджетыннан эшсез гражданнарны вакытлы эш урыннарына урнаштыруга 12,0 млн сум акча бүлеп бирелә) урнашуда өстенлекле хокукка ия була.

Моннан тыш, республикада махсус хәрби операциядә катнашучыларны, шул исәптән инвалидларны өстенлекле тәртиптә эшкә урнаштырырга әзер булган эш бирүчеләр реестры алып барыла. Бүгенге көндә реестрда 470 нән артык эш бирүчедән 2,6 мең вакансия турында мәгълүмат бар. Реестр даими рәвештә яңартылып тора.

Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары ихтыяҗ аеруча зур булган һөнәрләр буенча бушлай һөнәри белем алырга яисә өстәмә һөнәри белем алырга хокуклы. 2025 елда «Кадрлар» илкүләм проекты кысаларында 360 программа буенча укулар уздырыла.

Татарстанда эшсез дип танылган һәм үз эшләрен башлап җибәрергә теләге булган махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларына 145,1 мең сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелде. Ел саен әлеге максатларга 65,1 млн сум акча бүлеп бирелә (махсус хәрби операциядә катнашучы гаиләсеннән булган 8 кешегә үз эшләрен башлап җибәрүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтелде).

Махсус хәрби операциядә катнашучыларны кызыксындыру чаралары да эшләп килә, шул исәптән «Киләчәк яZмыш» махсус хәрби операциядә катнашучыларны социаль-хезмәт адаптациясе һәм тернәкләндерү прораммасы, аның бурычы – махсус хәрби операциядә катнашучыларның һөнәри траекториясен төзү. 2025 елдан өч халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү өчен оештырылган «Үзебезнекеләр өчен эш» клубы эшли башлады.

Республикада махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре өчен махсуслаштырылган эш урыннары вакансияләре ярминкәләре уздырыла. 2024 елда һәр муниципаль берәмлектә 3 гомумреспублика махсуслаштырылган ярминкә узды. Шулай итеп, 2025 елның 21 февралендә вакансияләр ярминкәләрендә 134 эш бирүче, 8 уку йорты катнашты, 3 меңгә якын вакансия тәкъдим ителде. Вакансияләр ярминкәләрендә 809 граждан, шул исәптән 192 махсус хәрби операциядә катнашучы һәм аларның гаилә әгъзасы катнашты, эшкә урнашуга 128 юллама бирелде.

Татарстанда инвалидлыгы булган махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен эш урыннары булдыру һәм саклап калуда эш бирүчеләргә ярдәм итүнең төбәк чарасы да гамәлдә:

эш бирүчеләрнең саклап калынган эш урыннарында эшләүчеләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарының бер өлешен каплауга компенсация буларак ел саен 29,3 млн сум акча бүлеп бирелә;

инвалидлар өчен махсус эш урыннары булдыруга яисә җиһазландыруга чыгымнарны каплауга ел саен республика бюджетыннан 1,1 млн сум акча бүлеп бирелә (һәр булдырылган (җиһазландырылган, яңадан җиһазландырылган) эш урыны өчен 73,6 мең сум дип исәпләнгәндә).

Субсидияләр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан бирелә.

Республика ярдәм чараларыннан тыш эш бирүчеләргә Россия Социаль фонд аша бирелә торган түбәндәге федераль ярдәм чаралары да гамәлдә:

«Кадрлар» илкүләм проекты кысаларында 2025 елдан хәрби хәрәкәтләр ветераннарын һәм аларның гаилә әгъзаларын эшкә урнаштырган эш бирүчеләргә өч минималь хезмәт хакы һәм иминият түләүләре күләмендә хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны каплауга (бер минималь хезмәт хакы өчен түләүгә 22 440 сум күләмендә һәм уртача 30 процент күләмендә иминият түләүләренә, эшкә урнашканнан соң 1 ,3 һәм 6 айдан соң һәр эшкә урнашкан граждан өчен 87,5 мең сум күләмендә);

эш бирүчеләргә I һәм II төркем инвалидлар өчен эш урыннары булдырган яисә җиһазландырган өчен 200 мең сумга кадәр субсидия бирелә.

2025 ел Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 27 сентябрендәге 748 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елы дип игълан ителде. Ватанны саклаучылар елында 2025 елның 18 февраленнән махсус хәрби операция ветераннары һәм анда катнашучылар өчен «Батырлар. Герои Татарстана» программасы эшли башлады һәм анда теркәлү мөмкинлеге ачылды. Аның максаты – квотлар билгеләү ярдәмендә дәүләт һәм муниципаль идарә системасында, шулай ук башка даирәләрдә вазыйфалар башкару өчен көчле җитәкчеләр командасын булдыру, аларга әзерлек бирү. Гаризалар бирү кампаниясе кысаларында хакимият органнары «Батырлар. Герои Татарстана» программасына кертелүгә тәкъдим ителергә һәм алга таба Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтенә керергә мөмкин булган махсус хәрби операция ветераннары һәм анда катнашучылар (https://batyrlar-rt.ru сайтында теркәлгән) арасыннан үз кандидатураларын тәкъдим итә ала.

**«Демография» илкүләм проекты**

2024 елда «Демография» илкүләм проекты максатларына ирешүгә юнәлдерелгән төбәк проектлары кысаларында түбәндәге чаралар тормышка ашырылды:

«Балалар туганнан соң гаиләләргә финанс ярдәме күрсәтү» төбәк проекты:

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация бирелде;

республика территориясендәге авылларда, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга беренче, өченче һәм аннан соңгы балалар туу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелде;

өч һәм аннан күбрәк игезәк балалар тәрбияләүче гаиләләргә пособиеләр бирелде;

«Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән аналарга, «Ата-ана фидакарьлеге» ордены белән бүләкләнгән ата-аналарга (уллыкка (кызлыкка) алучыларга) бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелде;

«Халыкка эшкә урнашуга ярдәм итү» федераль проекты һәм «Татарстан Республикасында халыкка эшкә урнашуга ярдәм итү» төбәк проекты:

оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре хезмәткәрләренә, шулай ук эшкә урнашуда ярдәм сорап халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре органнарына мөрәҗәгать иткән һәм оборона-сәнәгать предприятиеләре белән уку шартнамәләре

төзегән гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирелде;

эштән азат итү куркынычы алдында калган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру.

Федераль бюджет хисабыннан 4 385 кеше укырга җибәрелде, шул исәптән:

1 542 кеше – халыкны эш белән тәэмин итү органнарында теркәлгән, эштән азат итү куркынычы алдында калган гражданнар, пенсия алды яшендәге гражданнар һәм 50 яшь һәм аннан да өлкәнрәк булган эшсез граждан;

1 638 кеше – эш эзләп халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре органнарына мөрәҗәгать иткән гражданнар;

1 160 кеше – фактта бала карау белән шөгыльләнүче һәм баласына өч яшь тулганчы бала карау буенча отпускта булган гражданнар, хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар, җиде яшьне кертеп, тәрбияләүче хатын-кызлар;

16 кеше – 35 яшьне кертеп, яшьләрнең аерым категорияләренә караган затлар;

29 кеше – башка категория гражданнар исәбеннән булган затлар.

Укыту хезмәт базарында ихтыяҗ булган профессияләр һәм белгечлекләр буенча, шул исәптән эшкә алу турында гарантия белән тәгаен эш бирүче заказы буенча алып барыла. Укытудан соң эшкә урнаша алу дәрәҗәсе 80 процент тәшкил итә.

2024 елда Татарстан хезмәт базарында киеренкелекне киметү буенча өстәмә чаралар уздыруда катнашты, моңа 25,5 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән федераль бюджеттан – 20,7 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 4,8 млн сум. Әлеге чаралар:

6 предприятиедә эшсез калу куркынычы алдында торган 421 кешегә вакытлыча эш урыны тәкъдим итү нигезендә керемнәр һәм халыкның эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсен саклап калу;

оборона-сәнәгать комплексының 7 предприятиесендә эшсез калу куркынычы алдында торган 477 хезмәткәргә һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирелде.

«Өлкән буын гражданнарга системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш шартларын яхшырту программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру» төбәк проекты:

озак вакытка исәпләнгән тәрбияче хезмәте һәм гаиләгә тәрбиягә алу хезмәтен үстерү системасы оештырылды. Уздырылган чаралар нәтиҗәсендә:

бушлай социаль пакет кысаларында 5 988 өлкән яшьтәге гражданга һәм инвалидка озак вакытка исәпләнгән тәрбияче хезмәте, шул исәптән 854 өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) «Тәрбиядә ярдәм итүче» хезмәте күрсәтелде;

көндезге бүлекләрдәге (төркемнәрдәге) когнитив һәм менталь авырулары булган 1 065 өлкән яшьтәге кеше һәм инвалид көндезге вакытта эш белән тәэмин ителде;

2,9 мең гаилә әгъзасына гаиләдә тәрбияләү нигезләре өйрәтелде;

авылларда яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк булган 59,9 мең граждан медицина оешмаларына урнаштырылды, шул исәптән 45,9 мең кеше – диспансеризация һәм профилактик медицина тикшеренүләре узды;

31 өлкән яшьтәге граждан (инвалид) «Өлкәннәрне тәрбия алучы гаилә» проекты кысаларында гаиләгә тәрбиягә алынды;

65 яшьтән өлкәнрәк булган затларның пневмококк йогышлы авыруына каршы торучанлыгын арттыру максатларында вакцина эшләнде;

озак вакытка тәрбиягә мохтаҗ гражданнарның шәхси исәбен алып баруны тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы яңартып корылды.

2024–2025 елларда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында 120 урынга исәпләнгән Тәрбия Йорты төзелеше алып барыла.

«Җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» төбәк проекты:

муниципаль берәмлекләрдә предприятиеләрдә һәм оешмаларда эшләүчеләрнең сәламәтлеген ныгыту корпоратив программаларын гамәлгә кертү буенча 83 килешү (сәламәтлек саклау (3), мәгариф (36), сәнәгать җитештерүе (11), транспортта (4), сәүдә (1), дәүләт һәм муниципаль идарә (7), көнкүреш хезмәте күрсәтү (1) һәм башка эшчәнлек төрләрендә (20) төзелде;

Казан, Әлмәт, Зеленодольск, Түбән Кама шәһәрләрендә 4 җәмәгать сәламәтлеген саклау һәм медицина профилактикасы үзәге эшли;

Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлегендә халык арасында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту муниципаль программасы расланды;

Республика һәм районкүләм массакүләм мәгълүмат чараларында Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә наркоманияне, алкоголизмны, тәмәке тартуны профилактикалау һәм әлеге начар гадәтләргә каршы көрәшү буенча актив эш алып барыла. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы республика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең рәсми сайтларында һәм «ВКонтакте», «Одноклассники» һәм «Telegram» социаль челтәрләрендәге сәхифәләрендә тематика мәгълүмати бүлекләр урнаштырылган.

# ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ

Татарстан Республикасы елдан ел лаеклы рәвештә илебезнең иң яхшы спорт төбәге, ә Казан шәһәре спорт башкаласы дип таныла бара.

## Спорт инфраструктурасы

Татарстан – Россия Федерациясендә спорт объектлары белән тәэмин ителгән төбәкләр арасында лидерларның берсе. Гражданнарга бер үк вакытта спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирелгән спорт корылмалары белән тәэмин ителеш 2024 ел йомгаклары буенча 72,5 процент (2023 елда – 71,7 процент) тәшкил итте. Спорт корылмаларында бер үк вакытта 331 980 кеше шөгыльләнә ала.

Республикада спорт корылмаларының гомуми саны 12 мең берәмлек тәшкил итә, шулардан:

6 493 бер яссылыкта урнашкан спорт корылмасы;

2 116 спорт залы;

45 стадион;

56 ябык боз аренасы;

39 манеж (10 җиңел атлетика буенча, 29 футбол);

304 йөзү бассейны;

90 чаңгы базасы;

1 биатлон комплексы;

2 ишкәк ишү базы;

162 ату буенча спорт төрләре өчен корылма;

2 692 башка спорт корылмасы.

2024 елда 125 спорт корылмасы төзелде.

Универсаль спорт мәйданчыклары төзү буенча республика программасы кысаларында 2013 - 2024 еллар эчендә 1 172 спорт корылмасы, шул исәптән 40 хоккей тартмасы, 44 блоклы модульле чаңгы базасы һәм 19 ябык футбол кыры. Әлеге максатларга 2013 - 2024 еллар эчендә Татарстан Республикасы бюджетыннан 5 074,2 млн сум акча бүлеп бирелде.

2024 елда 15 универсаль спорт мәйданчыгы (Саба муниципаль районында – 4, Казан шәһәрендә һәм Кукмара муниципаль районында – 3 шәр, Чаллы шәһәрендә, Түбән Кама, Алабуга, Биектау һәм Яңа Чишмә муниципаль районнарында берешәр); 4 ябык футбол кыры (Аксубай, Кама Тамагы, Лаеш, Сарман муниципаль районында) төзелде.

2024 елда спорт объектларын капиталь төзекләндерү республика программасы кысаларында 18 спорт объектында төзекләндерү эшләре башкарылды, 1 объектта проект-тикшеренү эшләре алып барылды. Барлыгы 2020 елдан 90 спорт объекты капиталь төзекләндерелде.

2024 елда «БРИКС илләренең спорт уеннары» халыкара мультиспорт чарасын әзерләү һәм уздыру кысаларында спорт объектларын капиталь төзекләндерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә рәвештә 3,8 млрд сум акча бүлеп бирелде. Казан шәһәренең «Үзәк стадион» спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль автоном учреждениесе, «Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф

учреждениесе спорт объектлары («Теннис академиясе», «Буревестник» ябык йөзү бассейны, «Гимнастика үзәге», «Спортның су төрләре сарае», «Спортның ишкәкле төрләре үзәге»), «Бокс һәм өстәл теннисы үзәге» спорт комплексы, «Санкт-Петербург» волейбол үзәге, «Ком территориясе» ел әйләнәсе пляжда уйнала торган спорт төрләре үзәге, «Тулпар» универсаль спорт комплексы төзекләндерелде.

«Демография» илкүләм проектының «Спорт – тормыш нормасы» дигән төбәк проекты кысаларында:

спорт әзерлеге оешмаларын нормага туры китерү максатларында республиканың 10 олимпия резервы спорт мәктәбе спорт җиһазлары һәм кирәк-яраклары белән тәэмин ителде;

Россия Федерациясе җыелма спорт командалары өчен спорт резервы әзерли торган 10 спорт мәктәбе спорт җиһазлары, кирәк-яраклары һәм экипировкалар сатып алынды.

«Бизнес-спринт (Мин спортны сайлыйм)» федераль проекты кысаларында 2024 елда Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләрендә «ФИЗРА» спорт үзәге» физкультура-спорт комплексы» спорт инфраструктурасы объектлары төзү буенча дәүләт-хосусый партнерлыгы проекты гамәлгә ашырылды, Казан һәм Зеленодольск шәһәрләрендә әлеге проектны башлау көздә тотыла.

2025 елда объектлар төзү эше дәвам иттерелә:

Әгерҗе, Апас, Баулы, Саба һәм Ютазы муниципаль районнарында өстәл теннисы өчен 5 спорт залы төзеләчәк. Әлеге үзәкләрне төзүгә Россиянең өстәл теннисы федерациясеннән 500 млн сум күләмендә финанслау алынды;

«Фехтование буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе өчен спорт залы төзеләчәк. Объект төзүнең бәясе 670 млн сум тәшкил итә, шулардан 150 млн сумы – Россиянең фехтование федерациясе акчалары хисабыннан.

**Физик культура**

Халыкны системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итүгә исәпләнгән «TIMERMAN» социаль спорт проекты эшләп килә. 2024 елда «TIMERMAN» спорт проекты кысаларында 13 чара (Казан, Зеленодольск, Иннополис, Әлмәт, Түбән Кама, Менделеевск шәһәрләрендә, шулай ук «Свияжск утрау-шәһәре» музей-тыюлыгы территориясендә) уздырылды. Чараларда Россиянең 72 төбәгеннән һәм дөньяның 22 иленнән 60 мең кеше катнашты. «Казан марафоны» масштаблы ярышында йөгерү белән шөгыльләнүче 12 меңнән артык кеше катнашты.

Республикада «TIMERMAN» һәм «Ак Барс Банк Казан марафоны» спорт проектлары чараларында 28 меңнән артык йөгерүче катнашты.

Системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр 2024 елда 65,8 процент тәшкил итте, шулардан өлкән яшьтәге гражданнар – 37 процент (хатын-кызлар – 55–79 яшь, ирләр – 60–79 яшь), сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләр – 35 процент.

**Спорт резервын әзерләү**

Татарстанда 164 спорт мәктәбе (шулардан 27 спорт мәктәбе «олимпия

резервы» статусына ия), аларда 79 спорт төре укытыла. Барлыгы спорт мәктәпләрендә 90 852 кеше шөгыльләнә. Тренерлык эшчәнлеген 2 920 тренер-укытучы алып бара.

2024 елда Казан шәһәренең «Ак Барс» гольф клубы базасында гольф буенча яңа республика спорт мәктәбе ачылды.

2025 елда спортта югары казанышларга ирешкән өчен 998 спортчы (2024 елда – 1 065 спортчы) айлык стипендия ала, шулай ук спортчылар әзерләгән өчен республиканың 62 тренерына (2024 елда – 72) өстәмә түләү билгеләнде.

2024 елда бик күп санда спорт дәрәҗәсе һәм разряд бирелде: 3 Россиянең атказанган спорт мастеры, 13 халыкара класслы Россия спорт мастеры, 330 Россия спорт мастеры һәм 1 348 спорт мастерына кандидат.

**Югары казанышлар спорты**

Республикада 141 спорт федерациясе эшләп килә, алар 143 спорт төрен үстерү өчен җаваплы.

Ел саен бөтенроссия һәм халыкара ярышларда яулап алынган медальләр санының уңай динамикасы күзәтелә. Татарстан спортчылары тарафыннан спортның олимпия төрләре буенча бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге ярышларда 1 013 медаль яуланды, шулардан 307 – алтын, 341 – көмеш, 365 – бронза.

Россия җыелма командаларына Татарстаннан 1 005 спортчы кертелде, шулардан спортның олимпия төрләре буенча – 484 спортчы.

Татарстан спортның 35 база төре буенча җаваплы, аларга 33 спортның олимпия төре керә, шул исәптән:

27 индивидуаль (бадминтон, бокс, велосипед спорты, гольф, байдаркаларда һәм каноэда ишү, ишкәк ишү, дзюдо, җиңел атлетика, өстәл теннисы, йөзү, суга сикерү, ядрә белән ату, синхрон йөзү, спорт көрәше, спорт гимнастикасы, стендка ату, теннис, триатлон, тхэквондо, авыр атлетика, фехтование, фигуралы шуу, нәфис гимнастика, ике төрдә чаңгы ярышлары, чаңгы ярышлары, чаңгыда трамплиннан сикерү, сноуборд);

6 уен (су полосы, волейбол, регби, футбол, чирәмдә хоккей, хоккей);

1 паралимпия төре;

1 сурдлимпия төре (саңгырау кешеләр өчен спорт).

**Спорт чаралары**

2024 елда Татарстан территориясендә 50 дән артык зур спорт чарасы оештырылды, шулардан 10нан артыгы – халыкара дәрәҗәдәге:

- «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турниры (19 февраль – 3 март), анда 116 илдән 21 инновация дисциплинасында 1 811 кеше катнашты;
- «Ак Барс Кубогы» каратэ буенча халыкара турнир (11–15 апрель);
- Бильярд спортчы буенча дөнья чемпионаты (21–28 апрель);
- «Йолдыз» нәфис гимнастика буенча халыкара ярышлар (22–27 май);
- «БРИКС илләренең спорт уеннары» халыкара мультиспорт чарасы (12–13 июнь), анда 82 илдән 4 267 кеше катнашты;

- Көрәш буенча яшүсмерләр арасында чемпионат һәм дөнья беренчелегенә ярышлар (20–24 июнь);

- «Милләтләр кубогы» чирәмдә хоккей буенча ир-ат һәм хатын-кыз командалары арасында халыкара турнир (22–28 август), анда Россия Федерациясе һәм Беларусь Республикасының илкүләм һәм яшьләр җыелма командалары катнашты;

- Суга сикерү буенча «Татарстан Республикасы Рәисе кубогы» халыкара ярышлар (3–7 ноябрь);

- Билбаулы көрәш буенча чемпионат һәм дөнья беренчелегенә ярышлар (10–16 ноябрь);

- Самбо буенча «Татарстан Республикасы Рәисе призына» Гран-При халыкара ярышлары (5–8 декабрь).

Татарстан Республикасының профессиональ клубларының 2024 елда ирешкән иң яхшы нәтиҗәләре:

- «Динамо-Ак Барс» волейбол клубы – Россия чемпионы, Россия Кубогы, Россия Суперкубогы һәм Легендалар Кубогы иясе;

- «Зенит-Казан» волейбол клубы (ир-атлар) – Россия чемпионы, Россия Суперкубогы иясе;

- «Динамо-Ак Барс» чирәмдәге хоккей буенча клубы (ир-атлар) – Россия чемпионы, Россия Суперкубогы һәм Россия Кубогы иясе;

- «Ак Барс – Динамо» чирәмдәге хоккей буенча хатын-кызлар клубы – Россия чемпионы;

- «УНИКС» баскетбол клубы – ВТБ Бердәм лигасы көмеш призеры;

- «Стрела-Ак Барс» регби клубы – регби-7 буенча Россия чемпионы, Россия чемпионатының көмеш призеры, Россия Суперкубогы иясе;

- «Барс канатлары» коляскадагы инвалидлар баскетбол клубы – Россия чемпионы;

- «Синтез» су тубы клубы – Россия чемпионы, Россия Кубогы иясе;

- «КАМАЗ-Мастер» командасы – «Ефәк юл» халыкара ралли җиңүчесе;

- Әлмәт шәһәренең «Нефтьче» хоккей клубы – Югары хоккей лигасы чемпионы, Петров Кубогы иясе;

- «Зилант» гандбол клубы – Россия чемпионатының бронза призеры, югары лига.

## ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕ

Республикада яшьләр сәясәте буенча муниципаль берәмлекләр, югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары, предприятиеләр, яшьләр оешмалары белән киң колачлы эш алып барыла.

**Яшьләрнең ирекләләр хәрәкәте**

Республиканың 298 мең волонтердан һәм 3 332 ирекләләр хәрәкәте оешмаларыннан торган волонтерлар берләшмәсе «Игелекле Татарстан» бердәм брендына тупланды.

Муниципаль волонтерлар үзәкләре һәр муниципаль районда төзелде, ирекләләр хәрәкәтен үстерү стандартларын гамәлгә кертү буенча эш дәвам иттерелә.

Ирекләләр хәрәкәте вәкилләре тырышлары нигезендә республика «Игелекле эшләр төбәге» ирекләләр хәрәкәтенә (волонтерларга) ярдәм итүнең иң яхшы төбәк практикалары бөтенроссия конкурсында алтынчы ел рәттән җиңү яулады.

2024 ел конкурсы йомгаклары буенча республика 2025 елда ирекләләр хәрәкәтен үстерүгә 5,96 млн сум күләмендә федераль субсидия алды. Әлеге акча «Добрый край – Игелек җире» муниципаль берәмлекләр оешмаларына (учреждениеләренә) ярдәм итү буенча республика конкурсын һәм Бөтенроссия конкурсының төбәк этабында җиңгән проектларны гамәлгә ашыруга тотылачак.

Республиканың ирекләләр хәрәкәте һәр гражданга үзен кызыксындырган ирекләләр һәм хәйриячелек чаралары буенча юнәлеш бирүче «Игелек Үзәге» – иҗтимагый үсеш һәм волонтерлар, хәйриячелек һәм гражданлык башлангычларына булышлык итү үзәге федераль социаль франшиза составына керә. Татарстан Республикасында барлыгы 27 «Игелек Үзәге» ачылды.

2023 елдан Россиядә беренче буларак Биектау муниципаль районында «Игелек» волонтерлар өчен профильле балаларны сәламәтләндерү лагере үзенең эшчәнлеген алып бара. Ул яшьләрне ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлегенә җәлеп итү буенча комплекслы программаның бер өлеше булып тора. 2024 елда 2 221 кеше катнашында 36 профильле смена уздырылды.

2024 елның 14 декабрендә Казан шәһәрендә «Игелекле Татарстан» ирекләләр хәрәкәте (волонтерлык) өлкәсендә республика премиясен бирү тантанасы уздырылды. Барлыгы әлеге премияне алуга республиканың 45 муниципаль берәмлегеннән 373 гариза бирелде. Төрле өлкәләрдә – сәламәтлек саклау, экология, инклюзия, мәдәният, билгеле бер вакыйгага багышланган чара, МХО зонасында ярдәм күрсәтү һәм башка юнәлешләрдәге волонтерлык хәрәкәте лидерлары премиядә җиңүчеләр булып табылды. «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» республика хәрәкәте активисты Виктор Воропаев Донецк һәм Луганск халык республикаларына гуманитар командировкаларда, Казан шәһәренең «Профессор К.Ш. Зыятдинов исемендәге 18 номерлы үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә янгын нәтиҗәләрен бетерүдә, Газзә Секторында яшәүчеләргә гуманитар йөкне самолетка төяүдә һәм башка эшләрдә катнашканы өчен гран-при алды.

**Патриотик тәрбия**

2024 елда яшь буында ватанпәрвәрлек һәм гражданлык хисе тәрбияләү дәүләт дәрәҗәсендәге өстенлекле юнәлеш сыйфатында аерым билгеләнде. Яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү, гражданнарда ватанпәрвәрлек тәрбияләү бик актуаль һәм социаль әһәмияткә ия мәсьәлә булып тора. Татарстан Россия Федерациясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча алдынгылар сафында.

Республиканың 45 муниципаль берәмлегендә 209 хәрби-патриотик клубы бар, аларда 10–16 яшьтәге 17 меңнән артык яшүсмер катнаша, өч учреждениесе: «Патриот» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге республика үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе, «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Патриот» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе, «Чистай муниципаль районының «Ватан» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе составында «Авангард» хәрби-патриотик тәрбия уку-укыту һәм методика үзәге эшли.

Яшьләр сәясәте учреждениеләренең (яшьләр үзәкләре, яшьләр (яшүсмерләр) клублары, хәрби-патриотик тәрбия клублары, Форпост һәм «Патриот» үзәкләре, «Авангард» үзәкләре) киң инфраструктура челтәре яшьләрне гражданлык һәм хәрби-патриотик тәрбия чараларында катнашуга җәлеп итүгә ярдәм итә. Ватанпәрвәрлек юнәлешендәге чараларда 833 меңнән артык кеше катнашты, алар эзләү отрядлары, хәрби-патриотик юнәлештәге сменалар һәм клублар мәктәбен, хәрби-реконструкция хәрәкәтләре мәктәбен узды, хәрби хезмәткә әзерлек нигезләрен өйрәнде.

«Татарстан Республикасының «Ватан» берләшмәсе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасына 1 200 кеше катнашында 67 эзләү отряды керә. 2024 елда республика эзләү отрядлары Бөек Ватан сугышы яулары булган урыннар буенча 34 экспедициядә катнашты.

2024 елның ноябрендә «Мирас-Наследие» балалар сәламәтләндерү лагеры базасында «Архангел» пилотсыз очу аппаратлары мәктәбе белән берлектә «Пилотсыз очу аппараты пилотлары академиясе: киләчәк операторлары» проекты тормышка ашырылды. Пилотсыз авиация системаларына идарә итү һәм эксплуатацияләү нигезләре буенча курсны республиканың 41 муниципаль берәмлегеннән яшьләр сәясәте учреждениеләрендә эшләүче 103 белгеч узды.

2024 елда «Яшьләрнең хәрби-спорт әзерлеген үстерү һәм патриотик тәрбия бирү үзәге» автоном коммерциячел булмаган өстәмә белем бирү оешмасы филиалы инструкторлары- методистлары 14 яшьтән алып 18 яшькәчә 2 991 яшүсмерне укытып чыгарды, шул исәптән Биектау муниципаль районының «Чайка» балаларны сәламәтләндерү лагеры базасындагы «Батырлар вакыты» хәрби-патриотик лагерьларның 21 көнлек җәйге сменалары кысаларында. Яшь курсантлар «Тактик медицина нигезләре, «Хәрби-спорт җыеннары», «Хәрби-патриотик тәрбия һәм хәрби әзерлек нигезләре», «Хәрби-спорт әзерлеге һәм патриотик тәрбия» программалар буенча укыйлар.

2024 елның 1 сентябреннән мәгариф учреждениеләренең уку-укыту программаларына «Ватан куркынычсызлыгы һәм аны саклау нигезләре» дигән яңа фән кертелде. Мәгариф учреждениеләре педагогларын яңадан әзерләү максатында 2024 елның 15 августыннан алып 25 сентябрьгә кадәр кадет мәктәпләре, «Авангард» һәм «Патриот» үзәкләре базасында Казан, Чаллы, Түбән кама, Бөгелмә, Әлмәт шәһәрләрендә, Тәтеш һәм Саба муниципаль районнарында өч көнлек интенсивлар уздырылды, аларда 1 184 педагог катнашты, алар үзләренең һөнәри күнекмәләрен яхшырту өчен 24 сәгатьлек гамәли әзерлек дәресләре узды.

Икенче ел рәттән Татарстан «Россия Геройлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасы белән берлектә «Ватан Геройлары вахтасы» дигән бөтенроссия патриотик акциясендә катнаша. Әлеге проект кысаларында 2024 елның 12–16 ноябрь көннәрендә 16 Россия Федерациясе Герое «батырлык дәресләре», Татарстан Республикасы мәктәп (лицей) укучылары, училище курсантлары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары студентлары өчен мәгълүмати очрашулар һәм әңгәмәләр уздырды.

Уникаль проект – «Яшь десантчы» хәрби-патриотик профильле җәйге палата лагерьлары эшен дәвам итә.

2024 елда төзекләндерүдән соң 7 лагерь ачылды, аларда 3 мең кеше, шул исәптән авыр тормыш хәлендә калган 1,3 мең бала, МХО катнашучылар гаиләсеннән булган 131 бала ял итте. Лагерь сменалары барышында яшүсмерләр һава-десант, көрәш һәм кул көрәше, корал белән куллану һәм хәрби техникада йөрү күнекмәләре алды, тактик һәм медицина әзерлеге узды.

2024 елның 23 апрелендә 10 меңнән артык кеше, шул исәптән мәктәп балалары, студентлар тантаналы митингта катнашты һәм Россия Федерациясе Оборона министрлыгының агитация поезды музей-күргәзмә вагоннарына экскурсия ясады.

2024 елның 15 августында Казан шәһәренең Елга порты территориясендә «Татарстан яшь армиячесе» диверсиягә каршы катерын тантаналы рәвештә каршы алу чарасы оештырылды, аның кысаларында республиканың 500 дән артык яшь гражданы катерның техник төзелеше һәм морякларның көндәлек тормыш рәвеше белән танышты.

2024 елның 8 августында Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов ярдәме белән Курс өлкәсендә һәлакәткә очраганнарга гуманитар ярдәм җыю штабы ачылды. 2024 елда Курс өлкәсе һәм Курс шәһәренә азык-төлек товарлары, шәхси кирәк-яраклар, кием, техника һәм янгын сүндергечләр төялгән 23 фура җибәрелде.

«Мәгариф» илкүләм проектының «Россия Федерациясендә гражданнарда ватанпәрвәрлек тәрбияләү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2024 елның сентябрендә Татарстан Республикасында беренче тапкыр Көньяк, Идел буе һәм Төньяк-Кавказ федераль округларының 33 төбәгеннән ватанпәрвәрлек тәрбиясе бирү өлкәсендә эшләүче 235 кеше катнашында Округ ватанпәрвәрлек форумы уздырылды.

МХО дә катнашучы Татарстан Республикасы хәрби хезмәткәрләренә һәм аларның гаилә әгъзаларына гуманитар ярдәм күрсәтү иң мөһим һәм өстенлекле бурычларның берсе булып тора. Татарстанда 85 гуманитар ярдәм җыю пункты эшләп килә, шуларның 20 се Казан шәһәрендә урнашкан. Татарстан

Республикасыннан МХО зонасына җибәрелгән гуманитар ярдәмнең гомуми күләме 2 046 конвой тәшкил итә.

**Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе эшчәнлеге.**

2024 елның декабренә Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең (алга таба – Беренчеләр хәрәкәте) Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсенең 1 654 беренчел бүлекчәсе ачылды, шул исәптән 1 300 – республика мәктәпләрендә, 96 – урта һөнәри белем бирү оешмаларында. 2024 елга үсеш 16,7 процентны тәшкил итте.

Бүгенге көндә Беренчеләр хәрәкәтендә 281 540 кеше әгъза булып тора, шулардан 247 мең кеше укучылар һәм 34,5 мең кеше – остаз. Беренчеләр хәрәкәтендә катнашуларның 30 проценты Беренчеләр хәрәкәтенең беренчел бүлекчәләре базасында даими эшчәнлек алып бара.

2024 елда студентлар арасында уздырылган мониторинг мәгълүматлары буенча Беренчеләр хәрәкәтенең танылу дәрәҗәсе 17 процентка артты һәм хәзер 71 процент тәшкил итә. Мәктәп укучылары арасында танылу дәрәҗәсе – 94,4 процент.

Татарстан Республикасы 2 юнәлеш буенча – балалар бакчаларында Беренчеләр хәрәкәтен үстерү, шулай ук халыкара юнәлешне гамәлгә ашыру буенча сынау төбәге дип билгеләнде.

Остазларны, шул исәптән педагогларны өйрәтү программалары системалы нигездә гамәлгә ашырыла килә. 2024 елда 2 363 остаз укытып чыгарылды. Мәгариф, мәктәпкәчә белем бирү, яшьләр сәясәте, спорт, мәдәният, өстәмә белем бирү учреждениеләре өчен 37 методик кулланма әзерләнде.

Беренчеләр хәрәкәте җирле бүлекчәләре рәисләре «җәмгыять тәрбиячеләре» булып тора, алар сукбайлыкны һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау системасы органнарында һәм учреждениеләрендә исәптә торучы балигъ булмаган яшүсмерләр белән шәхси профилактика эше алып баралар. Алар 46 баланы шефлыкка алды, шуларның 17 се профилактик исәптән төшерелде.

Ел дәвамында барлыгы 76 проект гамәлгә ашырылды, барлык катнашучыларның саны – 160 288 кеше.

Беренчеләр хәрәкәтенең төбәк тематик сменаларында 16 038 кеше катнашты. Муниципаль сменаларда стационар лагерьларда 4 065 бала, 1 485 бала – мәктәп яны, 90 палата лагеренда катнашты.

Ватанпәрвәрлек тәрбиясе бирү – Беренчеләр хәрәкәтенең өстенлекле юнәлеше булып тора. Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә даими рәвештә балаларның батырлар белән очрашулары булып тора. Махсус хәрби операциядә катнашулар һәм аларның гаиләләренә аерым игътибар бирелә. Аерым алганда, «Ватанны саклаучылар» фонды белән берлектә махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын Беренчеләр хәрәкәтенә җәлеп итү буенча эш алып барыла. Беренчеләр хәрәкәтендә катнашучылар махсус хәрби операциядә катнашучыларга актив ярдәм күрсәтә: гуманитар ярдәм җыялар, маскировка челтәрләре үрәләр, окоп шәмнәре ясыйлар, хатлар язалар.

**Яшьләр мәйданчыклары**

2024 елда яшьләр сәясәтенең 34 объектында эшләр башкарылды, шул исәптән:

түбәндәгеләр төзелде:

1 яшьләр үзәге («Порт» яшьләр үзәге муниципаль өстәмә белем бирү учреждениесе, Зеленодольск шәһәре);

6 балалар өчен сәламәтләндерү лагеренда объектлар (Татарстан Республикасының Әлки, Сарман, Баулы, Кукмара, Ютазы муниципаль районнары, Казан шәһәре);

түбәндәгеләр төзекләндерелде:

6 яшьләр үзәге (Казан шәһәре (2 үзәк), Татарстан Республикасының Чүпрәле, Менделеевск, Тукай, Кукмара муниципаль районнары);

9 балалар өчен сәламәтләндерү лагере (Әлки, Балтач, Зеленодольск (2 лагерь), Татарстан Республикасының Менделеевск, Минзәлә, Мамадыш муниципаль районнары, Казан шәһәре, Анапа шәһәре);

6 яшьләр (яшүсмерләр) клубы (Татарстан Республикасының Азнакай, Биектау, Зеленодольск, Нурлат, Түбән Кама муниципаль районнары, Казан шәһәре);

6 психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге (Зеленодольск (3 үзәк), Татарстан Республикасының Зәй, Чистай муниципаль районнары, Казан шәһәре, Чаллы шәһәре).

«Мәгариф» илкүләм проектының «Яшьләргә ярдәм итү системасын үстерү («Россия яшьләре»)» федераль проекты кысаларында 2024 елда Казан шәһәрендә республика яшьләр үзәге (Химиклар мәдәния сарае) капиталь төзекләндерелде, әлеге эшләргә 116,4 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән 94,3 млн сум – федераль бюджеттан, 22,1 млн сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан.

**Балаларның ялын һәм сәламәтлеген ныгытуны оештыру**

2024 елда төрле милек рәвешендә булган 1 636 сәламәтләндерү учреждениесендә 214 118 бала өчен төрле формада ял һәм сәламәтләндерү чаралары оештырылды, шулардан 834 лагерь – көндезге (мәктәп яны), 138 шәһәр яны стационар сәламәтләндерү лагере, 602 лагерь – хезмәт һәм ялны оештыру, 46 палата лагере, 11 санаторий-курорт учреждениесе, 4 лагерь Кара диңгез яр буенда, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт – Ак Барс» яшьләр үзәге дәүләт автоном учреждениесе.

2024 елның җәйге чорында республика лагерьларында Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан килгән 512 бала, Белгород өлкәсеннән 292 бала һәм Оренбург өлкәсенең су баскан территорияләреннән 248 бала ял итте.

2024 елда Зеленодольск шәһәрендә һәм Азнакай шәһәрендә мәдәният һәм яшьләр сәясәте учреждениеләре базасында оештырылган көндезге лагерьлар ачылды.

2024 елда игълан ителгән Россия Федерациясендә Гаилә елы, Татарстанда Фәнни-технологик үсеш елы кысаларында балалар сәламәтләндерү лагерьларында тематик чаралар комплексы оештырылды. Балаларның сәламәтлеген ныгыту кампаниясе барышында ватанпәрвәрлек тәрбиясе бирүгә, юл хәрәкәте кагыйдәләрен, террорчылыктан саклану нигезләрен өйрәнүгә; цифрлы

куркынычсызлык күнекмәләренә, экстремистлыкны һәм террорчылыкны, деструктив тәртип һәм башка төрле социаль тискәре күренешләрне профилактикалауга зур игътибар бирелде.

**Вакыйгалар һәм чаралар**

Яшьләргә үз сәләтләрен һәм мөмкинлекләрен күрсәтү өчен шартлар тудыру яшьләр сәясәтенең иң өстенлекле бурычларыннан берсе. 2024 елда иҗади юнәлеш проектларында 400 мең бала һәм яшьләр катнашты.

Түбәндәге аеруча зур чаралар уздырылды:

«Татарстан Республикасының Ел студенты – 2024» XX республика премиясе;

«Елның иң яхшы яшь укытучысы – 2024» республика конкурсы;

һөнәри белем бирү оешмалары арасында «Ел студенты» бөтенроссия премиясе;

студентлар өчен транспорт гранты (югары уку йортлары һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларында укучылар арасында финанс ярдәме алучыларны сайлап алу буенча конкурс) (8,8 меңнән артык гариза, финанслау күләме – 60 млн сум);

«Ел казанышы – 2024» һөнәри белем бирү оешмаларында укучылар өчен республика премиясе;

XXIV «Созвездие-Йолдызлык – 2024» республика ачык телевидение яшьләр эстрада сәнгате фестивале;

XII «Наше время – Безнең заман» эшләүче яшьләр иҗатының еллык ачык республика телевидение фестивале (Татарстан Республикасының 138 предприятиесе һәм оешмасы катнашты, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе командасы гран-при яулады);

«Татарстан Республикасының яшь рационализаторы һәм уйлап табучысы – 2024» конкурсы;

«Әлбәдән» хәрби уеннары» VI бөтенроссия тарихи реконструкция фестивале;

«Сәләт» халыкара яшьләр мәгърифәти форумы;

Эшләүче яшьләрнең республика форумы;

Агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Үз һөнәрендә иң яхшысы» һөнәри осталык буенча республика конкурсы;

Татарстан Республикасының авыл яшьләре республика форумы;

«Республика гаилә диалогы» яшь гаиләләр форумы;

COMBOnation брейк-данс һәм урам сәнгате буенча халыкара турнир;

REACTOR FEST креатив индустрияләр бөтенроссия фестивале;

«УРАМ» урам сәнгате фестивале;

«Татарстан Республикасының шаяннар һәм тапкырлар клубы чемпионнары кубогы» юбилей уены (республиканың шаяннар һәм тапкырлар клубы уеннарында катнашкан өч дистә ел дәвамында 20 команда катнашты);

«Игелекле Татарстан» ирекләләр хәрәкәте өлкәсендә республика премиясе;

Округ ватанпәрвәрлек форумы;

Студентлар отряды бөтенроссия слеты.

2024 елда Татарстан Республикасы ирешкән казанышлар:

югары белем бирү мәгариф оешмалары студентлары өчен «Россия студентлар язы» XXIII бөтенроссия фестивалендә (Саратов шәһәре) 2 урын, «Төбәк

программасы» юнәлешендә 3 урын;

һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен «Россия студентлар язы» III бөтенроссия фестивалендә (Ставрополь шәһәре) 1 урын, «Төбәк программасы» юнәлешендә – 3 урын;

Студентлар хезмәт отрядлары республика хәрәкәте Россия Федерациясенең иң яхшы төбәк бүлекчәсе дип танылды;

«Ел студенты» һөнәри белем бирү учреждениеләре арасында бөтенроссия премиясендә «Елның иң яхшы укучылар советлары рәисе», «Елның патриотик берләшмәсе» номинацияләрендә Татарстан Республикасыннан 2 лауреат булды;

Югары белем бирү мәгариф оешмасы арасындагы яшьләр проектлары бөтенроссия конкурсында 4 югары уку йорты җиңү яулады һәм гомуми суммасы 21,5 млн сумга грант отты («Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе; «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе (алга таба – КМТТУ); «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе; «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе (алга таба – КДЭУ).

Яшьләр халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә аеруча зур чаралар түбәндәгеләр:

Бөтендөнья яшьләр фестивале (Татарстан Республикасын 225 делегат һәм 92 волонтер тәкъдим итте);

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XV Халыкара икътисадый форум кысаларында Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең яшь эшкуарларының X Казан форумы;

Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең VIII яшь дипломатлары форумы;

Казан глобаль яшьләр саммиты;

БРИКС Яшьләр советының кара-каршы очрашу форматындагы беренче утырышы (утырышның төп көн тәртибе – БРИКС илләре дәүләтләре башлыкларының карарларын һәм Казан декларациясен БРИКС илләре яшьләр уртак башлангычларына интеграцияләү);

яшьләрнең Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль директоры секретаре Антонио Гутерреш белән очрашуы;

«Уртак киләчәк өчен яңа мөмкинлекләр» БРИКС-2024 яшь лидерлар форумы кысаларында «БРИКС мөмкинлекләре» яшьләр диалогы;

«РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» II халыкара форум;

«Безнең Татарстан» яшьләр республика форумы уздыру кысаларында Байконур шәһәре делегациясе белән очрашу.

**Яшьләрне эшкә урнаштыру һәм аларның һөнәри яктан мөмкинлекләрен ачу**

Яшьләрне эшкә урнашу һәм һөнәри яктан мөмкинлекләрен ачу гаять мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора.

2024 елда 13 228 кеше вакытлыча, сезонлы һәм өстәмә эш белән тәэмин ителде, 4 946 кеше 65 млн сумга федераль грант акчалары хисабыннан 62 юнәлеш

буенча һөнәри белем алды.

Студентлар хезмәт отрядлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан 24 югары белем бирү оешмасында һәм аларның филиалларында, 37 һөнәри белем бирү оешмасында һәм Татарстан Республикасының 22 муниципаль берәмлегендә оештырылды. Студентларга икътисадның төрле тармаклары арасыннан эш юнәлеше сайлап алу, «һөнәр сайлау», шулай ук эшче һөнәрләр буенча белем алу мөмкинлеге бирелә.

Студентлар җитештерү һәм фәнни-җитештерү отрядлары юнәлеше буенча 2024 елда оборона-сәнәгать предприятиеләренә 3 984 студент җәлеп ителде, шул исәптән 5 293 студент республиканың сәнәгать предприятиеләренә – «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте; «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте; «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционер җәмгыяте; «Ремдизель» акционер җәмгыяте; «Казан төгәл машина төзү заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе» федераль казна предприятиесе; «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы.

**Яшь гаиләләргә ярдәм**

2024 ел йомгаклары буенча яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан гаилә мөнәсәбәтләре культурасын формалаштыруга юнәлтелгән 1 361 чара уздырылды, аларда 154 755 кеше катнашты.

Республиканың барлык муниципаль берәмлегендә яшьләр үзәкләре һәм яшьләр яшүсмерләр клублары базасында 55 яшь гаилә клубы эшләп килә, аларның максаты – гаилә әгъзаларын уртак мәдәни-ял итү эшчәнлегенә җәлеп итеп, яшь гаилә институтын ныгыту. Аларда гаилә төзү һәм гаиләне һәм гаилә кыйммәтләрен саклау буенча әңгәмәләр алып барыла; гаилә төзү һәм гаилә мөнәсәбәтләре кору буенча күнекмәләр бирелә; мәдәни һәм спорт конкурслары, тренинглар һәм осталык дәресләре форматында эш алып барыла; психологик һәм мәгълүмат ярдәм күрсәтелә.

2024 елның 11 мартында «Республика гаилә диалогы» яшь гаиләләр форумы узды, анда Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләреннән 100 кеше катнашты.

Татарстан Республикасында Гаилә елы кысаларында «Гаилә коды» дип исемләнгән проектлар сериясе эшли башлады, алар гаиләгә хас традицион рухи-әхлакый хәзинәләрне популярлаштыруга һәм гаилә мөнәсәбәтләренә ярдәм итүгә юнәлтелгән. Проектта 16 яшь гаилә катнашты.

2024 елның 3 сентябреннән 16 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан «Россия – мөмкинлекләр иле» автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән берлектә төрле категория яшьләр өчен биш проект сессиясе гамәлгә ашырылды, шуларның икесе яшь гаиләләргә багышланган иде.

2024 елның 10–12 сентябрендә Саба муниципаль районының «Мингәр» сәламәтләндерү үзәгендә «Гаилә коды: сәламәтлек турында» дип аталган беренче сессия булып узды, ул яшь парларның физик һәм менталь сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга багышланган.

2024 елның 16–18 октябрендә «Идел» яшьләр үзәге базасында «Гаилә коды: мөнәсәбәтләр турында» дип исемләнгән икенче сессия булып узды, ул гаиләдә гармонияле мөнәсәбәтләр төзүгә багышланган.

Дәүләт яшьләр сәясәтенең төп бурычы – яшь гаиләләргә ярдәм итү. Республикада яшьләр өчен дүрт торак программасы эшли, алар – республика ташламалы ипотека программасы, процентсыз өлешләп түләү, яшь гаиләләргә бушлай субсидияләр, шулай ук яшьләр өчен торак конкурсы.

2024 елда дәүләт ярдәме нәтиҗәсендә 658 яшь гаилә торак сатып алды:

27 муниципаль берәмлектән 551 гаилә – республика ташламалы ипотека программасы;

республиканың 41 муниципаль берәмлегеннән 84 гаилә федераль бюджеттан уртак финанслау шартларында;

16 гаилә – «Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү кысаларында;

7 гаилә – социаль ипотека программасы буенча торак алуга яшьләр торак конкурсы кысаларында.

**Яшьләр башлангычларына ярдәм итү**

Яшьләр өчен социаль әһәмияткә ия проектларга ярдәм итү максатларында түбәндәге чаралар гамәлгә ашырыла:

балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре арасында дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыруга республика грантлар конкурсы. Грантның гомуми суммасы 4,8 млн сум тәшкил итте. Балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең 12 проекты җиңүчеләр итеп танылды;

физик затлар өчен яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга субсидияләр рәвешендә республика грантлар конкурсы. Грантның гомуми суммасы 7,0 млн сум тәшкил итте. Конкурсның 14 юнәлеше буенча 40 проект җиңүче дип танылды;

яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре арасында Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм районнарында социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга республика грантлар конкурсы. Грант ярдәмен яшьләрне эш белән тәэмин итү, гражданлык-ватанпәрвәрлек тәрбиясе бирү, хокук бозуларны, яшүсмерләр һәм яшьләр өлкәсендә асоциаль күренешләрне профилактикалау, милли мәдәниятләрне һәм гореф-гадәтләрне саклау һәм башка мәсьәләләр белән шөгыльләнүче оешмалар алды. Грантның гомуми суммасы 50 млн сум тәшкил итте. Республиканың 37 муниципаль берәмлегеннән 70 проект җиңүчеләр дип танылды. Грантлар конкурсында катнашкан яшьләрнең саны 40 мең кеше тәшкил итте.

Татарстан яшьләре традицион рәвештә Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык уздырган форумнарда актив катнаша. Яшьләр эшләре буенча федераль агентлыктан грант яулап алу буенча Татарстан Россия төбәкләре арасында 5 урынны яулады. Республика яшьләренең башлангычларын тормышка ашыруга 71,8 млн сум күләмендә федераль акчалар җәлеп ителде.

# МӘДӘНИЯТ

Республикада мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәте Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр чорга мәдәниятне үстерү стратегиясе нигезендә алып барыла. Аның максаты – мәдәни үсеш өлкәсендә халыклар мәдәниятләренең гармонияле үсеше һәм алгарышы өчен шартлар тәэмин итәчәк, һәр шәхеснең һәм тулаем алганда җәмгыятьнең мәдәни һәм рухи потенциалын тормышка ашыруга этәргеч бирәчәк нәтиҗәле сәясәт формалаштыру.

Республикада барлыгы 3 807 мәдәният учреждениесе бар:

39 театраль-тамаша, шул исәптән 19 театр, 20 концерт оешмасы, 1 цирк;

1 505 китапханә (шулардан 1 296 – авылларда);

181 дәүләт һәм муниципаль музей челтәр берәмлеге;

1 892 мәдәни-ял итү учреждениесе, шул исәптән 73 күчмә мәдәният учреждениесе;

156 мәгариф оешмасы, шулардан 117 се – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы, 39 – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы;

14 киноучреждение;

13 халыклар дуслыгы йорты;

6 типик булмаган дәүләт мәдәният учреждениесе;

1 зоопарк.

**Театр-тамаша учреждениеләре.**

**Театрлар**

2024 елда республиканың дәүләт һәм муниципаль театрларында 100 премьера спектакле куелды, барлыгы 4 195 спектакль уйналды, шулардан 1 384 е – балалар һәм яшүсмерләр өчен. Театрларга 1 561,7 мең тамашачы килде.

Театр гастрольләре вакытында 280 спектакль, шул исәптән 130 спектакль Россия Федерациясе төбәкләрендә уйналды.

Үзенең 150 еллыгын бәйрәм иткән Муса Җәлил исемендәге татар академия дәүләт опера һәм балет театры «Аккош күле» һәм «Щелкунчик» балетлары белән Кытай Халык Республикасының күренекле театрларында зур уңыш белән чыгыш ясады.

Театр труппалары 67 төбәкара, бөтенроссия конкурсларында катнашты, 54 лауреат премиясе алды.

2024 елның 25 июнендә «Алтын битлек» бөтенроссия премиясе тапшыру тантанасында:

«Әкият» татар дәүләт академия курчак театры «Курчак театрларында иң яхшы спектакль», «Курчак театрларында иң яхшы режиссер эше», «Курчак театрында иң яхшы актер» номинацияләрендә 3 бүләк алды;

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры «Драма театрының иң яхшы спектакле», «Драма театрында костюмнар буенча рәссамның иң яхшы эше» номинациясендә 2 бүләк алды;

Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры «Ил язмышында катнашу һәм милли геройны эзләү» конкурсы жюри әгъзаларының

махсус премиясенә лаек булды.

Иң күренекле театраль вакыйгалар булып түбәндәгеләр санала:

Муса Җәлил исемендәге татар академия дәүләт опера һәм балет театрында Ф.И. Шаляпин исемендәге XLII халыкара опера фестивале (2024 елның 2 феврален – 1 марты);

XV балалар-яшүсмерләр театр (драма һәм курчак) коллективлары, студияләренең «Иделкәем& Кариев варислары» төбәкара фестиваль-конкурсы (2024 елның 1 апреле – 31 октябре);

Муса Җәлил исемендәге татар академия дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә Рудольф Нуриев исемендәге XXXVII халыкара классик балет фестивале (2024 елның 12–29 мае);

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында XVII «Нәүрүз» халыкара театраль-мәгърифәти форум (2024 елның 27 мае – 2 июне);

Минзәлә шәһәрендә «Ләкләк» II бөтенроссия бэби театрлар фестивале (2024 елның 30 мае – 3 июне);

Менделеевск шәһәрендә ЮНЕСКО ярдәме белән «Пастернак укулары» II халыкара әдәби-театраль фестиваль (2024 елның 20–22 сентябре);

«Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесендә «Һөнәр» XVI яшь режиссерларның бөтенроссия театр фестивале (2024 елның 3–8 декабре).

2024 елның 19 сентябрендә Мәскәү дәүләт консерваториясенең Зур залында «Партитура» III бөтенроссия композиторлар конкурсының финалы узды. «Опера» номинациясендә лауреатлар арасында Салават Камал либреттосына К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры баш режиссеры Ильяс Камал иҗат иткән «Урал бөркетләре» операсы да бар.

«Россия театраль куелышларының алтын фонды» проектында катнашу өчен сайлап алынган 300 иң яхшы спектакль арасында Чаллы дәүләт курчак театрының «Кроткая» спектакле дә бар.

2025 елның 20 гыйнварында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының киң вәкиллекле утырышы барышында Россия театр эшлеклеләре берлеге рәисе, Россия Федерациясенең халык артисты Владимир Машков 2025 елда «Алтын битлек» премиясен тапшыру тантанасы Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының яңа бинасында узачак дип белдерде.

**Концертлар оештыру**

Дәүләт һәм муниципаль концерт оешмалары тарафыннан 3 640 концерт программасы әзерләнде, шулардан 1 182 программа балалар һәм яшүсмерләр өчен уздырылды.

Концертларны 2 065,1 мең кеше тамаша кылды.

Иң әһәмиятле чаралар түбәндәгеләр:

«Рахлин сезоннары» XIII халыкара фестивале;

IX «Мирас» Нәҗип Җиһанов исемендәге татар музыкасы фестивале;

V халыкара орган фестивале;

Сергей Рахманинов исемендәге XIII «Ак канәфер» халыкара фестивале;

XXXIV «Бәхетле балачак» традицион фестивале;

Борис Березовскийның «Алабугада җәйге кичләр» VI халыкара музыка фестивале;

София Гобәйдуллина исемендәге «Concordia» XIV халыкара заманча музыка фестивале;

XIV «Казан көзе» халыкара опера фестивале;

XII «Денис Мацуев дуслары янында» музыка фестивале;

III «Россия-Көнчыгыш» милли мәдәниятләр халыкара фестивале («Казанда Шәрыкъ базары»).

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә 2024 елда еллык халыкара һәм бөтенроссия фестивальләре уздырылды: «Халык көйләре» бөтенроссия фестивале, «Джаз-Кроссоверфест-Казан» халыкара фестивале, «Джазлы Казан» халыкара фестивале, «Филармониада» халыкара сәнгать фестиале. Фестивальләр кысаларында 19 концерт программасы күрсәтелде, аларны 10 меңнән артык кеше тамаша кылды.

2024 елның 31 маенда Төркия Республикасының Әнкара шәһәрендә Татарстан Республикасының атказанган артисты Айдар Гайнуллинның «Айдар Гайнуллин һәм аның дуслары» дип исемләнгән концерты булып узды, ул Төркия Республикасының Президент симфоник оркестры сезоны ябылуга багышланды.

2024 елның июлендә «Бәхетле балачак» Татарстан Республикасы фольклор ансамбле «Сан-Педро Атокпан» һәм «Hala Hen» (Мехико шәһәре) халыкара фестивальләрендә катнашты.

2024 елның 8 сентябрендә Татарстан Республикасының иҗат делегациясе Казахстан Республикасының Астана шәһәрендә V күчмә халыклар уеннарында катнашты, делегация составына Татарстан Республикасының дәүләт җыр һәм бию ансамбле һәм Татарстан Республикасы халык сәнәгате осталары керде.

**Циркләр эшчәнлеге**

Казан шәһәрендә циркка 296,6 мең тамашачы килде. Цирк мәйданында 252 чара уздырылды, шулардан 9 ы – яңа тамашалар.

2025 елда «Белоруссия дәүләт циркы» дәүләт тамаша күрсәтү учреждениесенә (Минск шәһәре), Мәскәүнең Төсле бульварындагы Никулин циркына (Мәскәү шәһәре) гастрольләр оештырылды.

Балалар цирк мәктәбе укучылары «Кошки» номеры белән бөтенроссия үзешчән иҗат коллективлары фестиваль-конкурсында 1 урын алды.

Сен-Поль-ле-Дакс шәһәрендә узган XXIII халыкара цирк артистлары фестивалендә Казан дәүләт циркының балалар цирк мәктәбе укучылары Владимир Серов, Елизавета Демидова, Ярослав Краснов һәм Ксения Семёнова 2 урын яулады һәм тамашачылар мәхәббәте призына лаек булды.

**Музей эше**

Музейлар челтәренә 181 дәүләт һәм муниципаль музей берәмлеге, шул исәптән  структур бүлекчәләр керә (72 дәүләт музее һәм 109 муниципаль музей).

Музей фондлары күләме буенча Татарстан Республикасы Идел буе федераль округында беренче урында тора.

2024 ел йомгаклары буенча төп фонд предметларына 1 577,4 мең саклау берәмлеге керә (дәүләтнеке – 1 105,8 мең берәмлек, муниципаль – 471,6 мең

берәмлек). 2024 елда Музей фонды дәүләт каталогына 934 229 саклау берәмлеге кертелде.

2024 елда түбәндәге чаралар уздырылды:

«Мин Сезнең белән кечкенә шәһәрдә яшәргә теләр идем...» XI Халыкара Цветаева укулары (Алабуга шәһәре);

Татарстан Республикасы Милли музеенда А.С. Пушкинның тууына 225 ел тулуга багышланган «Боратынскийлар утарында әдәби укулар – 2024» бөтенроссия фәнни конференциясе;

Татарстан Республикасы Милли музеенда «Тукай укулары – 2024» халыкара дәрәҗәдәге бөтенроссия фәнни конференциясе;

«Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында «Мирас һәм туристлык: үзара хезмәттәшлек һәм үсеш юллары» XIII халыкара фәнни-гамәли конференция;

«Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында «Уникенче Кремль укулары» бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе.

2024 елда Татарстан Республикасы «Россиянең музей маршрутлары» федераль проектын гамәлгә ашыру мәйданчыгы булды. 2024 елның 25 апрелендә әлеге проект кысаларында Казан шәһәрендә «Мемориаль музейларның яңа тормышы» проект-аналитика сессиясе узды.

2024 елның 24 апрелендә Татарстан Республикасы Милли музеенда «Россиянең музей маршрутлары» бөтенроссия проекты кысаларында Бөтенроссия тарихи-этнография музееннан «Сезнең хат алынды. Туз грамоталары серләре» күргәзмә проекты тәкъдим ителде.

2024 елның 10 декабрендә «Царицыно» дәүләт музей-тыюлыгында татар һөнәрчелек сәнгате һәм аларның шәһәр мохитендә үзгәреш кичерүе турында «Шәһәр һәм һөнәрчеләр: Казанда очрашу. Идел буе татарларының традицион һөнәрчелек сәнгате» дигән күргәзмә ачылды. Экспозициядә 400 дән артык экспонат санала, алар арасында XII гасырга караган болгар алтыны, Алтын урда чоры көмеш чүмечләр, XIX гасыр ахыры көнкүреш кирәк-яраклары, кием-салым, аяк киеме, китаплар һәм журналлар һәм татар мәдәниятенең феномены булган күренекле шамаил бар.

2024 елда «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы «Юлбасма» нәшрияты белән берлектә «Казан Кремле серләре» дигән китап бастырып чыгарды, ул яңа гына эшли башлаган рәссамнар өчен иллюстрацияләр конкурсы йомгаклары буенча төзелде.

Республика музейларында 4 395 массакүләм һәм 21,5 мең мәдәни-мәгърифәти чара, 3 250 күргәзмә оештырылды, шулардан 59 проценты – шәхси фондлардан. 2024 елда музей учреждениеләрендә 11,1 млн кеше булды.

Татарстан Республикасы дәүләт музейлары һәм музей-тыюлыклары тарафыннан 817 күргәзмә проект оештырылды, шулардан Россия Федерациясенең башка төбәкләренә 73, чит илгә 11 күргәзмә проект алып барып күрсәтелде.

**Китапханәләр**

Республикада халыкка хезмәт күрсәтүче 1 505 китапханә исәпләнә, шул исәптән 4 республика (Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Республика

яшүсмерләр китапханәсе, Роберт Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсе, Республика сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус китапханә) һәм 1 501 муниципаль китапханә бар.

2024 елда китапханә фондын 23,5 млн саклау берәмлеге тәшкил итте.

«Татарстан Республикасының Электрон милли китапханәсе» порталында (kitap.tatar.ru) «Электрон коллекцияләр» бүлегендә 12 тематика коллекциядә документларның 15,8 мең электрон күчермәсе кертелде.

Республиканың гомуми кулланыштагы китапханәләренә 2024 елда 25 млн кеше килде, ә китапханәләр тарафыннан чараларда 1,5 млн кеше булды.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе «Цифрлы нигезгә корылган мәдәният» төбәк проектын тормышка ашыру кысаларында кульъязма һәм басма китаплар дип танылган документларны цифрлаштыру эшен дәвам итә. «Кульъязма һәм басма китаплар» коллекциясенә 1,5 мең электрон документ кертелде, фондларны цифрлаштыру барышында 42 мең нөсхә электрон документ булдырылды.

2024 елда Казан шәһәре «Россиянең китапханә башкаласы» дип танылды һәм 2024 елның 21–24 маенда Казан шәһәрендә Бөтенроссия китапханәчеләр конгрессы, Россия китапханәчеләр ассоциациясенең XXVIII еллык конференциясе уздырылды, анда Россия Федерациясенең барлык төбәкләреннән, шулай ук 12 якын чит һәм ерак чит ил дәүләтләреннән 1,5 меңнән артык делегат катнашты.

**Киноучреждениеләр**

Республиканың кино челтәренә 14 кино учреждениесе, 175 кино күрсәтү урыны, шул исәптән 1 «Мир» дәүләт кинотеатры, 7 муниципаль кинотеатрда 8 кино залы, мәдәни-күңел ачу учреждениеләрендә 43 муниципаль кино залы; 25 – коммерциячел кинотеатр, 27 – күчмә кино күрсәтү урыны керә.

2024 ел дәвамында кинотеатрларга һәм кино учреждениеләргә 3,8 млн кеше килде.

2024 елның мартында «Татаркино» учреждениесе оешуга 100 тулу бәйрәм ителде, аның кысаларында ерак һәм якын чит илләрдән кино индустрия вәкилләре катнашында «Кино индустрияне үстерүгә этәргеч буларак копродукция» дигән темага түгәрәк өстәл уздырылды.

2024 елның 8–15 июнендә Татарстан Республикасы делегациясе Малайзиядә Халыкара мөселман киносы фестивалендә катнашты.

Федераль Сабан туе кысаларында Марий Эл Республикасының Йошкар-Ола шәһәрендә 2024 елның 3–4 июлендә Татар киносы көннәре узды, анда «823 нче километр» һәм «Тарлан» фильмнары күрсәтелде.

2024 елның 6–11 сентябрендә «Алтын мөнбәр» XX юбилей Казан халыкара кинофестивале уздырылды, аның кысаларында 140 тан артык фильм күрсәтелде, шулардан конкурс программасы кысаларында – 51 фильм.

**Мәдәни-ял итү учреждениеләре**

Мәдәни-ял итү учреждениеләре 1 892 бинада урнашкан, шуларның 775 е – терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарланган затлар, 12 се – күрү сәләте начар булган

затлар, 12 се – ишетү сәләте начар булган затлар өчен. 39 муниципаль берәмлектә 73 күчмә мәдәният учреждениесе эшләп килә.

Мәдәни-ял итү учреждениеләрендә түбәндәгеләр эшли:

15 942 клуб формированиесе (212 671 кеше катнашында), шул исәптән 1 469 инклюзив (17 848 кеше катнашында);

8 609 үзешчән сәнгать коллективы, шул исәптән 583 коллектив «Үзешчән халык коллективы» һәм 72 коллектив «Үрнәк коллектив» дигән исемгә лаек, 774 коллектив халыкара конкурслар лауреатлары булды.

2024 елның 1 апреленнән авыл мәдәният йортлары базасында 7 муниципаль берәмлектә (Арча, Апас, Чүпрәле, Кукмара, Мөслим, Балык Бистәсе һәм Саба муниципаль районнарында) «Мәхәллә» иҗат мәйданчыгы» яңа проекты эшли башлады. ул этномәдәни күптөрлелекне, халык сәнгатен, матди булмаган мәдәни мирасны һәм традицион рухи-әхлакый хәзинәләрне саклауга һәм популярлаштыруга юнәлтелгән.

2024 елның 22 апреленнән 1 ноябренә кадәр Казан шәһәрендә «Татарстанның мәдәни башкаласы» республика муниципаль берәмлекләре арасында конкурс уздырылды, анда Казан шәһәрендә яшәүчеләргә тарихи-мәдәни күргәзмәләр, туристлык маршрутларын тәкъдим итү, милли аш-сулар, халык сәнгать һөнәрләре һәм иҗат коллективлары чыгышлары аша һәр районның үзенә генә хас мәдәни коды белән танышу мөмкинлеге бирелде. Әлеге чарада 23,5 меңнә артык кеше катнашты.

2024 елда мәдәни-ял итү учреждениеләре тарафыннан 381 524 массакүләм чара уздырылды. Мәдәни-ял итү учреждениеләрендә гражданнар 40,2 млн тапкыр булды.

**Матди булмаган мәдәни мирас**

Бүгенге көндә Татарстан Республикасының теркәлгән матди булмаган этномәдәни объектларының электрон реестрында (https://tatcultresurs.ru/onkn) 120 объект бар. Татарстан Республикасында Россиянең күпмилләтле мәдәниятенең үзенчәлекле чагылышы булган халык бәйрәмнәре һәм фестивальләрен саклауга һәм популярлаштыруга зур игътибар бирелә. Күп еллар дәвамында республика территориясендә яшәүче халыкларның гореф-гадәтләрен һәм йолаларын саклауга ярдәм итүче Татарстан халыкларының милли бәйрәмнәре: «Сабантуй» татар халык бәйрәме, «Нәүрүз» төрки халыклар бәйрәме, «Каравон» рус халык бәйрәме, «Валда шинясь» мордва мәдәнияте бәйрәме, «Семык» мари мәдәнияте бәйрәме, «Уяв» чуваш мәдәнияте бәйрәме, «Иван Купала» славян мәдәнияте бәйрәме, «Гырон быдтон» удмурт мәдәнияте бәйрәме, «Питрау» керәшен мәдәнияте бәйрәме уздырыла.

Марий Эл Республикасының Йошкар-Ола шәһәрендә XXIV Федераль Сабан туе, Пермь краенең Барда авылында XIV Бөтенроссия авыл сабан туе һәм II Халыкара Иртыш Сабан туе югары дәрәҗәдә узды.

2024 елда барлыгы 294 сабан туе оештырылды, шулардан 234 е – Россия Федерациясенең 46 төбәгендә, 60 ы – 22 ерак һәм якын чит ил дәүләтләрендә.

«Сабантуй» татар халык бәйрәмендә 3,5 меңнән артык Татарстан Республикасы артисты һәм халык сәнгать һөнәрчелеге осталары катнашты, бәйрәмне 955 меңнән артык кеше тамаша кылды.

Ватандашларыбызның иҗади активлыгын үстерүгә «Түгәрәк уен» бөтенроссия татар фольклоры фестивале, «Идел-йорт» театр коллективларының төбәкара фестивале, «Татар моңы» яшь башкаручыларның халыкара телевизион конкурсы, Р. Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестивале, «Шома бас» татар биюләрен башкаручыларның халыкара конкурсы, «Татар кызы» бөтенроссия конкурсы, «Сөйкемле Шүрәле» бөтенроссия иҗат эшләре конкурсы кебек халыкара һәм төбәк конкурслары, мәдәни проектлар ярдәм итә.

Мәскәү шәһәрендә «Уникаль Россия» сәнгать-сәнәгать күргәзмә-форумында Татарстан Республикасының 14 халык сәнгать һөнәрчелеге остасы катнашты. Күргәзмә кысаларында халык сәнгать һөнәрчелеге авторлык эшләре, «Россиянең кабатланмас осталары» декоратив-гамәли сәнгате осталары, дизайнерлары һәм рәссамнары бөтенроссия конкурсы узды. «Балчыкны сәнгати эшкәртү» номинациясендә Ирина Зубцова (курчак), «Металлны сәнгати эшкәртү» номинациясендә Айрат Шәмсетдинов (түбәтәй) конкурс лауреатлары булды.

2024 елның 19–23 июнендә Казан шәһәрендә Бөтенроссия балалар фольклориадасы булып узды, анда 10 яшьтән алып 18 яшькәчә балалар фольклор, хореография, халык җырлары һәм инструменталь ансамбльләре артистлары катнашында 20 дән артык чара уздырылды. Проектта Россия Федерациясенең 80 төбәгеннән 1 185 балалар һәм яшүсмерләр фольклор коллективы катнашты.

«Балаларны һөнәргә өйрәтү» республика проекты кысаларында Казан шәһәре территориясендә Татарстан Республикасының тугыз гомуми белем бирү учреждениесендә 13 осталык дәресе уздырылды, аларда 800 дән артык бала катнашты. 4 презентация буклеты («Каллиграфия сәнгате һәм шамаил», «Челтәр чигү», «Шәл бәйләү», «Курчаклар ясау») әзерләнде һәм 4 видеофильм («Металлны сәнгати эшкәртү», «Музыка кораллары ясау», «Татарларның зәркәнчелек сәнгате», «Келәм чигү сәнгате») төшерелде.

Татарстан Республикасында яшәүче җирле халыкларның традицион мәдәниятләре өлкәсендә гамәли тикшеренүләр эше дәвам иттерелә. «Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсенә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан «Россия фәннәр академиясенең Урал бүлекчәсе Пермь федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе, «В.Д. Поленов исемендәге Халык иҗаты Россия дәүләт йорты» федераль дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе белән берлектә Бөгелмә районының рус халкы күпләп яши торган торак пунктлар буенча фольклор-диалектология һәм этнолингвистик экспедицияләр оештырылды.

«Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсенә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе һөнәрчелек технологияләрен өйрәнү максатында Бөгелмә, Әлмәт, Биектау, Арча, Балтач муниципаль районнарына экспедицияләр үткәрелде.

**Мәдәният өлкәсендә белем бирү**

Республикада мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү буенча 156 мәгариф оешмасы эшләп килә: 105 балалар сәнгать мәктәбе һәм мәдәният идарәләре органнары карамагындагы 2 балалар үзәге, мәгариф идарәләре органнары

карамагындагы 38 балалар сәнгать мәктәбе, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге 9 һөнәри белем бирү оешмасы (көллиятләр), 2 югары белем бирү мәгариф оешмасы.

Әлеге оешмаларда 43 725 укучы белем ала, шулардан 38 472 бала – балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында, 2 163 бала – һөнәри белем бирү оешмаларында (көллиятләрдә), 3 090 укучы – югары белем бирү мәгариф оешмаларында.

Укытучылар составы 5 051 кешедән тора, шулардан өстәмә белем бирү оешмаларында 4 485 укытучы һәм концертмейстер, һөнәри белем бирү оешмаларында 709 укытучы, 307 кеше югары уку йортларының профессор-укытучылар составына керә.

Сәнгать өлкәсендә 13 өстәмә һөнәри белемгә кадәрле программасы гамәлгә ашырыла. Рәсем, фортепиано һәм халык уен кораллары ихтыяҗ иң күп булган юнәлешләр булып тора.

2024 елның 15 апреленнән 24 майга кадәр «Уен Фест» традицион халык уеннары фестиваль-конкурсы узды, анда 1 меңнән артык кеше катнашты.

2024 елның 20 июнендә «Моңлы тамчы» XII балалар фольклор коллективлары республика конкурсы үтте. Фестивальдә 3 меңнән артык кеше катнашты.

2024 елның 19–23 июнендә Татарстанда II Бөтенроссия балалар фольклориадасы булып узды, анда бөтен Россиядән 1 меңнән артык кеше катнашты.

2024 елда сәләтле балалар һәм яшьләр гомумроссия конкурсларында актив катнашты.

«Россиянең сәләтле яшьләре» гомумроссия конкурсында балалар сәнгать мәктәпләрендә укучы 10 бала бронза медале яулады, 3 бала «Яшь рәссамнар әсәрләрендә гаилә образы» бөтенроссия күргәзмә-конкурсы лауреатлары дип танылды.

Чаллы шәһәреннән яшь скрипкачы Лука Муромов «Щелкунчик» яшь музыкантлар халыкара телевидение конкурсында җиңүче дип танылды.

Казан шәһәренең «2 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укучысы Россия телевидениесе Беренче каналында «Голос. Дети» тапшыруының 11 сезоны финалисты булды.

**«Мәдәният» илкүләм проекты**

«Мәдәният» илкүләм проекты максатларына ирешү өчен «Мәдәни мохит», «Иҗади кешеләр» һәм «Цифрлы нигезгә корылган мәдәният» төбәк проектлары тормышка ашырылды. Аларга 2024 елда 1 270,8 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән 809,8 млн сум – федераль бюджеттан, 461,0 млн сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан.

«Мәдәни мохит» төбәк проекты кысаларында 2024 елда:

4 модульле муниципаль китапханә ачылды (Чүпрәле (1), Алабуга (1), Кукмара (2) муниципаль районнарында);

түбәндәге биналар капиталь төзекләндерелде һәм үзгәртеп корылды:

Сарман муниципаль районының «И.Г. Шакиров исемендәге Сарман балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасының дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

«Әлмәт татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

14 авыл мәдәният йорты;

авыл халкына хезмәт күрсәтү максатында 1 күчмә күпфункцияле үзәк (автоклуб) сатып алынды;

3 төбәк һәм муниципаль музее («Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, Арча муниципаль районының «Казан арты» Арча тарих-этнография музее» муниципаль бюджет учреждениесе, Тәтеш муниципаль районының «Тәтеш төбәге тарихы музее» муниципаль бюджет учреждениесе) һәм 3 муниципаль музей (Арча, Алабуга, Тәтеш муниципаль районнарында) техник җиһазландырылды;

14 балалар сәнгать мәктәбе музыка уен кораллары белән тәэмин ителде.

«Иҗади кешеләр» төбәк проектын тормышка ашыру кысаларында:

3 фестиваль уздырылды (Казан шәһәрендә XLII Ф.И. Шаляпин исемендәге опера фестивале, XXXVII Рудольф Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестивале, XVII «Нәүрүз» төрки халыкларның халыкара театр фестивале);

Яшь талантлар республика конкурсы оештырылды;

иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениесе һәм иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениесе хезмәткәренә дәүләт ярдәме күрсәтелде;

өзлексез белем бирү һәм мәдәният өлкәсе иҗади һәм идарәче кадрларның квалификациясен күтәрү үзәкләре базасында 1 218 мәдәният өлкәсе белгече квалификацияләрен күтәрү курслары узды.

«Россиянең кытай коллекцияләре» (Татарстан Республикасы Милли музее) һәм «Борынгы Русьның көн эшкәртү сәнәгате» («Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы) кебек киң колачлы күргәзмә проектлары эшләнде.

«Цифрлы нигезгә корылган мәдәният» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2024 елда «Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе» порталының «Китаплар» сәхифәсендә (https://kitap.tatar.ru/ru/ssearch/ecollection/) «Электрон коллекцияләр» бүлегендә 250 документ цифрлы нигезгә күчерелеп, урнаштырылды.

2024 елда Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе «ВКЗ иң яхшы проект офисы» номинациясендә иң яхшы виртуаль концерт заллары бөтенроссия конкурсында җиңүче дип танылды.

Татарстанның табигать тарихы музее һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгының Благовещение соборы тарихы музее «Артефакт» платформасында өстәмә чынбарлык технологиясен кулланып мультимедиа-гид булдыруга дәүләт һәм муниципаль музейлар күргәзмә проектлары арасында җиңүче дип танылдылар.

Ирекләләр хәрәкәте һәм волонтерлык өлкәсендә Татарстан Республикасы мәдәни волонтерлары командасы илебез субъектлары топ-10 керде, илебез төбәкләре арасында мәдәни волонтерлар саны буенча «Мәдәният өлкәсендә ирекләләр хәрәкәте иң яхшы төбәге 2024» исеменә лаек булды һәм гомуми

мониторинг йомгаклары буенча Идел буе федераль округында 3 урын алды.

**Мәдәният өлкәсенә грант ярдәме**

2024 елда мәдәният өлкәсендә түбәндәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары каралган:

мәдәният һәм сәнгать муниципаль учреждениеләре иҗат коллективлары проектларына ярдәм итүгә (гомуми суммасы 11,5 млн сумга 53 җиңүче);

халык сәнгать һөнәрчелеге өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итүгә (гомуми суммасы 10,0 млн сумга 12 җиңүче);

шәһәр татар һәм рус мәдәни-ял итү мохитен булдыруга грант (гомуми суммасы 300,0 мең сумга 5 җиңүче);

дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә квалификацияләрен күтәрү, тәҗрибә алмашу чараларында катнашуга ярдәм итүгә (гомуми суммасы 3,0 млн сумга 53 җиңүче);

иң яхшы дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итүгә (гомуми суммасы 4,0 млн сумга 6 җиңүче);

Татарстан Республикасындагы иҗтимагый оешмаларга һәм Россия Федерациясе төбәкләрендә гореф-гадәтләрне саклауга һәм милли мәдәниятне үстерүгә, этномәдәни һәм телләр күптөрлелеген саклауга, мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә булышлык итүгә (Россия Федерациясенең 14 субъектыннан гомуми суммасы 12,9 млн сумга 14 җиңүче).

Авыл җирлекләренең иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләренә һәм аларның хезмәткәрләренә акчалата бүләк (хезмәткәрләр арасыннан гомуми суммасы 2,4 млн сумга 38 җиңүче һәм учреждениеләр арасыннан гомуми суммасы 5,5 млн сумга 44 җиңүче).

Моннан тыш, Мәдәни инициативалары президент фонды тарафыннан уздырылган мәдәният, сәнгать һәм креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга президент грантлары конкурсы йомгаклары буенча 2024 елда 41 оешма җиңүче дип танылды, грантның гомуми суммасы – 44,1 млн сум, шулардан гомуми суммасы 21,9 млн сумга социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның 17 проекты.

**«Пушкин картасы» программасын гамәлгә ашыру**

Балаларны һәм яшьләрне художество мәдәнияте һәм сәнгатен өйрәнүгә җәлеп итү, илебез, аларда Россия һәм дөнья мәдәнияте рухи хәзинәләре белән танышуга кызыксындыру уяту, яшь буынның мәдәни үсеш дәрәҗәсен арттыру максатында 2021 елның 1 сентябреннән «Пушкин картасы» федераль проекты гамәлдә.

2024 елда 321,5 мең яшь татарстанлы «Пушкин картасы»н рәсмиләштерде.

«Мәдәният өлкәсендә дәүләт хезмәтләре» мобиль кушымтасында «Пушкин картасы» федераль проектыннан файдаланучылар өлеше буенча Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектлары арасында 2 урынны алды.

«PRO.Мәдәният.РФ» порталында «Пушкин картасы» федераль проектыннан файдаланучылар сыйфатында Татарстан Республикасының 468 оешмасы теркәлде.

**Республика программаларын гамәлгә ашыру**

Мәдәният объектларын капиталь төзекләндерү республика программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2024 елда түбәндәге биналар капиталь төзекләндерелде:

- «Чулпан» мәдәният йорты (Татарстан Республикасының Әгерҗе районы), 13 авыл мәдәният йорты (Татарстан Республикасының Алексеевск, Арча, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Лениногорск, Кукмара, Мөслим, Яңа Чишмә, Балык Бистәсе муниципаль районнары) һәм 2 муниципаль китапханә (Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәрендәге «Арча үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авылындагы «Үзәкләштерелгән китапханә» муниципаль бюджет учреждениесе), гомуми суммасы 467 675,33 мең сум;

- 4 балалар сәнгать мәктәбе («М.Х. Хәертдинов исемендәге Лениногорск балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе (икенче бинасы), Мамадыш шәһәренең «Мамадыш шәһәренең композитор Яруллиннар исемендәге балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе һәм Минзәлә шәһәрендәге «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе), гомуми суммасы 147 109,28 мең сум;

- 6 муниципаль музей («Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авылының Себер тракты тарихы һәм Муса Җәлил музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе, Югары Ослан районындагы «Югары Ослан муниципаль районының туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе, Биектау тимер юл станциясе поселогындагы «Биектау муниципаль районының туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Югары Тәкермән авылындагы «Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – «Туган як» тарих-этнография музее, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авылындагы К.Насыйри исемендәге архитектура-этнография комплексы, Тукай муниципаль районының Яңа Бүләк авылындагы Илһам Шакировның иҗат йорты (музее)» муниципаль бюджет учреждениесе), гомуми суммасы – 90 401,56 мең сум.

2024 елда Казан шәһәрендә бюджетның программадан тыш өлеше буенча «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең яңа бинасының масштаблы төзелеше тәмамланды (гомуми суммасы 27 792 350,00 сум). 2025 елның 20 гыйнварында театрның тантаналы ачылышында Россия Федерациясе Мәдәният министры О.Б. Любимова, Россиянең Төзелеш министры И.Ә. Фәйзуллин, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов һәм Россиянең Театр әһелләре берлеге рәисе В.Л. Машков катнашты. 59 609 кв метр мәйданда 1 348 урынга исәпләнгән дүрт тамаша залы (Зур зал – 766 урын, Универсаль зал – 300 урын, Түгәрәк зал – 242 урын, Камера залы – 40 урын), репетицияләр уздыру өчен иркен бүлмәләр, 40 машинага исәпләнгән җир асты парковкасы урнашкан. Татар хатын-кызларының бизәнү әйберләре театр интерьеры өчен бизәкләр эшләүгә илһам чыганагы булып тора. Театрның

планировкасы хезмәткәрләрнең: актерлар, администрация, техник хезмәткәрләрнең теләкләрен исәпкә алып эшләнде.

Моннан тыш, «Кама Тамагы районының халыкка мәдәни-ял итү хезмәте күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе, Чистай шәһәрендә урнашкан Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Мәдәни-ял итү үзәге» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе, Татарстан Республикасының «Биләр дәүләт тарих-археология һәм табигать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, «Сабаның үзәкләштерелгән туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе (Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Осиново авылы мәдәният йортында төзекләндерү эшләре алып барылды.

С.Сәйдәшев исемендәге балалар сәнгать мәктәбе төзелде (Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Стадион урамы) һәм Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында Балалар сәнгать мәктәбе, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишево авылында 350 урынга исәпләнгән күп функцияле үзәк, Татарстан Республикасы минзәлә муниципаль районының Җәмәк авылындагы күп функцияле үзәк төзелде, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәрендә Б.Урманче музее төзелеше башланды.

## КОММЕРЦИЯЧЕЛ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАРГА ЯРДӘМ ИТҮ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ

Граждан җәмгыяте институтлары белән актив хезмәттәшлек алып барыла. Идел буе федераль округында теркәлгән коммерциячел булмаган оешмалар (алга таба – КБО) саны ягыннан республика алдынгы урыннарның берсен алып тора. 2025 елның 1 гыйнварына республикада 6 261 КБО, шул исәптән 1 654 иҗтимагый оешма, 2 163 дини берләшмә, 2 425 коммерциячел булмаган башка оешмалар, шулай ук сәяси партияләрнең 19 төбәк бүлекчәсе теркәлгән.

2024 елның 1 гыйнварыннан республикада «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновация икътисады» дәүләт программасының Татарстан Республикасы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга (алга таба – СЮКБО) ярдәм буенча ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) гамәлдә. Аның максаты – Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешендә катнашуга СЮКБОга этәргеч бирү, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм милләтләр арасындагы татулыкны саклау, социаль сәясәтнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрнең баланслanган булуы нигезендә иҗтимагый иминлеккә ирешү. 2024 елда Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 364,9 млн сум тәшкил итте.

2024 елда КБОга грантлар бирүгә конкурслар уздыру буенча бердәм грант операторы («Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү буенча республика ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы) тарафыннан коммерциячел оешмаларга граждан җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирүгә конкурс уздырылды (конкурс фонды – 159,7 млн сум, шулардан – 71,4 млн сум – Президент грантлары фондыннан уртак финанслау). Конкурс йомгаклары буенча грантлар 21 юнәлеш буенча 151 СЮКБОга бирелде, шулардан 14 СЮКБО – Россия Федерациясе субъектларыннан.

Республикада КБОларның муниципальара ресурс үзәкләре эшли, алар Ярдәмче программа акчалары ярдәмендә укыту, консалтинг һәм КБОлар эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүне тормышка ашыра. КБОларның муниципальара ресурс үзәкләре Казан («Инновацияле үсеш һәм технологияләрне трансферлау» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Әлмәт («Вертикаль» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Чаллы («Горизонт» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Кукмара («Вектор» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Буа («Буа Грант» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Чистай («Бердәмлек» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы) шәһәрләрендә урнашкан.

Ел дәвамында әлеге үзәкләр 651 консультация һәм 192 семинар уздырды, шулар арасында «Мәгълүмат ачыклык, КБО һәм социаль проектларны тәкъдим итү», «Социаль проектка 21 адым: проектның яшәү фазалары һәм аларны бәяләү

төрләре», «Эксперт карашы: хаталарны анализлау», «Проектны тормышка ашыру: идеядән алып үтәүгә кадәр», «Социаль проектлар ясау һәм социаль проектларга идарә», «Яхшы тон: партнерлар КБОларның ачыклыгын ничек билгели», «СЮКБоларның мәгълүмат яктан ачыклыгына замана таләпләре», «СЮКБОларның мәгълүмат яктан ачыклыгы инструментлары», «Проектлар презентацияләрен һәм питчы булдыру», «Проектның гавами презентациясе», «СЮКБОларны мәгълүмати таныту технолгияләре». 2024 елда аларның ярдәме белән 32 СЮКБО төзелде.

9 халыклар дуслыгы йорты (Казан, Чаллы, Азнакай, Лениногорск, Менделеевск, Түбән Кама, Нурлат, Тәтеш һәм Буа шәһәрләрендә) һәм Татарстан халыклары ассамблеясе ресурс үзәкләре булып торган 4 халыклар дуслыгы йорты үзәге КБОларга этномәдәни һәм конфессияара хезмәттәшлек алып баруда ресурс үзәкләре булып тора. 4 муниципаль районда район мәдәният йортларының структур бүлекчәләре буларак халыклар дуслыгы үзәкләре эшләп килә (Татарстан Республикасының Апас, Чүпрәле, Яңа Чишмә һәм Спас муниципаль районнары).

Гражданлык инициативаларын хуплау һәм республикада граждан җәмгыяте институтларын формалаштыруга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы гамәлгә ашырыла. 2024 елда әлеге премияне дәгъвалауга үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча (гомуми приз фонды – 5,5 млн сум) 8 премия бирелде:

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе җаваплы секретаре Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин кызына;

Татарстан Республикасы Ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Иштирәков Хәбир Газиз улына;

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры Таҗиева Наилә Камил кызына;

«Зәкят» хәйрия фондына;

«Игелек» мөмкинлекләре чикләнгән һәм үсешендә үзенчәлекләр булган балалар аналарының Баулы районы җирле иҗтимагый оешмасына;

Татарстан Республикасының лейкемия белән авыручы балаларга ярдәм итү буенча Анжела Вавилова исемендәге төбәк иҗтимагый хәйрия фондына;

«Татарстан Республикасы башкорт милли-мәдәни мохтарияте – Башкортлар корылтае (конгрессы)» төбәк иҗтимагый оешмасына;

«Десантчылар берлеге» төбәкара иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсенә.

2015 елдан лауреат исеменә Татарстан Республикасының 29 күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм 44 КБО лаек булды.

Социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрында 31 дәүләтнеке булмаган оешма, шул исәптән:

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүче 21 оешма, 16 СЮКБОны да кертеп;

мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләргә һәм авыр тормыш

хәлендә калган балаларга социаль хезмәтләр күрсәтүче 10 оешма, 7 СЮКБОны да кертеп.

2024 елда социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның гомуми санында дәүләтнеке булмаган оешмаларның өлеше 21,7 процент тәшкил итте (2023 елда – 20,6 %, 2022 елда – 18,6 %). Дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан 11,0 мең кешегә хезмәт күрсәтелде.

2024 елда 19 дәүләтнеке булмаган оешма, шул исәптән сайлап алуда җиңгән 15 СЮКБО белән юридик затның социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарын компенсацияләү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүләр төзелде.

Гражданнарны граждан җәмгыятен үстерүгә җәлеп итү эше КБОларның Татарстан Республикасы ведомстволары һәм муниципаль иҗтимагый советларындагы, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарындагы вәкиллекләре аша алып барыла.

Территориаль иҗтимагый үзидарәләре гражданнарны территориядә булган мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү ресурсы буларак республиканың күп кенә муниципаль берәмлекләрендә актив кулланыла.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә СЮКБОларга ярдәм итү чараларын эшләү һәм үтәүдә методологик ярдәм күрсәтү максатларында СЮКБОлар белән хезмәттәшлекне көчәйтү, шулай ук алар эшчәнлегенең нәтиҗәле технологияләрен һәм ысулларын куллану буенча методик тәкъдимнәр эшләнде.

СЮКБОларның социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеген республика массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны үз эченә алган мәгълүмати ярдәмгә зур роль бирелә. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Татмедиа), шулай ук СЮКБОларга ярдәм итү буенча ресурс үзәкләре тарафыннан СЮКБОлар эшчәнлеген пропагандалау һәм популярлаштыру буенча эш алып барыла.

Татмедиа КБОларга әһәмиятле социаль гуманитар проектларны тормышка ашыруда, шулай ук ирекләләр хәрәкәте һәм хәйриячелек эшчәнлеге идеяләрен формалаштыруда мәгълүмати ярдәм күрсәтә.

2016 елдан башлап Татмедиа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы ярдәме белән СЮКБО эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырткан иң яхшы массакүләм мәгълүмат чаралары билгеләү буенча конкурс үткәрү турында» 2016 елның 2 декабрендәге 885 номерлы карары нигезендә) үткәрелә. Конкурста ММЧ редакцияләре, аерым авторлар, авторлар коллективлары һәм төркемнәре, шулай ук башка юридик затлар, шул исәптән СЮКБОлар да катнаша ала. 2024 елда конкурс 4 номинация буенча уздырылды: «Татарстан Республикасында СЮКБОлар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы телевидение сюжеты (яисә тапшыруы)», «Татарстан Республикасында СЮКБОлар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы радио сюжеты (яисә радио тапшыруы)», «Татарстан Республикасында СЮКБОлар эшчәнлеген яктырту буенча

басма массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы мәкалә», шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә СЮКБОлар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы язма». 12 массакүләм мәгълүмат чаралары авторы җиңүче булды. Конкурсның гомуми приз фонды – 400 мең сум.

Һәр елны республиканың КБОлары Россия Федерациясе Президенты грантларын бирү буенча конкурсларда катнаша. 2024 елда Татарстан Республикасының 61 СЮКБО проекты җиңүче дип танылды, грантларның гомуми суммасы 127,4 млн сум тәшкил итте.

Моннан тыш, Мәдәни инициативалар Президент фонды тарафыннан уздырылган мәдәният, сәнгать һәм креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга президент грантлары конкурсы йомгаклары буенча республика СЮКБОларының 17 проекты җиңүче дип танылды, грантның гомуми суммасы – 21,9 млн сум.

КБОларга ярдәм итү максатында 2018 елдан республикада махсус портал булдырылды, анда коммерциячел булмаган оешмалар интернетта бушлай үз сәхифәләрен булдыра ала (http://www.nkort.ru/), бу киләчәктә СЮКБОларның имиджын үстерергә, аларны медиа киңлектә тагын да танытуга этәргеч бирәчәк. Порталда КБОлар өчен кирәкле барлык мәгълүмат: норматив хокукый база, республика һәм шулай ук федераль конкурсларны уздыру, социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыру йомгаклары, СЮКБОларга ярдәм итү буенча муниципальара ресурс үзәкләре эшчәнлеге, муниципальара ресурс үзәкләре тарафыннан эшләнә торган мәгълүмати-методик материаллар урнаштырыла.

КБО турында мәгълүматларны үзәкләштерү максатларында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан 2014 елдан Татарстанда ярдәмнән файдаланган СЮКБОның республика реестры алып барыла. Төп мәгълүматны СЮКБОларга төрле ярдәм чаралары күрсәтүче дәүләт хакимияте башкарма органнары бирә. Шундый ук реестрлар республиканың муниципаль берәмлекләрендә дә алып барыла. Реестр мәгълүматлары нигезендә 2024 елда 321 СЮКБОга финанс ярдәме күрсәтелде. Реестр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Эшчәнлек» бүлегендә (https://mert.tatarstan.ru/reestr.htm) урнаштырылган.

# МӘДӘНИЯТ, СОЦИАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ, СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ҺӘМ МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ ОЕШМАЛАР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛГӘН ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ СЫЙФАТЫНА БӘЙСЕЗ БӘЯ БИРҮ

2013 елдан мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя бирү эше алып барыла (Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указын, «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя бирү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 256-ФЗ номерлы Федераль законны, «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя бирүне камилләштерү мәсьәләләре турында Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 5 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән).

Күрсәтелгән хезмәтләрне бәяләү оешма турында мәгълүматтан һәркемнең куллана алуын тәэмин итү, хезмәт күрсәтү шартларының уңайлылыгы, шул исәптән хезмәт күрсәтүне көтү вакыты, оешма хезмәткәрләренең яхшы мөнәсәбәте, әдәплелеге һәм итагатьлелеге, күрсәтелгән хезмәтләрдән канәгатьлелек дәрәҗәсе, шулай ук сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләрнең хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү кебек критерийлар буенча алып барыла.

Сыйфатка бәйсез бәя бирүне Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлекне саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, шулай ук республика җирле үзидарәләре органнары карамагындагы иҗтимагый советлар карарлары нигезендә оештырылган иҗтимагый оешмалар уздыра.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан күрсәтелгән хезмәт шартлары турында мәгълүматны җыюны һәм гомумиләштерүне иҗтимагый советлар тарафыннан билгеләнгән оешмалар исемлеге нигезендә операторлар тарафыннан башкарыла. 2024 елда әлеге максатларга дәүләт хакимияте органнары тарафыннан 216,5 мең сум акча бүлеп бирелде, шулардан мәдәният өлкәсендә – 48,0 мең сум, мәгариф өлкәсендә – 68,0 мең сум, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә – 100,5 мең сум, сәламәтлек саклау өлкәсендә сыйфатка бәйсез бәя бирү хезмәте җәмәгать башлангычларында башкарылды), җирле үзидарә органнарына – 112,5 мең сум (мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә – 1 мең сумнан алып 26 мең сумга кадәр, 16 муниципаль берәмлектә операторлар бушлай яисә җәмәгать башлангычларында эшләде).

Законнар нигезендә бер үк оешманың хезмәтләренә бәйсез бәя бирү елга бер тапкырдан да ешрак һәм өч елга бер тапкырдан да кимрәк булырга тиеш түгел. 2024 елда түбәндәге оешмаларга карата хезмәтләргә бәйсез бәя уздырылды:

200 социаль өлкә дәүләт оешмасы (хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя

уздырылырга тиешле оешмаларның 30 %), шуларга 16 мәдәният оешмасы, 62 медицина оешмасы, 78 белем бирү оешмасы, 44 социаль хезмәт күрсәтү оешмасы керә;

1 011 социаль өлкә муниципаль оешмасы (хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя уздырылырга тиешле оешмаларның 30 %), шулардан 80 мәдәният оешмасы, 931 мәгариф оешмасы.

Социаль өлкә оешмалары тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләргә бәйсез бәя бирү нәтиҗәләре буенча тулаем алганда уңай бәя бирелде.

Анкета һәм социологик сораштыру уздыру нәтиҗәләре буенча социаль өлкә оешмалары тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфаты турында кулланучылар фикере тупланды. 2024 елда анкета һәм социологик сораштыруда 179 755 кеше катнашты.

Сораштыру һәм бәяләү нәтиҗәләре буенча республиканың дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып, бәяләү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләрне бетерү планнары раслана. Әлеге планнарда хезмәт күрсәтү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затларга башкалар белән беррәттән хезмәтләрдән файдалану өчен шартлар булдыру өчен төзекләндерү эшләре алып бару, социаль өлкә хезмәткәрләренең квалификацияләрен арттыру, өлкән яшьтәге гражданнар һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар белән эшләүдә технологияләр куллану, оешмаларның рәсми сайтларында һәм мәгълүмати стендлардагы мәгълүматны вакытында яңартып тору һәм социаль өлкә оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән башка чаралар уздыру каралган.

Гражданнарга бәйсез бәя уздыруда катнашу мөмкинлеге турында хәбәр итү максатларында дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгълүмати-аңлату эшләре алып барыла.

Бәйсез бәя бирү процессын башкару социаль өлкә оешмаларының эш сыйфатын яхшыртуга, иҗтимагый оешмаларны әлеге эшне башкаруга җәлеп итү өчен шартлар булдыруга юнәлтелгән.

## ТУРИЗМ

Татарстан – Россиянең иң эре туристик үзәкләренең берсе, һәм ул ил буйлап традицион рәвештә әйдәп баручы туристлык юнәлешләре унлыгына керә.

2024 ел нәтиҗәләре буенча туристлар агымы, бәяләүләр буенча, 4,4 млн кеше тәшкил иткән. Бу күрсәткеч буенча республика Россия Федерациясе төбәкләре арасында 7 урында һәм Идел буе федераль округында 1 урында тора.

Республикада туризмны үстерүгә түбәндәгеләр ярдәм итә:

үсеш алган туристлык инфраструктурасы: 27 меңнән артык кунакханә номеры, 2 халыкара аэропорт, ике эре М-7 һәм М-12 федераль трассасы һәм башкалар;

күпсанлы истәлекле урыннар, шул исәптән ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасының 4 объекты булу. Татарстан - күрсәтелгән статуста объектлар саны шулкадәр булган Россиянең бердәнбер төбәге;

якты этномәдәни компонент һәм милли гастрономия традицияләренә бай.

Республиканың төп туристлык үзәкләрендә музейларда 8 671,4 мең кеше булды, бу 2023 ел дәрәҗәсеннән 3,6 процентка артты (8 370,9 мең кеше).

**Татарстан Республикасының төп туристлык үзәкләрендә музейларда булу динамикасы, кеше**

| Татарстан Республикасының төп туристлык үзәкләре | 2023 ел | 2024 ел | 2023 елга карата процентларда |
|---|---|---|---|
| «Казанский Кремле» музей-тыюлыгы | 4 518 898 | 4 581 489 | 101,4 |
| «Зөя утрау-шәһәрлеге» музей-тыюлыгы | 1 740 440 | 1 748 861 | 100,5 |
| Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгы | 868 211 | 909 362 | 104,7 |
| Алабуга музей-тыюлыгы | 1 008 029 | 1 134 937 | 112,6 |
| Чистай музей-тыюлыгы | 35 333 | 66 701 | 188,8 |
| Тәтеш крае тарихы музее | 199 989 | 230 007 | 115,0 |

**«Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проекты**

«Туризм һәм кунакчыллык» илкүләм проекты кысаларында 2024 елда Татарстанда «Туристлык инфраструктурасын үстерү» һәм «Идарәне камилләштерү» төбәк проектлары гамәлгә ашырылды, аларны финанслау күләме 306,4 млн сум тәшкил итте (федераль бюджет – 266,0 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты – 40,4 млн сум).

Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча 2023 – 2024 елларда 129 номерга модульле капиталь булмаган урнаштыру чараларын булдыру буенча Татарстан Республикасының 11 проекты хупланды. Бу максатларга 2024 елда 56,8 млн сум бүлеп бирелгән (2023 елда – 113,7 млн сум). Яңа глэмпинглар Татарстан Республикасының Югары Ослан, Биектау, Зеленодольск, Кама Тамагы, Лаеш, Мамадыш, Балык Бистәсе һәм Тукай муниципаль районнарында урнашкан.

Туристлык тармагына ярдәм итү максатында Татарстанга шулай ук 156,0 млн сум күләмендә бердәм субсидия бирелгән (федераль бюджет – 126,4 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты – 29,6 млн сум). Үткәрелгән конкурс сайлап алулары нәтиҗәләре буенча туристлык инфраструктурасын үстерү буенча 79 проект (урнаштыру һәм туристларга күрсәтү объектларында туристлык җиһазлары сатып алу, кемпинг-урнаштыру һәм кемптукталышлар объектларын төзү, капиталь булмаган стационар булмаган причал инфраструктурасын булдыру, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен уңайлы туристик мохитне үстерү) һәм Бөек Болгарда һәм Зөя утрау-шәһәрлегендә вакыйгалы чараларның 2 проекты хупланды.

Шулай ук 2024 елда Россия төбәкләре командаларын «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары һөнәри белем бирү ФДБМУ базасында 2023 елда төзелгән Туристик тармакның кадрлар потенциалын үстерү үзәгендә укыту дәвам итте. Хисап чорында 23 команда укулар узды.

Илкүләм проект кысаларында аерым юнәлеш – Лаеш муниципаль районында «Казан марина» яңа туристлык территориясен булдыру эше. Проектны гамәлгә ашыру «Корпорация Туризм.РФ» АҖ һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында 2022 елның 15 мартындагы төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Проектны гамәлгә ашыру өчен 72,87 гектар мәйданлы җир кишәрлекләре әзерләнгән һәм корпорациянең бүлендек предприятиесенә – «Туризм.РФ Татарстан» ҖЧҖ арендага бирелгән. Яңа туристик территориядә тәэмин итү инфраструктурасын проектлауга һәм төзүгә техник биремнәр эшләнде: керү өчен һәм мәйдан эчендәге юллар, инженерлык челтәрләре, яр буе ныгытмалары, гидротехник корылмалар һәм якын килү өчен суднолар йөри торган канал.

**Туристлык маршрутлары челтәрен үстерү һәм Татарстан Республикасының туристлык продуктын алга җибәрү**

«Бөек Идел юлы» төбәкара проекты кысаларында төбәкара тизйөрешле елга ташулары системасын үстерү дәвам итә. 2024 елгы навигациядә Казан – Чабаксар – Казан, Түбән Новгород – Чабаксар – Казан – Ульяновск, Казан – Сарапул – Казан юнәлешләре буенча маршрутлар эшләде. Күрсәтелгән маршрутлар буенча 13,6 мең пассажир йөртелгән.

Республиканың туристлык потенциалын үстерү өчен 5 халыкара туристлык күргәзмәсендә Visit Tatarstan стендлары оештырылган. Шулай ук Россиянең төрле төбәкләреннән, Дубай шәһәреннән, Маскат шәһәреннән, Эр-Риад шәһәреннән, Шанхай шәһәреннән, Әнкара шәһәреннән 500 туроператор һәм турагентлар өчен Татарстанның турпотенциалын тәкъдир итү булды, Россиядән, Индонезиядән, Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән, Кытайдан һәм Лаостан 185 туристлык компаниясе вәкиле һәм 92 журналист өчен реклама-мәгълүмат турлары уздырылды.

Татарстанның танылуын күтәрү һәм туристларның игътибарын җәлеп итү өчен тышкы реклама чыганакларында 2 реклама кампаниясе эшләтеп җибәрелде, шул исәптән Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләрендә City Sightseeing кызыл ике катлы туристлык автобусларда һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстанда яңа ел ялының 2 реклама кампаниясе.

**Эре халыкара чаралар үткәрү**

Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты тарафыннан 2024 елның октябрендә Казан шәһәрендә узган БРИКС дәүләтләре башлыклары саммитына кунакчыллык өлкәсен әзерләү оештырылды. Саммит алдыннан 14 күмәк урнаштыру чарасы президент номерларын һәм «люкс» категориясе номерларын булдыру буенча ремонт эшләре уздырды.

Саммитны уздыруга әзерлек кысаларында 2024 елның 19–20 сентябрендә Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты профильле ассоциацияләр белән берлектә «Кунакчыллык. Перезагрузка – 2024. БРИКС» махсус белем бирү программасы уздырды. Укуда 1 254 кеше катнашты: кунакханә һәм рестораннарның җитәкчеләре һәм линия персоналы, экскурсоводлар, туроператорлар, музей хезмәткәрләре.

**Волонтерлар хәрәкәте**

Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты «Татарстан Республикасы туристлык волонтерлары ассамблеясе» АКБО белән берлектә ел саен үткәрелә торган «Кунакчыл Казан» проектын гамәлгә ашырды, аның кысаларында республиканың югары белем бирү мәгариф оешмаларының туризм факультетлары студентлары туристларга Татарстанның төп туристлык үзәкләре турында мәгълүмат бирде, ориентлашырга ярдәм итте, шулай ук Казан шәһәре, Бөек Болгар һәм Зөя утрау-шәһәрлегенең өч телдә чыгарылган туристлык карталарын тәкъдим итте.

Проектны уздыру вакытында волонтерларга Россия шәһәрләреннән (Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Түбән Новгород, Самара, Махачкала, Новосибирск һ.б.), шулай ук чит илләрдән (Беларусь, Әрмәнстан, Казахстан, Әзәрбәйҗан, Мисыр, Грузия, Һиндстан, Кытай, Иран, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре һ.б.) 45 мең турист мөрәҗәгать иткән.

**Экскурсоводларны (гидларны), тәрҗемәче гидларны аттестацияләү**

«Экскурсоводларны (гидларны), тәрҗемәче гидларны аттестацияләү» (алга таба – аттестация) дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты тарафыннан «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» 1996 елның 24 ноябрендәге 132-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Экскурсоводларны (гидларны), тәрҗемәче гидларны аттестацияләү турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 7 маендагы 833 номерлы карары нигезендә 2022 елдан башлап күрсәтелә.

2024 елда Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы экскурсовод (гид), тәрҗемәче гидның эш профиленә туры килә торган өлкәдә эш эзләүчеләрдә белем һәм күнекмәләр булуын тикшерү буенча квалификация имтиханы кысаларында аттестация комиссиясенең 19 утырышы узды, аларның нәтиҗәләре буенча аттестация сынауларын 208 экскурсовод уңышлы узды.

Татарстанда барлыгы 440 экскурсовод, шул исәптән татар, инглиз, гарәп, немец, төрек, француз һәм испан телләрен белүче тәрҗемәче гидлар аттестацияләнгән.

# ЭКОЛОГИЯ

## Атмосфера һавасын саклау

Автотранспортның атмосфера һавасы торышына тискәре йогынтысын киметү максатларында 2024 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе һәм Ространснадзорның Идел буе федераль округы буенча төбәкара территориаль идарәсе белән берлектә линиягә чыгарыла торган һәм эксплуатацияләнә торган автотранспорт чараларының эшкәртелгән газларда пычраткыч матдәләр чыгаруларның билгеләнгән нормативларын үтәүне тикшереп тору буенча «Чиста һава» операциясе үткәрелде. Операция кысаларында 6 482 автомашина тикшерелде, шуларның 177 автомашина таләп ителә торган чыгарып ташлау нормативларына туры килмәде.

2024 елда Татарстан Республикасында «Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүенең 2026 елга кадәр исәпләнгән икенче этабы старт алды.

2024 елда 874 автомобиль сатып алынган һәм газ-мотор ягулыгына күчерелгән, бу атмосферага чыгарылмаларны 1,5 мең тоннадан артыкка киметергә мөмкинлек биргән. Программаны гамәлгә ашыру башыннан барлыгы компримирланган табигый газга 14,8 мең автомобиль күчерелгән, бу атмосферага күчмә чыганаклардан зарарлы матдәләр чыгаруны 25,0 мең тоннадан артык киметүгә ирешергә мөмкинлек бирде.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов йөкләмәләре нигезендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы 2014 елдан республика территориясендә чыгарылмаларны һәм парник газларын йотуларны инвентаризацияләү буенча эш алып бара, аның нәтиҗәләре буенча төп тенденцияләр билгеләнде һәм атмосфераны пычратуга иң зур йогынты ясый торган тармаклар билгеләнде. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, парник газларын әйләнә-тирә мохиткә чыгаруга төп өлешне энергетика һәм транспорт тармаклары, химия сәнәгате, авыл хуҗалыгы һәм су бүлү кертә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2030 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планын раслау турында» 2022 ел, 22 декабрь, 1390 нчы карары белән расланган 2022 – 2030 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планының үтәлешен күзәтү алып барыла.

Планда башкаручылары 6 фәнни оешма, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы булган түбән углеродлы сәясәт, фәнни-тикшеренү эшләре алып бару, кадрлар әзерләү буенча 12 чараны гамәлгә ашыру каралган.

2024 ел дәвамында хуҗалык итүче субъектлар белән аларның атмосфера һавасына тискәре йогынтысын киметү максатында планлы эш алып барылды.

**Су объектларын саклау**

Су объектлары чикләрен билгеләү

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслар министрлыгы Россия Федерациясенең су мөнәсәбәтләре өлкәсендәге тапшырылган аерым вәкаләтләре кысаларында Татарстан территориясендә урнашкан су объектларының яр сызыклары (су объекты чикләре), су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе яклау полосалары чикләрен билгеләү эшләрен башкара.

Республикада су объектларының чикләрен билгеләү эше дәвам итә, 15 977,29 км озынлыктагы чикләр билгеләнгән, ягъни республикада урнашкан барлык су объектларының яр буе линияләренең гомуми озынлыгының 37,23%ы, шул исәптән 2024 елда яр сызыкларының озынлыгы 231,13 км булган 6 су объектында чикләр билгеләнгән.

Шулай ук җирлектә су саклау зоналары һәм яр буен саклау полосалары чикләрен 93 данә махсус мәгълүмат билгеләре белән беркетү чаралары уздырылды. Урында билгеләнгән махсус мәгълүмат билгеләренең гомуми саны 1 952 берәмлек тәшкил итә.

Яр буе линияләренең урнашу урынын (су объектлары чикләрен), су саклау зоналары чикләрен һәм су объектларының яр буе саклау полосалары чикләрен билгеләү чаралары территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә җир кишәрлекләрен законсыз бүлеп бирү очракларын, җирләрне үз белдеге белән алу очракларын тулысынча кисәтергә, шулай ук су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә, шул исәптән су саклау зоналары һәм аларның яр буе саклау полосалары чикләрендә табигатьне саклау законнары таләпләрен бозучы хуҗалык субъектларына карата 2001 елның 30 декабрендәге 195-ФЗ номерлы  Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексында каралган административ йогынты чараларын куллану өлешендә, төбәк дәүләт күзәтчелегенең нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Казансу елгасының пычрану чыганакларын бәяләү һәм экологик торышын анализлау буенча фәнни-тикшеренү эшләре

2022 – 2024 елларда Россия Табигать министрлыгы ярдәмендә «ВНИИ Экология» ФДБУ белән үзара хезмәттәшлектә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларына тискәре йогынты ясау сәбәпләрен ачыклау, аларны ранжировка ясау өчен фәнни-тикшеренү эше буенча пилот проект гамәлгә ашырылды, Казансу елгасының сынау су объекты үрнәгендә чаралар комплексын алга таба эшләү белән. Проект кысаларында гидрологик һәм гидрохимик тикшеренүләр комплексы динамикада башкарылды, язгы ташу чорларын да кертеп, пычрану чыганакларына һәм факторларына анализ ясалды, шул исәптән Казансу елгасына биоген йөкләнешнең заманча торышына анализ ясалды, Казансу елгасы бассейнында урнашкан авыл хуҗалыгы предприятиеләреннән диффуз пычрануы чыганаклары анализланды, янәшәдәге сулыкларда табигый су сыйфатын контрольдә тоту өчен тәкъдимнәр эшләнде. Эш нәтиҗәләре буенча түбәндәге чаралар тәкъдим ителде:

су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрендә җирләрне сөрү фактларын төшереп калдыруны, терлекчелек калдыкларын эшкәртүнең алдынгы

технологияләрен гамәлгә кертүне һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан җитештерү һәм куллану калдыкларын (шул исәптән терлекчелек калдыкларын) су саклау зоналары һәм су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрендә урнаштыру (туплау) фактларын булдырмау буенча чаралар үткәрү;

су объектларының торышына тискәре йогынты ясау факторларын юкка чыгару буенча хокук бозучыларга карата чаралар күрү максатында күзәтчелек органнары вәкилләре тарафыннан су саклау зоналарын һәм су объектларының яр буе яклау полосаларын тикшерү;

су объектлары ярлары буенда урнашкан саклагыч урман утыртмаларын реконструкцияләү чараларын үткәрү;

су объектларының су җыю территориясндә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалану һәм аларны төзү кагыйдәләрен эшләү;

эрозиягә каршы чаралар үткәрү;

су объектларын мониторинглауның автоматлаштырылган системасын кертү;

ашламаларның кыенрак эрүчән экологик төрләрен (микробиологик, органоминерал) кулланучы авыл хуҗалыгы предприятиеләренә карата дәүләт ярдәме чараларын кертү мөмкинлеген карау.

«Ирекле ток» проекты

Су объектларының экологик торышын яхшыртуга юнәлтелгән эшләрне дәвам итү максатларында, 2023 елдан башлап Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы Рус география җәмгыятенең Татарстан бүлекчәсе белән берлектә «Ирекле ток» проекты кысаларында Казансу елгасы акваториясендә агач өемнәрен бетерү чаралары тормышка ашырыла. 2024 елда агач өемнәренең 30 урыны тикшерелде, 2 100 кубометр агач (1 500 тонна ауган агач) һәм 320 капчык чүп-чар чыгарылды. Ике ел эчендә 55 өем урыны тикшерелде, 3 800 кубометр агач (2 700 тонна ауган агач), 800 капчык чүп-чар чыгарылды.

Агачлар аз үлчәмле суднолар өчен куркыныч тудыра, балыклар яшәү тирәлегенең табигый шартларын боза, торак пунктлардан елгага керә торган көнкүреш калдыкларының тупланмасы булып тора һәм елганың агым тизлеген киметә, бу исә су агымының ләмләнүенә китерә. Казансу елгасы акваториясен агач өемнәреннән чистарту аны савыктыруга, экологик һәм эстетик хәлен яхшыртуга, су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын яхшыртуга, ташу чорында янәшә территорияләрне су басу куркынычы кимүгә ярдәм итәчәк.

**Җир асты сулары запасларын торгызу**

2024 елның 1 октябренә республика территориясендә расланган эксплуатация запаслары тәүлегенә 2 400,57 мең куб.метр яисә фараз ресурсларының 43,98 % тәшкил итә торган 542 чыганак һәм төче җир асты сулары ятмалары кишәрлекләре тикшерелде. Төче җир асты суларының расланган эксплуатация запасларының гомуми күләменнән геология-гидрогеология өйрәнелеш дәрәҗәсе буенча А категориясенә тәүлеккә 78,903 мең куб.метр, В категориясенә тәүлеккә – 419,948 мең кубометр, С1 категориясенә тәүлеккә – 674,099 мең куб метр, С2 категориясенә тәүлеккә – 1 227,623 мең куб метр керә.

Татарстан Республикасы территориясендәге төче җир асты сулары запасларының гомуми үсеше 2023 елның 1 октябреннән 2024 елның 1 октябренә

кадәрге чорда 10 яңа чыганак һәм чыганак кишәрлекләре буенча тәүлеккә 13,439 мең куб метр тәшкил итте, шул исәптән B категорияләре буенча тәүлеккә – 7,0 мең куб метр, C1 – 6,439 мең куб метр/тәүлек.

**Гомумтаралган файдалы казылмалар**

Татарстан Республикасының минераль-чимал базасын торгызу өчен 2024 елда гомумтаралган файдалы казылмалар запаслары 135,5 млн куб метр күләмендә артты, шул исәптән файдалы казылмалар төрләре буенча: комлы-гравийлы токымнар – 90,73 млн куб метр, төзелеш ташлары (известьташ) – 10,01 млн куб метр, төзелеш комы – 27,54 млн куб метр, комлы-балчыклы токымнар – 5,56 млн куб метр, кирпеч-чирәп чималы – 0,04 млн куб метр, комлык – 1,6 млн куб метр.

Җир асты байлыкларыннан тигез файдалану өчен республиканың гомумтаралган файдалы казылмалар запаслары белән тәэмин ителешен даими тикшереп тору алып барыла. 2025 елның 1 гыйнварына республика территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына 2 132 лицензия гамәлдә булды, шулардан:

204 предприятиегә гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару максатларында 321 лицензия рәсмиләштерелгән. Аларның 119 җир асты байлыклары кишәрлеге елгалар акваторияләрендә, 203 – коры җирдә урнашкан. 75 лицензия туктатып тору хәлендә;

эчәргә яраклы һәм техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмаган җир асты суларын геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару максаты белән 1 808 лицензия төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләргә, бакчачылык ширкәтләренә һәм индивидуаль эшкуарларга рәсмиләштерелде;

3 лицензия файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү максатыннан рәсмиләштерелде.

**Әйләнә-тирә мохит торышын күзәтү буенча территориаль системасын үстерү**

Территориаль әйләнә-тирә мохитне күзәтү системасы кысаларында республика территориясендә атмосфера һавасын пычратуны контрольдә тотуның 17 автоматлаштырылган станциясеннән торган атмосфера һавасын пычратуны күзәтү челтәре булдырылды, ул Казан шәһәрендә – 4, Зеленодольск муниципаль районында (Осиново авылы) – 1, Түбән Кама шәһәрендә – 4, Түбән Кама муниципаль районында (Зур Афанасово авылы) – 1, Чаллы шәһәрендә – 2, Менделеевск шәһәрендә – 1, Алабуга шәһәрендә – 1, Азнакай шәһәрендә – 1, Әлмәт муниципаль районында (Түбән Мактама штп., Кәләй авылы) – 2. 2024 елда атмосфера һавасының пычрануын контрольдә тотуның автоматлаштырылган станцияләре тарафыннан атмосфера һавасында пычраткыч матдәләр концентрациясен 4,3 млн артык үлчәү башкарылган.

Атмосфера һавасын мониторинглау өчен өстәмә 6 күчмә экологик лаборатория файдаланыла: Казан шәһәрендә – 2, Чаллы шәһәрендә – 1, Түбән Кама шәһәрендә – 1, Әлмәт шәһәрендә – 1, Азнакай шәһәрендә – 1. 2024 елда республикада атмосфера һавасының торышын тикшереп тору 105 ноктада гамәлгә

ашырылды.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, республиканың эре сәнәгать предприятиеләре белән мәгълүматлар алмашу турында төзелгән килешүләр кысаларында, атмосфера һавасында пычраткыч матдәләр концентрациясе турында атмосфера һавасының пычрануын күзәтүче В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ, «ТАИФ-НК» АҖ, «ТАНЕКО» АҖ, «Казаноргсинтез» ГАҖ 12 күзәтү станциясеннән мәгълүмат ала.

2024 елда 87 су объектында 204 күзәтү пунктында су объектларының гидрохимик торышын мониторинглау һәм контрольдә тоту үткәрелгән. Су өстендәге объектларының сыйфатын күзәтү кысаларында мәгълүмат «Татарстан Республикасының экологик картасы» дәүләт мәгълүмат системасына интеграцияләнде.

Куйбышев сусаклагычының өске суларына экологик мониторинг үткәрү өчен «Идел-М» судно табигатьне саклау комплексы урнаштырылган «Фламинго» фәнни-тикшеренү судносы кулланыла. 2024 елда судносы тарафыннан республика чикләрендә Куйбышев сусаклагычында тикшерү уздырылган. 1,7 млн артык гидрохимик күрсәткечләр үлчәнде, Идел елгасының өске суларының маршрут мониторингы, биологик чистарту корылмалары чыгарылмалары анализы, пычраткыч матдәләрне читтән тыш күчерү мониторингы гамәлгә ашырылды.

**Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)**

2024 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының территориаль идарәләре тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамаганлыгы һәм аларның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрү зарурлыгы турында 1 440 кисәтү бирелде.

Эшчәнлеге нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохит компонентларына зыян килергә мөмкин булган затларга профилактик һәм кисәтү чаралары комплексын кабул итү максатында профилактик визитлар үткәрү графигы эшләнде һәм расланды, контрольдә тотыла торган зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча профилактик әңгәмә формасында 133 профилактик чара үткәрелде.

Профилактика визиты барышында контрольдә тотыла торган зат аның эшчәнлегенә яисә аның карамагындагы контроль объектларына карата куелган мәҗбүри таләпләр турында хәбәр итә.

2024 елда төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кысаларында табигатьне саклау законнарын бозуның 1 727 очрагы ачыкланган һәм бетерелгән.

Хокук саклау органнары материаллары буенча 2,49 млн сумлык 127 административ штраф салынган, 87 кисәтү чыгарылган, шулай ук 2 телдән кисәтү ясалган.

Әйләнә-тирә мохит компонентларына зыян китерү фактлары буенча 369 дәгъва таләпләре белдерелгән, шуларның 240 ы – ачыкланган хокук бозуларны бетерүгә мәҗбүр итү, 129 ы – 114,7 млн сумлык зыянны каплау турында.

**Табигатьне саклау чараларын финанслау**

«Экология» илкүләм проекты

«Экология» илкүләм проекты кысаларында республикада өч федераль проектны гамәлгә ашыруга 2024 елда 4 007,3 млн сум бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджеттан – 3 258,0 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 749,3 млн сум:

1. «Иделне сәламәтләндерү» федераль проекты буенча – 3 842,0 млн сум, шул исәптән федераль бюджеттан – 3 112,0 млн сум. Проект кысаларында түбәндәге эш башкарылды:

«Идел елгасына чыгарыла торган пычрак агып төшүче сулар өлешен кыскарту» юнәлеше буенча Казан шәһәре канализациясенең биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү эшләре төгәлләнде. Чараны гамәлгә ашыру срогы: 2021 – 2024 еллар. 2024 елда 2 137,3 млн сум бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджеттан – 1 731,2 млн сум;

«Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зарар объектларын бетерү (рекультивацияләү) һәм Идел елгасына куркыныч тудыра торган әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян чыганакларын изоляцияләү» юнәлеше буенча Казан шәһәренең биологик чистарту корылмаларының ләм кырларын рекультивацияләүгә 2024 елда 1 704,7 млн сум бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджеттан – 1 380,8 млн сум. Чараны гамәлгә ашыру срогы: 2021 – 2025 еллар. Чараны төгәлләү 2025 елда «Экологик иминлек» илкүләм проектының «Россия суы» яңа федераль проекты кысаларында каралган.

2. «Чиста ил» федераль проекты буенча 2024 елда Саба муниципаль районының Шәмәрдән авылында Заводская урамында урнашкан нефтьле пычранып бозылган җирләрне рекультивацияләү эшләре төгәлләнде. Чараны гамәлгә ашыру срогы: 2023 – 2024 еллар. 2024 елда 48,3 млн сум бүлеп бирелгән һәм үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджеттан – 29,0 млн сум;

3. «Урманнарны саклау» федераль проекты буенча федераль бюджеттан 117,0 млн сум күләмендә субвенцияләр бүленде һәм үзләштерелде, шул исәптән урман орлыклары запасын булдыру, урман торгызу һәм урман үрчетүне тәэмин итү, урманнарны янгыннардан саклау техникасы һәм җиһазлары белән җиһазландыруга, учреждениеләрне урман торгызу һәм урман үрчетү өчен махсус техника һәм җайланмалар белән җиһазландыруга.

«Табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Россия Федерациясе дәүләт программасы

14 табигатьне саклау чарасын гамәлгә ашыруга 321,3 млн сум акча тотылган (федераль бюджеттан – 200,4 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 120,9 млн сум), шул исәптән:

302,3 млн сум (федераль бюджеттан – 181,4 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 120,9 млн сум) – 9 гидротехник корылманы капиталь ремонтлауны төгәлләүгә: Саба муниципаль районының Мичәнбаш авылы янында, Питрәч муниципаль районының Үшнә поселогы янында, Мамадыш муниципаль районының Сартык авылы янында, Алабуга муниципаль районының Атияз авылы янында, Биектау муниципаль районының Садилово авылы янында, Чистай муниципаль районы Каргалы авылы янында, Зеленодольск муниципаль районының

Бузый авылы янында, Олы Җәке авылы янында, Мулла Иле авылы янында;

19,0 млн сум – су мөнәсәбәтләре өлкәсендә аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга (240,05 км озынлыктагы яр сызыкларының (су объектлары чикләренең) урнашу урынын билгеләү буенча чаралар үткәрелгән; җирлектә су саклау зоналары һәм яр буе яклау полосалары чикләрен 93 данә санда су объектларының махсус мәгълүмат тамгалары белән беркетү; Лаеш муниципаль районының Державин авылында аскы буаны чистарту һәм Зеленодольск муниципаль районының Иваново авылындагы Сумка елгасы үзәнен чистарту эшләре дәвам иткән).

«Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы

2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан 73 табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыруга түбәндәге юнәлешләр буенча 712,4 млн сум акча бүлеп бирелде:

Татарстан Республикасы халкының экологик культурасын формалаштыру буенча 13 чара – 38,6 млн сум;

Су хуҗалыгы комплексын үстерү һәм су басудан һәм суларның башка тискәре йогынтысын яклау һәм Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча 37 чара – 597,8 млн сум (шул исәптән су хуҗалыгы комплексының 9 чарасын финанслашу – 120,9 млн сум);

әйләнә-тирә мохит сыйфатын җайга салу буенча 5 чара – 3,8 млн сум;

радиоактив калдыклар белән эш итү системасында җайга салу буенча чаралар – 1,0 млн сум;

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм минераль-чимал базасын һәм лаборатория тикшеренүләрен торгызу буенча 17 максатчан чара – 71,2 млн сум.

Җирле бюджетлар акчалары исәбеннән табигатьне саклау чараларын финанслау

Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында җирле үзидарә органнары тарафыннан ел саен, 2012 елдан башлап, Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 февралендәге ЙИ-25 номерлы йөкләмәләр исемлеге нигезендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы коллегиясе утырышы йомгаклары буенча экология түләүләреннән керемнәр күләмендә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән табигатьне саклау чаралары гамәлгә ашырыла (әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү, гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруга салым, табигатьне саклау законнары таләпләрен бозган өчен түләтелгән акчалар).

2024 елда табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыруга гомуми суммасы 561,1 млн сум булган 45 килешү төзелгән, шул исәптән 189,1 млн сум – 2023 елның файдаланылмаган калдык акчасы хисабына.

**«Лачын-балобанның Идел-Кама популяциясен торгызу» проекты**

2024 елда «Сибур Холдинг» ГАҖ грант ярдәме белән Лачын-балобанның Идел-Кама популяциясен торгызу проектын гамәлгә ашыру дәвам итте. Кошның оя коруы республикада 1974 елда соңгы тапкыр документлаштырылган. Лачын-балобан реинтродукциясе проектын тормышка ашыруның 2 елы эчендә табигый

яшәү тирәлегенә орнитолог галимнәр һәм волонтерлар күзәтүе астында 16 бала кош табигый яшәү тирәлегенә җайлаштырылган һәм табигатькә чыгарылган. 2024 елда проект кысаларында 4 зур кош пар барлыкка китерү һәм кош балаларын чыгару өчен Казан зооботбакчасы вольерларында урнаштырылган.

Проектны гамәлгә ашыру киләчәктә шундый ук проектларны уздыру өчен тәҗрибә тупларга мөмкинлек бирде, шулай ук Лачын-балобанның Идел-Кама популяциясен торгызу өчен алшартлар тудырды.

Проект фәнни бергәлекнең югары бәясен алды һәм 2023 елда «Ышанычлы партнер – Экология» бөтенроссия конкурсында җиңүче булды, ә 2024 елда – «Бәллүр компас» милли премиясе финалисты.

**Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фондын үстерү**

Махсус сакланыла торган табигать территорияләрен булдыру табигать байлыкларын саклауның һәм арттыруның иң нәтиҗәле механизмы булып тора, бу экологик балансны һәм табигый биотөрлелекне сакларга, шулай ук халыкның тормыш сыйфатының мөһим компонентларының берсе буларак республиканың экологик иминлеген тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Республиканың табигать-тыюлык фонды 464,99 мең гектар гомуми мәйданлы 194 махсус сакланыла торган табигать территорияләрен тәшкил итә, бу – Татарстан Республикасының гомуми мәйданының җиде проценты, монда табигать комплексларын, ландшафтларны һәм биологик төрлелекне саклау һәм торгызу өчен уңай шартлар тәэмин ителде:

Шулардан:

федераль әһәмияттәге 3 махсус сакланыла торган табигать территориясе;

төбәк әһәмиятендәге 187 махсус сакланыла торган табигать территориясе;

җирле әһәмияттәге 4 махсус сакланыла торган табигать территориясе.

Төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен булдыру өчен перспективалы кишәрлекләрне ачыклау максатында ел саен республика территориясендә хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең төр төрлелеген ачыклау буенча фәнни-тикшеренү эшләре алып барыла.

2024 елда Казан (Идел буе) федераль университеты тарафыннан Татарстан Республикасының Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Чирмешән һәм Мамадыш муниципаль районнары территориясендә фәнни-тикшеренү эшләре алып барылды. Эш нәтиҗәләре буенча махсус сакланыла торган табигать территорияләре статусы бирү өчен потенциаль территорияләр буларак кишәрлекләр билгеләнәчәк. Моның белән бергә республика территориясендә моңарчы очрамаган сирәк очрый торган хайван һәм үсемлек төрләренең яңа яшәү урыннары ачыкланды.

Шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының махсус сакланыла торган табигать территорияләре булдыру турында 6 карар проекты барлык кызыксынган министрлыклар һәм ведомстволар белән килештерелде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына карауга җибәрергә әзерләнә:

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә «Шифа» чишмәсе тирәсендә табигать комплексы,

Татарстан Республикасы Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль

районнары территориясендә «Акчарлаклар колонияләре»,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә «Байбаклар колонияләре»,

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә «Зур ак челән оя кору урыны»,

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә «Юеш Көрнәле»,

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә «Сфагново-верховое сазлыгы».

Өстәмә рәвештә 73 су махсус сакланыла торган табигать территорияләре зоналары булдыру турында Татарстан Республикасы Рәисенең 71 указы проектлары эшләнде.

**Урман комплексын үстерү**

Татарстан Республикасы урманнарының гомуми мәйданы – 1 261,3 мең гектар, шул исәптән файдалануга бирелгән урманнар – 304,9 мең гектар (барлык урман фонды территориясенең 24,2%), шулардан 212,8 мең гектар арендага, даими вакыты чикләнмәгән файдалануга – 91,8 мең гектар, түләүсез файдалануга - 0,28 мең гектар бирелгән.

2024 елда 3 223 гектар гомуми мәйданда урман яңартылды, шул исәптән 1 422 гектар мәйданда урман культуралары утыртылды, 104 гектар мәйданда урман утыртылды, 1 252 гектар мәйданда табигый урман торгызу эшләре, 4 гектар мәйданда катнаш урман торгызу эшләре башкарылды, 441 гектар мәйданда компенсацион урман торгызу һәм урман үрчетү үткәрелде. Булдырылган урман культураларын бетүдән саклап калу максатларында 12 880 гектар мәйданда агротехник тәрбия уздырылды, шулай ук 3 893 гектар мәйданда урман культуралары тулыландырылды. 2025 елда 1 409 гектар мәйданда урман культураларын утырту өчен туфрак әзерләнде. 109 гектр мәйданда утыртылганн урман орлыкчылыгы объектларын тиешенчә карау уздырылды. Әлеге эшләрне башкаруга федераль финанслау 2024 елда – 93,8 млн сум.

Янгынга каршы эшләр кысаларында 111,3 км урман юллары төзелде, урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән 426,5 км урман юлы реконструкцияләнде. Минераллаштырылган полосаларны төзү 2 395,2 км озынлыкта башкарылган. 4 806,9 км минераллаштырылган полосаларны карау уздырылды. 3 992 гектар мәйданда урман патологиясен тикшерү үткәрелде. 1 665 гектар мәйданда файдаланылмый торган агач җыештырылды. Урман янгыннары барлыкка килүне һәм таралуны кисәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру, шулай ук аларны сүндерү һәм барлыкка килүен профилактикалау, локальләштерү һәм юкка чыгару гамәлләрен финанслауга 2024 елда 95,4 млн сум акча бүлеп бирелгән.

**Экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы**

2024 елда Татарстан Республикасы экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасын – әйләнә-тирә мохитне саклау һәм җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге бурычларны хәл итү өчен бердәм цифрлы

киңлекне булдыру тәмамланды.

Цифрлы платформа өч функциональ ярдәмче системадан тора – «Җир асты», «Күзәтчелек» һәм «Экомониторинг»:

«Җир асты» ярдәмче системасы товар-транспорт накладнойларын исәпкә алу юлы белән законсыз казылган файдалы казылманы транспортировкалауны булдырмаска, җир асты байлыкларыннан лицензияле файдаланучылар өчен базарның өстәмә күләмен төзергә һәм законсыз табышны нульгә җиткерергә мөмкинлек бирәчәк;

«Экомониторинг» ярдәмче системасы - атмосфера һавасының торышын контрольдә тотуны көчәйтергә һәм аның начарлану фактларына оператив җавап бирергә ярдәм итә. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы инспекторлары автоматлаштырылган режимда мондый артуларның мөмкин булган чыганаклары турында мәгълүмат белән теркәлгән артулар хакында хәбәрләр алачак. Җавап бирү, тискәре йогынты чыганагын эзләү һәм тиешле чаралар күрү вакыты кими;

«Күзәтчелек» ярдәмче системасы – ачыкланган көнендә хокук бозу турында, штраф түләү һәм түләтүләр турында белешмәләр керүне контрольдә тоту. Коррупция куркынычларын булдырмау өлкәсендә дәүләт экология күзәтчелегенең ачыклыгы тәэмин ителәчәк. Моннан тыш, әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянның автоматлаштырылган исәбен үз эченә алган ярдәмче система мәҗбүри мәгълүматларны күрсәтү өлешендә административ материаллар составындагы хаталарны булдырмаска мөмкинлек бирәчәк, ә Федераль суд приставлары хезмәте һәм башка ведомстволар белән каралган интеграция материаллар хәрәкәтен һәм штрафлар керүне контрольдә тотуны тәэмин итәчәк. Ул хокук бозуларга оператив рәвештә җавап бирергә, аларны кисәтергә һәм аларга юл куймаска мөмкинлек бирәчәк, гражданнар мөрәҗәгатьләренең тулылыгын һәм үз вакытында каралывын катгый тикшереп торуны тәэмин итәчәк.

Экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы 2024 елда Россиядә цифрлы икътисад өлкәсендә иң эре чаралар бишлегенә керә торган иң эшлекле чара – «Россия сәнәгатенең цифрлы индустриясе» конференциясендә экологияне цифрлаштыру өлкәсендә иң яхшы проект дип танылды. Ул Россия проектларын һәм мәгълүматлар икътисады өлкәсендәге эшләнмәләрне популярлаштыруга юнәлдерелгән.

2024 елда экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы шулай ук «Өметле партнер – Экология» иң яхшы табигатьне саклау практикаларының VI бөтенроссия конкурсында «Экологияне һәм табигатьтән файдалануны цифрлаштыру өлкәсендә иң яхшы проект» номинациясендә лауреат булды.

«Татарстан Республикасының экологик картасы» геомәгълүмат системасын актив үстерү дәвам итә (https://ecokarta.tatar.ru).

2024 елда халыкның атмосфера һавасы торышы турында мәгълүматлылыгын арттыру максатларында «Атмосфера пычрануын контрольдә тотуның автоматлаштырылган станцияләре» ярдәмче системасына керү мөмкинлеге ачылды, анда атмосфера пычрануын контрольдә тоту станцияләре үлчәмнәре нәтиҗәләре белән реаль вакыт режимында танышырга мөмкин.

Экологик картаның «Яшел стандартлар» ярдәмче системасында калдыкларны аерым туплау пунктларын чагылдыру өчен бүлек булдырылды. Картада төрле төр икенчел чимал кабул итү пунктлары (павильоннар) югары төгәллек белән күрсәтелгән.

## ТӨП ИКЪТИСАДЫЙ КҮРСӘТКЕЧЛӘР

Татарстан Республикасы төп макроикътисадый күрсәткечләр буенча Россия Федерациясе төбәкләре арасында алдынгылыкны саклый: тулаем төбәк продукты күләме буенча – 7 урында, сәнәгать житештерүе буенча – 5 урында, авыл хуҗалыгы продукциясе буенча – 3 урында, төзелеш буенча – 2 урында, төп капиталга инвестицияләр буенча – 6 урында, ваклап сату әйләнеше буенча – 7 урында.

2024 ел нәтиҗәләре буенча тулаем төбәк продукты күләме, бәяләүләр буенча, 5 203,5 млрд сум тәшкил иткән, яки 2023 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 103,9 %.

**2024 елда Татарстан Республикасында тулаем төбәк продукты**




**2024 елда икътисадый эшчәнлек төрләре буенча Татарстан Республикасының ТТП житештерү структурасы (бәяләү), %**



Икътисад структурасында, бәяләүләр буенча, иң зур чагыштырма авырлыкны сәнәгать били – 47,1 % (шул исәптән, файдалы казылмалар чыгару – 25,6 %, эшкәртү производстволары – 19,5 %, электр энергиясе, газ, пар белән тәэмин итү; һаваны кондиционлаштыру – 1,6 %, су белән тәэмин итү; су чыгару, калдыкларны җыю һәм утильләштерүне оештыру, пычрануларны бетерү эшчәнлеге – 0,4 %), авыл хуҗалыгы – 3,9 %, төзелеш – 7,3 %, күпләп һәм ваклап сату – 10,5 %, транспортировка һәм саклау – 5,6 %.

**Сәнәгать**

2024 елда сәнәгать җитештерүе индексы 2023 ел дәрәҗәсенә 105% тәшкил итте, үз көчләре белән җитештерелгән сатылган товар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм хезмәтләр күләме – 5 651,4 млрд сум.

**2024 елда төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр**




Файдалы казылмалар чыгаруда җитештерү индексы 2023 ел дәрәҗәсенә карата 96,8 %, эшкәртү производстволарында – 109,7 %, электр энергиясе, газ, пар, һаваны кондицияләү белән тәэмин итү – 107,7 %, су белән тәэмин итү, су чыгару, калдыклар җыюны һәм утильләштерүне, пычракларны бетерү эшчәнлеген оештыру 107 % тәшкил итте.

Үсеш түбәндәге эшкәртү производстволарында күзәтелә: кокс һәм нефть продуктлары (106,6%), химик матдәләр һәм химик продуктлар (104,7%), резина һәм пластмасса эшләнмәләр (107,4%), дару чаралары һәм медицина максатларында кулланыла торган материаллар (109,8%), автотранспорт чаралары, прицеплар һәм ярымприцеплар (103,5%), машиналар һәм башка төркемнәргә кертелмәгән җиһазлар (138%), башка транспорт чаралары һәм җиһазлары (190,6%), компьютерлар, электрон һәм оптик эшләнмәләр (118,5%), электр җиһазлары (103,2%), металл җитештерүдә (108,8%), башка металл булмаган минераль продукция җитештерүдә

(106,5%), азык-төлек продуктлары (106%), эчемлекләр (101,9%), кәгазьләр һәм кәгазь әйберләр (106,5%), күн һәм күн эшләнмәләр (102,5%), җиһазлар (108,4%), башка әзер эшләнмәләр (112%) җитештерү.

Сәнәгать җитештерүе күләмнәре түбәндәгечә кимегән: агач эшкәртү һәм агачтан һәм бөкедән эшләнмәләр җитештерү (92,5%), әзер металл эшләнмәләр җитештерү, машиналар һәм җиһазлардан тыш (98,5%), тукыма эшләнмәләр (84,8%), кием (83,3%) җитештерү.

Төяп җибәрелгән продукция күләме структурасында файдалы казылмалар чыгару өлеше – 22,3%, эшкәртү производстволары өлеше – 72,9%, азык-төлек продуктлары өлеше – 3,6%, су белән тәэмин итү, су түгү, калдыкларны җыюны һәм утильләштерүне оештыру, пычрануларны бетерү эшчәнлеге өлеше – 1,2%.

**2024 елда төяп җибәрелгән товарлар, башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләме структурасында, %**




## Авыл хуҗалыгы

2024 ел нәтиҗәләре буенча авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 341,3 млрд сум тәшкил итте, яки 2023 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 110,1%.

**2024 елда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме**




3 894,9 мең тонна бөртекле ашлык (эшкәрткәннән соң үлчәүдә), 967,8 мең тонна бәрәңге, 2 655,7 мең тонна шикәр чөгендере, 296,0 мең тонна ачык һәм сакланган грунт яшелчәләре җыеп алынды.

2 281,0 мең тонна сөт савылган, 508,3 мең тонна терлек һәм кош ите (тере үлчәмдә), 1 605,3 млн данә йомырка җитештерелде.

**Төзелеш**

«Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме 2024 ел нәтиҗәләре буенча 908,9 млрд сум тәшкил итте, яки 2023 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 117,6%. Гомуми торак мәйданы 3 452,7 мең кв.метр (2023 ел дәрәҗәсенә карата 100,5%) эксплуатациягә кертелгән.

**2024 елда «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме**




**Кулланучылар базары**

2024 ел нәтиҗәләре буенча ваклап сату әйләнеше 1 611,2 млрд сум тәшкил итте, ягъни 2023 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 107,4%, шул исәптән азык-төлек продуктлары – 713,2 млрд сум (2023 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 103,7%), азык-төлек булмаган товарлар – 898,0 млрд сум (110,4%).

**2024 елда ваклап сату әйләнеше**




Халыкка түләүле хезмәтләр күләме 2024 елда 457,5 млрд сум тәшкил итте (2023 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 104,1%), җәмәгать туклануы әйләнеше – 80,2 млрд сум (108,8%).

## 2024 елда халыкка түләүле хезмәтләр күләме




## 2024 елда җәмәгать туклануы әйләнеше




Куллану бәяләре индексы 2024 елның декабрендә 2023 елның декабренә карата 109,7% тәшкил итте, шул исәптән азык-төлек товарларына – 112,4%, азык-төлек булмаган товарларга – 105,3%, хезмәт күрсәтүләргә – 112,4%.

# СӘНӘГАТЬ

## Нефть һәм газ химиясе комплексы

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ нефть чыгаруның һәм разведканың заманча ысулларын эшләүдә һәм куллануда лидерларның берсе булып тора, альтернатив энергия чыганаклары, экология, җитештерү һәм биотехнологияләр белән идарә итү өчен мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге проектларны уңышлы гамәлгә ашыра.

2024 ел нәтиҗәләре буенча компания углерод берәмлекләре реестрының климат проектлары саны буенча лидер булып тора: парник газларының һавага чыгуын 2,4 млн тонна СО2-экв. күләмендә киметү потенциалы булган 14 проект. .

Углекислый газны файдалы куллану һәм аны кыйммәтле продуктка эшкәртү буенча оптималь технологик чишелешләрне эзләү Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект институты (ТатНИПИнефть) тарафыннан Мәгълүмати технологияләр, механика һәм оптика университетының алдынгы инженер мәктәбе (ИТМО) һәм «ТН-Биотех фәнни-җитештерү берләшмәсе» ҖЧҖ белән берлектә эшләнә.

2024 елда «ТАНЕКО» АҖ нафтаны гидрочистарту куәтен 128% кадәр арттыру һәм некондиция һәм җиңел нефть резервуар паркларында парларны рекуперацияләү җайланмалары урнаштыру проектларында төзү-монтаж эшләре төгәлләнде һәм эшләтеп җибәрү-җайга салу эшләре башланды.

Шулай ук В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ нефть эшкәртү комплексы территориясендә «Яңа материаллар һәм химия» технологик лидерлыгының илкүләм проекты кысаларында өстенлекле чылбыр булып торучы «Параксилол-ТФК-ПЭТФ һәм полиэфир продукциясе» технологик чылбырын җитештерүне оештыру проектын гамәлгә ашыру буенча эш алып барыла.

«СИБУР Холдинг» ГАҖ Татарстанда инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны дәвам итә.

2024 елда «Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ:

ЭП-600 нефть химиясе комплексы төзелеше тәмамланды, аны эшләтеп җибәрү этилен һәм аның эшләнмәләрен җитештерү куәтләрен ике тапкыр арттырачак, киләчәктә Идел нефть химиясе кластерының перспектив производстволарын үстерүне тәэмин итәчәк һәм югары өстәлгән бәяле әзер продукция чыгаруның яңа чылбырларын булдыруга этәргеч булачак.

елына 50 мең тонна егәрлекле гексен-1 җитештерү җайланмасы төзелә, аны эшләтеп җибәрү гексен-1 импортына бәйлелекне киметергә һәм предприятиеләрне база полимерларын, шулай ук премиаль сыйфаттагы полиэтилен җитештерү өчен кискен мөһим чимал белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

«Казаноргсинтез» ГАҖ елына 50 мең тонна куәтле гексен-1 җитештерү проектын гамәлгә ашыра. Күрсәтелгән продукт безнең ил өчен уникаль булып тора. Проектны 2025 елда төгәлләү планлаштырыла.

«Казаноргсинтез» ГАҖ реконструкция төгәлләнде:

түбән басымлы полиэтилен җитештерү һәм эшкәртү заводында «В» реакторын, елга 120 мең тоннадан 220 мең тоннага кадәр җитештерү куәтен арттыру

белән. Барлык 3 линияне (A, B һәм C реакторларын) модернизацияләү нәтиҗәсендә аларның гомуми проект куәте елына 20% ка – 660 мең тоннага кадәр артты, ә продукция ассортименты 3 маркадан алып 10 марка полиэтиленга кадәр киңәйде;

408 нче номерлы Үзәк завод лабораториясе корпусларын, җиһазларны яңартып, нәтиҗәдә бердәм киңлектә предприятие продукциясен җитештерү циклларының барлык этапларында сыйфатны тикшереп тору функцияләре берләштерелде.

2024 елда «СИБУР» ҖЧҖ Түбән Кама шәһәрендә яңа проектларны гамәлгә ашыру буенча инвестицион карарлар кабул итте, шул исәптән:

этилбензол (елга 350 мең тонна), стирол (елга 400 мең тонна) һәм полистирол (елга 250 мең тонна) җитештерү, ул әлеге чылбырның ахыргы продукты булачак;

металл бәя катализаторы базасында полиэтилен производствосын реконструкцияләү (елга 300 мең тонна егәрлекле җитештерүне 2028 елда эшләтеп җибәрү планлаштырылган).

2024 елның февралендә «СИБУР» ҖЧҖ  Казан шәһәрендә заманча НИОКР-үзәк төзелә башлады, ул Россиянең нефть, газ, химия тармагының әйдәп баручы фәнни институты булырга тиеш. Үзәктә яңа катализаторлар һәм инновацион материаллар эшләү проектлары, шулай ук аларны лаборатория эшләнмәләреннән сәнәгать куәтләренә кадәр җәелдерү, 2026 елда объектны файдалануга тапшыру планлаштырылган.

Менделеевск муниципаль районында «Аммоний» АҖ ашламалар җитештерү буенча индустриаль кластер булдыра. Елына 2,95 млн  тонна гомуми суммар куәте булган аммиак һәм карбамид эре тонналы җитештерү буенча «Аммоний 2.0» заводын проектлау эше алып барыла.

«Нәфис Косметикс» АҖ 2024 елда Белоруссиягә, Казахстанга, Үзбәкстанга һәм Төркия Республикасына техник продукция китерү географиясен киңәйтте. «Көнкүреш химиясен һәм техник продукцияне җитештерүне киңәйтү һәм техник яктан яңадан коралландыру» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Sorti Home Фреш маркалы яңа чистарту чарасы, BMAX  спрея форматында тып чистарту чарасы, «Османтус» савыт-саба юу һәм кер юу чаралары, Купажъ ЗБК сериясендә исләндерелгән продуктлар җитештерү эшләтеп җибәрелде.

KAMA TYRES компаниясендә 2024 елда 500 миллионлы шина чыгарылган. Компания «Эре габаритлы шиннар җитештерүне оештыру һәм цельнометаллокорд йөк шиннары җитештерүне арттыру» проектын һәм башка проектларны гамәлгә ашыруны дәвам итә.

Компания тарафыннан серияле җитештерүгә KAMA һәм FORZA цельнометаллокорд йөк  шиннарының яңа модельләре җитештерүгә кертелде. Велосипедлар өчен KAMA VELTA һәм квадроцикллар өчен KAMA QUADRO шиннары ассортименты киңәйтелгән. SUV-класс автомобильләре өчен KAMA FLAME M/T шиннарының бертип үлчәм рәте  һәм KAMA ICE TRACE кышкы җиңел йөк машиналары өчен шиннарының  бертип үлчәм рәте  яңартылды.

«Л.Я.Карпов исемендәге химия заводы» АҖ «Электролизлы хлордан тоз кислотасы җитештерү» инвестиция проектын гамәлгә ашыра.

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ елга 50 мең тонна хлор һәм хлордан эшләнмәләр җитештерү проектын киләчәктә

киңәйтү мөмкинлеге белән гамәлгә ашыра.

Шулай ук полимерлар эшкәртү буенча проектлар гамәлгә ашырыла:

«ДАНАФИЛМЗ» ҖЧҖ – икенчел эшкәртү өчен яраклы яңа буын пленка материаллар җитештерү, 2025 елда эшләтеп җибәрү планлаштырыла;

«АЙ-ФЛЭКС» ҖЧҖ – азык-төлек продукциясе һәм көнкүреш техникасы өчен сыгылмалы төргәк җитештерү, 2025 елда эшләтеп җибәрү планлаштырыла;

«Техстрой» ҖЧҖ – полимер торбалар һәм фитинглар җитештерү, 2026 елга эшләтеп җибәрү планлаштырыла

Татарстан Республикасы Иминлек Советының 2024 елның 16 декабрендәге ПР-248 номерлы беркетмәсе белән 2025 – 2029 елларга Татарстан Республикасының нефть, газ, химия комплексын үстерү программасы расланды. Әлеге Программаның максаты – Татарстан Республикасында функциональ материаллар, урта һәм аз тонналы химия тармагын булдыру, углеводород ресурсларын чыгару һәм эшкәртүнең нәтиҗәлелеген арттырганда чыгарыла торган резин һәм пластмасса эшләнмәләр номенклатурасын киңәйтү.

**Энергетика комплексы**

Республика энергетика системасы Урта Идел берләштерелгән энергетика системасының электр куллану территориаль структурасында иң зурысы булып тора. Анда электр энергиясе җитештерүчеләр арасыннан иң зурлары – «Татэнерго» АҖ, «ТГК-16» АҖ, «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ эшли.

Республикада иң эре электр челтәре оешмасы - «Челтәр компаниясе» АҖ. 2025 елның 1 гыйнварына 11 территориаль челтәр оешмасы эшли.

Республика территориясендә гарантияле тәэмин итүче булып «Татэнергосбыт» АҖ тора.

Татарстан Республикасы энергетика системасының эш режимнары белән оператив-диспетчерлык идарә итү эшчәнлеген «Бердәм энергетика системасының система операторы» АҖ филиалы «Татарстан Республикасы энергосистемасының төбәк диспетчерлык идарәсе» (алга таба – Татарстан ТДИ) башкара.

2024 елда энергетика системасы кулланучыларны ышанычлы һәм куркынычсыз энергия белән тәэмин итте. Татарстан ТДИ мәгълүматлары буенча, 2024 елда бүленгән генерация объектларын исәпкә алып, электр энергиясе җитештерү 31,3 млрд кВт сәг тәшкил иткән (2023 ел дәрәҗәсенә карата 110,8 %) .

Татарстан Республикасының барлык кулланучыларын электр һәм җылылык энергиясе белән ышанычлы тәэмин итү, шулай ук конкурентлык сәләтен арттыру һәм энергетика тармагын тотрыклы үстерүне тәэмин итү өчен энергия системасының җитештерү объектларын модернизацияләү һәм яңа куәтләр кертү беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия.

2024 елда «Татэнерго» АҖ Казан ТЭЦ-2 65 МВт энергияле энергетика пар казанын яңарту эшләре төгәлләнде, «ТГК-16» АҖ Казан ТЭЦ-3 50 МВт энергияле пар турбинасы куәтләрен яңарту буенча эшләр башкарылды.

«Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ Түбән Кама ТЭЦ (ПТК-2) 155 МВт куәтле һәм «Казаноргсинтез» ГАҖ ПГУ-311 МВт куәтле газ турбинасы җайланмасын төзү, шулай ук «ТГК-16» АҖ Түбән Кама ТЭЦ пар турбиналарын модернизацияләү эшләре дәвам итә.

2024 елда «Челтәр компаниясе» АҖ Казанда 110 кВ булган «Водозабор» ЯС һәм «Крыловка» ЯС мөһим ярдәмче станцияләрне реконструкцияләгән, шулай ук Казан энергорайонын электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттыруга юнәлдерелгән югары вольтлы электр тапшыру линияләрен реконструкцияләгән.

Лаеш муниципаль районының һәм якын-тирәдәге районнарның, энергия куллануның актив үсешен исәпкә алып, 110 кВ Сокура яңа ярдәмче станциясе төзелде һәм гамәлгә кертелде.

2024 елда 17 электр энергетикасы объекты реконструкцияләнгән.

«Челтәр компаниясе» АҖ электр челтәре хуҗалыгын модернизацияләү эшен дәвам итә. Гамәлгә ашырылучы төп инвестиция проектлары арасында: 500 кВ Бөгелмә ЯС, 220 кВ Завод ЯС, 110 кВ Шилнә ЯС; 110 кВ Питрәч ЯС, 110 кВ Үзәк - Аэропорт 1, 2 чылбыр ЮВЛ.

Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү

2024 елда энергияне сак тоту программаларының логик дәвамына әверелгән «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» дәүләт программасының «Дәүләт секторында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» процессны чаралар комплексы кысаларында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларын гамәлгә ашыру дәвам итте (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 04 декабрь, 954 нче карары белән расланган).

Татарстанның энергия нәтиҗәлелеге дәрәҗәсен бәяләү максатында муниципаль районнар һәм шәһәр округлары, тармак министрлыклары киселешендә бюджет даирәсенең ирешелгән энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә квартал саен мониторинг кертү тәэмин ителде.

Энергияне сак тотуның дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның мөһим юнәлеше – энергияне нәтиҗәле тотучы проектларны гамәлгә ашыруга бюджеттан тыш финанслауны җәлеп итү. Әлеге юнәлешне гамәлгә ашыру инструментларының берсе – энергия сервисы контракты механизмнарын куллану (алга таба – ЭСК).

2024 елда энергетика ресурсларын куллануны экономияләүгә юнәлдерелгән республиканың сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә 3 бюджет учреждениесе буенча ЭСК төзүгә конкурс процедураларын әзерләү һәм уздыру тәэмин ителде. Төзелгән энергия сервисы контрактларында каралган төп чаралар: автоматлаштырылган индивидуаль җылылык пунктлары, һава җайга салу төеннәре урнаштыру.

Бюджет өлкәсендә төзелгән ЭСК гомуми саны 1 684,3 млн сумга 97 берәмлек тәшкил итә (шул исәптән муниципаль учреждениеләр буенча 67 ЭСК – 1 546,5 млн сумга, дәүләт учреждениеләре буенча 30 ЭСК - 137,8 млн сумга).

Энергияне саклауны популярлаштыру һәм пропагандалау, энергия ресурсларын нәтиҗәле куллануны арттыру, шулай ук «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасы чараларын үтәү максаты белән ел саен энергетика һәм энергия ресурслары нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы уздырыла.

2024 елда аның кысаларында узды:

«TatEnergyExpo» махсуслаштырылган күргәзмәсе, анда Россиянең 17 төбәгеннән һәм 3 төбәк әһәмиятендәге шәһәреннән һәм 2 чит илдән (Беларусия

Республикасы, Казахстан Республикасы) 87 компания катнашты.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «2023 елда «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын тормышка ашыру барышы һәм 2024 елга бурычлар турында» утырышы.

Барлыгы 2024 елның 3 апреленнән 5 апреленә кадәр форум кысаларында энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, ягулык-энергетика комплексын үстерү, энергиянең, водород энергетикасының альтернатив чыганакларын куллану, газ-мотор ягулыгы базарын үстерү, энергетика комплексында цифрлаштыру, электр транспорт чараларын һәм зарядка инфраструктурасын куллану мәсьәләләре буенча 26 чара, шулай ук мәктәп укучылары, студентлар һәм энергетика компанияләре яшьләре катнашында Яшьләр көне үткәрелде.

«Электромобиль и водородлы автомобиль» федераль проекты буенча сынау төбәкләре территориясендә заряд инфраструктурасын үстерү максатларында 2024 елда республикада 40,9 млн сум күләмендә тотылган чыгымнарны каплауга заряд станцияләре операторларына ярдәм чараларын күрсәтеп, 21 заряд станциясе билгеләнде. Республика җитештерүчеләренең «ЭнергоИнновация» ҖЧҖ (E-prom моделе станциясе) һәм «Технопрактика» ИК  ҖЧҖ (Relevant MAX моделе) заряд станцияләре урнаштырылды.

Республиканың 29 муниципаль берәмлегендә пилот  проектын гамәлгә ашыруның өч елында эре шәһәрләрдә һәм торак пунктларда 139 заряд станциясе урнаштырылган, федераль бюджеттан 260,5 млн сум акча җәлеп ителгән.

**Газлаштыру һәм газ белән тәэмин итү**

2024 елда Татарстанда табигый газ куллану тарихи максимумга – 19,0 млрд куб. метрга җитте (2023 елда – 17,65 млрд куб.м).

Газлаштырып бетерү  программасы буенча эш дәвам итә. Бу максатларга «Газпром» ГАҖ акчалары җәлеп ителде – 7,7 млрд сумнан артык. 2024 ел нәтиҗәләре буенча»социаль газлаштыру» программасы буенча  газүткәргеч 29 585 йорт биләмәсенең чикләренә кадәр сузылган, газга 24 046 йорт биләмәсе тоташтырылган.

Инвестиция программасы кысаларында Татарстан Республикасы Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерының (Иннокам) газ-транспорт куәтләрен үстерү максатларында  «Газпром» ГАҖ  Можга-Алабуга газүткәргеченең икенче җепләрен проектлау алып барыла.

Татарстанда газ-мотор ягулыгы базары актив үсеш ала. 2024 ел нәтиҗәләре буенча газ-мотор ягулыгы базарын үстерү дәүләт программасы буенча (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган) 551 транспорт чарасы метанга җиһазландырылган һәм газ-мотор ягулыгында 323 берәмлек транспорт чарасы сатып алынган. Табигый газны кулланучы транспорт чараларының гомуми саны мотор ягулыгы сыйфатында 14,8 мең автомобильдән арткан.

2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ сала торган компрессор станцияләрен төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 18 сентябрь, 789 нчы карары

белән расланган) Татарстанда кирәкле инфраструктура булдырылды:

48 автомобильне газ белән тутыру компрессор станцияләре;

6 криоген автоягулык салу станциясе;

1 күчмә автомобильне газ белән тутыру компрессор станциясе гамәлгә кертелде.

Югарыда күрсәтелгән программалар буенча проектларны гамәлгә ашыруга 2024 елда 71,488 млн сум финансланган, шул исәптән федераль бюджеттан 42,89 млн сум.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү турында» 2023 ел, 11 март, 231 нче карары белән йорт биләмәсе чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазлары сатып алуга тотылган чыгымнар күләмендә, әмма бер йорт биләмәсенә 100 мең сумнан артык булмаган күләмдә газ сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия билгеләнгән, ул бирелә:

Бөек Ватан сугышы ветераннарына, шул исәптән Бөек Ватан сугышы инвалидларына;

сугышчан хәрәкәтләр ветераннарына, шул исәптән хәрби хәрәкәтләр инвалидларына;

һәлак (вафат) булган сугыш инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзаларына;

I һәм II төркем инвалидларына;

инвалид балалары булган гаиләләргә;

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләргә;

җан башына уртача кереме 19 мең сумнан артмаган гаиләләргә;

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашучылар гаиләләренә;

инвалид балаларны караучы затларга.

Югарыда күрсәтелгән субсидияне бирү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. 2024 елда 949 кеше 92,24 млн. сум күләмендә субсидия алганнар.

**Машиналар төзү комплексы**

Тармакның эш йомгаклары, беренче чиратта, «КАМАЗ» ГАҖ күрсәткечләре белән билгеләнә. «КАМАЗ» ГАҖ оешмалары төркеменең бердәм җитештерү комплексы йөк автомобильләре җитештерүнең бөтен технологик циклын үз эченә ала – автотехника һәм автокомпонентлар эшләүдән, әзерләүдән, җыюдан башлап, әзер продукцияне сату һәм сервис белән тәэмин итүгә кадәр.

2024 елда базарга яңа модель чыгарылган – КАМАЗ-54902 (4x2). Яңалык КАМАЗ-54901 популяр йөк машинасының бәясе ягыннан кулайрак аналогы булып тора һәм кыскарак аралыкта йөк ташу өчен эшләнгән.

«Автоҗитештерү реинжиниринглы һәм КАМАЗ автомобильләренең перспектив гаиләсен булдыру» инвестиция проектын гамәлгә ашыру дәвам итә. Шасси детальләре өчен автомобиль заводында яңа катафорез линия эшләтеп җибәрелде.

Үзебезнең ил мәйданчыкларында яңа буын К5 кабинасының өч төрен локализацияләү 100% үзебезнең металл куллану белән тәмамланды.

Сәнәгатьне үстерү фонды ярдәмендә тимерчелек-пресс производствосын үстерү, 13 литр эш күләмендәге Р6 двигателен рәтен җитештерүнең җитештерү куәтләрен киңәйтү, шулай ук барлык КАМАЗ автомобильләре өчен әйдәп баручы күперләрне заманча җитештерү булдыру проектлары гамәлгә ашырыла.

Компаниянең продукт портфелендә ел яңалыкларының берсе – КАМАЗ Вега шәһәр автобусы (КАМАЗ-4280-F5 Вега). Автобусның заманча экстерьеры һәм иркен салоны бар. Арткы подвеска - пневматик, бу техниканы төрле климат шартларында эксплуатацияләргә мөмкинлек бирә.

«КАМАЗ» ГАҖ төрле кулланылыштагы пилотсыз йөк транспорты линейкасы эшләнде. Мисал буларак – автоном режимда карьер эшләре өчен билгеләнгән КАМАЗ-6559 («Юпитер 30») уникаль пилотсыз үзбушаткыч.

2023 елның июненнән «Нева» М-11 федераль трассасы буйлап КАМАЗ пилотсыз магистраль йөк машиналары хәрәкәтен эшләтеп җибәрү булды. Хәзерге вакытта трассада югары автоматлаштырылган 24 КАМАЗ транспорт чарасы файдаланыла. Проект нәтиҗәсендә югары автоматлаштырылган транспорт чаралары паркы белән идарә итү нигезләре һәм пассажирлар йөртү моделе эшләнде.

«ЦФ КАМА» ҖЧҖ мәйданчыгында А1310 эш исеме белән автоматлаштырылган тапшырулар тартмасы прототибы җыелган. Автоматлаштырылган тапшырулар тартмасын роботлаштыру өчен база булып 1310ТО механик тапшырулар тартмасы тора. Автоматлаштыруның барлык блоклары, программа белән тәэмин итүне дә кертеп, Россиядә җитештерелә. Бу илебез автоҗитештерүчеләренә үз продукцияләрен локальләштерү дәрәҗәсен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

СОЛЛЕРС компаниясе республикада проектларны гамәлгә ашыруны дәвам итә. Үзенең иң югары технологияле җитештерү мәйданчыкларының берсе – «Алабуга» махсус икътисадый зонасында заводта компания тулы цикл буенча Sollers Atlant җиңел коммерция автомобильләре һәм дизель двигательләре җитештерә.

2024 ел йомгаклары буенча «СОЛЛЕРС Алабуга» ҖЧҖ җитештерелгән автомобильләр күләмен 2023 елга карата 22 % арттырды. Sollers линейкасы автомобильләре өчен дизель двигательләре җитештерү үсә.

Төп детальләрне – Россия чималыннан эшләнгән цилиндр блогын, цилиндрның блогы башын һәм коленвалны коюны һәм механик эшкәртүне күздә тоткан двигательләрне локальләштерү процессы актив бара. Сәнәгатьне үстерү фондының 1,7 млрд сум заем акчаларын да кертеп, проектка инвестицияләрнең гомуми күләме 2,2 млрд сум тәшкил итә. Предприятиенең максималь егәрлеге – елына 50 мең двигатель.

Шулай ук республиканың штамповкалау җитештерүчесе белән берлектә Сәнәгатьне үстерү фонды ярдәмендә гамәлгә ашырыла торган Sollers Atlant һәм Sollers Argo автомобильләре өчен Россия чималыннан штамповкалана торган кузов детальләре җитештерү проекты тәмамланып килә. Инвестицияләрнең гомуми күләме – 4,3 млрд сум, шул исәптән ташламалы заем - 3,4 млрд сум.

«РИАТ» ААҖ газ һәм нефть чыгаруны интенсификацияләү өчен техника

импортын алыштыруда катнаша. Пластның гидравлик аермасы флотының 7 тип агрегаты өчен «РИАТ» ААҖ төрле тәгәрмәч формулаларның үзебезнең махсус шассиларын эшләде.

«Раритэк» компаниясе 2024 елда LOTOS йөк автомобильләре линейкасын тәкъдим итте. Модель рәте тулы массасы 10 тонналы JUNIOR автомобильләрен, тулы массасы 12 һәм 18 тонналы KADET һәм TITAN автомобильләрен үз эченә ала. LOTOS бренды үсешенең яңа тармагы – шулай ук табигый газда эшли торган төрле йөк күтәрүче йөк машиналары җитештерү.

«АЗ РариТЭК» ҖЧҖ җитештерә торган автобусларның модель рәтләрен киңәйтү өстендә актив эшли. LOTOS шәһәр автобусын базарга чыгаруның уңышлы тәҗрибәсе автобусның шәһәр яны версиясен булдыруга этәрде, шулай ук базарга «LOTOS NEON» яңа 12 метрлы шәһәр автобусын тәкъдим итәргә мөмкинлек бирде.

«Алабуга аккумулятор заводы» ҖЧҖ су ванналарында батарея формалаштыру өчен технологик җиһазлар эшләтеп җибәрде, EFB технологиясе буенча йөк батареялары җитештерә башлады. Электрод рәшәткәнең коррозиягә каршы торучанлыгын күтәрү һәм стартер пластиналарын җитештерү линиясенең җитештерүчәнлеген арттыру өчен завод үзебезнең җиһазларны сатып алды.

«ТПК МТЗ-Татарстан» ҖЧҖ «Беларус» 1221GT (136 л.с.) һәм 2022GT (212 л.с.) газ тракторлары җитештерә башлады, алар компримирлаштырылган һәм сыеклаңдырылган табигый газда уңышлы эшлиләр. Тракторлар сертификация сынауларын уңышлы үтте һәм туры килү сертификатларын алды. Тракторларны локальләштерү эше дәвам итә. Үзләре җитештергән гидроборылыш катламнарының ассортименты киңәйтелгән һәм төягечләр өчен алмаш чүмечләр җитештерү башланды. Россия Федерациясе территориясендә универсаль юл-коммуналь машиналарның дүрт моделен сәнәгать продукциясе җитештерүне раслау турында йомгак алынды.

«Казаньсельмаш» ҖЧҖ продукциянең билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максаты белән сату алды әзерлеген һәм чыгу контролен гамәлгә ашыру өчен 1,4 мең кв. метр мәйданлы җитештерү-саклау бинасын файдалануга тапшырды. Шулай ук компания сынауларны тәмамлады, КСМ-600 үзәктән куу насосын күпләп җитештерүне теркәде һәм эшләтеп җибәрде (прицеплы һәм үзйөрешле сиптергечләрдщ сиптерүнең төп системасы өчен). МРП-18 радиаль-поршеньлы гидромоторларны үзебездә җитештерүне эшләтеп җибәрде.

«Агромастер» ҖЧҖ соңгы елларда 100 берәмлектән артык заманча җиһазлар сатып алган: лазер, плазма җиһазлары, санлы программа белән идарә ителә торган станоклар, гильотиналар, листогиблар, тасма, пробивлы, бораулау, шомарту, галт, электроэрозион станоклар, эретеп ябыштыру автоматлары. Хәзерге вакытта «Agrator Disk» чәчү комплексы һәм «Tillermaster» культиваторы тулысынча цифрлаштырылган. Барлык өлешләр дә санлы программа белән идарә ителә торган станокларда әзерләнә, детальләрне кисү лазер җиһазларында башкарыла.

2024 елда завод вариаторлар җитештерү буенча яңа цех эшләтеп җибәрде, гидроцилиндрлар җитештерү җайга салынды. Импортны алыштыру программасы кысаларында шакмаклар, подшипник корпуслар, стойкалар, лапалар, шнеклар, икеле вентиляторлар җитештерү үзләштерелде.

«ЕЛАЗ» ҖБ АҖ нефть һәм газ скважиналарын ремонтлау һәм үзләштерү өчен

күтәртү агрегатларын серияләп җитештерүгә кереште.

ELAZ BL 880 һәм ELAZ BL 888 экскаватор-төяүчеләрен Россиядә җитештерелгән тапшыру тартмасы белән җыю башланды. 14 тонна йөк күтәрешле G-14 «җиңел» автогрейдерның сынау үрнәге эшләнде.

«Хайер Индастри Рус» ҖЧҖ 2024 елның ноябрендә Татарстанда электр су җылыткычлары җитештерү буенча яңа завод ачты, анда соңгы буын автоматлаштырылган җиһазлар урнаштырылган. Киң ассортимент стандарт һәм суперкомпактлы формадагы, 10 литрдан алып 100 литрга кадәр күләмле, электр җылыту элементларының киң диапазонлы куәтле су җылыткычларын үз эченә алачак.

ICL компанияләр төркеме радиоэлектрон продукция җитештерүне уңышлы үстерә, Россия ваклап сату техникасы базары өчен билгеләнгән OSiO яңа бренды эшли башлады. Үз материнская платаларын җитештерү заводы исәпләү техникасының 200дән артык төрен чыгарырга мөмкинлек бирәчәк. Серверлар, мәгълүматлар саклау системалары, шәхси компьютерлар, моноблоклар, ноутбуклар, планшетлар кебек әзер эшләнмәләр җитештерү куәте һәм алар нигезендә карарлар елына 1 млн җайланмага исәпләнгән.

«Казанькомпрессормаш» АҖ заказчының индивидуаль ихтыяҗларына һәм техник прогресс дәрәҗәсенә җавап бирә торган уникаль һәм көндәшлеккә сәләтле компрессор җайланмалар төзи.

Зеленодольск шәһәрендә төзелә торган СПГ эре тонналы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы катнаш хладагентлы компрессор агрегатлары – СПГ җитештерү буенча заводның эре тонналы технологик җиһазларының төп төрен, шулай ук газ һәм нефть эшкәртүнең, нефть химиясе һәм химиянең башка технологияләре өчен югары куәтле компрессорлар җитештерү һәм сынаулар өчен билгеләнгән.

«Эйдос» ҖЧҖ Lisa ALS өлкән пациент симуляторын серияле җитештерүгә кереште.

«Кукмара металл савыт-саба заводы» АҖ Үзбәкстан Республикасында «Ангрен» ирекле икътисадый зонасы территориясендә штамп алюминий савыт-саба җитештерү заводы төзелеше» инвестиция проектын, шулай ук «Кукмара металл савыт-саба заводы» АҖ территориясендә икенче җитештерү комплексын төзү», «3 нче өслек ясау цехы бинасын төзү» проектларын гамәлгә ашыруны дәвам итә.

2024 елда «ИНКОМСИСТЕМ» НИЦ сәнәгатьнең төрле тармакларының технологик процессларын автоматлаштыру системалары өчен билгеләнгән микропроцессор электроника базасында «АБАК» ПЛК югары технологияле җиһазлар җитештерүне киңәйтү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыра башлады. Проект «Химград» технополисы территориясендә 2,8 мең кв. метр мәйданлы аерым корпус төзүне күздә тота.

2024 ел йомгаклары буенча «Аккурайд Уилз Руссиа» ҖЧҖ җитештерү күләмен 2023 ел белән чагыштырганда 20 % арттырды. Яңа продукцияне үзләштерү өчен дисклар тәгәрәтү линиясе сатып алынган.

2024 елның апрелендә «Татлифт» ҖЧҖ лифт җиһазлары җитештерү заводын ачу тантанасы булды. Компания 400 дән 2 500 кг кадәр йөк күтәрү мөмкинлеге белән барлык төр зурлыктагы һәм төрле типтагы компоновка һәм кабиналар купесы

дизайны вариантлары белән лифт җайланмасы җитештерә. Предприятие эшли башлаганнан бирле 300  артык лифт эшләгән.

«Туполев» АҖ филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводында 2024 елның көзендә оча торган лаборатория сыйфатында кулланыла торган Ту-214 самолетында яңа Россия комплектлаучылары белән очу сынаулары программасы башланды. 2024 ел ахырында яңартылган Ту-214 һавага күтәрелде.

«Казан вертолет заводы» АҖ Ансат вертолетын яңартуны дәвам итә. Үзебездә җитештерелгән двигательлә  белән Ансат вертолетының җәйге сынауларына әзерлек бара. Ансат демонстраторы тулысынча импортны алыштыру кыяфәтендә беренче тапкыр «Армия-2024» форумы кысаларында тәкъдим ителде. Вертолетның идарә системалары һәм автопилоты үзебезнекеләргә алыштырылган, Россиядә җитештерелгән  двигательләр урнаштырылган.

2024 елда «Казан вертолет заводы» АҖ яңа җитештерү-уку үзәге эшли башлады – республика предприятиеләре һәм башка төбәкләр өчен киң профильле эшчеләрне әзерләү һәм яңадан әзерләү буенча уникаль проект.

«А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы» АҖ  2024 елда Татарстан Республикасы өчен 03830 «Метеор - 2020» проектының су асты канатларында ике тизйөрешле пассажир судносына нигез салу тантанасы булды, шулай ук 21631 «Ставрополь» проектының кече ракета корабле, 00393 проектының водород ягулыгында эшләүче һава юлы-экскурсия судносы суга төшерелде.

«Серго исемендәге завод» ҖБ» АҖ (POZIS) «Ростех» ДК  көнкүреш суыткыч техникасы җитештерүче бердәнбер предприятие булып тора. Предприятие Россиядә суыткыч техникасын эре җитештерүчеләрнең беренче җиделегенә керә.  Соңгы елларда базарга ХИТ-140 икор суыткычлары, ЗИЛ-77-1 камералы һәм шәраб суыткычлары, BENOIT (Бенуа) бренды астындагы суыткыч приборлар һәм автосуыткычлар, 2024 елда - микрояшеллекләр үстерү өчен көнкүреш культиваторы чыгарылган.

«Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» АҖ Россиянең эре нефть-газ компанияләре – «Новатэк» ГАҖ һәм «Газпромнефть» ГАҖ белән хезмәттәшлекне үстерүне дәвам итә. Көнчыгыш Себердә иң эре Чон кластеры ятмалары кишәрлекләре төркемен төзекләндерү өчен «Газпромнефть» ГАҖ белән «КМПО» АҖ двигательләре белән «Волга» газ суырту агрегатларын китерү шартнамәләре төзелде.

**Урман эшкәртү сәнәгате**

«С.П. Титов исемендәге Чаллы картон-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» ХЯАҖ 2024 елның сентябрендә икеләтә нәтиҗәле автоматлаштырылган склад өчен Emmepi яңа транспорт линиясе эшли башлады. Яңа линиянең җитештерүчәнлеге керү зонасында – 280 транспорт пакет/сәгать, автоматлаштырылган складка тапшыру зонасында – 140 икеләтелгән транспорт пакет/сәгать тәшкил итте.

«С.П. Титов исемендәге Чаллы картон-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» ХЯАҖ – роботлаштыру дәрәҗәсе буенча лидерларның берсе – бер роботка 28 хезмәткәр туры килә. Комбинатта барлыгы 58 автоматлаштырылган система эшли: 15 робот-манипулятор һәм 20дән артык линияле робот. Моннан тыш,

җитештерүгә 20 артык роботлаштырылган транспорт арбасы, 4 роботлаштырылган кран-штабелер, шулай ук әзер продукцияне паллетларга куя торган 4 робот җәлеп ителгән.

«Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ Россия Федерациясендә «Алабуга» МИЗ үз производствосы булган агач эшкәртү тармагының танылган лидеры булып тора.

2024 ел Kastamonu өчен актив үсеш вакыты булды. Компания 60тан артык чара оештырды, шул исәптән Алабуга шәһәрендәге заводта 30дан артык дилерлык экскурсиясе, алар партнерлар белән хезмәттәшлекне ныгытуга һәм үз продуктларын, беренче чиратта Evogloss, Evosoft, Acrymat һәм Acrylic декоратив панельләрен, шулай ук Floorpan һәм La Moena идән өслекләрен алга җибәрүгә юнәлдерелгән.

«Татарстан агач эшкәртү комбинаты» ҖЧҖ продукциянең ассортиментын һәм сату географиясен киңәйтү эшен дәвам итә. Предприятиедә республика хакимият органнары белән берлектә каен утыртмалары мәйданнарын арттыру һәм еллык исәп-хисап урман кисүне үзләштерү өлешен арттыру юлы белән агач эшкәртү предприятиеләре өчен чимал базасын киңәйтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру буенча эш алып барыла.

«Драйлок Технолоджиз» ҖЧҖ 2024 елның I кварталында компаниянең логистик һәм җитештерү куәтләрен киңәйтү буенча проект старт алды: 15 мең кв. метр мәйданлы склад бинасы төзү һәм яңа югары технологияле җитештерү линиясен сатып алу. 2024 елның декабрендә проектны гамәлгә ашыру тәмамланды. Склад бинасын файдалануга кертү 2025 елның июленә планлаштырылган.

«Хәят Кимья» ҖЧҖ 2024 елда елына 1 800 тоннага яңа салфетка линиясе эшли башлады.

**Җиңел сәнәгать**

«Завод Эластик» ҖЧҖ сәнәгатьнең төрле тармаклары өчен (шул исәптән медицина, авыл хуҗалыгы, төзелеш, автомобиль төзелеше һ.б.) продукция җитештерә. 2024 елда, алдынгы технологияләр белән җиһазландырылган спанбондтан бер тапкыр кулланыла торган медицина чүпрәкләрен һәм SMS материалын индивидуаль кушу өчен яңа заманча машина урнаштырылган. Җитештерү күләме 15 тонна/айга тәшкил итә.

«БАРС аяк киеме компаниясе» ҖЧҖ – Россиянең иң эре махсуслаштырылган аяк киеме җитештерүчеләрнең берсе. Полиуретаннан инновацион аяк киеме ясау буенча яңа цех эшли башлады. Инвестицияләр 200 млн сумга якын тәшкил итте.

«Бросско» тегү фабрикасы Татарстанның һәм Россиядәге башка төбәкләрнең 150 дән артык уку йорты өчен укучыларга һәм укытучыларга, шулай ук «Бросско» корпоратив киемнәргә заказ бирүче зур һәм кече предприятиеләр өчен форма җитештерә. 2024 елда җитештерү күләме 26% арткан, сату күләме 25% арткан.

«Бросско» компаниясе ел саен үткәрелә торган «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» акциясендә катнаша. 2024 елда Татарстан мәктәпләре укучыларына 800 мең сумлык ярдәм күрсәтелгән.

**Эчемлекләр җитештерү**

«Татспиртпром» АҖ – Россия Федерациясендә иң эре алкоголь

компанияләренең берсе. Предприятие 44 мең декалитр күләмендә яңа виски дистилляты җитештерә башлады.

2024 елның июнендә «Татспиртпром» АҖ алкоголь продукциясен Перуга Corporacion Kajatt Vaccari партнеры адресына китерү башланды. Төяп җибәрелгән продукция составына Tundra флагман бренды аракысы һәм биттерлары, Graf Ledoff миллионлы бренды аракысы һәм төнәтмәсе, «Ханская» аракысы, шулай ук Royal Raven джиннары линейкасы керде.

**«Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты**

2019 – 2024 елларда республикада «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проектын гамәлгә ашыру ике төбәк проекты кысаларында тормышка ашырылды:

«Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча системалы чаралар», ул гомуми оештыру чараларын күздә тота һәм илкүләм проектта катнашучы предприятиеләргә ярдәм итү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелә («Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» сәнәгатьне үстерү фонды программасы буенча ташламалы заем, «Җитештерү лидерлары» идарә кадрларын әзерләү программасы буенча уку, «Экспорт үсеше акселераторы», ел саен үткәрелә торган остазлыкның иң яхшы практикалары конкурсы, «Нәтиҗәлелек.рф» цифрлы карарлар платформасы;

«Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү», аның кысаларында хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендә компетенцияләрнең төбәк үзәге икътисадның чимал булмаган тармаклары предприятиеләрендә «сакчыл җитештерү» технологияләрен гамәлгә кертү, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең иң яхшы тәҗрибәләрен популярлаштыру, хезмәткәрләрне укыту буенча эш алып бара.

«Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре:

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән килешүләр төзеп, 264 предприятие проектта катнаша (план күрсәткече – 257 предприятие);

проектта катнашучы предприятиеләрнең 4 960 хезмәткәре һәм төбәк хакимият органнары вәкилләре хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру инструментларына өйрәтелгән (план күрсәткече – 4 155 кеше);

2019-2024 елларда проектта катнашучы 89 предприятиенең 532 вәкиле «Җитештерү лидерлары» идарә кадрларын укыту программасы узды;

проектта катнашучы предприятиеләрдән 59 команда «Экспорт үсеше акселераторы» экспорт потенциалын үстерү программасын узып, компетенцияләрен күтәрде;

илкүәм проектта катнашучы 15 предприятие «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» программасы буенча проектларны гамәлгә ашыруга еллык 3 – 5% ставка белән 5 елга кадәр срокка 3 210,1 млн сум күләмендә заемнар алды.

2024 елда «Остазлыкның иң яхшы практикалары» конкурсының төбәк этабы үткәрелде. Түбәндәге номинацияләрдә җиңүчеләр дип танылды: «Яшьләрне һөнәри үстерү» - «ПОЗиС» АҖ; «Предприятиедә цифрлы инновацияләр» - «Август Алабуга» ҖЧҖ; «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча остазлыкның иң яхшы практикалары» - «Татэнерго - Зәй ГРЭС» АҖ филиалы.

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2024 ел нәтиҗәләре буенча илкүләм проектны гамәлгә ашыру буенча башлангыч рейтингы нигезендә

Татарстан 2 урында тора.

Татарстан икътисадының чимал булмаган тармаклары предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру программалары чараларын үтәүче булып «Татарстан Республикасының Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге үзәге» ДАУ базасында төзелгән Татарстан Республикасының хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендә төбәк компетенцияләр үзәге тора.

2024 елда төбәк үзәге «Федераль компетенцияләр үзәге» АКБО һәм Россия Икътисади үсеш министрлыгы сертификациясен уңышлы үтте. Ул тотрыклы рәвештә Россиянең төбәк компетенцияләр үзәкләре рейтингында иң яхшылар бишлегенә керә (2024 ел нәтиҗәләре буенча илнең төбәк үзәкләре арасында беренче урында тора).

**«Халыкара кооперация һәм экспорт» илкүләм проекты**

«Халыкара кооперация һәм экспорт» илкүләм проекты кысаларында «Татарстан Республикасында халыкара кооперацияне һәм экспортны үстерү буенча системалы чаралар» төбәк проекты гамәлгә ашырылды. Экспортка ярдәм итүгә юнәлтелгән федераль һәм төбәк дәрәҗәсендәге институтлар булдырылды, Төбәк экспорт стандарты 2.0 эшләнде. Федераль проектның паспорты нигезендә 2024 елда аның 13 инструменты гамәлгә кертелгән.

Илкүләм максатларга һәм максатчан параметрларга ирешүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 2 ноябрь, 956 нчы карары белән 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясе расланды.

Илкүләм проектны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм «Россия экспорт үзәге» АҖ (алга таба – Россия экспорт үзәге) белән хезмәттәшлек итә. Татарстан предприятиеләре Россия экспорт үзәге, «Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фонды» коммерцияле булмаган микрокредит компаниясенең экспортны яклау үзәге (алга таба – Экспортка ярдәм үзәге), Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аша ярдәм, шул исәптән финанс ярдәме ала ала.

Россия экспорт үзәге һәм Экспортка ярдәм үзәге экспорт эшчәнлеген үстерүдә булышлык һәм предприятиеләргә тышкы базарларга чыгуның барлык этапларында ярдәм күрсәтә. 2024 елда республика экспортерлары өчен иң кирәкле ярдәм чаралары булып түбәндәгеләр торган:

сәнәгать продукциясен транспортлауга чыгымнарны компенсацияләү (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәнәгать продукциясен транспортлауга чыгымнарны компенсацияләү максатларында Россия сәнәгать оешмаларына дәүләт ярдәме турында» 2022 елның 28 июлендәге 1347 номерлы карары);

конкурентлыкка сәләтлелекне арттыру буенча корпоратив программаларны гамәлгә ашыручы сәнәгать предприятиеләренә дәүләт ярдәме (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Конкурентлык сәләтен үстерүнең корпоратив программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларга дәүләт ярдәме турында һәм «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясенә Россия Федерациясенең мөлкәти взносы рәвешендәге субсидия бирү кагыйдәләренә югары технологияле продукция җитештерүгә ярдәм итүгә бәйле

чыгымнар өлешен каплауга кертү хакында» 2019 елның 23 февралендәге 191 нче карары);

авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек продукциясен транспортировкалауга чыгымнар өлешен компенсацияләү (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек продукциясен транспортлауга чыгымнар өлешен компенсацияләү өчен Россия оешмаларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 1104 номерлы карары).

# АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫ

Гомумән алганда, илнең 2% авыл хуҗалыгы җирләренә ия булган республика авыл хуҗалыгы продукциясенең 3,5% ен җитештерә.

Авыл хуҗалыгы республика халкын үзенең сыйфатлы продукциясенең төп төрләре белән тулысынчы тәэмин итә.

Катлаулы һава шартларына (язгы кыраулар һәм бөртеклеләр чәчәк аткан чорда эссе һава шартлары) карамастан, республика аграрийлары тарафыннан 3 894,9 мең тонна ашлык суктырылган (эшкәрткәннән соң үлчәүдә).

Төп техник культура шикәр чөгендеренең тулаем җыемы 2 651,8 мең тонна тәшкил итте. 296,0 мең тонна яшелчә, 967,8 мең тонна бәрәңге җыеп алынган.

Республика Россия төбәкләре арасында сөт җитештерү буенча 1 урында, бәрәңге җыю буенча 2 урында тора, шулай ук терлек һәм кош ите, йомырка, шикәр чөгендере һәм ашлык җитештерү буенча беренче унлыкка керә.

Республикада 2025 ел уңышына нигез әзерләнгән:

1,6 млн гектар мәйдан туфракта төп эшкәртү эшләре үткәрелде;

485 мең гектар мәйданда уҗым культуралары чәчелде, аларның торышына мониторинг уздырыла.

Кайтартыла торган орлыклар белән тәэмин итүгә контрактлар төзү эше алып барыла.

Бүгенге көндә бөртекле, кузаклы культуралар орлыклары белән тәэмин ителеш ихтыяҗның 123% тәшкил итә. Сатып алынган орлыкларны кайтару дәвам итә. Орлыклар сатып алуга төзелгән контрактларны исәпкә алып, кукуруз буенча тәэмин ителеш 72 %, шикәр чөгендере – 91 %, көнбагыш – 75 %.

Федераль һәм төбәк программалары кысаларында 2024 елда 48 берәмлек су сиптерү машинасы сатып алынган, үсемлекчелек һәм терлекчелек объектларын су белән тәэмин итү өчен 20 скважина бораулаган.

Халыкны үзләре җитештергән продукция белән тәэмин итү максатларында 2024 елда 206 гектар яңа җимеш һәм җиләк-җимеш үсентеләре салынган.

2024 ел уңышы өчен 692 мең гектар чәчүлек иминиятләштерелгән, бу 2023 елга караганда 22% артык.

Республика үзен терлекчелек продукциясе белән тулысынча тәэмин итә.

Татарстан Республикасында илдәге иң эре мөгезле терлекләр саны (2024 ел йомгаклары буенча 854,9 мең баш, шул исәптән 316,9 мең баш сыер).

2024 елда барлык төр хуҗалыклар буенча сөт саву 2 281,0 мең тонна тәшкил итте (2023 елга карата 103,9 %), 508,3 мең тонна терлек һәм кош ите (99 %), 1 605,3 млн данә йомырка (102,7 %) җитештерелде.

Тармакны алга таба үстерү максатларында терлекчелек фермаларын һәм комплексларын төзү буенча эш дәвам итә. 8,6 мең башка исәпләнгән 6 сөтчелек комплексы файдалануга тапшырылган. 19,7 мең баш эре мөгезле терлеккә исәпләнгән 6 инвестиция проекты гамәлгә ашыруның төрле стадияләрендә тора.

Терлекләрне азык белән тәэмин итү өстенлекле бурыч булып кала. Республикада азык үзәкләре төзү дәвам итә. Хәзерге вакытта 53 үзәк кулланыла, алар 23 муниципаль районда 189 мең баштан артык эре мөгезле терлеккә хезмәт күрсәтә.

2024 елда 15,5 мең башка исәпләнгән 6 терлек азыгы үзәге сафка бастырылды. Хәзерге вакытта 4 азык үзәге төзелә.

Терлекләрне идентификацияләүнең бердәм системасы, көтү һәм ашату белән идарә итү программасы актив рәвештә гамәлгә кертелә. Бүгенге көндә республиканың 188 авыл хуҗалыгы оешмасы цифрлы системалар белән эшли, аларда 162 мең баш сыер исәпләнә.

Күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2024 елда республиканың авыл хуҗалыгы оешмаларында сыерларның уртача еллык продуктивлыгы 1 сыерга 8,3 тонна тәшкил итте (2023 елга карата 106,4 %).

**Техник модернизацияләү**

Машина-трактор паркы яңартыла. 2024 елда хуҗалыклар 530 трактор, 113 ашлык җыю комбайны, 45 азык җыю комбайны һәм 12,1 млрд сумлык 2 596 берәмлек башка техника сатып алганнар.

Республика Россия төбәкләре арасында инвестиция чыгымнары һәм сатып алынган техника саны буенча алдынгы урыннарны алып тора.

Тармак предприятиеләре өчен «Авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү» республика программасы зур стимул булып тора, ул сатып алынган техника бәясенең 30 % субсидияләүне һәм «Росагролизинг» АҖ ташламалы лизинг продуктларын күздә тота.

Ярдәмнең стимуллаштыручы чаралары 100 гектар чәчүлеккә энергия белән тәэмин ителешне 185 л.с. кадәр арттырырга мөмкинлек бирде.

**Хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү**

Республикада хуҗалык итүнең кече формалары актив үсә. 2024 елда бу максатларга 2,2 млрд сум күләмендә дәүләт ярдәме бүлеп бирелгән.

Ярдәмнең иң мөһим юнәлешләре – фермерларга һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына грантлар. Гаилә фермаларын үстерүгә (проектның гомуми суммасыннан үз акчаларын кимендә 40% керткән очракта) 30 млн сумга кадәр (1 фермерга) – эре мөгезле терлекләрнең сөт һәм ит юнәлеше буенча, башка юнәлешләр буенча – 20 млн сумга кадәр, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерүгә 70 млн сумга кадәр (1 кулланучылар кооперативына) бүлеп бирелә.

2024 елда 5 фермер 100 млн сумлык һәм 2 авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы 41 млн сумлык грантлар алган.

2022 елдан федераль дәрәҗәдә «Агротуризм» дигән яңа юнәлеш – туристлар урнаштыру һәм инфраструктура булдыру өчен объектлар төзүгә грант ярдәме гамәлгә кертелде.

Республикада 60 дән артык эшкуар агротуризм өлкәсендә эшчәнлек алып бара. Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы грантларын 2022-2024 елларда гомуми суммасы 57 млн сумлык 7 эшкуар (шул исәптән 2024 елда – 38 млн сумлык 4 эшкуар) алган, 5 эшкуар 2025 елда гомуми суммасы 42 млн сумлык грант алачак.

Республика юнәлешләре буенча төп чаралар шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә ярдәм итүгә юнәлтелгән. 2024 елда 447 млн сумлык 44 мең шәхси ярдәмче хуҗалык ярдәм алды, 2025 елда 711 млн сум каралган.

**Ярминкәләр үткәрү**

Авыл хуҗалыгы ярминкәләре – республика җитештерүчеләре тарафыннан җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кооперативлары һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар продукциясен сатуның иң кирәкле форматларыннан берсе.

Ярминкәләр уздыру өчен Казан шәһәрендә 12 мәйданчык, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында 3 мәйданчык һәм Чаллы шәһәрендә һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында икешәр мәйданчык каралган.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан 2024 елда уздырылган ярминкәләр йомгаклары буенча республиканың дүрт эре шәһәрендә (Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Зеленодольск шәһәре, Түбән Кама шәһәре) 1,7 млрд сумнан артык продукция сатылган (7 242,9 тонна яшелчә, 419,1 тонна сөт, 1 848,7 тонна ит, 941,5 тонна шикәр комы, 4 406 мең данә тавык йомыркасы).

Авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә ярдәм күрсәтү максаты белән ярминкәләрдә катнашучыларга ягулык-майлау материаллары чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бүлеп бирелә. 2024 ел йомгаклары буенча бу максатларга 12 млн сум бүлеп бирелгән. Шул ук вакытта ярминкәләрдә катнашучыларга сәүдә урыннары бушлай бирелә. Шушы чаралар ярдәмендә товар җитештерүчеләрнең авыл хуҗалыгы продукциясен ярминкәләрдә халыкка уртача ваклап сату бәясеннән 10-20 процентка түбәнрәк бәягә сатырга мөмкинлеге бар.

Моннан тыш, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар тарафыннан җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясен ел әйләнәсе көн дә сату өчен республика шәһәрләрендә 147 махсуслаштырылган мәйданчыклар каралган. Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән чатырдан эшләнгән 9 мәйданчык төзелде, аларда ел әйләнәсе көн саен авыл хуҗалыгы продукциясен сату өчен шартлар тудырылды.

Шулай ук Казан шәһәрендә гомуми мәйданы 8 гектардан артык булган «Казан» агросәнәгать паркы эшләп килә, аның эше авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлегенең кече һәм урта формаларына ярдәм итүгә һәм аларны үстерүгә, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүчеләр һәм китерүчеләр белән төбәкара хезмәттәшлеккә юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының рәсми сайтында («Эшчәнлек/Авыл хуҗалыгы ярминкәләре» бүлегендә) кулланучылар һәм продукция җитештерүчеләр өчен ярминкә чаралары турында актуаль мәгълүмат бирелеп тора.

**Экспорт**

Сату базарларын киңәйтү максатларында агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау буенча актив эш алып барыла. 2024 елда экспорт күләме 470 млн АКШ доллары тәшкил иткән.

Агросәнәгать комплексы продукциясе тышкы икътисадый эшчәнлекнең 258 катнашучысы тарафыннан дөньяның 56 иленә экспортлана.

«Хәләл» юнәлеше уңышлы үсеш алды. 2024 елда экспорт күләме 14 млн долларга җитте (2023 ел дәрәҗәсенә 122 %).

**«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру**

Тармакны үстерү өчен мөһим юнәлеш – авыл халкы өчен уңайлы шартлар тудыру.

2024 елда республикада «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруга 5,3 млрд сум акча тотылды. Түбәндәге чаралар гамәлгә ашырылды:

авылда 9,4 мең кв. метр торак файдалануга тапшырылган;

38 муниципаль районда 93 иҗтимагый киңлек төзекләндерелгән;

компакт торак төзелеше өчен инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру һәм мәйданчыкларны уңайлаштыру буенча 4 проект гамәлгә кертелде;

8 социаль һәм коммуналь инфраструктура объектына һәм 3 агросәнәгать комплексы объектына 37 км автомобиль юлы норматив хәлгә китерелде;

13 социаль һәм коммуналь инфраструктура объекты файдалануга тапшырылган, шул исәптән:

Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында балалар сәнгать мәктәбе; Апас муниципаль районының Апас шәһәр тибындагы поселогында футбол кырының административ бинасы; Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәрендә балалар бакчасы һәм чаңгы-роллер трассасы; Саба муниципаль районының Шәмәрдән авылында чистарту корылмалары;

16,6 км озынлыктагы су белән тәэмин итү челтәрләре, 1,3 км яктырту челтәрләре,3 км су чыгару челтәрләре, 8,9 км газ белән тәэмин итү челтәрләре, 1,1 км җепселле-оптик элемтә линияләре салынган.

2025 елда әлеге эш дәвам итәчәк, финанслау күләме 4,1 млрд сум тәшкил итәчәк.

**Фермерларга һәм кооперативларга ярдәм**

Фермерларга һәм кооперативларга ярдәм «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проектының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары акселерациясе» төбәк проекты кысаларында гамәлгә ашырылды.

2024 елда:

дәүләт ярдәмен кече һәм урта эшкуарлыкның 89 субъекты алды;

57 яңа эш урыны булдырылды;

авыл хуҗалыгы кооперациясе өлешендә республика өчен 2 300 яңа әгъзаны җәлеп итү буенча план-бирем билгеләнде. 2025 елның 1 гыйнварына 2 988 яңа әгъза кабул ителгән (планнан 130 %).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм

авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында 2025 елда күрсәтелгән чаралар гамәлгә ашырыла.

# ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ

## Юл тармагы эшенә йомгак

Юл эшләре программасына 2024 елда 108,6 млрд сум бүлеп бирелгән, шул исәптән 19,1 млрд сум – федераль бюджеттан, 89,5 млрд сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан, муниципаль юл фонды акчаларын да кертеп (1,55 млрд сум).

2024 елда юл эшләре программасы буенча бүленгән акчалар исәбенә 424,19 км төбәк юлларын ремонтлау, реконструкцияләү һәм төзү эшләре башкарылган, шул исәптән 220,22 км юл төзелгән һәм реконструкцияләнгән һәм 203,97 км юл ремонтланган.

Республика территориясендә 22 күпер файдалануга тапшырылды.

2024 елда барлыгы 486,66 км чамасы җирле юллар төзелгән, реконструкцияләнгән һәм норматив хәлгә китерелгән, шул исәптән:

28,82 км төзелеш һәм реконструкция;

торак пунктларның 87,11 км юлларын ремонтлау (муниципаль юл фонды акчаларыннан);

90,77 км вак таш салынган;

253,98 км юл ремонтланган;

25,98 км озынлыктагы гаилә фермаларына, терлекчелек комплексларына, бакча җәмгыятьләренә һәм балаларны савыктыру лагерьларына 41 килү юлын төзекләндерелгән.

2024 елда Казан шәһәренең шәһәр магистральләреннән чыгу трассаларында эшләр төгәлләнгән:

Җиңү проспектыннан «Идел» М-7 автомобиль юлына кадәр җирдә Вознесенск трактының II этабын төзү (озынлыгы 7,6 км, эшләр башлануы – 2022 елның марты);

Казан шәһәренең Киров районындагы Горький шоссесын реконструкцияләү, Болотников ур., Фрунзе ур., Горький шоссесы, Залесная ур., Музыкаль урамыннан алып федераль әһәмияттәге «Идел» М-7 автомобиль юлына кадәр (озынлыгы 11,35 км, эшләр башлану – 2022 елның марты).

Моннан тыш, 2024 елда Казан шәһәре чигенә кадәр А-295 Йошкар-Ола – Зеленодольск автомобиль юлы төзелеше тәмамланды (төзелеш сроклары – 2023 – 2024 еллар, озынлыгы - 6,6 км).

Дәүләти-хосусый партнерлык шартларында «Алексеевск – Әлмәт» автомобиль юлы кулланылышка кертелде (төзелеш сроклары – 2022 – 2024 еллар, озынлыгы – 144,72 км).

2024 елда федераль бюджеттан республикада федераль әһәмияттәге автомобиль юлларын һәм аларда ясалма корылмаларны карап тоту, ремонтлау, капиталь ремонтлау, төзү һәм реконструкцияләүгә юл эшләрен финанслау күләме «Идел-Нократидарәавтоюл» ФКУ буенча 92,1 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү – 83,5 млрд сум, юлларны капиталь ремонтлау – 3,0 млрд сум, юлларны комплекслы төзекләндерү – 1,4 млрд сум, ясалма корылмаларны төзекләндерү – 0,5 млрд сум, юлларны карап тоту – 2,5 млрд сум, күперләрне карап тоту – 0,2 млрд сум, башкасы – 1,0 млрд сум.

Әлеге акчалар хисабына 2024 елда М-7 «Идел» федераль трассасында эшләр тәмамланган:

Чувашия Республикасы чигеннән Иннополис шәһәре чишелешенә кадәр участокны реконструкцияләү буенча;

Кама елгасы аша күпер аша чыгу юлы белән Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу буенча.

**«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты**

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында 2024 елда 113,29 км юл ремонтланган, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын арттыру чаралары башкарылган: 1 405 юл билгесе, 2,2 км ясалма яктырту, 1,2 км юл куркынычсызлыгы киртәсе куелган, 11,49 км тротуар эшләнгән (төзелеш, ремонт), 20 җәяүлеләр кичүе, 19 ясалма тигезсезлек, 36 тукталыш төзекләндерелгән.

Казан агломерациясендә 8,76 км юл ремонтланган, шул исәптән Казан шәһәренең 6,58 км урамнары һәм 2,18 км төбәк юллары, бу норматив торышның 86,1 % тәэмин итә.

Чаллы агломерациясендә 17,25 км юл ремонтланган, шул исәптән Чаллы шәһәренең 11,19 км юл-урам челтәре, 6,06 км – төбәк юллары, бу агломерация юлларының норматив торышының 85,9 % җитүен тәэмин итте.

Түбән Кама агломерациясендә 7,9 км юл ремонтланган, шул исәптән Түбән Кама шәһәренең 5,0 км юл-урам челтәре, 2,9 км – төбәк юллары, бу юлларның норматив торышының 85 % ирешүне тәэмин итте.

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проектының «Юл хуҗалыгын үстерүнең гомумсистема чаралары» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Казан һәм Чаллы агломерацияләрендә 19 светофор объекты адаптив идарә системасы белән яңартылган, юл хәрәкәте ешлыгын исәпкә алуның 80 пункты монтажланган, ике юл чатында юл-транспорт һәлакәтләрен һәм гадәттән тыш хәлне кисәтү системасы гамәлгә ашырылган.

**Транспорт тармагы**

Һава транспорты предприятиеләре эшчәнлеге

Татарстанда һава транспорты түбәндәгеләр эшчәнлеге белән күрсәтелә:

өч аэропорт: Габдулла Тукай исемендәге «Казан» һәм Н.В. Лемаев исемендәге «Бигеш» халыкара аэропортлары, «Бөгелмә» төбәк аэропорты;

Татарстан Республикасы аэропортларыннан төбәк авиаташуларны башкара торган биш «ЮВТ АЭРО» авиакомпаниясе, шулай ук «Бизнес авиация» һәм «Вертолет белән ташулар» сегментында эшчәнлек башкаручы «Тулпар Эйр», «Тулпар Экспресс», «Казан авиапредприятиесе» һәм «Авиасервис» авиакомпанияләре.

2024 елда республика аэропортлары тарафыннан 6 106,5 мең пассажирга хезмәт күрсәтелгән (2023 ел дәрәҗәсенә карата 104,1 %), шулардан:

«Казан» халыкара аэропорты» АҖ 5 369,2 мең пассажирга (103,9 %) хезмәт күрсәтте;

«Бигеш» аэропорты» АҖ 693,1 мең пассажирга (106 %) хезмәт күрсәтте;

«Бөгелмә» аэропорты» ҖЧҖ 44,2 мең пассажирга хезмәт күрсәтте (105,7 %).

БРИКС саммитын үткәрүгә әзерлек кысаларында 2024 елның октябрендә 51 тукталышка яңа пассажир перроны файдалануга тапшырылган, аның мәйданы 160 мең кв. метр. Шулай ук деайсинг – бозлавыкка каршы эшкәртү өчен комплекс һәм тукталыш төзелгән , бу һава судноларын эшкәртү вакытын кыскартырга мөмкинлек бирәчәк.

Саммит кысаларында 2024 елның 21-24 октябрендә 500 рейска хезмәт күрсәтелгән, шул ук вакытта даими рейслар да үтәлгән. Очышларның уртача тәүлеклек интенсивлыгы 119 очып китү һәм очып килү тәшкил итте, бу гадәти көннәрдә һава хәрәкәтенең уртача тәүлеклек интенсивлыгыннан 37% югары.

БРИКС саммиты чорында аэропорт югары вазыйфаи затлар белән 41 рейс, делегацияләр белән 67 рейс һәм саммит эшен тәэмин итү өчен персонал һәм җайланмалар белән 18 артык рейс кабул итте.

Шулай ук Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе өчен стратегик мөһим юнәлешләр буенча авиамаршрут челтәрен киңәйтү буенча актив эш алып барыла. 2024 елның сентябрендә China Eastern Airlines (CEA) авиакомпаниясе Шанхай – Казан – Шанхай маршруты буенча даими пассажирлар йөртүгә кереште.

Тимер юл транспорты предприятиеләре эшчәнлеге

Татарстанда тимер юл транспорты Горький һәм Куйбышев тимер юллары – «РЖД» ААҖ филиаллары, шулай ук «Содружество» шәһәр яны пассажирлар йөртү операторы эшчәнлеге белән тәкъдим ителгән.

2024 елда республика территориясендә шәһәр яны тимер юл ташулары операторы »Содружество» АҖ 127 маршрутка хезмәт күрсәткән, алар буенча поездларның 59 составы йөргән.

2024 елда шәһәр яны хәбәрендә 6,75 млн пассажир җибәрелгән (6,53 млн пассажир – Горький тимер юлы буенча, 227 мең пассажир – Куйбышев тимер юлы буенча). Казан – Йошкар-Ола – Казан һәм Казан – Кукмара – Казан яңа маршрутлары буенча йөрү оештырылды.

Казан шәһәрендә БРИКС саммитын үткәр ү чорында Казан – Аэропорт – Казан маршруты буенча ЭПЗД сериясенең яңа хәрәкәт составы белән 45 меңнән артык пассажир китерелгән.

Татарстан территориясе буенча ерак арага 2024 елда 1,975 млн пассажир җибәрелгән (1,86 млн пассажир – Горький тимер юлы буенча, 115 мең пассажир – Куйбышев тимер юлы буенча).

2024 елда йөк ташу күләме 35,16 млн тонна тәшкил иткән, шулардан 16,27 млн тонна йөк җибәрелгән, 18,89 млн тонна йөк кабул ителгән.

Эчке су транспорты предприятиеләре эшчәнлеге

Республика чикләрендә эчке су юлларының гомуми озынлыгы – 1 057 км, шул исәптән Идел бассейнында – 788 км һәм Кама бассейнында 269 км тәшкил итә.

2024 елгы навигация өчен даими рейсларда 350 мең пассажир китерелгән (2023 ел дәрәҗәсенә 102,9%).

Шәһәр яны пассажир ташуларын оештыру өчен елга транспортының 9 социаль әһәмиятле маршруты буенча 2024 елда 16 пассажир теплоходы, 7 причал һәм 11 дебаркадер җәлеп ителгән.

Республика территориясендә 35 пассажир судносы, 172 баржа, 47 җир снаряды/җир суырулары, 141 буксир, 27 брандвахта, 5 танкер, 6 пар бар. 2024 елда

паром кичүләре (Зеленодольск – Карамалы Тау, Аракчино – Югары Ослан) апрель башында эшли башлады.

**Автомобиль транспорты**

Республиканың автомобиль транспорты төрле милек рәвешләрендәге 41 йөртүче, шул исәптән 14 эре автотранспорт предприятиесе эшчәнлеге белән күрсәтелә.

Республиканың пассажир транспорт предприятиеләре тарафыннан 2024 елда 403,3 млн пассажир (2023 ел дәрәҗәсенә карата 103,8%) йөртелгән.

Автомобиль һәм шәһәр электр транспортының күчмә составының уртача исемлек саны 848 даими маршрутка хезмәт күрсәтүче 2 мең берәмлектән артык транспорт берәмлеген тәшкил итә.

Автотранспорт тармагын субсидияләүгә юнәлтелгән финанс чаралары күләме 2,7 млрд сум тәшкил итте.

2023 – 2024 елларда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрдә җәмәгать транспортының күчмә составын яңарту буенча ике программада катнашты.

2023 елда финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән махсус казначылык кредитлары булган җәмәгать транспортын яңарту проекты кысаларында Татарстан Республикасының 12 муниципаль берәмлегендә транспорт хезмәте күрсәтү өчен 119 автобус сатып алынган. Транспорт чараларын тапшыру 2024 елда төгәлләнде.

2024 елда «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» АҖ аша алга таба лизингка тапшыру өчен «Җир өсте җәмәгать пассажир транспортының хәрәкәтчән составын алга таба лизингка тапшыру өчен сатып алу» инвестиция проекты кысаларында Казан шәһәре өчен 127 зур класслы автобус һәм Чаллы шәһәре өчен зур класслы 44 автобус сатып алынган.

Федераль әһәмияткә ия автомобиль юлларында юл эшләре планын 2025 елда Казан-Екатеринбург маршрутында «Идел» М-7 федераль трассасын реконструкцияләүне төгәлләү планлаштырыла, ул 96 км озынлыкта, Мәскәү – Казан – Екатеринбург – Төмән М-12 «Көнчыгыш» коридорының бер өлеше булачак.

Эре федераль проектлар арасында шулай ук Р-239 Казан – Оренбург – Акбулак – Казахстан Республикасы белән чик 20+238 км – 43+500 км участокта, Сокуры поселогын урап узып, автомобиль юлларын реконструкцияләү дәвам итәчәк.

2025 елга юл эшләрен финанслау күләме 28,0 млрд сум күләмендә бәяләнә.

## ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК

2024 елда 167,04 млрд сумга 3 730 социаль инфраструктура объектын төзү һәм капиталь ремонтлау чаралары гамәлгә ашырылды, шул исәптән түбәндәгеләр кысаларында:

44 республика программасы – 64,08 млрд сумга 3 097 объект;

6 илкүләм проекты– 11,46 млрд сумга 208 объект;

5 дәүләт программасы – 5,94 млрд сумга 40 объект;

программадан тыш чаралар – 76,05 млрд сумга 377 объект.

Моннан тыш, инфраструктура проектлары кысаларында 9,51 млрд сумга 8 объект гамәлгә ашырылды.

**Торак төзелеше**

Республика ел саен торакны файдалануга тапшыру күләмнәре буенча алдынгы урыннарны били һәм Россия Федерациясе субъектлары – лидерлары исемлегенә керә.

2024 ел йомгаклары буенча 3 452,7 мең кв.метр торак (2023 ел дәрәҗәсенә карата 100,5%) файдалануга тапшырылды, шул исәптән:

гомуми мәйданы 940,9 мең кв.метр булган 146 күпфатирлы йорт;

гомуми мәйданы 2 350,0 мең кв.метр булган 17 407 индивидуаль торак йорт;

социаль ипотека программасы кысаларында гомуми мәйданы 161,8 мең кв.метр булган 59 торак йорт.

Социаль ипотека программасына яшь гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, үзләренә беркетелгән торак урыны булмаган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларны, радиация һәлакәтләре һәм катастрофалар аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны, Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән территорияләрдән күченеп киткән гражданнарны, мәҗбүри күченгән затларны, инвалидларны, 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү, шулай ук запаска азат ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм аларга тиңләштерелгән затлар өчен торак төзү буенча федераль механизмнар интеграцияләнде.

2024 ел йомгаклары буенча республиканың бер кешесенә исәпләгәндә торакның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш 29,9 кв.метр тәшкил итте (бәяләү). 2025 елда 3 260,0 мең кв.метр торакны файдалануга тапшыру планлаштырыла.

«Аренда торагы» программасы

Аренда торагын төзү яңа җитештерү мәйданчыкларын ачуга, махсус икътисадый зоналар, сәнәгать парклары булдыруга, ИТ-өлкә, нефть химиясе сәнәгате предприятиеләрен, шулай ук белгечләр – бюджет өлкәсе хезмәткәрләрен (табиблар, укытучылар, мәдәният, спорт, көч структуралары хезмәткәрләре һ.б.) җәлеп итүгә ихтыяҗ аеруча кискен булган өлкәләрне үстерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Аренда торагы предприятие хезмәткәрләренә дә, чакырылган белгечләр – бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә дә бирелә.

2024 елда гомуми мәйданы 30,4 мең кв.метр булган 20 аренда йорты

файдалануга тапшырылды.

Өлешле төзелештәге проблемалы объектлар

Өлешле төзелештә алданган катнашучылар проблемасы системалы рәвештә хәл ителә. 2007 елдан 2023 елга кадәр өлешле төзелеш буенча 1 350,8 мең кв.метр мәйданлы 146 проблемалы объект файдалануга тапшырылды, 18 664 өлешче торак алды.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы буенча проблемалы объектларның бердәм реестрында объектлар юк.

Дәүләт ярдәме программалары

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак урыннары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру дәвам итә. Әлеге категория гражданнары өчен торак сертификатлары 2007 елдан рәсмиләштерелә. 2007 елдан 2024 елга кадәр Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчага барлыгы 2 478,7 млн сумга 624 күпбалалы гаилә, шул исәптән 2024 елда – 252,9 млн сумга 28 гаилә торак белән тәэмин ителде.

Федераль законнарда торак шартларын яхшырту гарантияләнгән гражданнар алдында дәүләт йөкләмәләрен үтәүгә юнәлдерелгән «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы гамәлгә ашырыла. Болар – Ерак Төньяк районнарыннан күченгән гражданнар, Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган, шулай ук күченергә мәҗбүри булган гражданнар.

2024 елда 20,59 млн сумга 5 субсидия рәсмиләштерелде, шул исәптән:

1 дәүләт торак сертификаты – 10,54 млн сумга Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга;

2 дәүләт торак сертификаты – 7,32 млн сумга билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри күченүчеләр дип танылган гражданнарга;

2 дәүләт торак сертификаты – 2,74 млн сумга Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән күченүче (күченеп киткән) гражданнарга.

**Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2024 елда 748 күпфатирлы йорт (4,6 млн кв.метр) ремонтланды, үз торак шартларын республиканың 166 меңнән артык гражданы яхшыртты.

Эшләр барышында файдаланырга яраксыз дип танылган 234 лифт җиһазы алыштырылды, 295 йортта 317 мең кв.метрдан артык түбә, 313 йортта 739 мең кв.метрдан артык фасад ремонтланды, электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итү һәм су чыгаруның 871 мең погонлы метрдан артык йорт эчендәге инженерлык системалары алыштырылды.

2024 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау чараларын гамәлгә ашыруга 8,13 млрд сум күләмендә финанслау лимиты каралды. Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән экономияне исәпкә алып, әлеге

чараларны финанслауның гомуми күләме 7,84 млрд сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1,36 млрд сум, муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасы – 1,07 млрд сум, гражданнар акчасы – 5,41 млрд сум.

**«Безнең ишегалды» программасы**

2020 елдан ишегалды территорияләрен төзекләндерү буенча «Безнең ишегалды» республика программасы гамәлгә ашырыла.

Программа кысаларында түбәндәге эшләр башкарыла: юллар һәм тротуарларны, урам яктырткычларын ремонтлау, эскәмияләр һәм урналар урнаштыру, каты коммуналь калдыклар мәйданчыкларын, комлы-чуерташлы катнашма җәелгән балалар мәйданчыкларын төзекләндерү, өлешчә яшелләндерү.

2024 елда 835 ишегалды территориясе төзекләндерелде, финанслау күләме 10 млрд сум тәшкил итте.

**«Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты**

2024 елда «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектын гамәлгә ашыру өчен 2 106,32 млн сум (федераль бюджеттан – 1 737,29 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 369,03 млн сум) күләмендә акча җибәрелде, шул исәптән түбәндәгеләргә:

«Торак» төбәк проектына – 491,25 млн сум (федераль бюджеттан – 397,91 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 93,34 млн сум).

Проект кысаларында Биектау муниципаль районында биологик чистарту корылмаларын, су чыгару челтәрләрен, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының су белән тәэмин итү һәм су чыгару челтәрләрен төзү, Казан шәһәрендә технологик тоташтыру гамәлгә ашырылды;

«Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» төбәк проектына (42 җәмәгатьчелек пространстволары төзекләндерелде) – 1 536,15 млн сум (федераль бюджеттан – 1 274,05 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 262,10 млн сум);

«Яшәү өчен яраксыз торак фондын тотрыклы киметүне тәэмин итү» төбәк проектына – 78,92 млн сум (федераль бюджеттан – 65,34 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 13,58 млн сум).

**Концессия килешүләре һәм инвестиция программалары кысаларында коммуналь объектларны реконструкцияләү һәм модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру**

Республикада 18 муниципаль районда 123 концессия килешүе гамәлдә, алар нигезендә концессионерларга 2 157 коммуналь инфраструктура объекты, шул исәптән 2 156 муниципаль милек объекты, 1 Татарстан Республикасы милке объекты тапшырылды.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә 83 концессия килешүе, шул исәптән Татарстан Республикасы милкендәге объект буенча 1 концессия килешүе төзелде. Барлыгы 457 җылылык белән тәэмин итү объекты тапшырылды. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә 1 694 объектны тапшыру буенча 34 концессия килешүе төзелде. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә 6 концессия килешүе төзелде.

**Инвестиция программалары**

Коммуналь хуҗалыкка өстәмә инвестицияләр җәлеп итү, торак фондын төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру, коммуналь инфраструктураның тузуын акрынайту максатларында коммуналь комплекс оешмалары тарафыннан коммуналь инфраструктура объектларын үстерү, модернизацияләү һәм реконструкцияләү буенча инвестиция программалары гамәлгә ашырыла. 2024 елда 35 инвестиция программасы, шул исәптән 15 коммуналь комплекс оешмасы өчен 19 – су белән тәэмин итү өлкәсендә, 16 – су бүлеп бирү өлкәсендә гамәлгә ашырылды.

2024 ел өчен инвестиция программалары чараларының үтәлешен оператив мониторинглау мәгълүматлары буенча оешмалар буенча тулаем алганда – 4 543,7 млн сум, шул исәптән су белән тәэмин итү буенча – 2 176,9 млн сум, су чыгару буенча 2 366,8 млн сум тәшкил итте.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә 19 оешма өчен 23 инвестиция программасы гамәлгә ашырылды. 2024 елда, оператив мониторинг мәгълүматларына караганда, оешмалар буенча тулаем алганда инвестиция программалары чараларының үтәлеше 8 482,9 млн сум тәшкил итте.

**Коммуналь инфраструктураны модернизацияләү буенча төбәк программасы**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2027 елларга Татарстан Республикасында коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү буенча төбәк программасын раслау турында» 2023 ел, 24 май, 633 нче карары (алга таба – Программа) нигезендә 2023–2024 елларга коммуналь инфраструктураны модернизацияләү буенча 4 496,3 млн сумлык гомуми суммага 67 чара гамәлгә ашыру каралды, шул исәптән Территорияләрне үстерү фонды бюджеты – 2 087,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты – 635,6 млн сум, бюджеттан тыш чаралар – 1 773,4 млн сум.

2024 елда 48 объектта эшләр тәмамланды: Казан шәһәре – 34, Чаллы шәһәре – 1, Әгерҗе муниципаль районы – 6, Кама Тамагы муниципаль районы – 1, Зәй муниципаль районы – 1, Сарман муниципаль районы – 3, Түбән Кама муниципаль районы – 1, Чистай муниципаль районы – 1.

2024 елда башкарылган эшләр нәтиҗәләре буенча чыгымнар 2 594,67 млн сум тәшкил итте, шул исәптән Территорияләрне үстерү фонды акчалары – 1 136,53 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 191,56 млн сум, бюджеттан тыш чаралар – 1 266,58 млн сум.

Бүгенге көндә Программаның барлык чаралары төгәлләнде.

Программаны үтәү кысаларында 128,2 км инженерлык челтәрләре, ягъни су белән тәэмин итү – 42,8 км, су чыгару – 19,3 км, җылылык белән тәэмин итү – 66,1 км төзелде, реконструкцияләнде һәм капиталь ремонтланды.

**ИНВЕСТИЦИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ**

Татарстан Республикасы Хөкүмәте төбәкнең инвестицион потенциалын алга этәрүгә һәм аның инвестицион климатын яхшыртуга, шулай ук инвесторлар өчен бизнес алып баруга уңайлы шартлар тудыруга зур игътибар бирә.

2024 ел йомгаклары буенча төп капиталга инвестицияләр күләме 1 435,1 млрд сум, ягъни 2023 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 112,7% тәшкил итте.

Кече эшкуарлык субъектларына карамаган оешмалар буенча төп капиталга инвестицияләрнең шактый күләме эшкәртү производстволарын үстерүгә юнәлтелде – 34%, шулардан 11% инвестицияләр – химик матдәләр һәм химик продуктлар җитештерүгә, 5,8% – кокс һәм нефть продуктлары җитештерүгә, 3% – автотранспорт чаралары, тагылмалар һәм ярымтагылмалар җитештерүгә, 3% – башка транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерүгә туры килде. Транспортлауга һәм саклауга төп капиталга инвестицияләрнең гомуми күләменнән 21,5 проценты җибәрелде, файдалы казылмалар чыгаруга – 10%, күчемсез мөлкәт белән операцияләр эшчәнлегенә – 9,6%.

Инвестиция максатларына юнәлдерелгән үз акчаларының чагыштырма авырлыгы 62,1%, җәлеп ителгән акча өлеше 37,9% тәшкил итте.

Ел саен «Яңа проектларны алга этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» коммерциягә карамаган автоном оешмасы тарафыннан төбәкләр Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы кысаларында бизнес алып бару шартлары буенча бәяләнә. 2024 елда Татарстан Республикасы алтынчы ел рәттән әлеге рейтингта икенче урынны ала. Интеграль индекс 0,8 баллга артты һәм 303,25 балл (2023 елда – 302,45 балл) тәшкил итте.

Республиканың күрсәткечләр буенча алдынгы позицияләрен саклап калу өчен бизнесны алып бару шартларының сыйфатын яхшырту өчен булган резервларга даими анализ ясала.

Регионнарның инвестицион җәлеп итүчәнлеген яхшыртуга юнәлдерелгән төп инструментларның берсе – Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2021 елның 30 сентябрендәге 591 номерлы боерыгы белән расланган Региональ инвестиция стандарты.

Стандарт яңа инвестиция проектларын башлап җибәрүнең бердәм принципларын һәм шартларын булдыруга юнәлдерелгән 5 төп элементны үз эченә ала:

инвестиция декларациясе;
инвестиция советы;
инвестицион үсеш агентлыгы;
инвестиция картасы;
инвестиция кагыйдәләре җыелмасы.

Стандартны һәм аның элементларын гамәлгә ашыру инвесторларның дәүләт структуралары белән үзара хезмәттәшлегенең үтә күренмәлелеген тәэмин итә, төп хезмәтләр һәм ярдәм чаралары күрсәтелә торган этапларның һәрберсендә инвесторларның (эшкуарларның) хокукларын яклау механизмнарын җайга сала.

2024 елда эшлекле берләшмәләрнең эксперт төркеме тарафыннан Региональ инвестиция стандартының барлык 5 элементын гамәлгә кертү расланды (Эшлекле

берләшмәләр Советы утырышының 2024 елның 3 июнендәге 6 номерлы беркетмәсе).

Инвестиция декларациясе Татарстан Республикасы Президентының «2028 елга кадәр Татарстан Республикасы инвестиция декларациясе турында» 2012 елның 18 июнендәге ПУ-477 номерлы Указы белән расланды. Документта Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру шартлары буенча инвесторлар алдында булган йөкләмәләр, аларның бозылмавы турында һәм Татарстан Республикасы инвестиция командасында җаваплылыкның бүленеше турында мәгълүмат ачыла.

Татарстан Республикасының Инвестиция советы Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указы белән оештырылды, аның рәисе – Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов. Совет инвестиция эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, инвесторның Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнары, республика җирле үзидарә органнары, вәкаләтле оешмалар белән барлыкка килгән, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы тарафыннан җайга салынмаган каршылыкларын һәм бәхәсләрен судка мөрәҗәгать иткәнгә кадәр хәл итү максатларында эшли.

Инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 ел, 20 февраль, 118 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламенты нигезендә башкарыла.

Татарстан Республикасының инвестиция картасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы инвестиция порталында (invest.tatarstan.ru/ru/map) урнаштырылды. Әлеге инструмент ярдәмендә инвесторларның республика территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен ресурсларны, кирәкле инфраструктураны, мәйданчыкларны бүлү, преференция режимнары (үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр, махсус икътисадый зоналар) булу өлешендә Татарстан Республикасы турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге тәэмин ителә.

Стандартның үз эчтәлеге буенча иң әһәмиятле элементы – инвестиция кагыйдәләре җыелмасы. Бу дәүләт хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар һәм инвесторларның үзләре тарафыннан инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда таләп ителә торган хезмәтләр буенча гамәлләр кылу алгоритмнары (объектлар төзелешенә, аларны файдалануга тапшыруга, электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итү һәм су чыгару челтәрләренә тоташтыруга, җир кишәрлекләрен арендага алуга рөхсәтләр бирү).

Булган резервлар буенча чаралар эшләү, шулай ук гамәлдәге административ

киртәләрне минимальләштерү өчен 2024 елда «Росатом» дәүләт корпорациясенең методологик ярдәме белән республикада 8 инвестор гамәлләре алгоритмы кысаларында «Үтәли инвестиция агымы» проектын гамәлгә ашыру эше дәвам итте:

«150 кВт ка кадәр электр челтәрләренә тоташтыру» һәм «150 кВт тан югары электр челтәрләренә тоташтыру»;

«Газ бүлү челтәрләренә тоташтыру»;

«Су белән тәэмин итү һәм су чыгару объектларына тоташтыру»;

«Җылылык белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру»;

«Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт алу»;

«Төзелешкә рөхсәт алу»;

«Торгларда җир кишәрлеген алу»;

«Җир кишәрлеген сатуларсыз арендага алу».

Проектның төп максаты – инвесторның идеясе барлыкка килгәннән алып капитал салуларны башкарганга кадәр үтә торган юлын кыскарту. Төбәктә сакчыл җитештерү принципларын кертү ярдәмендә инвестиция проектын әзерләүгә һәм гамәлгә ашыруга, шул исәптән инвесторның барлык төп процедуралар узуына сарыф ителә торган вакытны кыскарту һәм ресурсларны киметү буенча резервлар эзләү алып барыла.

Эш барышында процессларның агымдагы, идеаль, максатчан торышлары анализланды (аларның картасы ясалды); максималь озак срок белән башкарыла торган проблемалы участоклар ачыкланды; административ киртәләрнең төп сәбәпләрен (норматив җайга салу өлешендә дә, республикада эшне алып бару тәртибен оештыруда да) эзләү алып барыла.

2024 елда инвестиция стандарты инструментарие арттырылды, ул 2025 елда рейтинг кысаларында бәяләнәчәк. Татарстан «пилот» төбәге итеп билгеләнде.

Яңа стандарт элементы – инвестицион үсешнең өстенлекле юнәлешләрен алга җибәрүгә юнәлдерелгән инвестиция куышларын (тәкъдимнәр) формалаштыру.

Стандартның икенче яңа элементы – бизнес белән кире элемтә механизмы. Ул эшкуарларга «бер тәрәзә» принцибы буенча еш очрый торган проблемалы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләр җибәрергә мөмкинлек бирә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән кире элемтә механизмын формалаштыру һәм үстерү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 23 ноябрь, 1045 нче карары белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы бизнес мөрәҗәгатьләрен эшкәртүнең бердәм үзәге итеп билгеләнде.

2025 елның 21 гыйнварында Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов рәислегендә инвестицион климат торышын яхшырту һәм «Нәтиҗәле төбәк» пилот проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышы уздырылды. Утырыш нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының инвестицион климатын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында» 2025 ел, 7 февраль, 63 нче карары расланды.

**Татарстан Республикасының инвестиция меморандумы**

Инвестиция эшчәнлегендә катнашучылар хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген

арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 декабрь, 1296 нчы карары белән 2023–2025 елларга Татарстан Республикасының инвестиция меморандумы расланды, анда республикада инвестиция эшчәнлеге үсешенең өстенлекләре билгеләнде. Аерым алганда, болар инвестицияләр җәлеп итү һәм республика җитештерүчеләре продукциясен яңа базарларга чыгару өлкәсендә Россия Федерациясе төбәкләре һәм чит ил партнерлары белән хезмәттәшлекне үстерү, халыкара икътисадый кооперация пространствосыннан актив файдалану, электрон сәүдәне үстерү, шул исәптән Республика маркетинг үзәге потенциалыннан файдалану; эшкуарлыкка, шул исәптән махсус икътисадый зоналарга, үсеше алдан билгеләнә торган территорияләргә, инновацион фәнни-технологик үзәкләркә, технопаркларга, индустриаль паркларка ярдәм күрсәтү инфраструктурасын үстерү; цифрлы икътисадны булдыру һәм үстерү; технологик суверенитетны тәэмин итүгә ярдәм итә торган проектларны гамәлгә ашыру; экспортка юнәлтелгән тармакларда (импортны алыштыра торган товарлар, чимал һәм материаллар) проектларны гамәлгә ашыру, азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүгә һәм авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән инвестиция проектларын гамәлгә ашыру һ.б.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 декабрь, 1637 нче карары белән 2024 елга Татарстан Республикасының өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге расланды. Исемлеккә 156 проект, шул исәптән «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы (алга таба – «Алабуга» МИЗ) һәм «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналары (алга таба – «Иннополис» МИЗ) территорияләрендә, технопарклар, сәнәгать парклары, инновацион фәнни-технологик үзәкләр (шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары нигезендә төзелгән) территорияләрендә, үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрдә гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган инвестиция проектлары; җир кишәрлекләрен, сатулар үткәрмичә, арендага биреп; капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында, дәүләт партнерлыгы һәм хосусый партнерлык турында килешүләр һәм концессия килешүләре төзеп гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган масштаблы инвестиция проектлары кертелде.

2025 елга Татарстан Республикасының өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 20 декабрь, 1172 нче карары белән расланды.

**Инвестиция активлыгын стимуллау чараларын гамәлгә ашыру, инвестиция проектларын гамәлгә ашыру ысулларын һәм механизмнарын камилләштерү**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләренә таянып, инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвесторлар өчен оешма тарафыннан проектны гамәлгә ашыруга яңадан булдырылган яки сатып алынган мөлкәткә салым ставкасын 0,1 процентка кадәр киметү каралды. Инвестиция эшчәнлеге субъектларына әлеге ташламалар проектларның үз-үзен аклау срогына

бирелә, ләкин ул 7 елдан да артмаска тиеш, ә машина төзелеше тармагында салым ташламалары инвестицияләр башланган вакыттан алып 13 елга кадәр срок белән бирелергә мөмкин.

Дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 ел, 7 май, 284 нче һәм «Инвестиция эшчәнлеге субъекты белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы арасында инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне һәм инвестиция проектын тормышка ашыру турында шартнамә формасын раслау хакында» 2006 ел, 24 июль, 377 нче карарлары белән регламентлаштырылды.

Якынча бәяләүләр буенча, 2006 елдан 2024 елга кадәр республикада инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә барлыгы якынча 16,5 млрд сум күләмендә салым ташламалары бирелде. Әлеге инвестиция проектларын гамәлгә ашыру кысаларында 813 млрд сум күләмендә инвестицияләр җәлеп ителде, Татарстан Республикасы бюджетына салым түләүләре 28,0 млрд сум күләмендә бәяләнә. Ярдәм күрсәтелгән инвестиция проектлары кысаларында 18 меңнән артык яңа эш урыны булдырылды.

Бизнесның активлыгын стимуллау, проектларның инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру, шулай ук яңа югары технологияле производстволарны эшләтеп җибәрү өчен «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 26 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

Әлеге законда капиталь кертемнәр күләме кимендә 50 млрд сум күләмендә булган инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы һәм Татарстан Республикасы территориясендә корыч җөйсез торбалар җитештерүне гамәлгә ашыручы махсус инвестиция контрактларында катнашучыларга салым ташламалары бирү мөмкинлеге карала.

Кайбер территорияләрне (шул исәптән «Алабуга» МИЗ һәм «Иннополис» МИЗ) тизләтеп үстерү өчен шартлар һәм эшкуарлык эшчәнлеген алып баруның преференциаль шартларын тудыруга юнәлдерелгән инвестиция мәйданчыклары уңышлы эшләвен дәвам итә, аларны булдыру мөмкинлеге федераль законнарда карала.

«Алабуга» МИЗ республиканың нәтиҗәле инвестиция мәйданчыгына мисал булып тора. Аның резидентлары арасында бөтен дөньяга танылган UMATEX («Росатом» дәүләт корпорациясе бүлекчәсе), Rockwool, Knauf, Kastamonu, Hayat, Аурус, Air Liquide, Şişecam, Coşkunöz һ.б. кебек компанияләр бар.

2024 ел йомгаклары буенча «Алабуга» махсус икътисадый зонасында сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген 43 предприятие гамәлгә ашыра, резидентлар тарафыннан гамәлгә ашырылган инвестицияләр күләме территория эшли башлаганнан бирле арта бара торган йомгак белән 182,9 млрд сум, резидентларның

еллык табыш күләме 245,5 млрд сум тәшкил итте. Махсус икътисадый зона территориясендә 25,9 мең эш урыны булдырылды.

2024 елда «Алабуга» махсус икътисадый зонасы резидентлары статусын түбәндәгеләр алды:

«Фаворит» ҖЧҖ – товар бетоны, вак таш-бетон катнашмасы һәм тимер-бетон әйберләр җитештерүне оештыру буенча проект (планлаштырыла торган инвестицияләр күләме – 137,0 млн сум);

«ЕТС Машинери» ҖЧҖ – йөк техникасы өчен автокомпонентлар җитештерү буенча проект (планлаштырыла торган инвестицияләр күләме – 342,9 млн сум);

«КрафтПайп» АҖ – композитлы ныгытылган торба җитештерү буенча проект (планлаштырыла торган инвестицияләр күләме – 947,0 млн сум);

ООО «ПИК-ФАРМА ПРО» – актив фармацевтика субстанцияләре җитештерүне оештыру буенча проект (планлаштырыла торган инвестицияләр күләме – 2 000 млн сум);

«СИНТЕЗ» АҖ – этиленхлогидрин, 2,2 дихлордиэтилформаль җитештерүне оештыру буенча проект (планлаштырыла торган инвестицияләр күләме – 1 416,7 млн сум);

«РЕДД+» ҖЧҖ – хайваннар өчен тулы күләмдә әзер азыклар җитештерүне оештыру буенча проект (планлаштырыла торган инвестицияләр күләме – 441,5 млн сум);

«АЛЕСПРОМ» ҖЧҖ – каеннан ясала торган шпон җитештерүне оештыру буенча проект (планлаштырыла торган инвестицияләр күләме – 1 100 млн сум);

«Зименс Якагава» ҖЧҖ – навигация җиһазлары комплектлары, радиоэлектрон аппаратура блоклары җитештерүне оештыру (планлаштырыла торган инвестицияләр күләме – 1 185 млн сум).

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан үткәрелгән 2023 ел өчен бәяләү нәтиҗәләре буенча, «Алабуга» МИЗ чираттагы тапкыр, күрсәткечләрне 100 процентка үтәп, нәтиҗәлелек буенча лидер булды.

«Иннополис» МИЗда 342 югары технологияле компания (136 резидент, 59 партнер, 147 стартап) эшчәнлек алып бара. 2024 ел нәтиҗәләре буенча, бәяләүгә караганда, әлеге компанияләрнең инвестицияләр күләме территория эшли башлаганнан бирле арта бара торган йомгак белән 214,9 млрд сум тәшкил итте, компанияләр тарафыннан 11 217 эш урыны булдырылды.

«Иннополис» МИЗ бишенче ел рәттән Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналар арасында иң нәтиҗәлеләреннән берсе дип танылa һәм Россия Федерациясе махсус икътисадый зоналарының инвестиция җәлеп итүчәнлеге милли рейтингында алдынгы урыннарны алып тора.

«Иннополис» МИЗ территориясендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 октябрендәге 1119 номерлы карары кысаларында түбәндәгеләр төзелде:

116 га мәйданлы «Лаеш» индустриаль паркы, анда үз эшчәнлеген ICL компаниясенең Электрон басма платаларның өстен монтажлау һәм исәпләү техникасы җитештерү заводы гамәлгә ашыра;

Россиядә югары технологияләр өлкәсендәге беренче «ИнноПарк» технопаркы. Бүгенге көндә биредә 29 компания эшли һәм инновацион җитештерү проектлары

уңышлы үсеш кичерә.

2024 елның 3 июнендә «Иннополис» МИЗ территориясендә Югары Ослан муниципаль районында стратегик партнер – «Росатом» дәүләт корпорациясе тарафыннан төзелгән Мәгълүматларны эшкәртү үзәгенең беренче чираты файдалануга тапшырылды.

**Үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр**

2016 ел башыннан республикада Яр Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Зеленодольск һәм Менделеевск моношәһәрләре территорияләрендә үсеше алдан билгеләнә торган 5 территория төзелде.

Үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен түбәндәгеләр каралды:

табышка салымның киметелгән ставкасы (федераль бюджетка исәпләү өлешендә – эшчәнлектән беренче табыш алынган вакыттан беренче 5 салым чоры дәвамында 0 процент; Россия Федерациясе субъектлары бюджетына исәпләү өлешендә – беренче табыш алынган вакыттан 5 салым чоры дәвамында 5 процент һәм киләсе 5 салым чоры дәвамында 10 процент);

оешмалар мөлкәтенә салым түләүдән азат итү;

җир салымын түләүдән азат итү;

гадәти тәртиптә түләнә торган 30% урынына 7,6% күләмендә иминият кертемнәренең киметелгән тарифлары (ташлама АҮТ резиденты статусын алган көннән алып 12 ел дәвамында бирелә һәм АҮТ төзелгән көннән алып өч елдан да соңга калмыйча шундый статус алган резидентларга карата кулланыла).

2025 елның 1 гыйнварына карата Татарстан Республикасында үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрдә 145 резидент теркәлде, алар тарафыннан 80,3 млрд сум инвестиция, шул исәптән 65,0 млрд сум күләмендә капитал салулар (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) гамәлгә ашырылды, 26 297 яңа эш урыны булдырылды. Резидентларның керем күләме арта бара торган йомгак белән 591,5 млрд сум тәшкил итте.

2024 елда үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары тарафыннан проектлар гамәлгә ашыру моношәһәрләр икътисадын 14,2 млрд сумнан артык күләмдә инвестицияләүне тәэмин итәргә һәм 2 718 яңа эш урыны булдырырга мөмкинлек бирде. Резидентларның керем күләме 186,5 млрд сум тәшкил итте.

Үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрнең салым режимы моношәһәрләрдә яңа производстволар ачарга ярдәм итә һәм резидентларга проект табышка чыгу чорында бизнеска минималь салым йөкләнеше белән эшләргә мөмкинлек бирә. Үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентларына салым ташламалары бирү рентабельлекне арттырырга, инвестиция проектларын гамәлгә ашыру һәм аларның кайтару хакын киметергә мөмкинлек бирде.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрне үстерү буенча күрелә торган чаралар һәм оештырыла торган шартлар яңа тармаклар барлыкка килүгә, моношәһәрләр икътисады структурасын диверсификацияләүне һәм төзелә торган производстволарны кадрлар белән тәэмин итүне гамәлгә ашыруга ярдәм итә.

Территорияләрнең уңай социаль-икътисадый үсешенә йогынты ясый торган

мөһим аспект – ул Haier, OZON, «Вайлдберриз», «КазаньЭкспресс», «Магнит» һ.б. компанияләре кебек эре инвесторларны җәлеп итү.

**Моношәһәрләрне үстерү**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 29 июлендәге б-1398 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасыннан моношәһәрләр исемлегенә Зеленодольск, Яр Чаллы, Кама Аланы, Менделеевск, Алабуга, Чистай, Түбән Кама шәһәрләре керә.

Татарстан Республикасы халкының гомуми санында моношәһәрләр халкы санының өлеше 26,3% тәшкил итә (Чаллы шәһәре – 13,6%, Түбән Кама шәһәре – 6%, Зеленодольск шәһәре – 2,47%, Алабуга шәһәре – 1,85%, Чистай шәһәре – 1,45%, Менделеевск шәһәре – 0,57%, Кама Аланы – 0,35%). Моношәһәрләр халкының гомуми санында эшче көч өлеше 52% тәшкил итә.

2025 елның 1 гыйнварына карата республика моношәһәрләрендә 47 694 эш урыны булдырылды, 16 779 кече һәм урта предприятие (микропредприятиене кертеп) теркәлде.

2024 ел өчен моношәһәрләрнең салым һәм салымнан алынмаган керемнәре суммасы 11,7 млрд сум тәшкил итте һәм 2023 ел дәрәҗәсе белән чагыштырганда 5,02 процентка артты.

2025 елның 1 гыйнварына карата моношәһәрләрдә теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе түбәндәгечә тәшкил итте: Яр Чаллыда – 0,15%, Түбән Камада – 0,2%, Кама Аланында – 0,6%, Менделеевскта – 0,06%, Алабугада – 0,1%, Зеленодольскта – 0,09%, Чистайда – 0,06%. Татарстан Республикасы территориясендә моношәһәрләрдә эшсезлекнең уртача дәрәҗәсе 0,15% тәшкил итте.

2025 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы моношәһәрләрендә хезмәт базарындагы киеренкелек коэффициенты уртача 1 вакансиягә 0,03 кеше тәшкил итте.

Моношәһәрләрне үстерү өчен Татарстан Республикасы тарафыннан «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясенең (алга таба – ВЭБ.РФ) ярдәм чаралары актив файдаланылды.

Татарстан Республикасының инфраструктура проектларына финанс ярдәменең гомуми суммасы – 6,6 млрд сумнан артык, шул исәптән ВЭБ.РФ акчасы исәбеннән 4 млрд сум күләмендә тәшкил итә.

2023 елның 28 декабрендә ВЭБ.РФ белән, Менделеевск моношәһәрендә инфраструктура төзү һәм (яисә) аны реконструкцияләү чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын финанслашу турында килешү төзелде. «Менделеевск 2.0» сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасын төзү проекты кыйммәте – 870,4 млн сум, шул исәптән ВЭБ.РФ акчасы исәбеннән 426,0 млн сум тәшкил итә. Файдалануга тапшыру срогы – 2025 ел. Менделеевск моношәһәрендә инфраструктура төзү һәм (яисә) аны реконструкцияләү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру тулаем алганда 148 эш урыны булдырырга һәм 756,7 млн сум күләмендә инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

**Конгресс-күргәзмә чаралары**

Конгресс-күргәзмә чараларын үткәрү инвестиция потенциалын күрсәтүдә иң мөһим юнәлеш булып тора.

2024 елның 14–19 маенда «Россия-Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумы (алга таба шулай ук – KazanForum) үз мәйданчыгында 87 илдән һәм Россия Федерациясенең 87 төбәгеннән 20 меңнән артык катнашучыны берләштерде. 2023 елда Россия Федерациясе Президенты указы нигезендә чарага федераль статус бирелде. KazanForum кысаларында Россия һәм чит ил дәүләтләре вәкилләренең төрле форматларда: түгәрәк өстәллләрдән алып индустриаль диалогларга кадәр 9 очрашуы уздырылды. Аерым алганда, «Россия – Әзәрбәйҗан», «Россия – Әфганстан», «Россия – Иран», «Россия – Катар», «Россия – Кыргызстан», «Россия – Малайзия» һәм башка очрашулар булды.

Форум кысаларында Russia Halal Expo күргәзмәсе узды. Бу Россия Федерациясендә Россия Федерациясе төбәкләренең һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең икътисадый һәм фәнни-технологик хезмәттәшлек буенча иң зур күргәзмә. Күргәзмә эшендә 11 ил һәм Россиянең 17 төбәге катнашты.

«Казан» агросәнәгать паркы территориясендә оештырылган Kazan Halal Market ярминкәсендә 9 илдән 489 компания катнашты. Хәләл маркетта үз товарларын Әфганстан Ислам Республикасы, Кыргызстан Республикасы, Төркия Республикасы, Казахстан Республикасы, Пакистан Ислам Республикасы, Әзәрбәйҗан Республикасы, Шри-Ланка Демократик Социалистик Республикасы, Иран Ислам Республикасы тәкъдим итте.

KazanForum кысаларында беренче тапкыр International Property Market күчемсез мөлкәт күргәзмәсе уздырылды. Күргәзмәдә Россия Федерациясенең, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең, Төркия Республикасының һәм Индонезия Республикасының иң зур компанияләре, девелоперлары һәм архитекторлары катнашты.

Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең яшь дипломатлары форумы KazanForum мәйданчыгына 20 илдән 30 делегатны туплады. Делегатлар БДБ, Африка һәм Азия илләреннән килделәр. Форумда фикер алышу өчен темалар – якындагы берничә елда актуаль булачак хезмәттәшлек юнәлешләре, шул исәптән цифрлы һәм ИТ-дипломатия.

KazanForum кысаларында барлыгы форумда 120 килешүгә һәм меморандумга кул куелды.

2024 елның 13 – 15 ноябрендә «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – узара табышлы хезмәттәшлек» II Халыкара форумы уздырылды, анда дөньяның 36 иленнән 10 меңнән артык вәкил, шул исәптән Россиянең 71 төбәгеннән һәм Кытай Халык Республикасының 27 административ бүлекчәсеннән делегация катнашты. Бу – Россия төбәкләре һәм Кытай провинцияләре арасында икътисадый хезмәттәшлекне үстерү өчен ел саен уздырыла торган мәйданчык. 2024 елгы Форум кысаларында 77 эшлекле сессиясе үткәрелде, шулай ук Кытай һәм Россия оешмалары арасында B2B-очрашулар оештырылды, 15 000 кв.метр гомуми мәйданлы өч күргәзмә оештырылды. А1 павильонында «Чәй, кофе, какао» күргәзмәсе булды, А2 павильонында Russia China Expo һәм «РЕБУС» профильле күргәзмәсе узды, анда Россиянең 8 төбәгеннән һәм Кытайның 9 провинциясеннән 49 экспонент һәм 98

соэкспонент тәкъдим ителде.

Шулай ук махсуслаштырылган юнәлештәге чаралар уздырылды:

- 2024 елның 14–15 ноябрендә үткәрелгән «РЕБУС» халыкара форумы. Форум «Агломерации: Тәҗрибә. Мөмкинлекләр. Чакырулар» темасына багышланган. Агломерация үсеше өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм чит илләрнең хакимият органнары, бизнес һәм фән вәкилләре арасында тәҗрибә алмашу һәм агломерацияләр белән идарә итүнең норматив-хокукый базасын һәм механизмнарын камилләштерү турында тәкъдимнәр формалаштыру төп максатлар булып тора;

- Россия Федерациясе субъектларындагы муниципаль берәмлекләрнең инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру өчен «Инвестицияләр һәм үсеш агентлыклары илкүләм ассоциациясе» коммерциягә карамаган оешмасы тарафыннан Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы ярдщме белән 2024 ел эчендә Россия Икътисадый үсеш министрлыгы ярдәмендә Төмән, Иннополис, Липецк һәм Сочи шәһәрләрендә 4 муниципаль инвестицион форум уздырылды. Иннополис шәһәрендә форум 2024 елның 24 маеннан 25 маена кадәр үткәрелде. Форумда Россия Федерациясенең 38 субъектыннан 300 кеше катнашты. Болар – муниципаль инвестицион вәкаләтле вәкилләр, федераль һәм төбәк хакимият органнары, төбәк үсеш агентлыклары һәм эшлекле берләшмәләр вәкилләре. Иннополис шәһәрендә форум барышында Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының муниципаль инвестицион стандарт кертелешенә тулысынча туры килүен раслады дип игълан ителде;

- Дәүләти-хосусый партнерлык *буенча* VII Төбәкара тармак форумы (2024 елның 19 – 20 августы). 2024 елда форум мәйданчыгында беренче көнне – мәгариф программасы, икенче көнне дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендә әйдәүче экспертлар белән бизнес-уен үткәрелде. «Россиядә дәүләти-хосусый партнерлык: «хәл ителми торганнарны» хәл итәргә» дигән пленар утырышта эшкә йомгак ясалды, дәүләти-хосусый партнерлык механизмын яхшырту буенча иң яхшы идеяләр президиум әгъзаларына тәкъдим ителде;

- 2024 елның 30 сентябрендә Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында «Ислам (партнерлык) финанславы продуктлары буенча практикум» темасына түгәрәк өстәл оештырылды. Чара кысаларында ислам банкингын үстерү мәсьәләләре, аның яңа продуктлары, шулай ук тармакка йогынты ясый торган, законга кертелә торган үзгәрешләре буенча фикер алышынды. Түгәрәк өстәл йомгаклары буенча республика территориясендә ислам продуктлары турындагы мәгълүматны Ислам Үсеш банкына җибәрү хакында карар кабул ителде, бу мәгълүмат Татарстан Республикасына чит ил инвестицияләрен җәлеп итү һәм әлеге мәгълүматны дөнья күзәтүләренә кертү максатыннан эшләнде.

### Партнерлык финанслары

Татарстанда партнерлык финанславы буенча эшчәнлек алып баруга кирәкле шартлар тудыру өчен махсус җайга салуны билгеләү буенча экспериментны гамәлгә ашыру максатларында, банк секторы, югары белем бирү мәгариф оешмалары, руханилар, эксперт бергәлеге, базар катнашучылары, республика башкарма хакимият органнары белән берлектә, Татарстанда 2025 елның 1 сентябренә кадәр эксперимент чорына җентекле Чаралар планы (юл картасы) төзелде һәм расланды.

Чаралар планын гамәлгә ашыру кысаларында 6 төп юнәлеш буенча системалы эш алып барыла:

1. партнерлык (ислам) финанслары өлкәсендә халыкның һәм бизнесның мәгълүматлылыгын һәм финанс белемен арттыру;
2. партнерлык (ислам) финанслары өлкәсендә белгечләр әзерләү;
3. экспериментны гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм әлеге механизмны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;
4. партнерлык (ислам) финанслары өлкәсендә базар һәм финанс инфраструктурасын үстерү;
5. Татарстан Республикасында партнерлык (ислам) финанслары принципларында гамәлгә ашырыла торган проектларга инвестицияләр җәлеп итүгә ярдәм күрсәтү;
6. партнерлык (ислам) финанслары мәсьәләләре буенча халыкара хезмәттәшлекне киңәйтү.

Федераль һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларында ислам банкингына һәм партнерлык финансларына багышланган 1 600 материал бастырып чыгарылды. Базарда катнашучыларның мәгълүмати материалларын һәм финанс продуктларын бердәм цифрлы киңлеккә берләштерү, шулай ук потенциаль клиентлар белән максатчан адреслы эш алып бару өчен партнерлык финанславына багышланган бердәм портал – https://ifhub.ru эшләтеп җибәрелде.

Партнерлык финанслары турында мәгълүмат бирү чаралары халыкның финанс белемен күтәрү буенча төбәк программасына («2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы халкының финанс белемен арттыру һәм финанс культурасын формалаштыру») кертелде.

Мәгълүматлылык дәрәҗәсен, гамәлгә ашырыла торган чараларның нәтиҗәлелеген мониторинглау, ислам продуктларындагы проблемаларны һәм аларга ихтыяҗны ачыклау максатларында халыкның һәм базарда катнашучыларның социологик тикшеренүләре даими нигездә уздырыла. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы уздырган соңгы социологик сораштыру мәгълүматларына караганда, бизнесның мәгълүматлылыгы 20 процентка артуы теркәлә.

# ФӘННЕ ҺӘМ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ ҮСТЕРҮ

**Фәнни-технологик үсеш**

Татарстан Республикасының фәнни комплексы 120 оешмадан гыйбарәт, шул исәптән:

32 фәнни-тикшеренү учреждениесе;

39 югары белем бирү мәгариф оешмалары;

7 проект-конструкторлык бюросы;

25 корпоратив фәнни-тикшеренү институты һәм конструкторлык бюросы;

17 башка оешма.

Фәнни-технологик үсеш өлкәсендә барлык катнашучыларның координаторы роле «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» (алга таба – Фәннәр академиясе) дәүләт фәнни бюджет учреждениесенә – республиканың күпмилләтле халкы телләрен, мәдәни кодын һәм тарихи мирасын саклап калу белән беррәттән, эшчәнлеге фәнне үстерүгә ярдәм итүгә, фәнни белемнәрне таратуга, фән абруен күтәрүгә юнәлтелгән зур төбәк фәнни учреждениесенә бирелә.

Фәннәр академиясе эшчәнлегенең мөһим юнәлеше – аспирантурада яшь фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү (социогуманитар һәм табигый фәннәр буенча 17 фәнни белгечлек). Фәннәр академиясендә 2 фән (тарих һәм филология) тармагында 5 фәнни белгечлек буенча ике диссертация советы эшли.

Республикада «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге (алга таба – «РФА Казан фәнни үзәге» ФТҮ) эшли, ул 7 зур тикшеренү бүлекчәсен берләштерә торган интеграцион тикшеренү платформасы булып тора.

Республика фәнни-мәгариф комплексының нигезе – ул югары белем бирелә торган төп мәгариф оешмалары, алар арасында КФУ, КМТТУ-КАИ, КМТТУ аерым урын алып тора. Алар тикшеренүләрнең һәм эшләнмәләрнең төбәк секторын үстерүгә шактый өлеш кертә, аларга фәнни программаларны һәм проектларны фондка кертү өчен еллык җыелма чыгымнар күләменең якынча 30 проценты туры килә.

Татарстан Республикасы 2023 ел йомгаклары буенча Фәнни-технологик үсеш милли рейтингында (Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгы тарафыннан 2024 елның декабрендә тәкъдим ителгән) һәм «Икътисад югары мәктәбе» милли тикшеренү университеты әзерләгән Россия субъектларының инновацион үсеш рейтингында лидер төбәкнең өчлегенә керә.

Моннан тыш, Татарстан субъектларны фәнни-технологик үстерү буенча җитәкчеләр институтын кертү һәм үстерү методологиясен эшләү өчен Россия Федерациясенең 20 «пилот» төбәгенә керә. 2024 елда фәнни-технологик үсеш белән идарә итү системасының җитлеккәнлеген бәяләү уңышлы апробацияләнде. Аның нәтиҗәләре буенча фәнни-технологик үсеш белән идарә итү системасының җитлегү индексы буенча гомуми рейтингта республика өченче урынны яулады.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 декабрь, 1429 нчы карары белән «Татарстан Республикасын фәнни-технологик үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы расланды, ул илнең технологик суверенитетын формалаштыруда төбәк тикшеренүләре һәм эшләнмәләре секторы ролен арттыруга

юнәлдерелә. Әлеге программаның төп чаралары кысаларында Татарстанның белем бирү һәм тикшеренү потенциалын ныгыту, талантлар җәлеп итү, заманча үсешнең стратегик юнәлешләре буенча фән һәм сәнәгатьнең үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру буенча берничә яңа, мөһим инициатива башлап җибәрелде.

Шулай итеп, дәүләт программасы кысаларында квалификацияне күтәрү буенча «Школа завлабов» өстәмә һөнәри программасы гамәлгә ашырыла башлады, бу фундаменталь һәм гамәли фәнни тикшеренүләрнең сыйфатын яхшыртырга, республика фәнни-белем бирү комплексы эшенең кадрлар нигезләрен камилләштерергә, фән һәм югары белем бирү өлкәсендә интеграцион процессларны үстерергә, фәнни-мәгариф оешмаларының урта звено җитәкчеләренең идарә эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күтәрергә мөмкинлек бирәчәк. 2024 елда «Школа завлабов»та якынча 400 кеше белем алды.

Технологик үсеш драйверлары – аддитив технологияләр, пилотсыз авиация һәм ясалма интеллект кебек перспектив тармаклар.

Профильле министрлыклар һәм экспертлар белән берлектә, пилотсыз авиация системалары һәм аддитив технологияләр буенча ике республика программасы проектлары эшләнде. Программалар икътисадның кайбер төп проблемаларын хәл итүне тәэмин итә һәм фән, мәгариф, бизнес, хакимият органнары эшчәнлеген синхронлаштыра. 2025 елда программаларны гамәлгә ашыру буенча «юл карталары» эшләнә.

Фәнне популярлаштыру

Фәнне һәм технологияләрне алга таба үстерү, социаль-икътисадый үсешнең мөһим бурычларын хәл итүдә аларның ролен көчәйтү, шулай ук фәнне популярлаштыру һәм тикшеренүләр өлкәсенә яшь талантларны җәлеп итү максатларында республикада Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, б-3227 нче боерыгы белән расланган Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча тематик план гамәлгә ашырыла.

2024 ел Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан ителде, аны уздыру планы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 30 декабрь, б-3268 нче боерыгы белән расланды. Ел дәвамында конгресс-күргәзмә һәм иҗтимагый-агарту чаралары (фәнни-гамәли конференцияләр, күргәзмәләр, юбилей тантаналары, тармак форумнары һәм халыкара симпозиумнар) шактый санда уздырылды, алар якынча 500 мең кешене җәлеп итте.

2024 елның 25–26 апрелендә Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеш елы эгидасы белән Россия венчур форумы уздырылды. Форумны оештыру һәм үткәрү эше Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры В.Н.Фальков рәислегендәге оештыру комитеты тарафыннан алып барылды. Чарада 4 меңнән артык кеше катнашты, шуларның 150дән артыгы – инвесторлар һәм экспертлар.

2024 елның 9–11 сентябрендә Казан шәһәрендә «Kazan Digital Week – 2024» халыкара форумы үткәрелде. Форум миссиясе – фәнни–техник мәгълүмат алмашу, импортны алыштыру бурычларын нәтиҗәле хәл итәргә сәләтле фәнни-технологик активларны берләштерү, халыкара хезмәттәшлектә Россия Федерациясе лидерлыгының нигезе буларак белешмәләрнең технологик суверенитетын тәэмин итү. Форум мәйданчыкларында 140тан артык стенд тәкъдим ителде, аларда 200дән артык алдынгы ИТ-компания үз чишелешләрен күрсәтте. Чарада дөньяның 64

иленнән 18 меңгә якын кеше катнашты, якынча 7 мең тамашачы чарага онлайн кушылды. Шулай ук 100дән артык секция булды, аларда 600дән артык спикер чыгыш ясады.

Фәнне популярлаштыру, фәнни берләшмәләрне фәнни-тикшеренү эшләренең нәтиҗәлелеген күтәрүгә һәм яшьләрне фәнни тикшеренүләргә җәлеп итүгә стимуллау, фәнни хезмәтнең абруен күтәрү максатларында Фәннәр академиясе тарафыннан фән өлкәсендә «Научный прорыв. Фәнни алга китеш» премиясе гамәлгә куелды. 2024 ел йомгаклары буенча премия 11 номинация лауреатларына тапшырылды.

2024 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды һәм Татарстан Республикасының Фән һәм технологияләр фонды катнашында яңартылган «Ел инновациясе» республика конкурсы старт алды. Конкурс нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасындагы дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-белем бирү үзәге эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча 22 җиңүче проектка 5 млн сум күләмендә ярдәм күрсәтелде: «Мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләре», «Яңа химия, нефть химиясе һәм яңа материаллар», «Машина төзелеше һәм приборлар төзелеше», «Биотехнологияләр һәм агросәнәгать комплексы», «Медицина һәм кеше сәламәтлеге».

Моннан тыш, Татарстан Республикасының Фән һәм технологияләр фонды тарафыннан 2035 елга кадәр Татарстан Республикасында фәнни-популяр туризмны үстерү концепциясе эшләнде. Фәнни-популяр туризм объектларының бөтенроссия реестрына республиканың 71 объекты кертелде, шулай ук фәнни казанышларны һәм технологияләрне популярлаштыруга юнәлдерелгән 5 маршрут эшләнде.

**2024 елда «Фән һәм университетлар» илкүләм проектын һәм социаль-икътисадый үсешнең стратегик инициативаларын гамәлгә ашыру**

Татарстан Республикасының төп фәнни-мәгариф комплексы оешмалары илнең фәнни-технологик үсешенең барлык стратегик инициативаларында катнаша.

«Университет технологик эшкуарлыгы платформасы»

«Университет технологик эшкуарлыгы платформасы» федераль проекты кысаларында Татарстанда түбәндәге проектлар эшләтеп җибәрелде:

продуктны булдырудан алып аны масштаблауга күчерү максаты белән стартапларга инвестицион ярдәм күрсәтә торган «Лобачевский» университет венчур фонды;

студентларның эшкуарлык потенциалын үстерү өчен Татарстан Республикасының университет стартап-студиясе (гамәлгә куючылары – КФУ, «КАМАЗ» ГАҖ, Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды, Инфраструктура һәм мәгариф программалары федераль фонды). 2024 елда республика проект кысаларында үткәрелә торган «Студентлар стартабы» бөтенроссия конкурсында җиңүчеләр саны буенча абсолют рекордсмен булды: Россия төбәкләре арасында ТОП-100 рейтингына кергән стартап-проектлар саны буенча 1 урын һәм ТОП-50гә кергән стартап-проектлар саны буенча 2 урын алды.

«Приоритет-2030» стратегик академик лидерлыгы программасы

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 13 маендагы 729 номерлы карары нигезендә 2021 елдан бирле гамәлгә ашырыла торган «Приоритет-2030»

стратегик академик лидерлык программасы университетларны үстерү программаларына ярдәм күрсәтүгә һәм 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешүдә Россия университетларының өлешен арттыруга, илнең балансланган пространстволы үсешенә, сыйфатлы югары белем алу мөмкинлеген тәэмин итүгә юнәлдерелде.

2024 елда программага Казан дәүләт медицина университеты керде, ул республиканың 4 югары белем бирү мәгариф оешмасы: КФУ, КМТТУ-КАИ, КМТТУ, КДЭУ белән беррәттән, программа грантының база өлешен гамәлгә ашыруда катнашты.

Казан дәүләт мәдәният институты 2024 елның апрелендә программа кандидатлары төркеменә керде. Югары белем бирү мәгариф оешмасы бу статуста 3 елга кадәр булырга һәм җәлеп ителгән финанс хисабына үсеш программасын тормышка ашырырга мөмкин.

КФУ һәм КМТТУ грантның махсус өлешен алуны билгеләп үтәргә кирәк. 2024 елда республикада югары уку йортларына бирелгән ассигнованиеләр суммасы 1,6 млрд сум тәшкил итте. Программаны гамәлгә ашыруның бөтен чорында республикага 4,5 млрд сум җәлеп ителде.

2025 елда Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгы тарафыннан, Россиянең технологик лидерлыгына ирешүгә фокус ясап, «Приоритет-2030» программасын яңадан эшләтеп җибәрү планлаштырыла.

Алдынгы инженерлык мәктәпләре

Югары квалификацияле инженерлык кадрларын, шулай ук икътисадның өстенлекле тармаклары ихтыяҗлары өчен эшче белгечлекләрен алдан әзерләү максатларында Татарстанда республиканың югары белем бирелә торган алдынгы мәгариф оешмалары базасында төзелгән инженерлык мәктәпләренә дәүләт ярдәме күрсәтелә. Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 25 маендагы 388 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм итү өчен 2024 елга биш югары уку йорты өчен 411,78 млн сум тәшкил итте.

Хәзерге вакытта Татарстан территориясендә Санкт-Петербург милли тикшеренү мәгълүмат технологияләре, механика һәм оптика университеты белән бергәләп эшләүче алдынгы инженерлык мәктәбен кертеп, түбәндәге алдынгы инженерлык мәктәпләре эшли:

беренче чираттагы 3 мәктәп (2022 елдан бирле эшли): «Кибер Авто ТЕХ» алдынгы инженерлык мәктәбе (КФУ), «Промхимтех» алдынгы инженерлык мәктәбе (КМТТУ), «Яңа буын ИТ-инженерлар һәм технологик бизнес өчен Россия программа тәэминатын эшләү» алдынгы инженерлык мәктәбе (Иннополис университеты);

икенче чираттагы 2 мәктәп (2024 ел башыннан бирле эшли): «Комплекслы авиация инженериясе» алдынгы инженерлык мәктәбе (КМТТУ-КАИ), «Алдынгы инженерлык нефть мәктәбе» алдынгы инженерлык мәктәбе («Нефть югары мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты).

Әлеге алдынгы инженерлык мәктәпләре югары квалификацияле белгечләр әзерләүне актив алып баралар һәм икътисадның төп тармаклары өчен технологик карарлар әзерлиләр.

Заманча кампуслар челтәрен төзү

Республикада дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф инфраструктурасы объектлары актив проектлана, төзелә һәм яңартыла.

2024 елның 1 февралендә Әлмәт шәһәрендә Әлмәт дәүләт технология университеты базасында «Нефть югары мәктәбе» кампусын ачу тантанасы уздырылды («Татнефть» ГАҖ ярдәмендә). Тантанада Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин катнашты. Кампус территориясендә студентларны, яшь галимнәрне һәм аларның гаиләләрен уңайлы яшәү һәм укыту өчен кирәкле бөтен инфраструктура булдырылды. Биредә югары уку йортлары һәм тармак фәне, гамәли юнәлешле белем бирү һәм реаль производство гармонияле рәвештә берләшә. Кампус территориясендә Әлмәт дәүләт технология университеты һәм ТатНИПИнефтьның тармак институты бергәләп эшли.

СИБУР холдингы ярдәме белән КНИТУ Түбән Кама химия-технология институтының фәнни-белем бирү кампусы иң заманча халыкара стандартларына кадәр яңартылды.

**Инновацион үсеш**

Инновация эшчәнлеген үстерүгә зур игътибар бирелә, чөнки ул инновацияләр икътисадның уңышлы үсеше өчен драйвер булып тора.

Татарстан Республикасы һәрвакыт инновацион эшчәнлек күрсәткечләре буенча алдынгы регионнар исемлегенә керә.

Заманча инновация инфраструктурасы булу һәм дәүләт тарафыннан актив ярдәм күрсәтелү республикада инновация активлыгын үстерү өчен уңай шартлар тудырды. Төяп җибәрелгән инновация продукциясе күләме, технологик инновацияләрне гамәлгә ашыручы оешмалар өлеше, инновацияләргә чыгымнар һ.б. арту моңа дәлил булып тора.

2023 елда төяп җибәрелгән инновацион товарлар, эшләр, хезмәтләр күләме 1 126,2 млрд сум тәшкил итте, бу 170,6 млрд сумга, ягъни 2022 елга караганда 17,8 процентка (955,6 млрд сум) күбрәк. Бу күрсәткеч буенча Татарстан Россия Федерациясе төбәкләре арасында 2 нче урынны (Мәскәү шәһәреннән соң – 1 358,9 млрд сум) алды.

Төяп җибәрелгән инновацион товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең гомуми күләмендә сәнәгать предприятиеләренең инновацион продукциясен төяп җибәрү өлеше 93% (1 044,6 млрд сум) тәшкил итте. 2023 елда сәнәгать оешмаларында төяп җибәрелгән үз җитештерүендәге товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең гомуми күләмендә төяп җибәрелгән инновация продукциясе өлеше 22,9% (2022 елга караганда 1,4 процент пунктка күбрәк) тәшкил итте.

2023 елда 22 процентка инновация чыгымнары артты, ул 314,9 млрд сум (2022 елда – 258,2 млрд сум) күләмендә тәшкил итте.

Төяп җибәрелгән товарларның, башкарылган эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең гомуми күләмендә инновацион эшчәнлеккә чыгымнарның чагыштырма күләме 2023 елда 5,5% (2022 елда – 5,1%) тәшкил итте. Бу күрсәткеч буенча Татарстан Россия Федерациясе төбәкләре арасында икенче урында (Түбән Новгород өлкәсеннән соң – 5,7%) тора.

Оешмаларның инновацион активлыгы дәрәҗәсе арту дәвам итте, ул 2023 елда

33,6% (2022 елда – 32%) тәшкил итте. Бу күрсәткеч буенча Татарстан Россия Федерациясе төбәкләре арасында 1 урында тора.

Тикшерелгән оешмаларның гомуми санында технологик инновацияләрне гамәлгә ашыручы оешмалар өлеше арту дәвам итә, 2023 елда 47% (2022 елда – 46%) тәшкил итте. Бу күрсәткеч буенча Татарстан Республикасы Идел буе федераль округында алда бара һәм Россия Федерациясе төбәкләре арасында Ростов өлкәсеннән соң 2 нче урында тора.

2023 елда 126 кече предприятие технологик инновацияләрне гамәлгә ашырды, бу 2021 елга караганда 77 процентка күбрәк (71 кече предприятие). 2023 елда технологик инновацияләрне гамәлгә ашыручы кече предприятиеләр өлеше, тикшерелгән кече предприятиеләрнең гомуми санында 14% тәшкил итте. Бу күрсәткеч буенча Татарстан Россия Федерациясе субъектлары арасында алда бара.

2023 елда кече предприятиеләр тарафыннан инновацион товарларны төяп җибәрү күләме 24,4 млрд сум тәшкил итте, 2021 ел дәрәҗәсенә карата 3,5 тапкырга (2021 елда – 6,9 млрд сум) артты. Кече предприятиеләрнең инновацияләргә чыгымнары дүрт тапкырга артты, бу 2023 елда 8 млрд сум (2021 елда – 1,9 млрд сум) тәшкил итте.

**Кече инновация эшкуарлыгына ярдәм чаралары**

Татарстанның икътисад үсеше резервларыннан берсе – ул кече һәм урта эшкуарлыкны, шул исәптән югары технологияле эшкуарлыкны үстерү, аның эшчәнлеге нигезендә югары технологияле җитештерүләр булдыру, шулай ук яңа технологияләрне гамәлгә кертү һәм куллану ята, бу республика предприятиеләренең эчке һәм чит ил базарларында конкурентлык сәләтенә йогынты ясый, әлбәттә. Мондый бизнесны үстерү өчен яңа эшләнмәләрне апробацияләү һәм кертү өчен грант һәм заем акчасы рәвешендә өстәмә финанслар җәлеп итү зур ярдәм булып тора.

Татарстанның Фәнни-техник өлкәдә кече формадагы предприятиеләр үсешенә ярдәм фонды (алга таба – Инновацияләргә ярдәм фонды) белән хезмәттәшлек итүе инновацион проектларга инвестицияләр җәлеп итү өчен өстәмә мөмкинлекләр ача, бу сәнәгатьне модернизацияләү процессын, яңа технологияләр үсешен һәм төбәктә тормыш дәрәҗәсен күтәрүне тизләтергә мөмкинлек бирә. Инновацияләргә ярдәм фонды инновацион эшләнмәләр белән шөгыльләнүче яңа компанияләр оештыру һәм булганнарын үстерү өчен конкурс нигезендә грантлар бирә.

Шулай итеп, 2024 елда Инновацияләргә ярдәм фонды тарафыннан 317 республика инновацион проектына ярдәм күрсәтелде, 441 млн сумлык гомуми суммага федераль финанслар җәлеп ителде.

Республикада Инновацияләргә ярдәм фондының төбәк вәкиле – Татарстан Республикасының Эшкуарлыкка ярдәм фонды, 2024 елда аның белән бергә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Инновацияләргә ярдәм фонды конкурсларында катнашу, заявкалар әзерләү һәм хисаплылык бирү мәсьәләләре буенча физик затларга һәм кече инновацион предприятиеләргә якынча 3 400 консультация бирелде.

Моннан тыш, 2024 елда республика студентлары һәм кече предприятиеләре өчен Инновацияләргә ярдәм фонды программаларын презентацияләү максаты белән

32 күчмә семинар оештырылды һәм уздырылды. Күчмә семинарлар республика башкарма хакимият органнарында, муниципаль районнарда, инновацион инфраструктура оешмаларында, югары уку йортларында үткәрелде.

Төбәктә кече һәм урта бизнеска ярдәм итүдә һәм аны үстерүдә «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорациясе» АҖ (алга таба – «КУЭ» корпорациясе» АҖ) белән үзара хезмәттәшлек итү мөһим роль уйный, югары технологияле һәм инновацион предприятиеләр өчен эшләнгән ташламалы кредит бирү программасы ярдәм итүнең бер чарасы булып тора. Программа перспективалы проектларны гамәлгә ашыру, яңа технологияләр кертү һәм җитештерү куәтләрен киңәйтү өчен кирәкле, бик уңай һәм отышлы финанс шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелде.

Әлеге программа Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан «МСП» корпорациясе» АҖ һәм «МСП Банк» АҖ белән берлектә гамәлгә ашырыла. Кредитлар «МСП Банк» АҖ тарафыннан бер заем алучыга 1 млрд сумга кадәр күләмдә ташламалы ставка белән бирелә. 2024 елның 1 февраленнән ташламалы кредитлардан кече һәм урта эшкуарлык субъектларына гына түгел, ә кече технологик компанияләргә дә файдаланырга мөмкин.

Ярдәм күрсәтелү өчен 14 тармак предприятиеләре өстенлеккә ия. Ясалма интеллект, коммуникация технологияләре, интернет әйберләр, яңа җитештерү һәм генетика технологияләре, биотехнологияләр һәм фармацевтика, яңа материаллар һәм матдәләр технологияләре белән бәйле компанияләр ярдәм күрсәтүгә дәгъва итәргә мөмкин.

2024 елда югары технологияле, инновацион компанияләргә ташламалы кредит бирү программасында катнашу кысаларында 4 республика компаниясе 410 млн сумга кредит шартнамәләре төзеде.

Кече технологик компанияләр (алга таба – КТК) Татарстан Республикасының инновацион экосистемасында мөһим урын алып тора, аның икътисадый үсешенә һәм технологик үсешенә шактый дәрәҗәдә ярдәм итә.

Аларның эшчәнлегенең хокукый нигезләрен билгели торган «Россия Федерациясендә технологик компанияләрне үстерү турында» 2023 елның 4 августындагы 478-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителде. 2024 ел нәтиҗәләре буенча КТК реестрында 159 Татарстан компаниясе бар (Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән соң Россия буенча 3 урын).

**Инновацион инфраструктураны үстерү**

Татарстанда КУЭ үсешенә республикада бизнеска ярдәм күрсәтү буенча булдырылган инфраструктура да ярдәм итә. Элеккечә, мәйданчыкларның белгечлеген исәпкә алып, инновацион компанияләрне үстерүгә ярдәм итә торган технопарклар структуралары республиканың инновация инфраструктурасы чылбырында төп звенолар булып кала. Технопаркларда республика үсешенең өстенлекле юнәлешләре буенча инновацияләр генерациясе бара.

Мәсәлән, 2024 ел йомгаклары буенча «Идея» инновация-җитештерү технопаркында 143 резидент компания эшләде, алар нигездә мәгълүмат технологияләре һәм автоматлаштыру, инжиниринг һәм метрология, консалтинг һәм мәгариф хезмәтләре, тренажер-симуляторлар җитештерү өлкәсендә эш алып бара.

Технопарк кече инновацион компанияләргә ярдәм күрсәтә, аларга бүлмәләрне, җайланмаларны, җиһазларны ташламалы шартларда арендага бирә, проектларны алып бару буенча комплекслы хезмәтләр күрсәтә. 2024 елда технопаркта стартаплар өчен акселерацион программалар буенча компетенцияләр үзәге булдырылды.

Шулай ук Татарстанда югары технологияләр өлкәсендә 4 технопарк мәйданчыгы булдырылды – бу мәгълүмат һәм коммуникация технологияләре тармагын үстерү өчен уникаль мәйданчыклар.

«Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» ДАУ (алга таба – «ИТ-парк» ДАУ) Казан һәм Чаллы шәһәрләренең өч мәйданчыгында урнаша һәм үз илебезнең программа тәэминатын эшләп чыгару белән шөгыльләнә. ИТ-парк резидентлары – 600дән артык компания (экстерриториаль резидентларны исәпкә алып). 2024 елда Бәшир Рәмиев исемендәге технопарк нәтиҗәле эш алып баруын күрсәтте, ул цифрлы үсешнең катализаторына әверелде һәм республика икътисадына инвестицияләр җәлеп итүче йөзләрчә перспектив стартапларны, балалар ИТ-паркы фиджитал-технологияләрне берләштерде (физик һәм цифрлы чынбарлыкны яраштыру).

ИТ-паркның техник һәм бизнес инфраструктурасы, өзлексез камилләшеп һәм резидентлар өчен төрледән төрле сервислар тәкъдим итеп, стартап-проектларны һәм ИТ-компанияләрне барлык үсеш стадияләрендә: югары технологияле продукт чыгару идеясеннән башлап аның соңгы продуктын базарга чыгарганга кадәр комплекслы үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтү өчен экосистема тудыра.

«Иннополис» МИЗ территориясендә урнашкан «ИнноПарк» югары технологияләр өлкәсендә тагын бер технопарк актив үсеш ала. Аның мәйданчыгында «Марс Технологии» компаниясенең «МАРС-АРСЕНАЛ» (халыкка хәбәр итү системалары) һәм «МАРС-МОНИТОРИНГ» (процессларны һәм куркыныч факторларны мониторинглау системалары) мәгълүмат-коммуникация платформаларының техник гамәлгә кертү потенциалы базасында дөньякүләм дәрәҗәдәге махсус программа тәэминаты һәм электрон җиһазлар булдыру, аппарат-программа комплекслары җитештерү, «ТА-Мәгълүмат технологияләре» Россия-Кытай предприятиесенең телекоммуникация һәм ИТ-җиһазлары җитештерү, Ozon Tech конвейер системаларын автоматлаштыру, Иннополис университетының «Робототехника үзәге» фәнни-җитештерү үзәгенең һәм «ДАС» компаниясенең алга киткән үтәли технологияләрен кулланып, предприятиедә җитештерү процессларын роботлаштыру, Монтанум компаниясе төзелеше өлкәсендә автоматлаштыру комплексы («Проект24»), Россия базарында «РУСДРОНОПОРТ» компаниясенең беренче серияле дронопортлар производствосы кебек инновацион җитештерү проектлары уңышлы үстерелә.

**Интеллектуаль милек өлкәсен үстерү**

Интеллектуаль милек өлкәсен үстерүгә аерым игътибар бирелә, анда патент активлыгы хәл-торыш индикаторларының берсе булып тора.

Интеллектуаль милек федераль хезмәте (Роспатент) мәгълүматлары буенча, 2024 елда республика предприятиеләре һәм оешмалары тарафыннан 1 481 заявка бирелде һәм интеллектуаль милек объектларына 1 066 патент алынды, шулардан 701 патент – уйлап табуга, 284 – файдалы модельгә, 81 сәнәгать үрнәгенә бирелде.

Инновацион эшчәнлек өлкәсендә эшкуарлык һәм фәнни бергәлеккә мәгълүмат һәм консультация бирү характерында ярдәм күрсәтү өчен цифрлы платформа – «Татпатент» «Татарстан Республикасы интеллектуаль потенциалы» мәгълүматлар банкы» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасы эшли. Платформа инновацион бизнеска ярдәм итү чаралары, патент эзләү һәм интеллектуаль милек объектларын теркәү буенча мәгълүмат һәм консультацияләр алырга мөмкинлек бирә. 2024 елда әлеге платформа 9 309 тапкыр файдаланылды, 330 шәхси кабинет (физик затларның 180 шәхси кабинеты һәм юридик затларның 150 шәхси кабинеты) булдырылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасының граждан билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләрен дәүләт исәбенә алу һәм саклау бердәм системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 ел, 12 март, 133 нче карары нигезендә граждан билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләрен дәүләт исәбенә алу һәм саклау эше дәвам итте, аларның финанс белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла. 2006–2024 елларда әлеге системада 2,3 млрд сумлык гомуми суммага 2 543 гражданлык билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр теркәлде.

«Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының ведомство буйсынуындагы «Татарстан Республикасының Фәнни-техник мәгълүмат үзәге» ДАУ базасында уйлап чыгару эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү, фән һәм техникада талантларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү, предприятиеләрнең гамәли фәнни-тикшеренү эшчәнлеге нәтиҗәләрен коммерцияләштерү процессларын үстерү, технологияләр трансферының нәтиҗәлелеген, технологияләр экспортын һәм техник характердагы хезмәтләрне арттыру максатларында Уйлап чыгару эшчәнлеге буенча күпфункцияле республика үзәге төзелде.

Инновацион проектларга ярдәм күрсәтү һәм технологик үсешкә бюджеттан тыш инвестицияләү инструментларын стимуллаштыру максатларында 2024 елда интеллектуаль милек объектларына хокукларны залогка алып эшкуарлык субъектларына кредит бирү буенча пилот проекты эшли башлады. Татарстан Республикасының Гарантия фонды, Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды белән берлектә, түбәндәге финанс продуктлары гамәлгә ашырыла:

«Файдалы модель»: заем күләме 6 млн сумнан 15 млн сумга кадәр, ставкасы – бер елга 7%, заемның максималь срогы 48 айга кадәр;

«Приоритетлы» микрофинанс продукты: микрозаем күләме 300 мең сумнан 5 млн сумга кадәр, ставкасы – бер елга 9,5%, максималь срогы 36 айга кадәр.

Бу продуктлар буенча тәэмин ителеш булып физик йә юридик затның, йә индивидуаль эшкуарның акча түләүне үз өстенә алу йөкләмәсе һәм Татарстан Республикасы Гарантия фондының акча түләүне үз өстенә алу йөкләмәсе тора.

Татарстан Республикасы Гарантия фондының акча түләүне үз өстенә алу йөкләмәсе өчен бүләкләү күләме бер елга 0,75% тәшкил итә. Акча түләүне үз өстенә алу йөкләмәсенең тәэмин ителеше – кече һәм урта эшкуарлык субъектларына

караган интеллектуаль милек объектларына хокуклар залогы, аларның кыйммәте бәйсез бәяләү уздыру турында хисап белән раслана һәм акча түләүне үз өстенә алу йөкләмәсе күләменнән артып китә.

Залогны теркәү Интеллектуаль милек федераль хезмәте (Роспатент) тарафыннан башкарыла.

## КЕЧЕҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫК

2025 елның 1 гыйнварына республикада түбәндәгеләр теркәлде:

178,3 мең кече һәм урта эшкуарлык (алга таба – КУЭ) субъекты яисә 2024 ел башына карата 103,3% (5,7 мең субъектка арту);

КУЭ өлкәсендә эшләүче 620,0 мең кеше, яисә 2024 ел башына 103,7% (22,3 мең кешегә арту);

357,3 мең үзмәшгуль граждан яисә 2024 ел башына карата 116,7% (51,1 мең үзмәшгуль кешегә арту). Икътисадый актив үзмәшгуль затлар өлеше 67,7% тәшкил итте.

2024 елда кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс һәм финанс булмаган ярдәм чаралары комплексы күрсәтелде. Якынча 40 мең КУЭ субъектына ярдәм күрсәтелде, шуларның 4 меңнән күбрәге 83 млрд сумнан артык гомуми суммага финанс ярдәменнән файдаланды:

республика ярдәм чаралары:

акча түләүне үз өстенә алу йөкләмәсе – 4,1 млрд сум (4 083,4 млн сумга 715 акча түләүне үз өстенә алу йөкләмәсе), бу эшкуарларга 9 843,5 млн сум күләмендә заем финансларын җәлеп итәргә мөмкинлек бирде;

ташламалы заемнар һәм микрозаемнар – 2,4 млрд сум (2 273,5 млн сумга 885 микрозаем һәм 22,2 млн сумга 2,2 займ;

партнерлык финанславы – 130,2 млн сум (39 алыш-биреш);

электр энергиясе чыгымнарын субсидияләү – 29,9 млн сум (20 субсидия);

ташламалы лизинг – 438,4 млн сум (63 лизинг алучы);

федераль ярдәм чаралары:

сәнәгать ипотекасы – 933,4 млн сум;

кредит бирүне субсидияләү – 11,0 млрд сум;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләр өчен ташламалы кредит бирү – 53,1 млрд сум;

2,5 – 4% белән ташламалы кредит бирү – 550,0 млн сум;

ИТ-оешмалар өчен ташламалы кредитлар – 501,6 млн сум;

кредитларны реструктуризацияләү – 9,4 млрд сум.

2024 елда «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуар инициативасына ярдәм» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында республикада түбәндәге 3 төбәк проекты тормышка ашырылды:

1. «Үзмәшгуль гражданнар тарафыннан эшчәнлек гамәлгә ашырылу өчен уңай шартлар тудыру».

Проект кысаларында ташламалы ставка буенча микрозаемнар, акча түләүне үз өстенә алу йөкләмәсе бирелде, «Минем бизнес» үзәге базасында үзмәшгуль гражданнарга мәгълүмат-консультация хезмәтләре күрсәтелде;

2. «Җиңел старт алу һәм бизнесны уңайлы алып бару өчен шартлар тудыру».

Проект кысаларында комплекслы хезмәтләр күрсәтү, эш башлаучы эшкуарларга комплекслы финанс-гарантия ярдәме күрсәтү (микрозаемнар, акча түләүне үз өстенә алу йөкләмәсе) тәэмин ителде;

3. «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектлары акселерациясе».

Проект кысаларында комплекслы финанс-гарантия ярдәме, ташламалы микрозаемнар бирелде, КУЭның экспортка юнәлтелгән субъектларына ярдәм итү, сәнәгать мәйданчыкларын үстерү буенча комплекслы хезмәтләр күрсәтелде.

2024 елда эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына дәүләт ярдәме өчен 1,1 млрд сумнан артык акча җибәрелде, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 1,0 млрд сум һәм «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында федераль бюджет исәбеннән – 129,4 млн сум.

**Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасын үстерү**

Территорияләрне комплекслы үстерү, сәнәгать паркларының нәтиҗәлелеген арттыру һәм эш урыннары санын арттыру өчен Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов тарафыннан авыл җирендә сәнәгать паркларына карата концепция килештерелде, аның кысаларында аккредитацияләнгән сәнәгать паркларының резидентларына һәм идарәче компанияләренә түбәндәге мөмкинлекләрне бирә торган закон чыгару инициативалары кабул ителде:

салым салуның гадиләштерелгән системасы буенча салым ставкаларын (керемнәр ставкасы – 1 %, чыгымнар тотып калынган керемнәр ставкасы – 5 %) киметергә;

транспорт салымын түләү буенча салым ташламасын (0%) алырга;

оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым ташламасын (0%) алырга.

Аккредитацияләнгән, тулыланышы түбән дәрәҗәдә булган сәнәгать парклары территорияләрендә эшчәнлек алып баручы һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килешү төзегән резидентлар һәм идарәче компанияләр 10 елга кадәр салым ташламаларыннан файдаланырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан 94 сәнәгать паркы, шул исәптән 2024 елда – 11 сәнәгать паркы аккредитацияләнде.

КУЭ субъектларына һәм үзмәшгуль гражданнарга мөлкәти ярдәме күрсәтү өчен республикада дәүләт һәм муниципаль күчемле һәм күчемсез мөлкәт исемлеге расланды, аларга ташламалы ставка буенча арендага бирү өчен 1 240 объект керә.

Республикада «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проекты кысаларында «Кече һәм урта эшкуарлык корпорациясе» акционер җәмгыятенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын «үстерү» программасын тормышка ашыру дәвам итә. 2024 елда 40 КУЭ субъекты сайлап алынды, шуларның 12се – Инновацияләргә ярдәм фондының «Студентлар стартабы» грантында җиңүчеләр.

Субъектларга «Корпорации МСП» АҖ цифрлы платформасында скоринг бәяләре үткәрелде, үсешнең индивидуаль карталары эшләнде һәм гамәлгә ашырыла. 2020 – 2024 елларда «үстерү» чараларында катнашучыларга 9 млрд сумнан артык күләмдә финанс ярдәме күрсәтелде, шул исәптән Инновацияләргә булышлык фонды, Инжинирингка һәм инновацияләргә ярдәм үзәге (Иннопрактика) һәм «Технологик үсеш агентлыгы» коммерциягә карамаган автоном оешмасы грантлары, Сәнәгатьне үстерү фонды заемнары, ташламалы кредит, ташламалы заемнар һ.б. бирелде.

Моннан тыш, әлеге чор дәвамында 730га якын финанс булмаган ярдәм чарасы

күрсәтелде (продукцияне популярлаштыру, сертификацияләү, патент тикшеренүләре, маркетинг тикшеренүләре, товар билгесен теркәү, техник-икътисадый нигезләүне эшләү, бизнес-миссия һ.б.).

**Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм**

2024 елда яңа эшли башлаган, 23 айдан да элгәре теркәлмәгән КУЭ субъектлары өчен «Татарстан Республикасының Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит оешмасы (алга таба – Эшкуарлыкка ярдәм фонды) тарафыннан «Начинающие+» микрофинанс продукты булдырылды.

Эшләүче эшкуарлар өчен, шул исәптән икътисадның реаль секторыннан, түбәндәге дәүләт ярдәме чаралары тормышка ашырылды:

төп эшчәнлек төрләре файдалы казылмалар чыгару, электр энергиясе белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, транспорт белән ташу, төзелеш, сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү һ.б. булган КУЭ субъектлары өчен «Содействие» микрофинанс продукты (Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы B, D, E, F, H, L, M, S, Q, R бүлекләре);

КУЭ субъектлары өчен түбәндәге бер генә таләпкә булса да җавап бирүче КУЭ субъектлары өчен КУЭның өстенлекле юнәлешләрен үстерү бурычлары кысаларында «Приоритетлы» микрофинанс продукты:

төп эшчәнлек төре: эшкәртү производстволары, мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек, кунакханәләр һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре эшчәнлеге (Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы классификаторының C, J, I бүлекләре);

ташламалы шартларда бирү өчен билгеләнгән Региональ һәм муниципаль мөлкәт исемлегеннән күчемсез мөлкәт объектлары буенча гамәлдәге аренда шартнамәләре булган;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән индустриаль (сәнәгать) парклар территориясендә эшчәнлек башкару турында килешү төзегән;

2023 елда һәм (яисә) 2024 елда төяп җибәрүе расланган гамәлдәге экспорт контракты булган;

«Россия Федерациясендә технологик компанияләрне үстерү турында» 2023 елның 4 августындагы 478-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кече технология компанияләре реестрында торган;

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының норматив актында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләре буенча интеллектуаль милек залогы белән өстенлекле проектлар гамәлгә ашырган;

микрозаемга заявка биргән вакытта хәрби хезмәт үтәргә бурычлы бер һәм аннан да күбрәк хезмәткәрен контракт буенча хәрби хезмәт үтәргә җибәргән яисә махсус хәрби операция зонасында хәрби хезмәт үтеп кайткан шәхси эшмәкәре булган барлык КУЭ субъектлары өчен «Махсус хәрби операциягә ярдәм» микрофинанс продукты;

икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының төп коды нигезендә өстенлекле проектларны гамәлгә ашыручы КУЭ субъектлары – юридик затлар өчен, интеллектуаль милекне залогка биреп, «Файдалы модель» финанс продукты.

Моннан тыш, Татарстан территориясендә бизнесны партнерлык финанславы буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында махсус җайга салуны билгеләү буенча экспериментны гамәлгә ашыру кысаларында партнерлык (ислам) финанславы принциплары продуктларыннан файдаланырга мөмкин:

«Мурабаха-Ярдәм» – өлешләп түләгән өчен акчалата бүләкләү алып, түләү срогын озынайту шартларында эшкуарлык эшчәнлеге өчен кулланыла торган товарларны (җиһазларны) сатып алу-сату юлы белән финанслау;

«Иджара-Җитештерүне үстерү» – финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча сәнәгать парклары территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җиһазлар бирү юлы белән финанслау.

2024 елда Эшкуарлыкка ярдәм фондының «Минем бизнес» үзәге тарафыннан:

28 меңнән артык КУЭ субъекты һәм үзмәшгуль гражданнар, физик затлар өчен 46 меңнән артык хезмәт күрсәтелде, 77 чара, шул исәптән Татарстан Республикасында эшкуарлар көне, «Минем бизнес. E-com» форумы, үзмәшгуль гражданнар өчен «Мин Татарстан инде ул» дигән ярминкәләр һ.б. оештырылды;

«Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорация» АҖ тарафыннан эшләнгән 50дән артык тренинг үткәрелде, аларда 2 600дән артык кеше катнашты;

5 100дән артык үзмәшгуль гражданга мәгълүмат-консультация бирү характерындагы хезмәтләр күрсәтелде;

201 КУЭ субъекты социаль предприятие итеп танылды;

социаль эшкуарлык мәсьәләләре, социаль һәм социаль-эшкуарлык проектларын үстерү буенча 3 500 меңнән артык консультация бирелде;

1 600дән артык граждан социаль контракт буенча укуларда булды һәм сертификатлар алды;

социаль эшкуарлык өлкәсендә һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар проектлары буенча «Минем игелекле бизнес» бөтенроссия конкурсының төбәк этабы уздырылды, аның кысаларында социаль предприятиеләрнең 9 проекты һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның 7 проекты җиңү яулады;

күргәзмә-ярминкә чараларында катнашу, маркетплейсларга чыгу, үз продукциясен/хезмәтләрен тарату буенча 2 700дән артык комплекслы хезмәт күрсәтелде.

Эшкуарлыкка ярдәм фондының Экспортка ярдәм үзәге тарафыннан:

«Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проекты кысаларында якынча 3,4 КУЭ субъектына ярдәм чаралары күрсәтелде;

58 КУЭ субъектына чит ил базарларына чыгуда ярдәм күрсәтелде;

20 халыкара күргәзмә-ярминкә чарасында 61 уникаль КУЭ субъектының катнашуы оештырылды;

халыкара электрон сәүдә мәйданчыкларында КУЭ субъектлары продукциясен урнаштыру оештырылды;

«Россия экспорт үзәге» АҖнең белем бирү семинарларында 64 КУЭ субъектының катнашуы оештырылды;

2 КУЭ субъектына үз продукциясенә сертификатлар алуда хезмәт күрсәтелде;

15 КУЭ субъектына экспорт контрактын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтелде;

3 түгәрәк өстәл, 90нан артык вебинар һәм семинар үткәрелде.

**Конкуренцияне үстерү**

Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр базарларында конкурентлык мохитен үстерү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 2 сентябрендәге б-2424 номерлы боерыгы белән расланган 2021 – 2025 елларга Россия Федерациясендә конкуренцияне үстерү илкүләм планы («юл картасы») һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 апрелендәге б-768 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларында конкуренцияне үстерү стандарты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстанда әлеге документлар нигезендә 2019–2025 елларга конкуренцияне үстерүгә ярдәм күрсәтү буенча юл картасы кабул ителде, ул Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү өчен товар базарлары исемлеген һәм 2019–2025 елларга Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерүгә ярдәм күрсәтү чаралары («юл картасы») планын раслау турында» 2019 елның 31 августындагы 306 номерлы боерыгы белән расланды.

Республика «юл картасына» түбәндәгеләр кертелде:

47 базар (37 – Конкуренция үсеше стандартыннан, 10 – төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алып);

49 төп күрсәткеч, һәр базарда төп күрсәткечләргә ирешү өчен 62 чара;

конкрет базарлардан тыш, шулай ук конкурентлык мохитен үстерүгә юнәлдерелгән 62 системалы чара;

Конкуренцияне үстерү илкүләм планыннан 9 чара.

2024 ел нәтиҗәләре буенча республикада конкуренцияне үстерүгә ярдәм күрсәтү буенча юл картасының барлык төп чаралары үтәлде. Татарстанның тәҗрибәләре берничә тапкыр Монополиягә каршы федераль хезмәт тарафыннан эшләнә торган конкуренциянең үстерүнең иң яхшы практикалары буенча «ак китапта» күрсәтелде.

**Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының сатып алулардан файдалану мөмкинлеге**

КУЭ субъектларыннан сатып алулар өлешен арттыру максатларында, вәкаләтле орган буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы «Юридик затларның кайбер төрләре товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 223-ФЗ номерлы Федераль закон) кысаларында республиканың иң зур һәм кайбер заказчыларына карата, аларның КУЭ субъектларыннан планлаштырыла торган сатып алуларның еллык күләменнән кимендә 25 % күләмендә сатып алуларны гамәлгә ашыруын тикшереп, сатып алулар планнарын бәяли һәм мониторинглый.

2024 елда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге б-717 номерлы боерыгы нигезендә 25 эре заказчыга һәм 68 аерым заказчыга карата мониторинг үткәрелде, аларның сатып алулар буенча 3,1 меңнән артык планы

(планнар проектлары) карап тикшерелде һәм килештерелде. Иң эре заказчылар тарафыннан 63 млрд сумга (109 млрд сумнан) КУЭ субъектларында якынча 58% сатып алулар гамәлгә ашырылды.

Кече һәм урта эшкуарлыкның сату базарларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, шул исәптән бердәнбер сайлап алынган федераль дәрәҗәдәге zakazrf төбәк мәйданчыгын (калган 7 мәйданчык Мәскәү шәһәрендә) исәпкә алып, барлык кирәкле инструментлар да бар.

2024 ел нәтиҗәләре буенча Республика маркетинг елы ресурсларында КУЭ субъектлары – республика тәэмин итүчеләренең табышы 229 млрд сумга җитте, бу 19,0 млрд сумга 2023 елдагы табыш нәтиҗәсеннән артып китә.

Моннан тыш, Республика маркетинг үзәге мәйданчыгында 223etp.zakazrf.ru 223-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында республика оешмалары – заказчылары тарафыннан КУЭ субъектларында конкурентлы ысул белән 20,5 меңнән артык сатып алу урнаштырылды.

**Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге процессларын цифрлаштыру**

Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген реформалауның бер юнәлеше – контрольдә тотылучы субъектлар белән үзара хезмәттәшлек иткәндә цифрлы яссылыкка күчү. Бу контроль (күзәтчелек) органнары гамәлләренең үтә күренмәлелеген тәэмин итәчәк, эшкуарларга административ йөкләнешне киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге процессларын цифрлаштыру кысаларында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, системалы эш алып барылды.

Республикада «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасының (алга таба – ККЭ ББК ДМС) төрле модульләренә түбәндәгеләр тоташтырылды:

Контроль (күзәтчелек) һәм рөхсәт бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы 21 республика башкарма хакимият органы;

республиканың 45 муниципаль берәмлеге («Судка кадәр шикаять бирү» ярдәмче системасына тоташтырылды).

Контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан бизнес белән дистанцион хезмәттәшлек технологияләрен, шул исәптән ККЭ ББЧ ДМС базасында «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып күчмә тикшерүләр үткәрүнең дистанцион формасын кертү эше оештырылды, ул тикшерү үткәрү турында акт төзү өчен нигез булып торган видеоконференция элемтәсе файлын саклап калу мөмкинлеге белән дистанцион форматта тикшерүләр уздыруны күздә тота.

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы рейтингы нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы 2024 елда барлык контроль-күзәтчелек чараларының 20 процентын «Инспектор» мобиль кушымтасы аша уздыруны тәэмин итте, бу республиканы дистанцион тикшерүләр, консультацияләр һәм башка чаралар саны буенча барлык төбәкләр арасында 1 урынга чыгарды.

Шулай ук 4 меңнән артык контроль (күзәтчелек) чарасы уздырылды, аларның 1,5 меңнән артыгы «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелде. Татарстан эшкуарларына онлайн тикшерүләр уздырылды, дистанцион

консультацияләр бирелде һәм аларның контрольдә тотучы органнар белән кире элемтәсе булдырылды.

Республикада мобиль кушымтадан файдалану буенча иң яхшы нәтиҗәләрне Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе, Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе күрсәтте.

Бүгенге көндә республикада Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталының шәхси кабинеты ярдәмендә профилактик визитка һәм консультациягә онлайн язылу, шулай ук профилактик визит нәтиҗәләре буенча эшкуарны бәяләү мөмкинлеге тормышка ашырылды. 2025 елда республиканың зур муниципаль берәмлекләренә мобиль кушымтаны кулланышка кертү планлаштырылды.

Контроль (күзәтчелек) органнарның карарларына, аларның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр шикаять бирү процедурасын тәэмин итү

Республикада республика контроль (күзәтчелек) органнарына һәм муниципаль районнарга карата судка кадәр шикаять бирү тәртибе механизмын гамәлгә ашыру өчен чаралар тулы күләмдә башкарылды. 2025 елда җирле үзидарә органнарының авыл җирлекләрендә судка кадәр шикаять бирүнең ярдәмче системасын сәнәгый эксплуатацияләүгә старт бирү планлаштырылды.

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан рөхсәт бирү эшчәнлегенең реестр моделенә күчү эше оештырылды, аның кысаларында ККЭ ББЧ ДМСнда; республиканың 6 башкарма хакимият органының (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, аларны әйләнештә йөртү һәм аларның сыйфатын тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе) шәхси кабинетлары булдырылды.

Төрле рөхсәтләрне исәпкә алуны кәгазь чыганаклардан электрон реестр моделенә күчерү максаты белән ККЭ ББЧ ДИСнда «Гади реестрлар» функционалын гамәлгә кертү эше оештырылды, анда республика башкарма хакимият органнары (Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты) һәм республиканың барлык муниципаль берәмлекләре катнашты.

2024 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан «Гади реестрлар» функционалын гамәлгә

кертү буенча төбәкләр рейтингында 1 урынны алды (393 язма тәэмин ителде).

**Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге реформасы**

Эшкуарларга уңай шартлар тудыру һәм бизнеска административ киртәләрне киметү мәсьәләсе республиканың барлык дәрәҗәләрдәге хакимияте өчен бик мөһим эшчәнлек юнәлеше булып тора. Әлеге максатлар өчен бизнес-бергәлек һәм контроль-күзәтчелек органнарының үзара хезмәттәшлеге җайга салынды.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан контроль-күзәтчелек органнары эшчәнлегенә тикшерү кәгазьләрен куллану, кисәтүне белдерү, профилактик визит ясау, беренче җәза буларак кисәтү куллану аша яңа профилактика инструментларын кертү эшләре алып барыла.

План буенча тикшерүләр үткәрү гамәлдән чыгарылганнан соң, контроль-күзәтчелек органнары тарафыннан алар урынына профилактик визитлар каралды. Аларны үткәрү нәтиҗәлелеге бизнестан алынган кире элемтә нәтиҗәләре белән раслана. Тулаем алганда, 2024 елда республика буенча 2 091 (республика башкарма хакимият органнары – 1 428, җирле үзидарә органнары – 663) профилактик визит ясалды, 11 635 (республика башкарма хакимият органнары – 9 631, җирле үзидарә органнары – 2 004) кисәтү ясалды. Профилактик чаралар өлеше контроль (күзәтчелек) һәм профилактик чараларның гомуми саныннан 60% процент тәшкил итте.

Контрольдә тотылучы затларның хокукый белемен арттыру, законнар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү турында мәгълүмат бирү һәм эшкуарлар белән нәтиҗәле «кире элемтә» механизмнарын булдыру эшләре оештырылды. Аңлату эшләре барлык кулланыла торган каналлар (социаль челтәрләрне, мессенджерларны һ.б. кертеп) буенча даими нигездә үткәрелә.

Мораторий кертелүне исәпкә алып, 2024 елда тикшерүләрнең гомуми саны 2019 ел белән чагыштырганда (шартлы репрезентатив) 4 тапкырдан артык кимеде (2024 елда – 4 520 тикшерү; 2019 елда – 19 258). Бизнес өчен административ киртәләрне киметү мәсьәләсе квартал саен Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил катнашында Татарстан Республикасы прокуроры рәислегендәге эшкуарлар хокукларын яклау буенча ведомствоара эш төркеме утырышларында тикшерелә.

Барлык контроль-күзәтчелек органнары белән профилактик чаралар санын һәм төрләрен арттыру исәбенә кылу ихтималы булган бозуларны кисәтү буенча хезмәттәшлек алып барыла. Тикшерүләрнең кайбер күрсәткечләре арту сәбәпләре анализлана, административ басымны киметү турында тәкъдимнәр эшләнә. Бизнеска законнарның гамәлдәге таләпләре турында оператив мәгълүмат бирү максатларында, республикада «Тикшерелгән бизнес» интернет ресурсы эшли. Ресурсның функционалы эшкуарларның хокукый грамоталылыгын арттырудан, шулай ук бизнес белән контроль-күзәтчелек органнары арасында диалог төзүдән гыйбарәт. provbiz.ru сайтында законнарга кертелә торган үзгәрешләр буенча актуаль яңалыклар, контроль-күзәтчелек органнарының үткәреләчәк чаралар анонслары (аларда катнашу мөмкинлеге белән), бертип хокук бозулар һәм аларны булдырмау ысуллары күрсәтелгән 1 350 истәлек, тормыш хәлләре буенча 1 300 сорауга җавап табарга мөмкин.

Тикшерүләрнең электрон журналында тулаем республика буенча да һәм һәр эшкуарга карата да бизнеска туры килә торган административ авырлыкның реаль өлешен динамикада күрергә мөмкинлек бирә. Эшкуарлар алдан ук интерактив сораштыру узу һәм инспекторлар тарафыннан ачыкланырга мөмкин хаталарны билгеләрү юлы белән тикшерүгә әзерләнә ала.

Хәзерге вакытта «Тикшерелгән бизнес» интернет ресурсын алга таба үстерү мәсьәләләре җентекләп өйрәнелә.

## ЦИФРЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ

Бүген республиканың ИТ-тармагында якынча 42 мең белгечне эш урыннары белән тәэмин итүче 3 500 компания бар.

2024 ел нәтиҗәләре буенча тармакның кереме 225 млрд сум дип бәяләнә. Тармак буенча салым керемнәре дәрәҗәсе бер елда, 33 млрд сумга җитеп, 43 процентка кадәр күтәрелде.

### Инфраструктура

Мобиль Интернет абонентлары саны арта. 2024 ел нәтиҗәләре буенча 5,4 млн абонент (2023 ел дәрәҗәсенә карата 106%) теркәлде, 2 854 торак пунктта мәгълүматлар тапшыруның мобиль челтәреннән файдалану мөмкинлеге бар, бу республикадагы барлык торак пунктларының 91 процентыннан артыгын тәшкил итә.

Татарстан территориясендә якынча 24 мең мобиль элемтә станциясе эшли. 2024 елда 223 яңа база станциясе һәм 827 база станциясе яңартылды. Үткәрелә торган интернет абонентлары саны 1,3 млн абонент (2023 ел дәрәҗәсенә карата 105%) тәшкил итте.

«Таттелеком» ГАҖ үткәрелә торган элемтә хезмәтләренең сыйфатын яхшырту максатларында искергән бакыр элемтә линияләрен GPON технологиясе буенча җепселле оптик элемтә линияләренә алыштыру эше дәвам итә. Башкарыла торган эш нәтиҗәләре буенча 444 поселокта 335 меңнән артык йорт хуҗалыгының югары тизлекле элемтә хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеге барлыкка килде.

Цифрлы тигезсезлекне бетерү буенча федераль проектны гамәлгә ашыру дәвам итә, аның кысаларында «Ростелеком» ГАҖ һәм «Т2 Мобайл» ҖЧҖ 100 кешедән алып 500 кешегә кадәр яши торган торак пунктларны мобиль элемтә һәм «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәреннән мобиль файдалану мөмкинлеге белән тәэмин итә. 2022 – 2024 елларда республиканың 115 торак пунктында база станцияләре урнаштырылды, шулардан 17есе – 2024 елда.

Хәзерге вакытта республикада автомобиль юлларының сыйфатлы мобиль элемтәсе белән тәэмин итү мөһим мәсьәлә булып тора. 2024 ел башында мобиль элемтә операторларының уртак тырышлыгы белән республика территориясендә М-12 «Восток» тизйөрешле автомобиль юлы участогы тулысынча түшәлде. Проект кысаларында Татарстан территориясендә «Автодор» һәм «Сервис-Телеком» компанияләре тарафыннан М-12 «Восток» автомобиль юлы буйлап 29 телекоммуникация терәге урнаштырылды, аларда элемтә операторлары тарафыннан мобиль элемтәнең 46 база станциясе куелды.

Шулай ук 2024 елда М-7 «Волга» автомобиль юлында мобиль элемтә белән тәэмин итүне яхшырту эшләре башкарылды. Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту өчен мобиль интернет белән тәэмин итүне яхшырту буенча этаплап эш алып барыла, 33 яңа база станциясе урнаштыру карала, шулардан 10ысы 2024 елда урнаштырылды.

2024 елда Алексеевск – Әлмәт яңа республика автомобиль юлы файдалануга тапшырылды. Әлеге автомобиль юлында мобиль элемтәнең сыйфатлы радиосигнал таралышын тәэмин итү максатларында «Регионара инфраструктура төркеме» ҖЧҖ

операторы тарафыннан 11 база станциясе урнаштырылган 7 телекоммуникация терәге куелды.

Элемтә операторлары белән берлектә, иминлекне тәэмин итү инфраструктурасын үстерү эше алып барыла. Республикада кешеләр күпләп җыела торган урыннарда һәм күпфатирлы торак йортларда 80 меңнән артык видеокамера урнаштырылды һәм эшли. Видеокамералар куелган акыллы видеодомофоннар челтәре киңәя, хәзерге вакытта аларның саны 19 меңнән артык берәмлек тәшкил итә.

Почта элемтәсе

Республика территориясендә почта элемтәсе челтәре 1 139 объекттан тора, шул исәптән 1 107 (257 шәһәр, 850 авыл) стационар почта элемтәсе бүлеге, 29 күчмә почта элемтәсе бүлеге һәм 3 заказлар бирү пункты.

Федераль программаны үтәү кысаларында 2024 елда республиканың 26 авыл почта элемтәсе бүлеге модернизацияләнде. 2022 – 2024 елларда барлыгы Татарстан территориясендә урнашкан 73 авыл почта элемтәсе бүлеге яңартылды. 2025 елда Татарстан Республикасының 19 почта бүлеген модернизацияләү планлаштырыла.

2024 елда «Россия почтасы» АҖ тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан 42,6 млн сум күләмендә (2023 ел өчен түләнгән оешмалар мөлкәтенә салым, транспорт салымы, җир салымы күләмендә) субсидия бирелде. Субсидиянең бөтен күләме республикада «Россия почтасы» АҖнең авыл хезмәткәрләренә (2 394 хезмәткәргә) өстәмә түләү өчен тотылды.

Социаль миссияне саклап, Россия почтасы, төрле йөкләрне илтеп бирү һәм саклау буенча республика компанияләренең мөмкинлекләрен киңәйтеп, логистик оператор буларак үсә. Стандарт продуктлар белән беррәттән индивидуаль чишелешләр дә эшләнә. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы ярдәмендә республика предприятиеләре өчен берничә проект гамәлгә ашырылды:

Казан шәһәрендә логистик почта үзәге мәйданчыгында җиһазлар җитештерә торган «АйСиЭлТехно» компаниясе белән продукция саклау һәм илтеп бирү буенча уртак проект башлап җибәрелде;

2024 елның июлендә «КАМАЗ» ГАҖ белән арттырылган авыр габаритлы характеристикаларга ия запас частьләр илтеп бирү буенча проект эшли башлады.

«Алабуга» МИЗ белән Кытай Халык Республиккасыннан «Бигеш» аэропортына чартер рейслары белән йөкләр алып кайту буенча проект стартка әзер.

**Мәгълүмат системалары**

Республикада мәгълүмат системаларында һәм сервисларда эшләү өчен Татарстан Республикасы телекоммуникацияләренең дәүләт интеграцияләнгән системасы булдырылды. Хәзерге вакытта аңа 9 944 республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм бюджет оешмалары тоташтырылды.

2024 елда Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары «Татарстан Республикасы электрон мәгарифе» яңартылган системасына күчте, анда элеккеге системага караганда 75 процентка күбрәк мөмкинлекләр һәм функциональ күбрәк, шул исәптән:

дәресләргә әзерлек барышы һәм сыйныфлардагы вәзгыятьне анализлау гадиләштерелгән;

хисаплар әзерләүгә, гаризаларны җыюга, аттестатларны чыгаруга һәм башка процессларга сарыф ителә торган вакыт киметелгән;

педагоглар өчен «Минем мәктәп. Журнал», ата-аналар өчен «Минем мәктәп. Көндәлек» кебек мобиль кушымталардан файдалану мөмкинлеге каралды;

«Мәскәү электрон китапханәсендә» дәресләр (өй эше) өчен 2 миллионнан артык цифрлы белем бирү материалыннан файдалану мөмкинлеге каралган.

2024 елда түбәндәгеләргә бәйле процессларны комплекслы мониторинглау һәм алар белән идарә итү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы эшләп бетерелде:

республика милкендәге табигать ресурслары белән эш итүгә, аларның бик нык кимүен кисәтү максаты белән алардан рациональ файдалануны тәэмин итүгә;

җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар таләпләре үтәлешенә;

тенденцияләрне фаразлау максаты белән әйләнә-тирә мохитнең торышын контрольдә тотуга.

Экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы ЦИПР-2024 конференциясе кысаларында «Цифрлы табигать» номинациясендә CIPR Digital премиясен алды.

«ТАТСФЕРА» мәгълүмат системасы

Аналитик бурычларның киң спектрын «ТАТСФЕРА» платформасы хәл итәргә мөмкинлек бирә, ул мәгълүматлар саклагычыннан, мәгълүматларны үзгәртү һәм чистарту инструментларыннан, аларны анализлау һәм визуализацияләүдән тора.

Аннан файдалану нәтиҗәләре:

Федераль салым хезмәте базасыннан алынган 75 ГБ товар чеклары;

15 млрд эшкәртелгән товар һәм хезмәт күрсәтүләр;

2,5 ТБ мәгълүматлар ТАТСФЕРА компонентларын кулланып анализлана;

4 дәүләт органы зур мәгълүматларны анализлау нигезендә карарлар кабул итә;

19 мең күрсәткеч РСЦ платформасына тапшырылды;

260 дәүләт хезмәткәре зур мәгълүматлар нигезендә идарә итү буенча белем алды;

ТАТСФЕРАга мәгълүматлар урнаштыру өчен Татарстан ведомстволары белән имзаланган 9 килешү.

Платформа ПРОФ-IT Инновация милли конкурсының «Зур мәгълүматлар» номинациясендә I урын алды.

**Күпфункцияле үзәкләр һәм электрон рәвештә хезмәтләр күрсәтү**

Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү эше дәвам итә. Хәзерге вакытта барлык 319 хезмәт онлайн файдаланып була. Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталында 3 миллионнан артык кулланучыга хезмәт күрсәтелә. 2024 елда 42 хезмәткә реинжиниринг үткәрелде, бу эшкәртүнең гомуми вакытын 900 көнгә кыскартырга мөмкинлек бирде.

Татарстанда 300гә якын дәүләт хезмәтләре, муниципаль һәм башка төр хезмәтләр күрсәтелә торган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең (алга таба – КФҮ) 60 бүлеге эшли. Шулай ук Казан шәһәрендә бизнес өчен КФҮнең 1 офисы оештырылды.

Көн саен КФҮ офисларында 15 меңнән артык гражданга хезмәт күрсәтелә. 2024 елда аларда 6,1 миллионнан артык хезмәт күрсәтелде. 2024 елдан башлап яңа клиент сервисы барлыкка килде – гражданның хезмәт күрсәтүгә гариза тутыру өчен кирәкле документлары турында белешмәләрне аның Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталындагы «Шәхси кабинеты» профиленнән КФҮның мәгълүмат системасына автомат рәвештә бирү буенча.

«Цифрлы профиль»не кулланганда белешмәләр гариза бирүче тарафыннан аның ризалыгы белән «Дәүләт хезмәтләре» кушымтасы аша кәрәзле телефонда махсус Qr-кодны сканерлау юлы белән бирелә. Сервис КФҮ белгеченә гражданның паспорты, СНИЛСы, ИННы, электрон почтасы һәм башка мәгълүматларны автомат рәвештә бирергә мөмкинлек бирә. Әлеге технология хезмәт күрсәтү процессын шактый җиңеләйтә һәм тизләтә, шулай ук кабул итүдә хаталарны булдырмый.

2024 елдан КФҮ тарафыннан КФУның Дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә югары мәктәбе белән үзара хезмәттәшлек гамәлгә ашырыла. КФҮнең Укыту үзәге базасында республика хезмәткәрләре стажировкасы программасы эшләнде. КФҮ спикерлары катнашында программа буенча министрлыклар, ведомстволарның, шулай ук муниципалитетларның 500гә якын хезмәткәре белем алды.

**Мәгълүмат иминлеге**

2021 елдан Татарстан Республикасының Киберкуркынычларны булдырмау үзәге (алга таба – Үзәк) эшли, анда тәүлек буе мәгълүмат куркынычсызлыгы буенча инженерлар тарафыннан республикада мәгълүмат куркынычсызлыгы инцидентларын ачыклау һәм анализлау буенча чаралар уздыру тәэмин ителә.

2024 елда әлеге үзәк тарафыннан республика дәүләт ресурсларына юнәлтелгән 732 мең киберһөҗүм теркәлде һәм нейтральләштерелде.

Киберһөҗүмнәр санының шактый артуы түбәндәге әһәмиятле иҗтимагый-сәяси һәм спорт чараларын уздыру чорында теркәлде: «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турниры, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» икътисадый форумы, «БРИКС уеннары» һәм XVI БРИКС саммиты.

XVI БРИКС саммиты барышында Мәгълүматларны эшкәртү федераль үзәге ресурсларына һөҗүмнең куәте иң югары ноктасында секундына 450 Гбитка җитте, һөҗүм 364 млн IP-адрестан ясалды, интенсивлыгы секундына 175 млн пакет булды.

**Ясалма интеллект технологияләре файдаланыла торган проектлар**

Республикада ясалма интеллект технологияләре кулланыла торган берничә проект гамәлгә ашырыла:

«Урам» проекты – реаль вакыт режимында ясалма интеллект ярдәмендә урам видеокүзәтү камераларыннан видеоагымнарны анализлый, төрле объектларны һәм вакыйгаларны билгели торган система. 2025 елда «Урам» системасына 1,5 меңнән артык урам видеокүзәтү камерасын тоташтыру, тыелган наркотик матдәләрне куеп калдыручыларны тану һәм таратучылар сервисын сынау рәвешендә эшләтеп җибәрү, шулай ук функционалны киңәйтү һәм кешеләрнең егылуларын, сугышуларны, йортсыз кешеләрне алга таба «Кеше приюты» социаль тернәкләндерү үзәгенә урнаштыру өчен, башка вакыйгалар һәм аномаль ситуацияләрне тану планлаштырыла;

2024 елда башланган «ГосПромпт» проекты, ул һәр дәүләт хезмәткәре, шул ук вакытта промпт-инжиниринг күнекмәсе дип аталган махсус күнемәсе булмаган килеш, үз эшендә һөнәри дәрәҗәдә зур тел модельләрен җиңел һәм ансат куллануга, сыйфатлы нәтиҗәләр алуга, вакытны экономияләүгә, ә кайбер очракларда үз эшенең сыйфатын яхшыртуга юнәлтелә. Сервисның максаты – дәүләт хезмәткәрләренең рутиналы бурычларын тизләтү һәм аларның сыйфатын яхшырту.

**Иннополис – югары технологияләр һәм инновацияләр шәһәре**

ИТ-өлкәне үстерүдә Татарстанның төп конкурент өстенлекләренең берсе – Иннополис – хәзерге заман Россия тарихында нульдән төзелгән беренче шәһәр. Бу яшь һәм талантлы кешеләр өчен яңа җәлеп итү ноктасы. Бүгенге көндә шәһәрдә 7,8 меңнән артык кеше яши һәм эшли. Шул ук вакытта Иннополиста һәр өченче кеше – ИТ-белгеч яки галим.

Иннополис проекты өч өлештән гыйбарәт: фәнни-мәгариф инфраструктурасы, махсус икътисадый зона һәм шәһәр мохите.

Биредә Россиядә беренче ИТ-югары уку йорты – Иннополис университеты ачылды, ул ил университетларының ТОП-рейтингына керә. Югары уку йорты базасында Россиядә беренче цифрлы операция ясау уйлап табылды, беренче ясалма интеллект институты ачылды, университетны тәмамлаучылар стартапларны гамәлгә ашыру юлы белән диплом яклый.

Иннополис университеты Россия өчен уникаль модель буенча үз эшчәнлеген алып бара, ул Иннополис шәһәре экосистемасы кысаларында мәгариф, фән һәм бизнесның үзара хезмәттәшлеге өчен шартлар тудыруны күздә тота.

Университет цифрлы үсеш, мәгълүмат технологияләре, робототехника һәм ясалма интеллект өлкәсендә таләп ителә торган белгечләр әзерләү һәм уникаль чишелешләр булдыру миссиясен уңышлы гамәлгә ашыра, бу Татарстан Республикасының инновацион экосистемасын үстерүгә һәм илнең стратегик бурычларын хәл итүгә ярдәм итә.

2024 елда Иннополис университеты беренче тапкыр, илнең ТОП-10 иң яхшы уку йортлары арасына эләгеп, Times Higher Education иң яхшы югары уку йортларының дөнья рейтингына керде. Университет шулай ук Forbes версиясе буенча Россия Федерациясенең иң яхшы 100 югары уку йорты рейтингында ТОП-30 га, RAEX версиясе буенча БРИКС илләре университетларының ТОП-30ына, ясалма интеллект өлкәсендә Альянс югары уку йортлары рейтингында B+ төркеменә керде.

Иннополис Университетында илнең һәм дөньяның әйдәүче югары уку йортлары, компанияләре һәм экспертлары белән берлектә махсус эшләнгән бакалавриат, магистратура һәм аспирантура модульләрендә һәм дисциплиналарында 31 илдән 1 540 студент (шул исәптән 207 чит ил студенты) белем ала. 2024 елда университетны 235 укучы: 148 бакалавр, 79 магистр һәм 8 аспирант тәмамлады.

Иннополис университеты илкүләм проектларын һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыруда актив катнаша.

«Россия Федерациясенең Цифрлы икътисады» илкүләм программасы: «Ясалма интеллекты федераль проекты

Иннополис университетында бизнес һәм икътисадның өстенлекле тармаклары һәм ясалма интеллектның тармакара технологияләре мәнфәгатьләрендә экспортка

юнәлтелгән үзебезнең платформа чишелешләрен эшләү өчен федераль тикшеренү Ясалма интеллект үзәге булдырылды.

«Ясалма интеллект» федераль проекты кысаларында:

ясалма интеллектның яңа технологияләре базасында Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм үз илебезнең иң эре предприятиеләре («СИБУР Холдинг» ГАЖ, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАЖ, «ТАНЕКО» АЖ, «ХимРар» ДК, «Аэрофлот» ГАЖ, «Синара-Транспортные Машины» АЖ, «Ростелеком» ГАЖ, А.С. Логинов исемендәге Мәскәү клиник фәнни үзәге) мәнфәгатьләрендә 5 тармак цифрлы чишелеш эшләнде;

югары рейтинглы журналлар өчен 30дан артык мәкалә һәм зур һөнәри конференцияләр өчен материаллар әзерләнде;

9–11 сыйныф укучылары һәм 1–2 курс студентлары өчен 2 хакатон, олимпиада, ясалма интеллект буенча «Digital Innopolis Days 2024 & Innopolis AI Conference» халыкара форумы» халыкара конференциясе үткәрелде.

Университет – гражданнар өчен ясалма интеллект өлкәсендә өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү программаларының һәм мәйданчыкларының төп провайдерларыннан берсе. 2024 елда илнең 27 төбәгеннән 100дән артык тыңлаучы белем алды.

«ИТ-тармакның кадрлар потенциалын үстерү» федераль проекты

2024 елда Иннополис университетының ИТ-белгечләрен әзерләү сыйфатын бәяләү буенча илдә бердәнбер ассессмент-үзәк «Приоритет-2030» программасы кысаларында 150 меңнән артык «цифрлы кафедралар» студентының ИТ-компетенцияләр формалашуына комплекслы бәя бирде. 2022 елдан башлап, Иннополис университеты тарафыннан барлыгы 367 меңнән артык студент бәяләнде (119 югары уку йорты катнашты).

Иннополис университеты «Киләчәк коды» проектының төп башкаручыларыннан берсе, ул талантлы мәктәп укучыларына программалаштыруның заманча телләргә өйрәтү буенча өстәмә ике еллык курс узу мөмкинлеген бирә. 2024 елда 8–11 сыйныфларның 5 196 мәктәп укучысы һәм Россия Федерациясе субъектларыннан урта һөнәри белем бирү оешмалары студентлары «Киләчәк коды» проекты кысаларында программалаштыру буенча белем алды.

«Цифрлы технологияләр» федераль проекты

«Цифрлы технологияләр» федераль проекты кысаларында 2024 елда Университет югары технологияле сәнәгать продукциясен җитештерүне булдыру һәм (яисә) үстерү максатларында цифрлы платформалар һәм программа продуктлары эшләү буенча ике проектны уңышлы гамәлгә ашыруны дәвам итте:

- «InnoPolim» полимер материаллардан әзер продукциянең үзлекләрен фаразлау һәм оптимальләштерү өчен мәгълүматларны интеллектуаль анализлауның цифрлы платформасын эшләп бетерү буенча эшләр башкарылды;

- 2024 елда робот-манипуляторлар нигезендә сәнәгать предприятиеләренең технологик комплекслары торышын мониторинглауның һәм предиктив фаразлауның цифрлы платформасын эшләп бетерү һәм гамәлгә кертү проекты кысаларында эскиз проекты һәм техник проект әзерләнде, интеллектуаль

эшчәнлекнең дүрт нәтиҗәсе теркәлде.

«Җитештерү һәм автоматлаштыру чаралары» илкүләм проекты: «Сәнәгать робототехникасын һәм производствоны автоматлаштыруны үстерү» федераль проекты

Иннополис университеты «Сәнәгать робототехникасын үстерү үзәкләрен булдыру һәм үстерү» чарасының төп башкаручы һәм операторы булып тора. 2024 елда югары уку йорты базасында Россиядә беренче федераль сәнәгать робототехникасы үсеше үзәге булдырылды, күмәк куллану үзәге ачылды, предприятиеләргә техник-технологик аудитлар уздыруның бердәм методикасы эшләнде, аның буенча өч предприятие аудиты төгәлләнде («Казан «Электроприбор» заводы», «Казан төгәл машиналар төзү заводы», «Бәләбәй сөт комбинаты»). Шулай ук мәгариф-агарту эшчәнлегендә 6 800 кеше катнашты, 2 технологик комплекс булдырылды.

«Алдынгы инженерлык мәктәпләре» федераль проекты

2022 елдан Татарстан Республикасы һәм Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәмендә Университет базасында программа инженериясе һәм импортны алмаштыру өлкәсендә «Россия программа тәэминатын тизләтеп эшләү һәм гамәлгә кертү өчен яңа буын ИТ-инженерлары» алдынгы инженерлык мәктәбе эшли.

Иннополис университетының алдынгы инженерлык мәктәбе партнерлары: Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы ярдәмендә «Ростелеком» ГАҖ, VK, «Газпром» ГАҖ, «Газпром нефть» ГАҖ, «МТС Лаб» ҖЧҖ, «Открытый код» коммерциягә карамаган АҖ .

2025 ел нәтиҗәләре буенча:

Программа кодын (GitFlame) саклау һәм версион контрольдә тотуның үз илебез системасы, бурычлар кую һәм эшләнмәләр белән идарә итү системасы (TeamFlame) эшләтеп җибәрелде;

кодны статик анализлау һәм өзлексез интеграцияләү системасының база функционалы төзелде;

ИТ-индустриядән һәм университетлардан 1,5 меңнән артык белгеч укыды;

программалы продуктларга интеллектуаль эшчәнлекнең 37 нәтиҗәсе алынды;

2 яңа цифрлы лаборатория эшли башлады.

«Фән һәм университетлар» илкүләм проекты

«Өстенлекле тикшеренү юнәлешләре буенча масштаблы фәнни һәм фәнни-технологик проектларны үстерү» федераль проекты

Университет базасында Технологияләр трансферы тармакара үзәге булдырылды, аның бурычы структур бүлекчәләргә ярдәм итү һәм интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен алга этәрүдә һәм коммерцияләштерүдә булышлык күрсәтү. 2024 ел нәтиҗәләре буенча 260 интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе (шул исәптән 65 уйлап табылган әйберләр) теркәлде, Технологияләр трансферы үзәге катнашында интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә махсус хокук белән эш итү турында 54

лицензия килешүенә имза куелды, Технологияләр трансферы үзәге катнашында фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренә 36 шартнамә төзелде.

«Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проекты:

«Пилотсыз авиация системалары өчен кадрлар» федераль проекты

Иннополис университеты – «Пилотсыз авиация системалары өчен кадрлар» федераль проекты кысаларында мәгариф провайдеры һәм терәк үзәге, Россия Федерациясе төбәкләре гражданнарын укыта.

2024 елда проект кысаларында университет тарафыннан Россия Федерациясенең 28 субъектында 44 белем бирү программасы тормышка ашырылды, алар кысаларында 1 148 кеше белем алды.

2024 елда Иннополис университеты, «НТИ 20.35 университеты» белән берлектә, федераль проектны гамәлгә ашыру кысаларында «Пилотсыз авиация системалары өчен кадрлар цифрлы реестры» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын булдыру (эшләү) буенча эш алып барды.

«Пилотсыз авиация системалары өчен перспективалы технологияләр» федераль проекты

2024 елда Иннополис университеты пилотсыз авиация системалары өчен перспектив технологияләр буенча фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен уздыру буенча сайлап алынды һәм өч проектның үтәүчесе булды, шул исәптән:

1. «Пилотсыз һава суднолары һәм пилотсыз һава суднолары белән автоном идарә итү һәм аларның навигациясе өчен нейрочелтәр алгоритмнары базасында борт аппарат-программа комплексы технологияләрен һәм демонстраторын эшләү». 2024 елда дроннар төркеме белән идарә итү алгоритмнары эшләнде, интеллектуаль эшчәнлекнең бер нәтиҗәсе алынды;

2. «Урта һәм авыр класслы пилотсыз очу аппаратлары өчен интегральләшкән челтәр исәпләү мохитен төзү технологиясен эшләү (моңа нейрон челтәрләрен һәм машинада укытуның технологияләрен кулланып, интеллектуаль исәпләүләрнең ярдәмче системаларын кертеп)». 2024 елда унификацияләнгән модульле интегральләшкән челтәр исәпләү мохитен төзү технологияләре булдырылды, урта һәм авыр класслы пилотсыз очу аппаратлары өчен эксперименталь үрнәк әзерләнде, төзелгән һәм системалы программа белән тәэмин итү, база алгоритмнары китапханәсе эшләнде;

3. «Җир өсте объектларының торышын тану һәм фаразлау мөмкинлеге белән югары рөхсәтле радиолокация кадрлары агымнарын техник күрү һәм комплекслы эшкәртү ысуллары нигезендә пилотсыз авиация системалары ярдәмендә җир өслегенең күппозицияле мониторингы технологиясен эшләү». 2024 елда аналитик хисап, патентлы ландшафт, алгоритмнар эшләнде.

Технологик лидерлык проектларына ярдәм итү буенча «Милли технологик инициатива» чараларын гамәлгә ашыру кысаларында Иннополис университеты тарафыннан пилотсыз авиация системаларының капиталь булмаган инфраструктурасы белән бергәләп эшләү өчен пилотсыз һава судноларын югары төгәллек белән утырту буенча программа-аппарат системасын эшләү проекты

гамәлгә ашырылды.

2024 елда нәтиҗә – «Русдронопорт» ҖЧҖ заказчы-координаторы инфраструктурасы составында пилотсыз һава судноларын югары төгәллек белән утырту мәйданчыгына автомат утырту системасын эшләү һәм тәҗрибә үрнәген сынау.

«Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеше» Россия Федерациясе дәүләт программасы

Иннополис университеты түбәндәге проектларны үтәде:

«Ясалма интеллект ысулларын кулланып, эластик үзлекләрне бәяләү һәм компенсацияләү исәбенә металларның роботлаштырылган формалары төгәллеген арттыру». 2024 елда нәтиҗә: ясалма интеллект ысулларын кулланып, эластик үзлекләрне бәяләү һәм компенсацияләү исәбенә металларның роботлаштырылган формасы төгәллеген арттыру эшләрен башкару. Нәтиҗәләр 18 фәнни эштә басылып чыкты, шулардан кимендә дүртесе – абруйлы фәнни журналларда (Scopus) бастырылды;

«Алгебраик структураларның алгоритмик үзлекләре». 2024 елда алгебраик структураларның алгоритмик үзлекләре өйрәнелде, мәкаләләр бастырылды;

«MIMO голографик системалары: 6Gга ирешү өчен коммуникация технологиясе». 2024 елда голографик MIMO төп үзлекләрен тикшерү үткәрелгән, бу 6G системаларын эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә ярдәм итә.

«Университет технологик эшкуарлыгы платформасы» федераль проекты

Иннополис университеты «Университет технологик эшкуарлыгы платформасы» федераль проекты кысаларында эшкуарлык компетенцияләре тренинглары белән аккредитацияләнгән тәэмин итүче булып тора, бөтен ил буйлап тренинг мәйданчыклары заказларын үти. Федераль проект кысаларында Россия югары уку йортларының 8 714 студенты «Трендвотчинг – эшкуарлар өчен уен» тренингы узды.

Проект һәм технологик эшчәнлек

Университет проект эшчәнлеген алып бара һәм федераль көн үзәген мәгариф мәйданчыгы буларак кына түгел, ә ясалма интеллект, пилотсыз авиация системалары, робототехника һәм технологияләр трансферы кебек юнәлешләр буенча компетенцияләрнең терәк үзәге буларак та катнаша.

2024 елда Иннополис университеты проект эшчәнлеге кысаларында 5 млрд сумнан артык акча җәлеп итте, портфельдә – илнең һәм Татарстан Республикасының әйдәүче компанияләренең бурычларын хәл итү мәнфәгатьләрендә югары технологияле юнәлешләр буенча 192 проект. 2012 елдан Иннополис университеты 500дән артык проектны гамәлгә ашырды, алар арасында 93 грант проекты.

Иннополис университетының төп заказчылары арасында Россиянең эре компанияләре: «Роскосмос» ДК, «Газпром» ГАҖ, «СИБУР Холдинг» ГАҖ, «КАМАЗ» ГАҖ, «Татнефть» ГАҖ, «Данафлекс-Нано»ҖЧҖ, «Газпром нефть» ГАҖ, «Россети» ГАҖ, «ОДК Кузнецов» ГАҖ, «ЕвроХим» АҖ, Huawei, «Ростелеком» ГАҖ, «Крылья Сахалина» ФҖҮ, «РЖД» ААҖ, «ОМК» АҖ һәм

башкалар.

**ИТ-бизнес өчен инфраструктура**

Казан һәм Чаллы шәһәрләрендәге технопаркларның техник, эшлекле һәм бизнес инфраструктурасы стартап-проектларның һәм ИТ-компанияләрнең барлык үсеш стадияләрендә: югары технологияле продукт эшләү идеясеннән алып соңгы продуктны гамәлгә керткәнгә кадәр аларны комплекслы үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтү платформасын булдыра. Технопаркларның гомуми мәйданы 100 мең кв.метрдан артык тәшкил итә, аларда 600дән артык резидент эшчәнлек алып бара, 5,7 мең эш урыны булдырыла.

ИТ-парк гадәттәгечә Россия Федерациясендә төбәк операторлары арасында «Сколково» фонды рейтингында алдынгы урыннарны алып тора.

2024 елда ИТ-парк тарафыннан 293 тармак ИТ-чарасы уздырыла, гомумән 47 меңнән артык кеше җәлеп ителә.

Татарстан Республикасының ИТ-паркы ИТ-компанияләр өчен дәүләт ярдәме чараларын кертүгә һәм аңлатуга актив ярдәм күрсәтә. Мәгълүмат кампаниясе һәм консультация ярдәме белән төбәк компанияләре грантлардан, субсидияләрдән, ташламалы кредитлардан, салым ташламаларыннан һәм «Россия Федерациясе Цифрлы икътисады» программасы кысаларында башка ярдәм чараларыннан файдаланырга мөмкин.

Татарстан Республикасыннан 15 ИТ-компания Инновацияләргә ярдәм фондыннан 87,9 млн сумлык гомуми суммага грантлар алды.

181 компания «кИТык» программасына күчте – ИТ-компанияләр өчен салым салуның гадиләштерелгән системасы, бу түбән ставкаларны кулланырга мөмкинлек бирде.

Балалар ИТ-паркы – уку-укыту форматы, анда балалар төп белем бирүне төрле темаларга үз проектларын булдыру белән бергә алып баралар. 2024 елда:

39 укучы төп белем бирүнең тулы көне программасы буенча укыды;

702 бала белем бирү сменаларында белем алды;

200дән артык бала өстәмә белем бирү курсларын тәмамлады;

2,7 меңнән артык бала мастер-классларда катнашты.

Стартап-Хаб – стартап-проектларны үстерү мәйданчыгы. Резидентлар ИТ-эшмәкәрләр бергәлегенә, спикерлар чыгышларына һәм мастер-классларга, питч-шоуларга, инвесторларга, экспертларга, трекингка, акселерацион һәм мәгариф программаларына керергә, шулай ук бизнеска ярдәм итүнең төбәк һәм федераль чаралары буенча консультацияләр алырга, Татарстан Республикасының һәм башка төбәкләрнең дәүләт хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлектән файдаланырга мөмкин. 2024 елда Стартап-Хаб территориясендә 20 резидент компания урнашты. Аларны файдаланудан җыелма табыш 6,3 млн сум тәшкил итте. 2024 елда Стартап-Хаб резидентларының җәлеп ителгән инвестицияләре 208 млн сумга җитте.

Бизнес-инкубатор – Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә стартап-проектларга ярдәм итү һәм аларны үстерү мәйданчыгы. 2024 елда Бизнес-инкубатор резиденты статусына 4 сайлап алу уздырылды, 320дән артык заявка бирелде, 50дән артык стартап-проект сайлап алынды.

2022 елда ИТ-парк резидентларының цифрлы чишелешләрен тарату максаты белән оештырылган Инновацион чишелешләр үзәге 2024 елда корпоратив клиентлар белән 90 млн сумнан артык суммага шартнамәләр төзеде.

«СФЕРА» оборона һәм инженерлык үсеше акселераторы – Россиядә инженерлык проектлау, оборона инновацион чишелешләре һәм хәрби тармак өлкәсендә стартап-проектларны үстерүгә һәм аларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән беренче акселерацион программа. 2024 елда программа Россиянең 7 төбәгеннән 57 заявка җәлеп итте, 10 стартап-команда акселерациянең тулы циклын уңышлы узды.

**Импортны алыштыру**

«АйСиЭл Техно» ҖЧҖ компьютерларда, ноутбукларда һәм серверлы җиһазларда кулланылачак ана платалар чыгару буенча беренче җитештерү линиясен эшләтеп җибәрде. 2024 елда беренче чираттагы җитештерү күләме 300 меңнән артык берәмлек тәшкил итте. План нигезендә, икенче чиратны башлап җибәрүне исәпкә алып, 2025 елда җитештерү күләме 1 млн берәмлектән артып китәчәк.

Бүгенге көндә Россиянең сәламәтлек саклау һәм мәгариф буенча илкүләм проектлары өчен компьютерларның 40 проценттан артыгы ICL компаниясендә җитештерелә. 2022 – 2024 елларда Россия операция системасы куелган, үз илебездә җитештерелгән 36 мең ноутбуклар республика укытучыларына бирелде.

Реверслы инжиниринг технологиясе кысаларында «В.И.Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ фәнни-техник партнер – КМТТУ-КАИ һәм инфраструктура партнеры – «Таттелеком» ГАҖ белән хезмәттәшлек итеп, кәрәзле элемтә өчен җиһазлар эшләү белән шөгыльләнә. Шулай ук гражданнар юнәлешендәге продукцияне үстерү өчен әлеге акционерлык җәмгыяте базасында радиоэлектрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопаркы төзү турында килешүгә ирешелде.

«Иннополис» МИЗ территориясендә микроэлектроника кластерын булдыру мөмкинлеге җентекләп өйрәнелә. Иярчен производстволар өчен 60 гектарга кадәр арттыру мөмкинлеге белән 21 га мәйданлы җир кишәрлеге бүлеп бирелде. Кластер төзелешен финанслау чыганагын билгеләү эше алып барыла.

Россия Федерациясе төбәкләре арасыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм бюджет учреждениеләренең Астра Линукс Россия операция системасына комплекслы күчешен беренче булып башлады. 2024 елда 95% эш урыннары күчерелде. 2025 елда Россия операция системасына 100% эш урыннарын күчерү планлаштырыла.

Цифрлы икътисад үсеше өчен мәгълүмат саклау үзәкләре күп санда таләп ителә. Республика территориясендә «Атомдата-Иннополис» АҖ «Иннополис» мәгълүматлар эшкәртү үзәге операторы булып тора, ул Идел буе федераль округында мәгълүматларны эшкәртү буенча иң эре коммерция үзәге (16 МВт гомуми электр куәте белән 2 меңгә кадәр стойка-урын). Компания коммерция һәм дәүләт предприятиеләре өчен сервер җиһазларын урнаштыру, сервер җиһазлары, элемтә (Telecom), болыт платформасын арендалау буенча хезмәтләр күрсәтү өлешендә югары технологияле сервисның киң спектрын тәэмин итә.

## КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ КӨРӘШҮ

Коррупция икътисад үсешенә, дәүләт идарәсе процессларына, хакимият белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләргә тискәре йогынты ясый торган тотрыксызландыру факторы булып тора.

Коррупциягә каршы тору буенча системалы чаралар икътисад үсешенә, сәламәт конкуренция тәэмин итүгә һәм инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга уңай шартлар тудыра.

Бу эшчәнлек юнәлешенең актуальлеге турында ел саен халык фикерен социологик тикшерү нәтиҗәләре раслый. Әйтик, 2024 елда соңгы ел дәвамында коррупция вәзгыятенә эләккән гражданнар өлеше республиканың 3 меңнән артык сораштырылган кешесеннән 9,6% тәшкил итте.

Гражданнар югары уку йортлары мөгаллимнәре, предприятиеләр җитәкчеләре, җирле администрацияләр чиновниклары, табиблар һәм медицина хезмәткәрләре эшчәнлегендә аеруча коррупция хәленә эләгү рискы бар дип саныйлар.

Республикада коррупциягә каршы тору эшчәнлеге хокук саклау, контроль-күзәтчелек органнары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, бизнес-берлекләр, фәнни берләшмәләр, иҗтимагый һәм дини оешмалар һәм гражданнарның үзләре катнашында комплекслы рәвештә алып барыла.

Республиканың дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары (54 зат – дәүләт хакимияте органнарында, 163 зат – җирле үзидарә органнарында) эшли.

Коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау максатларында барлык дәрәҗәләрдә системалы эш алып барыла, ул коррупциячел ситуацияләр барлыкка килүгә китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны минимальләштерүгә, коррупциячел хокук бозуларны кылудан салынган зыяннарны киметүгә юнәлдерелә, шул исәптән әлеге өлкәдә законнарны камилләштерү юлы белән алып барыла.

Шулай итеп, 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелде, анда чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен дисциплинар җаваплылыктан азат итү шартлары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләр һәм бу затка бәйле булмаган хәлләр (чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу һәм бурычларны башкару турындагы таләпләрне үтәү мөмкинлеген юкка чыгара торган гадәттән тыш һәм туктатып булмый торган хәлләр) аркасында булган очракларда йөкләмәләрне үтәмәү аңлатыла.

Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан үтәлеше контрольдә тотыла торган чикләүләр һәм тыюлар коррупциягә каршы тору турында, дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт турында федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына йөкләнде.

Хезмәткәрләр тарафыннан билгеләнгән чикләүләрнең һәм тыюларның, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрнең

үтәлеше буенча үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча хокук бозулар өчен дисциплинар җаваплылыкка Татарстан Республикасының 6 дәүләт граждан хезмәткәре тартылды.

Бу уңайдан дәүләт граждан хезмәткәрләренең коррупциягә каршы аң-белем бирү мәсьәләләренә аерым әһәмият бирелә.

Хезмәткәрләр тарафыннан чикләүләр һәм тыюлар, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне контрольдә тоту эшен башкару нәтиҗәлелеген арттыру, алар тарафыннан коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән йөкләмәләр үтәлү коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы вазыйфаи затларның хокукый белемнәрен актуальләштерергә ярдәм итә.

2024 елда, әлеге максатларны күздә тотып, КФУның Дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә югары мәктәбе базасында дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр квалификациясен күтәрү өчен дистанцион һәм турыдан-туры катнашу формасында «Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау бүлекчәләре функцияләре» һәм «Коррупцияне профилактикалау нигезләре» дигән 4 программа гамәлгә ашырылды. Программалар түбәндәге блокларны үз эченә ала: коррупциягә каршы законнарда билгеләнгән коррупцияне профилактикалау буенча чаралар, йөкләмәләр, чикләүләр, тыюлар, коррупциягә каршы үз-үзеңне тоту стандартлары, коррупциягә каршы тору системасының гомуми тасвирнамәсе, дәүләт хакимияте органнарында һәм җирле үзидарә органнарында коррупция рискларын бәяләүне уздыру, социологик тикшеренүләр, республика дәүләт хакимиятенең һәм җирле үзидарә органнарының коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә карата коррупциягә каршы мониторинг ясау, керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында белешмә тапшыру.

Әлеге программалар буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары кадрлар хезмәтләренең коррупциячел хокук бозуларны профилактикалауга җаваплы 41 вазыйфаи заты белем алды.

Коррупцияне профилактикалауда башкарма хакимият органнарының иҗтимагый оешмалар һәм башка гражданлык җәмгыяте институтлары белән, шул исәптән хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре һәм коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссияләре эшчәнлеге кысаларында хезмәттәшлеге мөһим роль уйный. Әлеге комиссияләрдә 38 иҗтимагый оешма вәкиле катнаша.

Шулай ук гражданнарга хокукый һәм коррупциягә каршы аң-белем бирү максатларында конференцияләр, түгәрәк өстәлләр һәм фәнни-гамәли семинарлар уздыру кебек үзара хезмәттәшлек формалары актуаль булып тора. 2024 елда дәүләт хакимияте органнарында иҗтимагый оешмалар катнашында 148 чара уздырылды. Бу юнәлештә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе актив эшли.

Татарстанда «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кабул ителде

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланды), аның нигезендә икътисад һәм социаль өлкә белән дәүләт идарә итүен камилләштерүгә, шулай ук гражданнарга хокукый белем бирүгә һәм аларда коррупциягә каршы караш формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырыла.

Аерым алганда, дәүләт программасында махсус агитация һәм иҗтимагый, мәгълүмат һәм аң-белем бирү акцияләре циклын гамәлгә ашыру карала, ул җәмгыять тормышында һәм үсешендә тулысынча катнашуга, гражданлык активлыгына әхлакый әзер булган яшьләр буынын тәрбияләүгә юнәлдерелә, бу озак сроклы перспективадан чыгып караганда коррупция барлыкка килү шартларын минимальләштерә.

2024 елның декабрендә Коррупциягә каршы республика форумы үткәрелде. Бер мәйданчыкта 300дән артык катнашучыны берләштергән чараның төп максаты – җәмгыятькә коррупциянең куркыныч булуын аңлауны һәм законнарда каралган барлык спектрдагы инструментларны каршы куярга кирәклеген күрсәтү. Форумга республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе, җирле үзидарә органнары, коррупцияне профилактикалау чараларын гамәлгә ашыруда катнашучы мәгариф, фәнни һәм эшкуарлык берләшмәләре, иҗтимагый һәм яшьләр оешмалары вәкилләре чакырылды һәм спикер буларак чыгыш ясады. Форум «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының рәсми сайтында трансляцияләнде.

Коррупцияне профилактикалау чараларына республиканың төрле оешмалары тоташа. Мәсәлән, республика башкарма хакимият органнарының һәм җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларда (якынча 5 мең оешмада) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау буенча чаралар гамәлгә кертелде. Республиканың зур предприятиеләре коррупциягә каршы сәясәтне һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы нигезләмәләрне раслады. Хезмәткәрләрнең законга каршы килә торган гамәлләрен кисәтү буенча комплаенс-системаны гамәлгә кертү буенча актив эшләр В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «КАМАЗ» ГАҖ, «СИБУР Холдинг» ГАҖ һ.б. тарафыннан алып барыла.

Ачык профилактика эшенә игътибар бирелә. 2024 елның июнендә Татарстан Республикасында коррупциягә каршы комплаенсны һәм эшлекле этиканы үстерү советының «Комплаенс-системаны кертүнең һәм коррупциягә каршы һәм репутацион рискларны киметүнең, шул исәптән кече һәм урта бизнес өчен, нәтиҗәле инструмент буларак хакимият синергиясенә, коммерциячел булмаган секторга, эшлекле һәм фәнни бергәлеккә нигезләнгән эре бизнесның уңышлы корпоратив тәҗрибәләрен трансляцияләү» темасына утырыш уздырылды. Чарада турыдан-туры һәм читтән торып бизнес-структураларның, дәүләт хакимияте органнарының, фәнни һәм иҗтимагый оешмаларның 400дән артык вәкиле катнашты.

Коррупциягә каршы сәясәтне тәэмин итүнең төп чараларыннан берсе – коррупциягә каршы аң-белем бирүне һәм пропаганданы оештыру. Массакүләм мәгълүмат чаралары җәмгыятькә коррупциянең яшерен механизмнары турында мәгълүмат бирү мөмкинлеген тәэмин итә, шулай итеп аның таралуын туктата. 2024 елда мөстәкыйль рәвештә яисә дәүләт хакимияте органы ярдәмендә коррупциягә

каршы торуга багышланган якынча 4 400 материал – программалар, фильмнар, басмалар эшләнде.

Коррупциягә каршы тору законнарының таләпләрен исәпкә алып, коррупцияне профилактикалау өлкәсендә түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру дәвам итәчәк:

дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары эшенә хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюлар, чикләүләр һәм таләпләрне үтәвен тәэмин итү буенча методик һәм консультация ярдәме күрсәтү;

дәүләт хакимияте һәм муниципаль хакимият башкарма органнарының ведомство буйсынуындагы бюджет оешмаларында мәнфәгатьләр конфликтын кисәтүгә һәм җайга салуга юнәлдерелгән эш;

дәүләт ихтыяҗларын яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә коррупциягә каршы тору чараларын камилләштерү;

дәүләт хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы үз-үзләрен тотышын формалаштыруга, җәмгыятьтә коррупциягә каршы стандартларны популярлаштыруга һәм иҗтимагый хокук аңын үстерүгә юнәлдерелгән агарту, белем бирү һәм башка чараларның нәтиҗәлелеген арттыру;

бизнес өлкәсендә коррупциягә каршы тору буенча чараларны камилләштерү.

# Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында сораулар исемлеге буенча мәгълүмат

## Икътисад, бюджет

**1. Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан 2025 елда хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм түбән квалификацияле эш урыннарын бетерү буенча күрелгән программалы чаралар турында.**

Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча ике инструменттан файдаланыла:

1. «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү» төбәк проекты.

Проектны гамәлгә ашыру 2025 елдан 2027 елга кадәр планлаштырыла һәм ул кереме кимендә 200 млн сум булган предприятиеләргә түбәндәгеләргә кагылышлы эксперт ярдәме күрсәтүне күздә тота:

- сакчыл җитештерү инструментларын гамәлгә кертү һәм хезмәткәрләрне алардан файдаланырга өйрәтү;
- диагностика буенча комплекслы проектларны гамәлгә ашыру: предприятиедә диагностика уздыру һәм бизнес процессларында, сакчыл җитештерү алымнарын һәм ИТ-продуктлар файдаланып, иң яхшы нәтиҗәләргә ирешү буенча карарлар эшләү;

2. «Хезмәт җитештерүчәнлеге» төбәк проекты – «Нәтиҗәле һәм конкуренциячел икътисад» илкүләм проектының структурасына керә торган «Хезмәт җитештерүчәнлеге» федераль проектының төбәк өлеше.

Проектны 2025 елдан 2030 елга кадәр гамәлгә ашыру каралган һәм ул сакчыл җитештерү инструментларын гамәлгә кертүне һәм хезмәткәрләрне алардан файдаланырга өйрәтүне күздә тота. Предприятиеләрне сайлап алуның төп критерийлары: елына кимендә 400 млн сум керем алу; устав капиталында чит ил илләрнең катнашуы өлеше 50 процентган артып китмәү. Туристлык өлкәсе чыгарма булып тора – монда еллык керем кимендә 180 млн сум булырга тиеш.

Төбәк проектларында түләүсез катнашу каралган, эшләр федераль һәм төбәк бюджетлары хисабыннан финанслана.

Икътисадның чимал булмаган продуктлар җитештерү тармаклары предприятиеләрендә җитештерүне үстерү программалары чараларын үтәүче – Татарстан Республикасының Хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендәге төбәк компетенцияләр үзәге (алга таба – ТКҮ). Ул «Татарстан Республикасында энергия ресурслары ягыннан нәтиҗәле технологияләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе базасында төзелде.

2024 елда ТКҮ «Федераль компетенцияләр үзәге» акционер коммерциячел булмаган оешмасында һәм Россиянең Икътисадый үсеш министрлыгында рәвештә сертификацияләүне уңышлы узды. ТКҮ Россия Федерациясенең иң яхшы төбәк компетенцияләр үзәкләре бишлегендә тотрыклы рәвештә урын тота (2024 ел йомгаклары буенча – беренче урында).

2019–2024 елларда «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проектын гамәлгә ашыру республикада ике төбәк проекты кысаларында гамәлгә ашырылды:

- «Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча системалы чаралар», анда гомуми оештыру чаралары күздә тотыла һәм ул илкүләм проектта катнаша торган предприятиеләргә ярдәм итү өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән («Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү» сәнәгатьне үстерү фонды программасы буенча ташламалы займ, «Җитештерү алдынгылары» идарә кадрларын әзерләү программасы буенча укыту, «Эксперт үсеше акселераторы», ел саен уздырыла торган остазлыкның иң яхшы тәҗрибәләре бәйгесе, «Нәтиҗәлелек.рф» цифрлы нигездә кабул ителгән карарлар платформасы), финанслау каралмаган;

- «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм» төбәк проекты, аның кысаларында ТКҮ икътисадның чимал булмаган продуктлар җитештерү тармаклары предприятиеләрендә «сакчыл җитештерү» технологияләрен гамәлгә кертү, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең һәм хезмәткәрләрне өйрәтүнең иң яхшы тәҗрибәләрен популярлаштыру чараларын оештырды.

Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проектын гамәлгә ашыру йомгаклары:

- Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән килешү төзеп, 264 предприятие проектта катнаша (план күрсәткече – 257 предприятие);

- проектта катнаша торган предприятиеләрнең 4960 хезмәткәре һәм шул исәптән төбәк хакимият органнары вәкилләре хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү инструментларыннан файдаланырга өйрәтелде (план күрсәткече – 4 155 кеше);

- проектта катнашучы 89 предприятиенең 532 вәкиле 2019–2024 елларда «Җитештерү алдынгылары» идарә кадрларын укыту программасын узды;

- «Эксперт үсеше акселераторы» экспорт мөмкинлекләрен үстерү программасын узып, проектта катнаша торган предприятиеләрнең 59 командасы үз компетенциясен күтәрде;

- илкүләм проектта катнашучы 15 предприятие Сәнәгатьне үстерү фондының «Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү» программасы буенча 5 елга кадәр вакытка проектларны гамәлгә ашыруга еллык 3 процenttан алып 5 процентка кадәр ставка буенча 3 210,1 млн сум күләмдә займнар алды.

2024 елда «Остазлыкның иң яхшы тәҗрибәләре» бәйгесенең төбәк этабы үткәрелде. Төбәк этабында җиңүчеләр дип танылдылар: «Яшьләрне һөнәри яктан үстерү» номинациясендә – «ПОЗиС» АҖ; «Предприятиедә цифрлы инновацияләр» номинациясендә – «Август Алабуга» ҖЧҖ; «Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча остазлыкның иң яхшы тәҗрибәләре» номинациясендә – «Татэнерго» АҖ филалы – Зәй ДРЭС.

Россиянең Икътисадый үсеш министрлыгының якынча рейтингы мәгълүматларына караганда, илкүләм проектны гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында 2024 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы 2 урында тора.

**2. Республика тармак программалары гамәленең бишьеллык срогы тәмамлану белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасының 2030 елга кадәрге чорга социаль-икътисадый үсеше стратегиясен гамәлгә ашыру индикаторларына төзәтмәләр кертүнең максатка ярашлыгы турында.**

Татарстан Республикасының 2030 елга кадәрге чорга социаль-икътисадый үсеше стратегиясенең (алга таба – Стратегия-2030) төп максатлары үзгәрешсез кала. Төп өстенлек кеше һәм кеше капиталын үстерү дип танылa.

Стратегия-2030 дәүләт программалары, шулай ук илкүләм проектлар ярдәмендә башкарыла. Аларны төзегәндә һәм гамәлгә ашырганда бара торган үзгәрешләр һәм агымдагы вазгыять исәпкә алына. Аерым алганда, республикада җәмгыять тормышының икътисадый һәм социаль өлкәсенә кагылышлы 34 дәүләт программасы гамәлгә ашырыла. 2024 елда 33 дәүләт программасына аларның гамәле вакытын 2027 елга кадәр, «Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасының гамәле вакытын 2030 елга кадәр озайту өлешендә үзгәреш кертелде.

Гамәлгә ашыру индикаторлары өлешендә Стратегия-2030-га үзгәрешләр кертүне, 2020 елда икътисадка, социаль өлкәгә коронавирус чиренең йогынты ясавы, 2022 елда илгә карата моңарчы күрелмәгән чикләүләр кертелү, яңа стратегик планлаштыру документлары, аерым алганда, Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеше стратегиясе турында» 2024 елның 28 февралендәге 145 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр фаразлап Россия Федерациясенең пространство үсеше стратегиясен раслау турында» 2024 елның 28 декабрендәге 4146-р номерлы боерыгы кабул ителү белән бәйле рәвештә, геосәяси шартлар тотрыклы хәлгә килгәннән соң әзерләү планлаштырыла.

## 3. Чикләүләр кертү белән басым ясау шартларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру турында.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына (алга таба – КУЭ) 2024 елда финанслар белән һәм финанслар булмаган ярдәм чаралары комплексы күрсәтелә. Мондый чаралардан якынча 40 мең КУЭ субъекты файдаланды, шулардан 4 меңнән артык субъектка якынча 83 млрд сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелде.

Түбәндәге республика ярдәм чаралары күрсәтелде:

- поручительлек – 4,1 млрд сумга (715 поручительлек, эшкуарларга бу 9 843,5 млн сумга заем финанславыннан файдаланырга мөмкинлек бирде);
- ташламалы заемнар һәм микрозаемнар – 2,3 млрд сумга (22,2 млн сумга 2 заем һәм 2 273,5 млн сумлык 885 микрозаем ) бирелде;
- партнерлык финанславы – 130,2 млн сумга (39 килешү);
- электр энергиясенә чыгымнарны субсидияләү – 29,9 млн сумга (20 субсидия);
- ташламалы лизинг – 438,4 млн сумга (лизинг алучы 63 зат).

Түбәндәге федераль ярдәм чаралары күрсәтелде:

- сәнәгать ипотекасы – 933,4 млн сум;
- кредитларга субсидияләр – 11,0 млрд сум;
- авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен ташламалы кредит бирү – 53,1 млрд сум;
- 2,5–4% ташламалы кредит бирү – 550,0 млн сум;
- ИТ-оешмаларга ташламалы кредит бирү – 501,6 млн сум;
- кредитларны реструктуризацияләү – 9,4 млрд сум.

2024 елда «Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык башлангычына ярдәм» илкүләм проекты кысаларында республикада өч төбәк проекты гамәлгә ашырылды:

1. «Үзмәшгуль гражданнар эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен уңай шартлар булдыру» (ташламалы ставка белән микрозаемнар бирү, поручительлекләр бирү, үзмәшгуль гражданнарга «Минем бизнес» үзәге базасында мәгълүмати һәм консультация хезмәте күрсәтү);

2. «Бизнесны җиңел башлап җибәрү һәм уңай шартларда алып бару өчен шартлар булдыру» (комплекслы хезмәт күрсәтү, эш башлаучы эшкуарларга комплекслы финанс-гарантия ярдәме (микрозаемнар, поручительлек) күрсәтү);

3. «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының акселерациясе» (комплекслы финанс-гарантия ярдәме, ташламалы микрозаемнар бирү, комплекслы хезмәт күрсәтү, экспортка эшләүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү, сәнәгать мәйданчыкларын үстерү).

2024 елда эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына дәүләт ярдәме күрсәтүгә 1,1 млрд сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан – 1,0 млрд сум, «Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык башлангычына ярдәм» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында федераль бюджет акчалары хисабыннан – 129,4 млн сум.

КУЭ субъектларына финанс ярдәменең кайбер продуктлары бирелде.

Теркәлү вакыты 23 айдан артып китмәгән эш башлаучы КУЭ субъектларына, 2024 елда «Татарстан Республикасы эшкуарлыкка ярдәм фонды» (алга таба – «Татарстан Республикасы эшкуарлыкка ярдәм фонды» МКК КБО) коммерциячел булмаган микрокредит оешмасының «Эшкә керешүчеләр+» микрофинанс продукты гамәлгә кертелде.

Гамәлдәге эшкуарлар өчен, шул исәптән икътисадның реаль секторында эшләүчеләр өчен, түбәндәге дәүләт ярдәме чаралары күрсәтелде:

- төп эшчәнлек төре файдалы казылмалар чыгару, электр энергиясе белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, транспортлау, төзелеш, сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәт күрсәтү һәм башкалар (ОКВЭД классификаторының B, D, E, F, H, L, M, S, Q, R бүлекләре) булган КУЭ субъектлары өчен «Ярдәм» микрофинанс продукты.

- КУЭ өчен түбәндәге өстенлекле юнәлешләрне үстерү таләпләренең берсенә булса да җавап биргән КУЭ субъектлары өчен «Өстенлекле» микрофинанс продукты:

а) төп эшчәнлек төре: эшкәртү производстволары, мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек, кунакханәләр һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре эшчәнлеге (ОКВЭД классификаторының C, J, I бүлекләре);

б) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектына ярдәм инфраструктурасы булып торган оешмаларга, үзмәшгуль гражданнарга аренда түләвенең ташламалы ставкасы белән озак вакытка биләүгә һәм (яисә) файдалануга бирү өчен төбәк һәм муниципаль милек исемлекләренә кертелгән күчемсез милек объектлары буенча гамәлдәге аренда шартнамәләре булган;

в) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән индустриаль (сәнәгать) парклары территорияләрендә эшчәнлек алып бару турында килешү төзегән;

г) 2023 елда һәм (яисә) 2024 елда товарның төяп озатылуы расланган гамәлдәге экспорт контракты булган;

д) «Россия Федерациясендә технология компанияләрен үстерү турында» 2023

елның 4 августындагы Федераль закон нигезендә кече технология компанияләре реестрына кертелгән;

е) Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы норматив акты белән билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләре буенча, интеллектуаль милекне залогка биреп, өстенлекле проектлар гамәлгә ашыручы;

- микрозаемга заявка биргән вакытка контракт буенча хәрби хезмәткә бер яисә бердән артык хәрби хезмәткәр җибәргән КУЭ субъектларының барысы яисә МХО зонасыннан хәрби хезмәттән әйләнеп кайткан шәхси эшкуар өчен «МХОга ярдәм итү» микрофинанс продукты;

- интеллектуаль милекне залогка биреп, өстенлекле проектларны гамәлгә ашыручы КУЭ субъектлары – юридик затлар өчен «Файдалы модель» финанс продукты.

Моннан тыш, Татарстан территориясендә бизнес өчен партнерлык финанславы буенча экспериментны гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәге продуктлардан файдаланырга мөмкин:

- «мурабаха-ярдәм» – эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган товарларны/җиһазларны, кичектереп түләү биргән өчен акча алып, кичектереп түләү шартларында сату-алу юлы белән финанслау;

- «иджара-җитештерүне үстерү» – финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча сәнәгать парклары территорияләрендә җитештерү эшчәнлеге алып бару өчен җиһазлар бирү юлы белән финанслау.

«Татарстан Республикасы эшкуарлыкка ярдәм фонды» МКК КБОның «Минем бизнес» үзәге һәм экспортка ярдәм итү үзәге тарафыннан финанс ярдәме булмаган күп кенә төрле ярдәм күрсәтелә.

«Татарстан Республикасы эшкуарлыкка ярдәм фонды» МКК КБОның «Минем бизнес» үзәге тарафыннан 2024 елда:

- 28 меңнән артык КУЭ субъектлары һәм үзмәшгуль гражданнар, физик затлар өчен 46 меңнән артыграк хезмәт күрсәтелде, 77 чара оештырылды (Татарстан Республикасында эшкуар көне, «Минем бизнес. E-com» форумы, үзмәшгуль гражданнар өчен «Мин инде ул Татарстан» ярминкәсе һ.б.);

- «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорациясе» АҖ тарафыннан эшләнгән 50дән артык тренинг уздырылды, аларда 2,6 меңнән артык кеше катнашты;

- 5,1 меңнән артык үзмәшгуль гражданга мәгълүмати-консультация хезмәте күрсәтелде;

- 201 КУЭ субъекты социаль предприятие дип танылды;

- социаль эшкуарлык, социаль һәм социаль-эшкуарлык проектлары мәсьәләләре буенча 3,5 меңнән артык консультация уздырылды;

- 1,6 меңнән артык граждан социаль контракт буенча укып, сертификатлар алдылар;

- социаль эшкуарлык өлкәсендәге һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның проектлары буенча «Минем игелекле бизнес» бөтенроссия конкурсының төбәк этабы уздырылды, аның кысаларында социаль предприятиеләрнең 9 проекты һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның 7 проекты җиңүче дип танылды;

- күргәзмә-ярминкә чараларында катнашу, маркетплейсларга чыгу, үз продукциясен/хезмәтләрен тарату буенча 2,7 меңнән артык комплекслы хезмәт

күрсәтелде.

«Татарстан Республикасы эшкуарлыкка ярдәм фонды» МКК КБО экспортка ярдәм үзәге тарафыннан:

- «Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык башлангычына ярдәм» илкүләм проекты кысаларында 3,4 мең диярлек КУЭ субъектына ярдәм чаралары күрсәтелде;

58 КУЭ субъектына чит ил базарларына чыгуда ярдәм күрсәтелде;

20 халыкара күргәзмә-ярминкә чарасында 61 уникаль КУЭ субъектының катнашуы оештырылды;

халыкара электрон сәүдә мәйданчыкларында КУЭ субъектлары продукциясен урнаштыру оештырылды;

«Россия экспорт үзәге» АҖнең белем бирү семинарларында 64 КУЭ субъектының катнашуы оештырылды;

ике КУЭ субъектына үз продукциясенә сертификатлар алуда хезмәт күрсәтелде;

15 КУЭ субъектына экспорт контрактын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтелде;

өч түгәрәк өстәл, 90 нан артык вебинар һәм семинар үткәрелде.

**4. Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү чаралары турында.**

Республиканың хезмәт базарында хәзерге вазгыять түбәндәгеләр белән характерлана:

- эш белән тәэмин ителешнең югары дәрәҗәсе – 62,4 % (Идел буе федераль округында – 60,7%, Россия Федерациясендә – 61,8%);

- гомуми эшсезлекнең түбән дәрәҗәсе – 1,8% (Идел буе федераль округында – 1,7%, Россия Федерациясендә – 2,3%);

- теркәлгән эшсезлекнең түбән дәрәҗәсе – 0,16% (Идел буе федераль округында – 0,3%, Россия Федерациясендә – 0,4%);

- кадрларга ихтыяҗ саклану – бүгенге көнгә «Россиядә эш» бердәм цифрлы платформасында вакансияләр саны – 34 мең эш урыны, шул исәптән сәнәгать секторында – 10,3 мең эш урыны.

Республикада республика һәм муниципаль башкарма хакимият органнары арасында ведомствоара хезмәттәшлек урнаштырылган. Предприятиеләрне кадрлар белән тәэмин итү, иң беренче чиратта ОСК предприятиеләрен кадрлар белән тәэмин итү, республика хөкүмәтенең күзәтчелегендә тотыла.

Кадрларга ихтыяҗны канәгатьләндерүне оештыруда өстенлекле аерым тармаклар исемлеге нигезендә республикада 257 ОСК предприятиесе билгеләнде, шул исәптән алар арасында өстенлекле әһәмияткә ия предприятиеләр бар («КАМАЗ» ГАҖ (Чаллы шәһәре), «Ремдизель» АҖ (Чаллы шәһәре), «АСТЕЙС» АҖ (Чаллы шәһәре), «Эникс» АҖ (Казан шәһәре). 2025 елның 20 мартына 257 предприятиедә кадрларга ихтыяҗ 17 317 кеше тәшкил итте, хезмәткәрләрнең исемлек нигезендәге исәбе – 160,9 мең кеше.

Республика хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан ОСК предприятиеләренә һәм аларның хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән ярдәм чараларының гамәлгә ашырыла. ОСК предприятиеләре эшенең четерекле мәсьәләләрен карап тикшерү һәм хәл итүгә ярдәм итү буенча төбәк

штабы оештырылды.

Татарстан Республикасы эшкә урнаштыру үзәкләре тарафыннан алар хезмәт күрсәтә торган территорияләрдә урнашкан барлык ОСК предприятиеләре белән хезмәттәшлек урнаштырылган. Шулай ук һәр предприятиегә предприятиенең кадрлар хезмәте белән индивидуаль хезмәттәшлек оештыру максаты белән кадрлар хезмәте буенча персональ консультант беркетелгән, ул түбәндәгеләрне башкара:

- әлеге предприятиеләрдә кадрларга ихтыяҗны тәэмин итүнең барлык мәсьәләләре буенча мәгълүмат һәм консультация бирү;
- «Россиядә эш урыннары» цифрлы платформасында вакансияләр турында мәгълүмат урнаштыруда ярдәм күрсәтү;
- әлеге предприятиеләрдән (аларның вәкилләреннән) кирәкле хезмәткәрләр сайлап алуда ярдәм итү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүдә ярдәм итү;
- «Россиядә эш урыннары» цифрлы платформада эш бирүченең шәхси кабинетында предприятие турында мәгълүматларга үзгәрешләр кертү.

Республикада ОСК предприятиеләрен кадрлар белән комплектлау планнары эшләнде һәм расланды.

Предприятиеләрнең кадрларга ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен түбәндәге чаралар башкарыла:

- Россия Федерациясенең башка субъектларыннан гражданнарның «Россиядә эш урыннары» цифрлы платформада үзләре турында биргән мәгълүматлары  (резюме) предприятиеләрдә расланган исемлек нигезендә кирәкле булган һөнәрләр (вазыйфалар, белгечлекләр) буенча анализ ясала һәм җитәкчеләргә тапшырыла;
- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елда аерым категориядәге гражданнарны эш белән тәэмин  итүне стимуллаштыру максатларында юридик затларга, коммерциячел булмаган оешмаларны да кертеп, шәхси эшкуарларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2021 елның 13 мартындагы 362 номерлы карары нигезендә гражданнар эшкә урнаштырыла;
- предприятиеләр хезмәткәрләренә Һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирелә,
- эшсез калган гражданнарга хезмәт базарында кирәкле һөнәрләр буенча белем һәм өстәмә белем бирелә.

Шул исәптән, ОСК предприятиеләренә мәгариф учреждениеләрен тәмамлаучыларны урнаштыру максатларында югары һәм урта мәгариф учреждениеләре белән хезмәттәшлек урнаштырылган. Алар өчен ОСК предприятиеләре вәкилләре катнашында Эш бирүче көннәре уздырыла, алар шулай ук предприятиеләр вәкилләре белән танышу өчен эш урыннары ярминкәләренә чакырылалар, яшьләргә үзләренең шәхси үзенчәлекләрен һәм хезмәт базарындагы актуаль вазгыятьне исәпкә алып һөнәр сайларга ярдәм итә торган һөнәр юнәлешен сайлау уздырыла.

Социаль челтәрләр, телеграм-каналлар, халыкны эшкә урнаштыру үзәкләрендә мониторлар аша, электрон почта һәм смс-мәгълүмат, профильле төркемнәр аша, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре чаралары (эш урыннары ярминкәләр,  эш бирүчеләр көннәре, семинарларлар, тренинглар һ.б.) кысаларында эшкә  персонал җыю турында мәгълүмат урнаштыру буенча киң мәгълүмати кампания алып барыла.

2024 елда Татарстан Республикасы халыкны эшкә урнаштыру үзәкләре тарафыннан 384 вакансияләр һәм эшкә өйрәтү урыннары ярминкәләре уздырылды, аларда эшкә урнаштыру өчен 42 203 потенциаль кандидат катнашты. Вакансияләр ярминкәләрендә 2 589 предприятие һәм 233 уку йорты катнашты. Аларны уздыру нәтиҗәсендә 6 123 кеше эшкә урнаштырылды.

Халыкны эшкә урнаштыруга ярдәм итү буенча киң мәгълүмати кампания уздыру максатларында Татарстан Республикасы күпфункцияле үзәкләр офисларында һәм сәүдә үзәкләрендә предприятиеләрдә эш урыннары турында мәгълүмат урнаштырган стендлар куелды. Халыкны эшкә урнаштыру үзәкләрендә ОСК предприятиеләренең реклама буклетлары урнаштырылды.

«Авито» платформасында хезмәттәшлек кысаларында кадрларга ихтыяҗ һәм буш эш урыннары турында мәгълүмат урнаштырылган аккаунт булдырылды.

Вакансияләр турындагы мәгълүмат «Россиядә эш урыннары» цифрлы платформасында чагылыш тапты.

2025 елның 29 мартына ОСК предприятиеләре өчен эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан сайлап алынган кандидатларның гомуми саны 15 764 кеше тәшкил итте.

Шулай итеп, 2022 елның ноябреннән (Роструд хисабы кертелгәннән башлап) 2025 елның 29 мартына кадәр ОСК предприятиеләрендә хезмәткәрләр эшкә урнаштырылган эш урыннары (вакансияләр) гомуми саны 70 356 берәмлек булды, шул исәптән:

- 7 191 – эшкә урнаштыру хезмәте аша, эш урыннары ярминкәләрен оештыруны да кертеп;
- 5 393 – югары белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү учреждение студентларын җәлеп итү хисабына;
- 663 – Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте учреждениеләре контингентын җәлеп итү хисабына.

ОСК предприятиеләренә башка төбәкләрдән хезмәткәрләрне җәлеп итү максатларында эш бирүчеләрнең хезмәткәрләргә эш хакы түләүгә тоткан чыгымнарын компенсацияләү механизмы гамәлгә ашырылды.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елда аерым категориядәге гражданнарны эш белән тәэмин итүне стимуллаштыру максатларында юридик затларга, коммерциячел булмаган оешмаларны да кертеп, шәхси эшкуарларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2021 елның 13 мартындагы 362 номерлы карары нигезендә 2024 елда икътисад өчен мөһим ОСК предприятиеләренә хезмәткәрләр җәлеп итүгә ярдәм күрсәтү максатларында эш бирүчеләрнең Россия Федерациясенең башка субъектларыннан яисә, элеккеге яшәү урыныннан яңа эш урынына кадәр булган ара 50 километрдан ким булмаса, субъект чикләреннән җәлеп ителгән хезмәткәрләргә эш хакы түләүгә чыгымнарын каплау механизмы гамәлгә ашырылды. Хезмәткәрләр җәлеп итүгә ихтыяҗы булган, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмалар исемлегенә кертелгән ОСК оешмаларга субсидияләр алу мөмкинлеге бирелде (63 оешма). Әлеге карарны гамәлгә ашыру кысаларында 1 898 кеше эшкә урнаштырылды (субсидияле наем).

Эшкә урнаштырылган бер граждан өчен эш бирүчегә өч айга бер тапкыр күләме «Хезмәт хакының минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларына түләнгән иминиятләштерү кертемнәре суммасына арттырылган 3

минималь хезмәт хакы түләнде. Эш бирүчегә чыгымнарын каплауның иң чик күләме 2024 елда 300,2 мең сум тәшкил итте.

2024 елда эш бирүчеләрнең алтысына («КАМАЗ» ГАЖ, «Л.Я.Карпов исемендәге химия заводы» АЖ, «Казан вертолет заводы» АЖ, «Элекон» заводы» АЖ, «Электросоединитель» АЖ, «Федерал-Могул Чаллы» ҖЧЖ) 57 кеше урнаштырылды.

2025 елда әлеге ярдәм чарасы Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының «Башка җирләрдән яисә башка территорияләрдән килгән хезмәткәрләрне эшкә урнаштыруга дәүләт ярдәменә субсидия бирү тәртибе турында карарны раслау турында» 2024 елның 29 декабрендәге 2713 номерлы боерыгы чикләрендә башкарылачак. Эш бирүчегә чыгымнарын каплауның иң чик күләме 350,1 мең сум тәшкил итәчәк.

Республика предприятиеләренең квалификацияле кадрларга ихтыяҗын бетерү өчен күрелә торган чараларның берсе – ОСК предприятиеләре хезмәткәрләренә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү. Укытуны оештыру механизмы – ОСК предприятиеләренә бер кешене укытуга тотыла торган чыгымның уртача күләменнән – ул 59 580 мең сум тәшкил итә – чыгып исәпләп субсидия бирү.

2024 елда Казан, Чаллы, Зеленодольск шәһәрләренең һәм Ютазы муниципаль районының 7 предприятиесеннән 477 хезмәткәр һөнәри белем алды . 2025 елда чаралар «Кадрлар» илкүләм проекты кысаларында дәвам иттереләчәк.

Хезмәткәрләренә һөнәри белем бирү хокукы булган ОСК предприятиеләре исемлеге Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы боерыгы нигезендә раслана. 2025 елда бу исемлеккә республиканың 42 предприятиесе кертелде (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2025 елның 25 гыйнварындагы 294 номерлы боерыгы (хезмәт урынында файдалану өчен).

Әлеге максатларга 26,6 млн сум каралган, шул исәптән федераль бюджеттан – 21,0 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 5,6 млн сум.

## 5. Һөнәрләр категорияләре буенча цифрлы нигездә бердәм республика вакансияләр базасын булдыру мөмкинлеге турында.

Россия Федерациясендә «Россиядә эш урыннары» эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә цифрлы нигезгә корылган бердәм платформа булдырылды, анда хезмәткәрләргә ихтыяҗы булган эш бирүчеләр, буш эш урыннары һәм вазыйфалар булуы, эш табарга теләүче гражданнар, шулай ук гражданлык-хокукый шартнамә буенча эш башкару һәм (яисә) хезмәт күрсәтү ихтыяҗы турында мәгълүмат урнаштырыла.

Хәзерге вакытта «Россиядә эш урыннары» цифрлы платформасында Россия Федерациясенең барлык субъектлары, шул исәптән Татарстан Республикасы буенча вакансиләр турында мәгълүмат туплана (https://trudvsem.ru). Ул эш бирүчеләргә дә, гражданнарга да хезмәт итә.

Моннан тыш, «Россиядә эш урыннары» цифрлы платформасын эш урынын алдан билгеләп белем алу, стажировка, практика узу өчен гаризалар бирү, шулай ук эш бирүчеләрнең сораштыруларына җавап бирү, резюме урнаштыру максатларында файдаланырга мөмкин.

Республиканың үзенә аерым цифрлы нигезгә корылган вакансияләр базасын булдыру максатка ярашлы түгел.

**6. Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексында Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм сату күләмен арттыруга, хуҗалык итүнең кече формалары, кооперативлар эшенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлтелгән кооперация элемтәләрен үстерү өчен күрелә торган чаралар турында.**

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясе авылда хуҗалык итүнең кече формаларының актив үсүен күрсәтә.

Татарстанда авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына дәүләт ярдәме күрсәтүгә түбәндәге чаралар каралган:

- авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә грант – бер авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативына 70 млн сумга кадәр. Грант алу шартлары түбәндәгеләр: проектның гомуми суммасының 40 процентын грантка дәгъва кылучы үзе салырга (60% – грант) һәм эшчәнлеген кимендә 1 ел дәвам иттерергә тиеш. 2025 елда әлеге максатларга 42 млн сум тоту каралган;

- яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары матди-техник базасын үстерүгә грант – 1 авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативына 15 млн сум, проектның гомуми суммасыннан 10 процентын грантка дәгъва кылучы үзе салырга (90% – грант) тиеш. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары эшчәнлеге вакыты 12 айдан артып китмәве шарт. Авыл хуҗалыгы кооперативларының «Авыл хуҗалыгы кооперациясе турында» 1995 елның 8 декабрендәге 193-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы нигезендә гамәлдә булган ревизия берлегендә әгъза булып тору мәҗбүри. 2025 елда әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетында 120 млн сум бүлеп бирү каралган.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына грант ярдәме күрсәтү турында» 2021 елның 14 июлендәге 572 номерлы карары нигезендә әлеге грантларны бирү тәртибе расланды.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына – савым сыерлары асрау кече парклары территориясендә сөтчелек юнәлешендә мөгезле эре терлекләр асрау фермаларын төзүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен 2025 елда субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 19 февралендәге 140 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетында 30 млн сум каралды.

Моннан тыш, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары мөлкәт, авыл хуҗалыгы техникасы, җиһазлары сатып алуга, шулай ук кооператив әгъзаларыннан продукция сатып алуга чыгымнарын каплауга субсидия алырга мөмкин. Аларның күләме чыгымнарны каплауның 50 процентка кадәр өлешен тәшкил итәргә мөмкин, әмма бер кооперативка мөлкәткә тотылган чыгымнарын каплауга 3 млн сумнан да, техника һәм җиһазларга чыгымнарын каплауга 5 млн сумнан да артып китә алмый. Шулай ук кооператив әгъзаларыннан продукция сатып алуга тотылган чыгымнарның 10 процентыннан 15 процентына кадәр капларга мөмкин, әмма бер кооперативка бу очракта 10 млн сумнан артык бирелми. Субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 30 июнендәге 514 номерлы карары белән регламентлана. Бу максатларга 2025 елда Татарстан Республикасы бюджетында 193 млн сум каралган.

**7. Республиканың агросәнәгать комплексын, шул исәптән агросәнәгать комплексының төрле тармакларында цифрлаштыру өлкәсендә белемнәре булган югары квалификацияле белгечләр әзерләү өлкәсен дә, цифрлы нигезгә кору турында. Татарстан Республикасы оешмаларында (сәнәгатьтә, авыл хуҗалыгында, төзелештә) ИТ-технологияләр кертү нигезендә җитештерү үсешен күрсәтүче уңай тәгаен мисаллар бармы?**

Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектлары арасында агросәнәгать комплексын цифрлы нигезгә кору рейтингында алдынгы урында тора.

Цифрлаштыру өлкәсенә кагылышлы карарлар авыл хуҗалыгының төрле тармакларында кулланыла:

- үсемлекчелек өлкәсендә – геомәгълүмати һәм метеомониторинг системалары, спутник мониторингы кулланыла;
- терлекчелектә көтү һәм терлекләрне ашату белән идарә итү системалары, терлекнең цифрлы паспорты, регламентларны мониторинглау һәм аларга күзәтчелек, саву аппаратлары актив кулланылышка кертелә;
- эшкәртү өлкәсендә ясалма фәһемне кулланып автоматлаштырылган линияләр һәм системалар файдаланыла.

Буа муниципаль районының «ЯНБУЛАТ» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы авыл хуҗалыгында цифрлаштыру карарларын файдалануга уңышлы мисал булып тора. Анда кырларның торышын мониторинглау өчен космик фотосурәтләргә нигезләнгән ExactFarming системасы кулланышка кертелде. 2023 елда бодай уңышын җыеп алуның тоткарлануы нәтиҗәсендә килгән зыян 12 процент тәшкил итте, бу исә кырларның торышын тулысынча һәм чәчүлекләрне аерым кишәрлекләп тикшерү мөмкинлеге булмау нәтиҗәсендә килеп чыкты. 2024 елда әлеге система ярдәмендә уңыш җыеп алуның тиешле вакытларын һәм тәртибен бозмау мөмкинлеге туды, бу исә хуҗалыкның уңышны югалтуын булдырмаска мөмкинлек бирде.

Тәтеш муниципаль районының «Башак» агрофирмасы» ҖЧҖ цифрлы нигездә берничә яңа ысул куллана башлады. Авыл хуҗалыгы техникасына автоном идарә итү өчен автопилот системалары үсемлекләрне саклауга чыгымнарны һәм орлыкның тиешсезгә сарыф ителү күләмен киметергә ярдәм итте. Автопилот системасыннан куллану нәтиҗәсендә 3 мең гектардан артык мәйданда экономия 2,5 млн сум тәшкил итте. Авыл хуҗалыгы эшләрен башкаруга лимит урнаштырып һәм транспорт чараларын мониторинглап автомат рәвештә ягулык салу системасын кертү чыгымнарны киметү хисабына 1,9 млн сум экономияләргә мөмкинлек бирде. Экономиянең күләме бергә кушып санаганда 4,4 млн сум тәшкил итте.

«МТС» ГАҖның финанс ярдәме белән 2024 елда Татарстан Республикасы предприятиеләрендә терлекчелектә ясалма фәһем системаларын кертү буенча сынау проектлары уңышлы башкарылды:

- сыер савуны реаль вакыт режимында мониторинглау һәм технологик регламент бозылуны ачыклауны тәэмин итә торган интеллектуаль контроль системасы эшләтеп җибәрелде. Системаны кулланышка кертүдән көтелгән нәтиҗә – сыерларның имчәкләре шешүен булдырмау аша терлекләрнең сәламәтлеген яхшырту;
- терлекләрнең хәлен визуаль тәңгәлләштереп анализлау системасы кертелде. Система автомат рәвештә терлекнең аксавын башлангыч чорында ук күреп ала, аның симезлек дәрәҗәсен билгели, шул рәвешчә көтүгә өзлексез мониторинг ясау

тәэмин ителә. Тәҗрибә өчен эшләтеп карау барышында сыерларның гомуми баш санынннан 5 процентында 3,4 һәм 5 дәрәҗәдәге аксаклык билгеләре ачылган. Система тәкъдимнәре буенча сыерларга тикшерү уздырылган һәм дәвалау башланган. Системаның фаразланган икътисадый нәтиҗәлелеге аксаклыкны ачыклауның заманча мөмкинлекләре белән бәйле, бу исә сөтнең кимүен туктатырга мөмкинлек бирә.

Моннан тыш, Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының агросәнәгать комплексы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Система) эшли, ул Татарстанның агросәнәгать комплексында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары эшендә катнашучыларга хезмәт итә.

Система терлекчелектә, үсемлекчелектә, эшкәртү өлкәсендә, кадрлар мәсьәләләрендә һәм башка юнәлешләрдә белешмәләрне җыярга, сакларга, тапшырырга һәм анализларга мөмкинлек бирә. Бүгенге көндә Системадан 4 мең кеше файдалана.

Система ярдәмендә:

- 770 мең баш мөгезле эре терлек таныкланган;
- 2,8 млн га авыл хуҗалыгы җирләренә паспорт ачылган;
- 10 меңнән артык данә техникага GPS/ГЛОНАСС системалары куелган,;
- 11 мең гектардан артык авыл хуҗалыгы кырлары әйләнешкә кертелгән.

Сәнәгать өлкәсендә цифрлы проектларны гамәлгә ашыру дәвам иттерелә. Россия Федерациясендә Сәнәгатьнең дәүләт мәгълүмат системасы платформасында сәнәгать предприятиесенең цифрлаштырылу дәрәҗәсен билгеләү методикасы бар. Әлеге системаның мәгълүматларына караганда, Татарстанның сәнәгать секторы предприятиеләрен цифрлаштыру буенча 517 проект гамәлгә ашыра (2023 елда – 449 проект).

Аеруча уңышлы тәҗрибә дип түбәндәгеләрне атарга мөмкин:

- «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте «Акыллы челтәр» системасын эшләтеп җибәрде, ул исә штаттан тыш вазгыять килеп чыкканда, зыян күргән урынны таба һәм таралуын туктата, резерв линияләргә күчереп, кулланучыларны электр энергиясе белән тәэмин итә. Бу очракта эшкә кеше- нең катнашуы таләп ителми.

- «Камаз» гавами акционер җәмгыятендә «Цифрлы нигезгә күчү үзәге» булдырылды. Үзәкнең беренче эшләү елында предприятие сату күләмен 21 процентка арттыра алды.

- «Татнефть» гавами акционер җәмгыятендә 2023 елда Россиядә эре проектларның берсе – ил программа тәэминатына корылган 1С: ERP бердәм системасын булдыру проекты гамәлгә куелды.

Республиканың кайбер сәнәгать предприятиеләре актив төстә автоматлаштыру һәм роботлаштыру эшләре белән шөгыльләнә.

Татарстан 2024 елда роботлаштыру дәрәҗәсе буенча илнең алдынгы 4 төбәге арасына кертелде. Мәсәлән, «КАМАЗ» ГАҖ илебез сәнәгать предприятиеләре арасында иң югары күрсәткечләргә иреште. Гомумән алганда, бу предприятиенең җитештерү өлкәсендә барлыгы 231 робот файдаланыла. 2026 елга аларның санын 615 берәмлеккә җиткерү планлаштырыла, ә 2030 елда җитештерү өлкәсендә 923 роботны эшләтү күздә тотыла.

**8. Шәһәр яны районнарыннан кала, авыл җирендә торак төзелешен киңрәк җәелдерү.**

2024 ел йомгаклары буенча авыл җирлегендә торак төзү күләме якынча 595 мең кв. метр тәшкил итте (файдалануга тапшырылган барлык торакның 17,2%).

2025 елда якынча 650 кв.метр торак төзү планлаштырыла (тапшырылырга тиешле барлык торакның 20%).

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары нигезендә расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасында (алга таба – Программа) авылны торак белән тәэмин итү буенча түбәндәге чаралар каралган:

1. Торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләүләр бирү.

Авылда яшәүче һәм эшләүче гражданнарның торак шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар кысаларында торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләүләр алучылар исемлегенә кертү турында карарны чират буенча һәм Программа шартлары нигезендә муниципаль район торак комиссиясе кабул итә. Программада торак шартларын яхшыртуга ихтыяҗы бар дип танылган, авылда яшәүче һәм кимендә бер ел авыл хуҗалыгы территориясендә агросәнәгать комплексында яисә социаль өлкәдә эшләүче, шулай ук торак төзү (сатып алу) хисап бәясенең кимендә 30 процентын тәшкил иткән үз һәм (яисә) заем акчасы булган гаилә яисә граждан катнаша ала.

Акча торак йорт төзүгә яисә сатып алуга (торак төзелеше объекты булдыруга) бүлеп бирелә. Субсидиянең күләме торакның хисапланган бәясенең федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган 70 процентан артып китмәгән өлешен тәшкил итә.

Граждан тарафыннан социаль түләүдән файдалану шарты – социаль түләү алганнан соң аның социаль түләү акчасы хисабына торак төзелгән (сатып алынган) авыл территориясендә бер үк эшчәнлек өлкәсе оешмасында кимендә биш ел дәвамында хезмәт яисә эшкуарлык эшчәнлеге алып баруы.

2020–2024 елларда Программаны финанслау 1 016,94 млн сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджеттан – 413,87 млн сум; Татарстан Республикасы бюджетыннан – 213,53 млн сум; җирле бюджеттан – 4,11 млн сум; бюджеттан тыш чыганаклардан – 385,43 млн сум. 469 гаилә өчен 33,5 мең кв.метр торак файдалануга тапшырылды;

2. Авыл территориясендә, төп торак пунктлар территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак биналар төзү (сатып алу).

Субсидияләр муниципаль районнарга гражданнарга наем шартнамәсе буенча торак биналар төзүгә һәм сатып алуга бирелә.

Субсидия торакның норматив бәясеннән чыгып исәпләнә:

- әгәр эш бирүче бюджет учреждениесе булса: 99% – бюджет акчасы, 1% – җирле бюджет акчасы;
- әгәр эш бирүче бюджет учреждениесе булмаса: 80% – бюджет акчасы, 1% – җирле бюджет акчасы, 19% – эш бирүче акчасы.

Эшләрне муниципаль район уздыра торган аукционнарда билгеләнгән подрядчылар башкара.

Торак йорт яисә фатир муниципаль район милке буларак рәсмиләштерелә, аренда өчен түләү күләмен муниципаль район билгели.

Граждан әлеге торакны сатып алырга хокуклы: 5 елдан алып 10 елга кадәр эшләгәндә хисапланган бәядән 10 процентка, 10 елдан артык эшләгән өчен –1 процентка.

Граждан район белән аренда шартнамәсен өзә ала. Бу очракта муниципаль район торак шартларын яхшыртуга ихтыяҗы булган башка граждан белән шартнамә төзи.

Программада катнашучыга карата төп шартлар тагын түбәндәгеләр:

- торак шартларын яхшыртуга ихтыяҗы булуны тану яисә эти-әнисе белән даими бергә яшәү;

- авыл территорияләрендә, төп торак пунктлар территорияләрендә хезмәт шартнамәсе нигезендә эшчәнлек алып бару (төп эш урыны).

Субсидия күләме авыл җирлегендәге бер квадрат метр торакның ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә раслана торган бәясенә тапкырланган норматив торак мәйданыннан (гаилә әгъзалары саныннан чыгып билгеләнә) чыгып хисаплана.

2020 елдан 2024 елга кадәр Программаны финанслау күләме 1 320,4 млн сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджет – 761,2 млн сум; Татарстан Республикасы бюджеты – 240,2 млн сум; җирле бюджет – 20,9 млн сум; бюджеттан тыш чыганаклар – 298,1 млн сум. 344 гаилә өчен 24,4 мең кв.метр торак файдалануга тапшырылды.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 12 декабрендәге 1767 номерлы карары нигезендә Программага «аз катлы торак комплексы» дигән төшенчә кертелде һәм авыл территорияләрендә, төп торак пунктлар территорияләрендә һәм алар янындагы территорияләрдә кимендә 10 индивидуаль торак йорттан һәм блоклар рәвешендә төзелгән йортлардан, шулай ук инженерлык инфраструктурасыннан, урамнарны яктырту, урам юл челтәреннән торган аз катлы торак комплексларын төзүне яисә сатып алуны күздә тота.

Федераль законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы карары нигезендә расланган Муниципаль районнарның наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак биналар төзү (сатып алу) буенча чыгым йөкләмәләрен үтәве барышында Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренә кертү өчен тиешле үзгәрешләр әзерләнде.

3. «Авыл ипотекасы» программасы.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 ноябрендәге 1567 номерлы карары белән Россиянең кредит оешмаларына һәм «ДОМ.РФ» АҖ авыл территорияләрендә (авыл агломерацияләрендә) Россия Федерациясе гражданнарына торак (торак йорт) төзү (сатып алу) өчен бирелгән ипотека кредитлары (заемнар) буенча тулысынча алынмаган керемнәрен каплау өчен субсидияләр бирү кагыйдәләре расланды.

Механизм Россия Федерациясе гражданнарына авыл территорияләрендә һәм авыл агломерацияләрендә торак төзү һәм сатып алу өчен 3 процентка кадәр ставка белән 6 миллионга кадәр ташламалы ипотека кредитлары бирүне күздә тота.

Кагыйдәләр нигезендә Россиянең кредит оешмаларына һәм «ДОМ.РФ» АҖ федераль бюджеттан ипотека бирүне Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы башкара.

Республикада «Авыл ипотекасы» программасы буенча 2020–2024 елларда авылларда торак төзү (сатып алу) өчен 14,9 млрд сумга 4,9 меңнән артык ипотека кредиты бирелде.

**9. Торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар үсүне чикләү чаралары турында.**

Россия Федерациясе Торак кодексының (алга таба – Торак кодексы) 157.1 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары буенча коммуналь хезмәтләр өчен уртача түләү күләменең үзгәрүе индексларын һәм муниципаль берәмлекләрдә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең чик (максималь) үзгәрү индексларын (алга таба – чик индекслар) раслау аша гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең артуын чикләү кертелде.

Торак кодексы нигезләмәләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Гражданнарның Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр өчен түләве күләме үзгәрү индексларын формалаштыру нигезләре буенча Россия Федерациясе субъектлары буенча индекслар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 15 ноябрендәге 3287-р номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасында гражданнарның коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләме үзгәрүнең уртача индекслары расланды: 2025 елның 1 гыйнварыннан – 0 % (гражданнарның хезмәт күрсәтүләр өчен түләвендә үзгәреш каралмаган), 2025 елның 1 июленнән –17,5 %. 2025 елның 1 гыйнварыннан чик тайпылыш – 0 %, 2025 елның 1 июленнән – 4,8 %. Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә чик индекс күләме 2025 елның 1 июленнән 22,3 процентка җитәргә мөмкин.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өчен 2025 елга чик индекслар, һәр ярты еллыкка айларга бүлеп, Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 14 декабрендәге 962 номерлы Указы белән расланды.

Шулай итеп, гражданнарның коммуналь хезмәтләр өчен түләве арту 2025 елның 1 июленнән 17,5% чикләрендә 874 муниципаль берәмлектә һәм 22,3% (4,8% күләмдә чик тайпылышны исәпкә алып) 39 муниципаль берәмлектә (шул исәптән 19 шәһәр, 14 шәһәр тибындагы поселок, 6 авыл) булачак.

Коммуналь хезмәтләр өчен түләү артуының 17,5 процenttан артып китүе нигездә аеруча файда китерми дип санала торган (коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең артуы күзлегеннән чыгып караганда) коммуналь хезмәтләр җыелмасыннан файдаланучыларга кагылачак. Бу хезмәтләргә салкын һәм җылы су белән тәэмин итү, юынтык су агызу, су белән тәэмин итү, җылылык, электр энергиясе белән тәэмин итү (стационар электр плитәләре һәм (яисә) электр ярдәмендә җылыту җиһазлары куелган йортларда) каты коммуналь калдыклар белән эш итү керә.

Татарстан Республикасында торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм күрсәтү чаралары комплексы каралган.

Гражданнарның аерым категорияләренә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә торак бина һәм коммуналь хезмәтләр өчен (алга таба шулай ук – ТКХ) бирелә торган субсидия-ташламалар төп чара булып тора.

Татарстан Республикасында ТКХ түләүгә субсидия-ташламалар алучылар

саны 682 670 граждан булды, шул исәптән:

- 278 881 федераль ташламадан файдаланучы, субсидия-ташламаның уртача күләме – 755,41 сум;
- 403 789 төбәк ташламасыннан файдаланучы, аларга түләнгән акча күләме 2 549,4 млн сум тәшкил итте, субсидия-ташламаның уртача күләме – 526,14 сум.
- Моннан тыш, торак бина һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә адреслы берничә социаль ярдәм чарасы каралды.

Торак кодексының 159 статьясы нигезендә гражданнарның норматив торак бина мәйданының субсидияләр исәпләү өчен файдаланыла торган төбәк стандарты күләменнән һәм торак-коммуналь хезмәтләр бәясенең төбәк стандарты күләменнән чыгып исәпләнгән торак бина һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләвенә тотылган чыгымнары гаиләләренең тулысынча керемендә гражданнарның торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнарының рөхсәт ителгән чик өлешенә туры килә торган күләменнән артып киткән очракта (Татарстан Республикасында – 21%), гражданнарга субсидияләр каралган. Республикада шулай ук субсидияләрнең өстәмә 6 төре каралган.

ТКХ өчен түләүгә субсидияләр алучылар саны 2024 елда 59 685 кеше булды, аларга 862,0 млн сум күләмдә субсидия түләнде. Субсидиянең уртача күләме – 1 203,52 сум.

Әлеге социаль ярдәм күрсәтү чаралары ТКХ өчен субсидия алучы гражданнарның үзләренең түләгән күләме аларның керемнәрендә җылылык бирелгән чорда 12 % һәм җылылык бирелмәгән чорда 7 % тәшкил итте. Шунысын да билгеләргә кирәк, гражданнарның ТКХ га түләүгә үз чыгымнарының чик мөмкин булган өлеше федераль стандарты гаиләнең гомуми кереме күләмендә 22 %, ә Татарстан Республикасында гражданнарның ТКХ га түләүгә үз чыгымнарының мөмкин булган чик өлеше 21% тәшкил итә.

Моннан тыш, Торак бинадан һәм (яисә) торак йорттан файдаланган вакытта коммуналь хезмәтләрдән файдаланучы гражданнарның ТКХ өчен түләү күләменең чынлыкта артуы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан түләүләр күләменең билгеләнгән чик (максималь) үзгәрү индекслары күләменнән артып китсә, Татарстан Республикасында компенсация каралган. Аларны түләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 17 октябрендәге 918 номерлы карары нигезендә билгеләнгән.

**10. Халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән, шулай ук район үзәге булган шәһәрләрдә җәмәгать транспорты эшен оештыруга кагылышлы чаралар турында.**

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан республиканың муниципаль берәмлекләрендә пассажирлар йөртү белән даими шөгыльләнүче транспорт предприятиеләре хәрәкәттәге составының норматив торышына анализ ясалды. Республиканың муниципаль маршрутларында барлыгы 1306 автобус йөри ( шул исәптән Казанда – 634, Чаллыда – 147, Түбән Камада – 74, башка муниципаль берәмлекләрдә – 451).

Казан шәһәре эчендә йөрүче пассажир транспортының маршрут челтәре пассажир транспортының дүрт төреннән тора: автобус, трамвай, троллейбус һәм

метро. Маршрутларда хәрәкәт сызымнары, хәрәкәтчән состав саны һәм шәһәр пассажир транспорты эшенең графигы пассажирлар агымын комплексны төстә өйрәнү нигезендә төзелде. Пассажирлар йөртү белән Казанда 7 оешма шөгыльләнә («Метроэлектротранс» МУП, «ПАТП №2» МУП һәм 5 хосусый оешма).

Республиканың пассажир транспорты предприятиеләре 2024 елда 402,3 млн пассажир йөрткән, 2023 ел белән чагыштырганда бу 3,5 процентка артыграк.

Республика транспортының хәрәкәттәге составы республика гражданнарына, шул исәптән сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен дә, һәркем файдалана алырдай һәм уңайлы шартлар тудырып хезмәт күрсәтә. Җәмәгать транспорты автоматлаштырылган диспетчер системасы ярдәмендә идарә ителә, бу исә рейсларның үтәлешенә, килештерелгән бердәм хәрәкәт расписаниесендә аларның эзлеклелегенә һәм тизлек режимына күзәтчелек итәргә мөмкинлек бирә. Транспортта татар һәм рус телләрендә автоном рәвештә тукталышлар турында хәбәр бирелә.

Транспорт хезмәте күрсәтүне яхшырту өчен хәрәкәттәге состав яңартыла. 2024 елда 127 автобус һәм 39 троллейбус сатып алынды. 2019 елдан 2024 елга кадәр Татарстан Республикасында 461 автобус һәм 74 троллейбус яңартылды.

Чаллы шәһәре Башкарма комитеты һәм «Автомобиль транспорты фәнни-тикшеренү институты» ААҖ тарафыннан Чаллы шәһәре маршрут челтәрен яхшырту эше башкарыла (эшне 2025 елның I кварталында тәмамлау каралган). Эшнең нәтиҗәсе маршрут челтәрен, расписаниене төгәл билгеләү, хәрәкәттәге составның таләп ителгән санын ачыклау булыр дип көтелә.

**11. Татарстан Республикасында коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәтләрен социаль нигездә газлаштыру һәм йортларны газга тоташтыру программаларын гамәлгә ашыру турында.**

Гражданнар акчаларын җәлеп итмичә, газүткәргеч торбалар салынган торак пунктларда җир кишәрлекләре чикләренә кадәр газ үткәрүне күздә тоткан социаль нигездә газлаштыру (йортларны газга тоташтыру) программасы 2021 елда Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин йөкләмәсе буенча эшли башлады.

Татарстан Республикасында әлеге программа гамәлгә ашырыла башлаган чордан (2025 елның 15 мартына карата) 31 303 җир кишәрлегенә чигенә кадәр газүткәргеч торбалар сузылды, 25 670 йорт хуҗалыгы газга тоташтырылды.

Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның 2024 елның 29 февралендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасы кысаларында коммерциячел булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрен (алга таба – КББШ) социаль нигездә газлаштыру программасына кертү турында йөкләмә бирелде.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм муниципаль берәмлекләр белән бергәләп КББШ территорияләре чикләрендә урнашкан йорт хуҗалыкларына уздырылган инвентаризация йомгаклары буенча йортларны газга тоташтыруның җыелма һәм һәр объект буенча аерым план-графиклары эшләнде, аларга 13 муниципаль берәмлектә – Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Азнакай, Әлмәт, Бөгелмә, Югары Ослан, Алабуга, Зеленодольск, Лаеш,

Түбән Кама, Питрәч, Сарман һәм Чистай муниципаль районнарындагы 713 йорт хуҗалыгы, 81 КББШ кертелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 декабрендәге 1265 номерлы карары белән расланган 2019-2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыкларын, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыру төбәк программасына әлеге йорт хуҗалыклары турында тиешле үзгәрешләр кертелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү турында» 2023 елның 11 мартындагы 231 номерлы карары нигезендә тотылган чыгымнарны каплауга, ләкин бер йортка 100 мең сумнан да артыграк булмаган күләмдә субсидия билгеләнде, ул түбәндәгеләргә бирелә:

- Бөек Ватан сугышы ветераннарына, шул исәптән Бөек Ватан сугышы инвалидларына;
- хәрби хәрәкәтләр ветераннарына, шул исәптән хәрби хәрәкәтләр инвалидларына;
- һәлак (вафат) булган сугыш инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзаларына;
- I һәм II төркем инвалидларга;
- инвалид балалары булган гаиләләргә;
- 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләргә;
- җан башына уртача кереме 19 мең сумнан артмаган гаиләләргә;
- Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә;
- инвалид балалар караучы затларга.

Әлеге субсидия Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан бирелә. 2024 елда субсидия 974 кешегә бирелде, гомуми суммасы – 94,7 млн сум.

## Социаль сәясәт

### 12. Хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга (ветераннарга) һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль түләүләр һәм ярдәм чаралары бердәм республика базасы (реестры) булдыру мөмкинлеге турында.

2023 елның ноябрендә Татарстанда «Үзебезнекеләр турында кайгырту» проекты эшли башлады, анда гражданнар махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү чаралары турында мәгълүмат белән таныша ала.

Проект кысаларында «Үзебезнекеләр турында кайгырту» дигән мәгълүмати ресурс (https://zabotasvo.tatar/) һәм «Үзебезнекеләр турында кайгырту» дип аталган телеграм-бот (t.me/Svoi_tatarstan_bot) эшләп килә, аларда федераль, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәдә ярдәм чаралары турында мәгълүмат урнаштырылган.

**13. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны, шул исәптән инвалид калучыларны һәм МХОдә һәлак булганнарның гаилә әгъзаларын социаль шартларга җайлаштыру (медицина, тернәкләндерү системасы үзәге булдыру, психологик яктан, эшкә урнаштыру һ.б.) кирәклеге турында.**

Республиканың медицина оешмаларында 2022 елның декабреннән 2024 декабренә кадәрге чорда 17 495 махсус хәрби операциядә катнашучыга медицина ярдәме күрсәтелде.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында (300 урынга исәпләнгән), Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (100 урынга исәпләнгән), Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» (60 урынга исәпләнгән) дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында тәүлек әйләнәсе медицина ярдәме күрсәтү мөмкинлеге тәэмин ителгән урыннар булдырылды.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына медицина ярдәме күрсәтү өчен җаваплы үзәкләр булып Казан шәһәренең һәм Чаллы шәһәренең сугыш ветераннары госпитальләре тора. 2024 елда сугыш ветераннары госпитальләрендә 2 364 хәрби операциядә катнашучы дәваланды.

«Медицина тернәкләндерүе» юнәлеше буенча чираттан тыш тәртиптә медицина ярдәме күрсәтү оештырылды, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары булган затлардан 2 324 авыруга ярдәм күрсәтелде.

Республикада медицина-психология консультацияләре уздыру буенча 70 кабинет эшләп килә. 2024 елда әлеге кабинетларда эшләүче медицина психологлары тарафыннан 823 махсус хәрби операциядә катнашучыга һәм аларның 2 013 гаилә әгъзасына һәм һәлак булган хәрбиләрнең гаилә әгъзаларына, шул исәптән 169 балага консультация уздырылды.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В.М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе һәм республиканың район үзәк хастаханәләре табиб-психиатрлары тарафыннан 2024 елда 114 махсус хәрби операциядә катнашучыга һәм аларның 135 гаилә әгъзасына, шул исәптән 25 балага амбулатория шартларында, 49 махсус хәрби операциядә катнашучыга һәм 43 гаилә әгъзасына, шул исәптән 6 балага стационар шартларында махсуслаштырылган психиатрия һәм психотерапия ярдәме күрсәтелде.

«Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасындагы филиалында да ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның туганнары, һәлак булган хәрбиләрнең гаиләләре белән эш алып барыла. 2024 елда медицина психологлары тарафыннан 181 махсус хәрби операциядә катнашучыга һәм 644 гаилә әгъзасына 825 консультация уздырылды, шулардан 584 кеше психиатрия юнәлешендә эшләүче белгечләргә юлланды.

Хәрби хәрәкәтләр инвалидлары медицина-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениесе тарафыннан эшләнгән түләүсез нигездә инвалидка реабилитация яисә

абилитация уздыру индивидуаль программасында тәкъдим ителгән чаралар буенча социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар шартларында чираттан тыш социаль хезмәт күрсәтүгә хокуклы.

Социаль тернәкләндерү хезмәтләре 5 дәүләт тернәкләндерү үзәгендә, сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен социаль тернәкләндерү республика үзәгендә, 2 дәүләтнеке булмаган социаль хезмәт күрсәтү оешмасында күрсәтелә.

Шулай ук хәрби хәрәкәтләр инвалидларына халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре составында эшләп килүче 5 социаль-тернәкләндерү бүлекчәсендә (Аксубай, Балтач, Мамадыш, Түбән Кама, Сарман муниципаль районнарында) социаль хезмәт күрсәтелә.

Барлык тернәкләндерү учреждениеләре районара принцип буенча эшли, тернәкләндерү буенча барлык кирәкле заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән. Социаль тернәкләндерү алгоритмы тернәкләндерүнең төп максатларын һәм бурычларын билгеләү өчен тирәнтен комплекслы диагностика уздыруны (социаль, психологик һәм һөнәри) үз эченә ала, ул хәрби хәрәкәтләр инвалидларына, шул исәптән яраланулар һәм терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарлану (шул исәптән ампутацияләр), сулыш, периферия нерв системасы (баш сөяге-биш мие яралары һ.б.) органнары зарарлану белән бәйле авырулар буенча сыйфатлы социаль хезмәт күрсәтү мөмкинлеге бирә.

2024 елның гыйнварыннан «Идел» инвалидларны социаль тернәкләндерү республика үзәге» (Зеленодольск шәһәре) дәүләт бюджет учреждениесе базасында даими рәвештә кеше тәрбиясенә мохтаҗ булган хәрби хәрәкәтләр инвалидларына өч ай дәвамында тернәкләндерү узу өчен шартлар булдырылды.

Әлеге эшне дәвам итү максатларында Татарстан Республикасы Рәисе карары нигезендә 2025 елның май аенда Казан шәһәрендә «Восхождение» инвалидлар өчен тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе базасында хәрби хәрәкәтләр инвалидлары өчен 40 урынга исәпләнгән стационар бүлекчә ачу планлаштырыла.

Шулай итеп, 2025 елдан махсус хәрби операциядә катнашуларны социаль тернәкләндерү өчен 282 стационар урын һәм 130 ярымстационар урын булдырылачак.

Тиешле җиһазлар сатып алу һәм төзекләндерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан 56,7 млн сум акча бүлеп бирелде.

Республикада махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә урнаштыру буенча ведомствоара эш җайга салынган, анда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, «Ватанны саклаучылар» фонды, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты һәм Татарстан Республикасы медицина-социаль экспертиза бюросы катнаша.

2025 елның 28 мартына 2024 елның 1 июненнән хәрби хезмәттән азат ителгән махсус хәрби операциядә катнашучыларның 80 проценты эш белән тәэмин ителгән, 20 проценты тернәкләндерү уза, эшләргә яраксыз дип танылган инвалидлык төркеменә карый яисә уку йортларында көндезге уку бүлекләрендә белем ала.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга эшкә урнашуда ярдәм итү өчен (843) 564-11-11 телефоны буенча кайнар линия эшли.

Махсус хәрби операциядә катнашучылар эш бирүчеләр тарафыннан тәкъдим

ителгән вакантлы урыннарга, шул исәптән инвалидлар өчен квота бирелгән урыннарга (2,8 мең эш урыны), республика бюджеты акчалары хисабыннан кеше башына аена 2 650 сум күләмендә матди ярдәм күрсәтелә торган вакытлы эш урыннарына (ел саен Татарстан Республикасы бюджетыннан эшсез гражданнарны вакытлы эш урыннарына урнаштыруга 12,0 млн сум акча бүлеп бирелә) урнашуда өстенлекле хокукка ия була. 2025 елның 28 мартына «Россиядә эш» цифрлы платформасында 37,0 мең вакансия урнаштырылган.

Моннан тыш, республикада махсус хәрби операциядә катнашучыларны, шул исәптән инвалидларны өстенлекле тәртиптә эшкә урнаштырырга әзер булган эш бирүчеләр реестры алып барыла. Бүгенге көндә реестрда 470 нән артык эш бирүчедән 2,6 мең вакансия турында мәгълүмат бар. Реестр даими рәвештә яңартылып тора.

Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары ихтыяҗ аеруча зур булган һөнәрләр буенча бушлай һөнәри белем алырга яисә өстәмә һөнәри белем алырга хокуклы. 2025 елда «Кадрлар» илкүләм проекты кысаларында 360 программа буенча укулар уздырыла.

Татарстанда эшсез дип танылган һәм үз эшләрен башлап җибәрергә теләге булган махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларына 145,1 мең сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелде. Ел саен әлеге максатларга 65,1 млн сум акча бүлеп бирелә (махсус хәрби операциядә катнашучы гаиләсеннән булган 8 кешегә үз эшләрен башлап җибәрүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтелде).

Махсус хәрби операциядә катнашучыларны кызыксындыру чаралары да эшләп килә, шул исәптән «Киләчәк яZмыш» махсус хәрби операциядә катнашучыларны социаль-хезмәт адаптациясе һәм тернәкләндерү прораммасы, аның бурычы – махсус хәрби операциядә катнашучыларның һөнәри траекториясен төзү. 2025 елдан өч халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү өчен оештырылган «Үзебезнекеләр өчен эш» клубы эшли башлады.

Республикада махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре өчен махсуслаштырылган эш урыннары вакансияләре ярминкәләре уздырыла. 2024 елда һәр муниципаль берәмлектә 3 гомумреспублика махсуслаштырылган ярминкә узды. Шулай итеп, 2025 елның 21 февралендә вакансияләр ярминкәләрендә 134 эш бирүче, 8 уку йорты катнашты, 3 меңгә якын вакансия тәкъдим ителде. Вакансияләр ярминкәләрендә 809 граждан, шул исәптән 192 махсус хәрби операциядә катнашучы һәм аларның гаилә әгъзасы катнашты, эшкә урнашуга 128 юллама бирелде.

Татарстанда инвалидлыгы булган махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен эш урыннары булдыру һәм саклап калуда эш бирүчеләргә ярдәм итүнең төбәк чарасы да гамәлдә:

- эш бирүчеләрнең саклап калынган эш урыннарында эшләүчеләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарының бер өлешен каплауга компенсация буларак ел саен 29,3 млн сум акча бүлеп бирелә;

- инвалидлар өчен махсус эш урыннары булдыруга яисә җиһазландыруга чыгымнарны каплауга ел саен республика бюджетыннан 1,1 млн сум акча бүлеп

бирелә (һәр булдырылган (җиһазландырылган, яңадан җиһазландырылган) эш урыны өчен 73,6 мең сум дип исәпләнгәндә).

Субсидияләр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан бирелә.

Республика ярдәм чараларыннан тыш эш бирүчеләргә Россия Социаль фонд аша бирелә торган түбәндәге федераль ярдәм чаралары да гамәлдә:

- «Кадрлар» илкүләм проекты кысаларында 2025 елдан хәрби хәрәкәтләр ветераннарын һәм аларның гаилә әгъзаларын эшкә урнаштырган эш бирүчеләргә өч минималь хезмәт хакы һәм иминият түләүләре күләмендә хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны каплауга (бер минималь хезмәт хакы өчен түләүгә 22 440 сум күләмендә һәм уртача 30 процент күләмендә иминият түләүләренә, эшкә урнашканнан соң 1 ,3 һәм 6 айдан соң һәр эшкә урнашкан граждан өчен 87,5 мең сум күләмендә);

- эш бирүчеләргә I һәм II төркем инвалидлар өчен эш урыннары булдырган яисә җиһазландырган өчен 200 мең сумга кадәр субсидия бирелә.

**14. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларының хокукларын, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучыларның кайда булуы һәм статусы (яраланган, һәлак булган, хәбәрсез югалган) турында үз вакытында дөрес мәгълүмат алуга хокукларын тәэмин итүгә юнәлтелгән чаралар турында.**

Республика Хәрби комиссариатында хәбәрсез югалган хәрби хезмәткәрләрне һәм әсирлеккә эләккән хәрби хезмәткәрләрне исәпкә алу эше оештырылган.

Үзәк хәрби округы гаскәрләре командующие күрсәтмәләре нигезендә элемтәгә чыкмаучы һәм кайда икәнлеге билгеле булмаган махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары белән килеп туган хәл буенча аңлату эшләре алып барыла.

Әлеге мәсьәләне Үзәк хәрби округының иң югары җитәкчеләре һәм командование үз контроленә алды, хәрби хезмәткәрләрне эзләү мәсьәләсен хәл итү буенча барлык тиешле эшләр алып барыла.

Россия Федерациясе Оборона министрлыгы җитәкчелегендә хәбәргә чыкмаучы хәрби хезмәткәрләрнең кайдалыгын мониторинглау һәм аларны эзләү буенча үзәкләр оештырылган.

Хәрби частьләр командованиесе хәрби хезмәткәрләрнең хәбәргә чыкмау очракларының барысы буенча да тикшерү эшләре алып бара, хәрби частьләрдә эзләүгә бәйле рәвештә документлар тупланмасы формалаштырыла, хәбәрсез югалучыларның карточкалары рәсмиләштерелә. Карточкаларга хәрби хезмәткәрне эзләү өчен кирәк булган төп мәгълүмат кертелә. Бер ай узганнан соң муниципаль берәмлек хәрби комиссариатына хәбәргә чыкмаган хәрби хезмәткәр турында хәбәрнамә килә. Хәбәрсез югалган хәрби хезмәткәрнең туганнарына хәрби хезмәт өчен түләнә торган хезмәт хакы күләмендә акчалата түләү бирүгә документлар әзерләнә һәм хәрби частькә җибәрелә.

**15. 2024 елда Татарстан Республикасында Гаилә елын уздыру йомгаклары турында һәм 2025 елда Татарстан Республикасында гаилә институтына ярдәм итүне дәвам итү юнәлешендәге планнар хакында.**

Гаиләне һәм гаиләгә хас рухи-әхлакый хәзинәләрне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен популярлаштыру максатында Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә 2024 ел Россия Федерациясендә Гаилә елы дип игълан ителде.

Республикада үткәрелгән барлык чаралар гаиләгә багышланган иде, әлеге елның һәр көне чаралар һәм вакыйгаларга бай булды. Республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә төрле форматтагы 1 меңнән артык чара уздырылды.

Россия Федерациясендә Гаилә елын башлап җибәрүгә багышлап Мәскәү шәһәре «Россия» форумы халыкара күргәзмәсе мәйданында уздырылган «Кадерлеләрем – Яратканнарым» бөтенроссия гаилә форумында Татарстан Республикасын лаеклы төстә «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятеннән Гайфуллиннар-Сафиннар хезмәт династиясе тәкъдим итте, аларның предприятиедәге гомуми эш стажы 279 ел тәшкил итә. Форум кысаларында «Безнең йөрәкләр ялкыны» дигән тантаналы чара уздырылды. Гаилә учагын кабызу тантанасы чара программасының төп өлеше булды, анда тантанада катнашкан гаиләләргә үз төбәкләрендә Гаилә елын башлап җибәрү өчен символик «утлы» касә тапшырдылар. Яшь парлар – Зыятдиновлар әлеге гаилә учагын Татарстан Республикасына алып кайтты, аннары әлеге ут тантаналы рәвештә Идел буе федераль округы төбәкләренә таратылды.

2024 елның маеннан сентябренә кадәр вакыт аралыгында «Гаилә белән ял көннәре» һәм 2024 елның октябреннән ноябренә кадәр вакыт аралыгында «Гаилә көзе» иң киң колачлы чаралары дип танылды, аларда 50 меңнән артык балалы гаилә катнашты. Әлеге чаралар кысаларында гаилә спорт эстафеталары, М.Горький исемендәге паркта гаилә пикниклары, Казансу елгасы яр буенда «Гаилә ал җилкәннәре» бәйрәме, гаилә хезмәт династияләрен котлау тантаналары, җәяүле экскурсияләр, гаиләләр белән музейларга бару һәм башка чаралар уздырылды. Нурлат шәһәрендә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга һәм гаиләне ныгытуга юнәлдерелгән гаилә велоузышы үткәрелде, Буа шәһәрендә «бала арбалары парады» уздырылды.

Гаилә елында яшь буынга тәрбия бирүдә аталарның абруен арттыруга аерым игътибар бирелде. Әтиләр, үз чиратында, үз балаларында аларга киләчәктә илебезнең лаеклы гражданы булырга этәргеч бирәчәк сыйфатлар тәрбияли ала. Татарстан Республикасының «Әтиләр берлеге» республика иҗтимагый оешмасы тарафыннан «Әти+Мин» конкурсы оештырылды, аның финалы Түбән Кама шәһәрендә узды һәм анда республиканың барлык муниципаль берәмлекләреннән 150 кеше катнашты.

2024 елның 22 маенда республикада «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» IV республика шәҗәрәләр фестивале узды, анда 4 айдан алып 90 яшькә кадәрле 2 меңнән гаилә вәкиле катнашында 157 гаилә династиясе ярышты.

Муниципаль районнарда һәм шәһәрләрдә балалы гаиләләр өчен уздырыла торган Гаилә елына багышланган барлык чаралар муниципалитетларның интернет-сәхифәләрендә, учреждениеләрнең социаль челтәрләрендә, шулай ук республика (https://family-tatarstan.ru) һәм федераль (https://семья2024.рф) сайтларында

урнаштырылып килә.

Гаилә елы чараларын гамәлгә ашыруда республика предприятиеләре һәм оешмалары актив катнашты.

Республика оешмаларында балалы гаиләләргә ярдәм итүнең корпоратив практикалары кертелде, шулардан:

- беренче сыйныфка укырга кергән һәм мәктәптә укучы балалары булган күп балалы гаиләләргә акча сертификатлары бирү;

- предприятие хезмәткәрләренә гаилә кору, бала туу уңаеннан, шулай ук күп балалы гаиләләргә акча бүлеп бирү.

Балалы гаиләләргә федераль һәм төбәк дәрәҗәсендә социаль ярдәм чараларының тулы пакеты күрсәтелә.

Шулай итеп, кереме яшәү минимумыннан түбән булган аз керемле балалы гаиләләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә ярдәм чаралары күрсәтелә (2024 елда – 13 135 сум, 2025 елда – 15 073 сум), шул исәптән:

- күп балалы кереме аз булган гаиләләргә балалар бакчасы өчен түләүне тулысынча компенсацияләү (2024 елда 3,9 мең балага);

- аз керемле гаиләләрдәге 3 яшенә кадәрле балаларга елына 10 мең сум күләмендә дарулар сатып алуга түләү (2024 елда – 6,2 мең балага);

- инвалид бала тәрбияләүче һәм (яисә) әтисе-әнисе инвалид булган, 5 яисә аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие, ул республикада җан башына туры килә торган яшәү минимумы белән гаиләнең җан башына туры килә торган уртача кереме арасында аермага тиңдәш күләмдә түләнә ( 2024 елда – 181 кешегә);

- яңа туган сабыйлары булган аз керемле гаиләләргә бала кирәк-яраклары белән бүләк комплектлар (2024 елда – 2,3 мең балага).

Авылларда яшәүче хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү – республиканың тиңдәше булмаган демографияне арттыру чарасы булып тора. Шулай итеп, 25 яшькәчә хатын-кызларга беренче баласын тапкан өчен – 50 мең сум, 29 яшькәчә хатын-кызларга өченче һәм аннан да күбрәк бала тапкан өчен 100 мең сум күләмендә акчалата түләү бирелә. 2018 елдан 14,1 мең кеше әлеге акчалата түләү алды, шул исәптән 2024 елда – 1,6 мең хатын-кыз.

Ярлы тормышта яшәүче гаиләләргә ярдәм күрсәтү буенча эшнең әһәмияте гаять зур. 2024 елда төзелгән социаль контрактларның 39 проценты (2,3 мең контракт) балигъ булмаган балалары булган гаиләләргә бирелде.

2024 елда Россия Федерациясе Президентының «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы нигезендә олы баласы 18 яшькә яисә ул көндезге уку формасында мәгариф оешмасында укыган очракта, 23 яшькә җиткәнче өч яисә аннан күбрәк балалы гаиләләргә даими нигездә күп балалы гаилә статусы билгеләнде.

Республикада соңгы 12 елда күп балалы гаиләләрнең саны 2,4 тапкырга артты һәм 57,9 мең гаилә тәшкил итә, аларда 185,0 мең бала тәрбияләнә.

2000 елдан 5 һәм аннан күбрәк бала табып, аларга лаеклы тәрбия бирүче (тәрбия биргән) хатын-кызларны югары дәрәҗәдә бәяләү билгесе буларак, дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале гамәлгә куелды. 2024 елдан медаль белән бүләкләнгән 5 бала тәрбияләп үстергән аналарга 100 мең сум

күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелә (2023 елга кадәр – 50 мең сум), ә 6 яисә аннан күбрәк бала тәрбияләп үстергән аналарга – бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләме алтынчы балага һәм аннан соң килә торган һәр балага хисаплап, бүләкләү көненә аларның өч яше тулган булу шарты үтәлгәндә, тиешенчә 20 мең сумга арта. 2000 елдан «Ана даны – Материнская слава» медале белән 1,6 мең ана, шул исәптән 2024 елда 62 хатын-кыз бүләкләнде.

Гаиләнең һәм ата-ана хезмәтенең абруен күтәрү максатларында дәүләт бүләге – «Ата-ана фидакарьлеге» медале гамәлгә куелды, ул җиде һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче яисә тәрбияләгән гаиләләргә биреләчәк. Гаиләдә бердән күбрәк балигълык яшенә җитмәгән балалар булган очракта, аларга 200 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк бирелә. 2022 елдан әлеге медаль белән 14 гаилә (26 кеше), шул исәптән 2024 елда 2 гаилә бүләкләнде.

Моннан тыш, күп балалы гаиләләргә төрле яклы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:

- торак мәйданының социаль нормативлары һәм хезмәтләрдән файдалануга билгеләнгән нормативлар чикләрендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнарның 30 проценты күләмендә субсидия (әлеге түләүләрне алучылар (ата-аналар һәм балалар) – 234,8 мең кеше);

- 6 яшькә кадәрле балаларга дарулар сатып алуга субсидия. 2024 елда түләү айга 164 сум тәшкил итте, 2025 елда – 171 сум (әлеге түләүне алучылар – 53,4 мең бала);

- гомуми белем бирү оешмаларында укуларын тәмамлаганчы, ләкин 23 яшькә кадәр, укучыларга транспортта йөрүгә субсидия. 2024 елда түләү аена 369 сум тәшкил итте, 2025 елда – 384 сум (түләүне алучылар саны – 69,8 мең кеше).

Татарстан Республикасы Президентының «Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туу белән бәйле рәвештә балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2008 елның 20 августындагы ПУ-397 номерлы Указы нигезендә берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк балалар туганда гаиләләргә түбәндәге түләүләр билгеләнде:

- 10 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие (1 гаилә алды);

- берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк яшь ярым тулмаган балалар тәрбияләүче гаиләләргә айлык пособие. Аның күләме аена 1 мең сум тәшкил итә (алучылар саны – 18 бала).

2024 ел йомгаклары буенча гаиләләргә һәм балаларга күрсәтелә торган ярдәм чаралары нигезендә Татарстанда:

- гомуми халык санын алганда 1 мең кешегә туры килә торган яңа туган сабыйлар күрсәткече – 8,8, республика Идел буе федераль округында беренче урынны алып тора (7,7) һәм Россия Федерациясе белән чагыштырганда югарырак күрсәткечне саклый килә (8,4);

- барлык яңа туган сабыйларның гомуми санында беренче бала табучылар 39 процентны тәшкил итә;

- өченче һәм аннан күбрәк бала табучылар саны 2023 ел белән чагыштырганда 27 проценттан 2024 ел йомгаклары буенча 28 процентка артты.

Бүгенге көндә республика территориясендә түбәндәгеләр эшли:

- 45 халыкка комплекслы ярдәм күрсәтү үзәге, аларда төрле яклы ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән гаиләләргә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәләре бар;

- авыр тормыш хәлендә калган гаиләләрдә тәрбияләнә торган балалар өчен 14 социаль приют;

- сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен 11 тернәкләндерү үзәге;

- инвалид балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтелә торган 7 дәүләтнеке булмаган оешма.

2024 елда гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекчәләре булган халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләрендә 7,1 мең гаиләгә ярдәм күрсәтелде. Социаль приютларда 11,1 мең инвалид балага һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балага хезмәт күрсәтелде.

«Инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләргә ярдәм итү» төбәк чаралар комплексы кысаларында «Минем гаиләм» программасы буенча халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре базасында 2025 елда өйдә шөгыльләнү өчен 6 микрореабилитация үзәге, 11 тернәкләндерү җиһазларын прокатка алу пункты, 14 социаль-көнкүреш адаптация кабинеты булдырылачак.

Гаилә елы кысаларында «Гаилә кунак бүлмәсе» иҗтимагый проекты эшли башлады, ул стационар оешмаларда яши торган балаларның үз әти-әниләре (законлы вәкилләре) белән мөнәсәбәтләрен торгызуга һәм тәртипкә салуга, баланы гаиләгә кайтаруга юнәлтелгән. 16 стационар учреждение базасында балаларга әти-әниләре, башка туганнары, уллыкка (кызлыкка) алырга теләүчеләр, опекуннары (попечительләре) белән очрашулар уздыру өчен «Гаилә кунак бүлмәсе» дип аталган махсуслаштырылган бүлмәләр җиһазландырылды, ата-аналар һәм башка гаилә әгъзалары белән эшләүнең төрле формаларын үз эченә алган гаилә программалары тормышка ашырылды. Проектны эшләүгә спонсорлар һәм хәйриячеләр акчалары җәлеп ителде. Җәлеп ителгән спонсор ярдәме 2024 елда 1,2 млн сум тәшкил итте. Гаилә тормышы формасындагы стационар оешмалардан гаиләләргә кайткан балалар санының артуы проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып тора.

Шулай ук Гаилә елы кысаларында һәр айның соңгы сишәмбесендә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү учреждениеләрендә һәм инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белгечләре катнашында «Ачык гаилә/ата-аналар көне» уздырылды, анда 2,7 меңнән артык кеше катнашты. Әлеге очрашулар вакытында анда катнашучыларга социаль интеграция, белем алу, спорт һәм мәдәният учреждениеләренә бару мәсьәләләре буенча консультацияләр бирелә, ата-аналар һәм инвалид балалар өчен мастер-класслар, спорт чаралары уздырыла.

Казан һәм Әлмәт шәһәрләренең халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре базасында ярдәмгә мохтаҗ балалы гаиләләргә комплекслы төстә социаль хезмәт күрсәтүне һәм социаль ярдәм чараларын күрсәтүне тәэмин итү максатларында Күпфункцияле гаилә үзәкләре төзеләчәк.

2024 елның 8 июлендә Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнендә «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медале белән 25 елдан артык бер-берсен яратып, тату яшәгән һәм балалар тәрбияләгән 70 гаилә бүләкләнде.

Татарстан Республикасы Көне алдыннан Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Рәисе һәм аның тормыш иптәше гадәттәгечә республиканың 45 гаиләсен тантаналы рәвештә котлады.

Татарстан Республикасы Көнендә «Казан» гаилә үзәгендә бер үк вакытта 45 парның гаиләсе теркәлде.

Республиканың гражданлык хәле актларын теркәү идарәләре 2 207 гаиләне котлады, шулардан 46 пар – «көмеш» юбилярлар (25 ел бергә яшәүче), 1 854 пар – «алтын» юбилярлар (50 ел), 292 пар – «бриллиант» юбилярлар (60 ел), 15 пар – «бәхетле» юбилярлар (70 ел), 16 507 гаилә теркәү тантаналары уздырылды.

Гаиләгә хас рухи-әхлакый хәзинәләрне һәм күп балалар табуны популярлаштыру максатларында республиканың барлык граждан хәле актларын теркәү органнарында «Яшь гаилә мәктәбе» проекты кысаларында гаилә коруга гариза биргән парлар белән очрашулар уздырылды. Булачак яшь парлар белән очрашуларда психологлар, дин әһелләре, табиблар катнашты; дискуссияләр, мастер-класслар, тренинглар уздырылды.

Мәктәпләр һәм урта белем бирү оешмалары өлкән сыйныф укучылары белән даими нигездә эш алып бара, аларны гаилә тормышына әзерләү, гаилә җанлы шәхесләр формалаштыру, гаиләгә хас традицион рухи-әхлакый хәзинәләргә хөрмәт тәрбияләүгә юнәлтелгән дәресләр уздырыла.

Татарстанда Гаилә елы 2024 елның 2 декабрендә «ТНВ-Татарстан» һәм «ТНВ-Планета» телеканалларында «Яңа ел белән, гаилә!» дип аталган 12 сәгатьлек телемарафон белән ябылды. Эфирда Татарстанның ватанпәрвәрлек үрнәге булган, җыр-моңга гашыйк, спорт белән шөгыльләнүче 50 актив гаилә катнашты. Телемарафонның азагында туры эфирда берьюлы берничә гаиләнең никахын теркәү тантанасы уздырылды.

2025 елда гаиләгә хас традицион рухи-әхлакый хәзинәләрне, күп балалар табуны, яшьләрдә ата-ана булуга җаваплы караш тәрбияләү эше дәвам иттереләчәк.

**16. Опекуннарга һәм попечительләргә Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^1$ статьясы нигезендә билгеләнгән түләүләр күләмен арттыруның максатка ярашлыгы турында.**

2024 елда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләр дәүләт банкында исәптә торучы балаларның гомуми саны – 544 кеше тәшкил итте, аларның күбесе 10 яшьтән өлкәнрәк булган яшүсмерләр (413 кеше), сиблинглар (335 кеше).

Татарстан Республикасы Гаилә кодексында үз вазыйфаларын түләүле нигездә башкарган опекуннар һәм попечительләргә акчалата түләү билгеләнде. Бер бала тәрбияләгән өчен түләү аена 3 мең сум тәшкил итә.

Җирле үзидарә органнары җирле бюджет акчалары хисабыннан опекуннар һәм попечительләргә өстәмә түләү билгеләргә хокуклы. Казан шәһәрендә бер бала тәрбияләү өчен акчалата түләү 5 мең сум тәшкил итә, шулардан 2 мең сумы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге акчалары хисабыннан.

Моннан тыш, опекуннар (попечительләргә), шул исәптән үз вазыйфаларын түләүле нигездә башкарган тәрбиягә бала алган ата-аналарга түбәндәге өстәмә түләүләр билгеләнде:

тәрбиягә бала алган, педагогик һәм медицина белеме булган ата-аналарга федераль законнарда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән 50 проценты (9 621 сум, 2025 елга – 11 220 сум);

өч яше тулмаган баланы тәрбиягә алган яисә инвалид бала  яки психик яисә физик үсешендә тайпылышлары булган баланы яисә девиант тәртипле бала тәрбияләгән өчен билгеләнгән акчалата түләүнең 30 проценты (900 сум).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 13 июлендәге 493 номерлы карары нигезендә 2017 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алган гражданнарга 200 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләнде.

Шулай ук федераль бюджеттан 26 941,71 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү баланы гаиләгә тапшырганда бирелә, ә инвалид баланы, 7 яшьтән өлкәнрәк булган баланы, абыйлы-энеле яисә  апалы-сеңелле туганнарны гаиләгә тәрбиягә алганда 205 856,59 сум күләмендә пособие түләнә.

Татарстан Республикасы бюджетында 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларда план чорына үз вазыйфаларын түләүле нигездә башкарган опекуннарга һәм попечительләргә айлык акчалата түләү өчен чыгымнарны каплауга 2025 елда 198,5 млн сум, 2026 елга – 206,4 млн сум, 2027 елга – 214,7 млн сум каралган.

**17. Опекуннарга (попечительләргә), алар җәмәгать транспортында озата барган затлардан башка йөргәндә, бушлай йөрү хокукы бирү турында.**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган  Транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 2 пункты нигезендә I төркем инвалидларны (хезмәт эшчәнлеге башкаруга III дәрәҗә мөмкинлекләре чикле) яисә инвалид балаларны (I төркем инвалидларны (хезмәт эшчәнлеге башкаруга III дәрәҗә мөмкинлекләре чикле) яисә инвалид балаларны озата баручы бер кешегә генә) озата баручы гражданнарга транспортта йөрү өчен социаль билет барлык төр шәһәр җәмәгать транспортында һәм шәһәр яны автомобиль транспортында, озата баручы затка I төркем инвалид (хезмәт эшчәнлеге башкаруга III дәрәҗә мөмкинлекләре чикле) яисә инвалид бала белән бергә барган очракта транспортта йөрүгә ташламалы хокуктан файдалану хокукы бирә.

**18. Инвалидларга республика әһәмиятендәге  түләүле юллардан бушлай йөрү мөмкинлеге бирү турында.**

Түләүле автомобиль юлларыннан һәм автомобиль юлларының түләүле өлешләреннән ташламалы нигездә файдалану яисә бушлай йөрү хокукы «Россия Федерациясе автомобиль юллары һәм юллар төзү эшчәнлеге һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 43-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законының 33 статьясы нигезендә билгеләнде, шулардан чыгып түбәндәгеләр түләүле автомобиль юлларыннан һәм автомобиль юлларының түләүле өлешләреннән файдаланган өчен транспорт чаралары өчен түләүдән азат ителә:

гомуми кулланыштагы транспорт (такси, шул исәптән маршрут таксилары, шулай ук шәһәрара һәм халыкара юлларда пассажирлар йөртүче автобуслардан тыш);

махсус ут һәм тавыш ярдәмендә сигнал бирү җайланмалары белән җиһазландырылган, янгыннан саклау, полиция, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү, авария-коткару хезмәтләре, хәрби автомобиль инспекцияләре эшчәнлеген башкару өчен файдаланыла торган транспорт чаралары;

почта (махсус почта элемтәсе) һәм акчалар ташуны, шулай ук федераль почта элемтәсе, шул исәптән махсус почта элемтәсе оешмалары хезмәткәрләре почтасын (махсус почта элемтәсе аша юллана торган почтаны) адресатка илтү белән шөгыльләнүче федераль почта элемтәсе, шул исәптән махсус почта элемтәсе оешмаларының транспорт чаралары;

мәктәп автобуслары һәм оешкан төстә балалар төркемнәрен йөртүче автобуслар.

Түләүле автомобиль юлларыннан һәм түләүле өлешләре булган автомобиль юлларыннан файдаланган очракта концессия килешүе нигезендә концессионер өстәмә рәвештә түләүле автомобиль юлларыннан һәм түләүле өлешләре булган автомобиль юлларыннан файдаланучыларның аерым ташламалы категорияләрен билгели ала.

Инвалидларга республика әһәмиятендәге түләүле юллардан бушлай йөрү хокукы бирү каралмаган.

**19. Социаль инфраструктура объектларыннан файдалану мөмкинлекләрен арттыру максатларында инвалидлар өчен социаль учреждениеләр һәм сәламәтлек саклау учреждениеләре янында бушлай автомобиль кую урыннары төзү кирәклеге турында.**

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә гомуми кулланылыштагы барлык парковкаларда, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары (җәмәгать һәм производство бинаалары, корылмалар, физкультура-спорт оешмасы, мәдәният оешмасы һәм башка оешмалар урнашкан биналар), ял итү урыннары янындагы һәр автотранспорт кую (туктау) урынында аның кимендә 10% ы (ләкин бер урыннан күбрәк) I, II төркем инвалидлар йөри торган транспорт чаралары, әлеге инвалидларны яисә инвалид балаларны озатып йөртүче затларның транспорт чараларын кую өчен бушлай транспорт кую урыны төзелергә тиеш дип билгеләнде. Әлеге норма мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге чикләнгән III төркем инвалидларга да карый.

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан инвалидлар өчен автомобиль кую урыннары муниципаль парковка урыннары төзегәндә, шул исәптән шәһәр өчен бердәм парковка урыннарын киңәйтү кысаларында булдырыла.

Барлык муниципаль парковка урыннарында инвалидлар өчен урыннар юл

билгеләре һәм «Инвалидлар» билгесе белән күрсәтелә һәм алар учреждениеләргә керү урыннары, җәяүлеләр өчен юл чыгу урыннары һәм башкаларга якын урнашкан.

«Казан», «Бигеш» һәм «Бөгелмә» аэропортларының вокзал яны мәйданнарындагы автомобиль кую урыннарында тиешле маркировка билгесе һәм юл күрсәткечләре булган I, II төркем инвалидлар йөри торган транспорт чаралары, әлеге инвалидларны яисә инвалид балаларны озатып йөртүче затларның транспорт чараларын кую өчен парковка урыннары бүлеп бирелде.

**20. Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү буенча алып барыла торган эш турында.**

Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү буенча эш Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында граждан мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә алып барыла.

2024 елда Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан 88 382 граждан мөрәҗәгате карап тикшерелде (2023 елның әлеге чорында – 78 545 мөрәҗәгать), 46 782 мөрәҗәгать контрольгә алынды. 4 567 мөрәҗәгать урыннарга барып тикшерелде. Электрон рәвештә (интернет-кабул итү бүлмәсе ярдәмендә) 23 592 мөрәҗәгать килде.

8 581 кеше шәхсән кабул ителде, шулардан 1 160 граждан шәхсән министрлык һәм ведомство җитәкчеләре тарафыннан кабул ителде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү максатларында 2024 елда министрлыклар һәм ведомстволар видео-конференция системасы ярдәмендә сакланыла торган каналлар буенча гражданнарны кабул итүне (алга таба – видео-кабул итү) оештыру мөмкинлегеннән файдалануны дәвам итте. Тулаем алганда 2024 елда республика министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан 59 видео-кабул итү оештырылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гражданнарны шәхсән кабул итүне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары бурычлары турында» 2006 елның 13 ноябрендәге 537 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасында гражданнарны кабул итүнең бердәм көне билгеләнде – һәр сишәмбе көнне 14 сәгатьтән соң. Гражданнарны кабул итүнең бердәм көнендә 2024 елда республика министрлыкларына һәм ведомстволарына 2 416 кеше мөрәҗәгать итте, шулардан 914 ы – җитәкчеләр тарафыннан кабул ителде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләренең эчтәлеге һәм саны халык ихтыяҗларын, аларны борчыган мәсьәләләрне һәм аларның күңел халәтен чагылдыручы мөһим мәгълүмат чыганагы булып тора һәм аерым мәсьәләләр буенча җәмәгатьчелек фикерен күрсәтә. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшне нәтиҗәле оештыру халык

мәнфәгатьләрен канәгатьләндерергә, социаль өлкәдә киеренкелекне киметергә һәм хакимият органнарының абруен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Гражданнардан мөрәҗәгатьләр килүгә йогынты ясаучы сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында органнар һәм вазыйфаи затлар билгеле бер вакыт аралыгында, ләкин кимендә елга бер тапкыр мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерергә һәм аларга анализ уздырырга тиеш. Органнар гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализны, шулай ук республика халкы мәнфәгатьләренә кагылышлы аеруча актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмаларны үзләренең рәсми сайтларында урнаштыра. Әлеге анализ килгән, бүтән адреска юлланган һәм карап тикшерелгән язмача мөрәҗәгатьләрнең; электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны турында; гражданнарны кабул итү урыны, көннәре һәм сәгатьләре турында; гражданнарны шәхсән кабул итү буенча вәкаләтле затлар һәм урыннарга барып шәхсән кабул итү турында; мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында; мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар (булган очракта) хакында мәгълүматны үз эченә ала.

## Сәламәтлек саклау

### 21. Сәламәтлек саклау амбулатория-поликлиника учреждениеләрендә беренчел медицина-санитария ярдәменнән файдалану мөмкинлекләрен арттыруны тәэмин итү турында.

Татарстан Республикасында медицина ярдәме күрсәтүнең өчбуынлы системасы булдырылды:

- беренче буын – беренчел медицина-санитария ярдәме, шул исәптән беренчел махсуслаштырылган, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү;
- икенче буын – махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү ( югары технологияле медицина ярдәменнән тыш) (махсуслаштырылган муниципальара (районара) бүлекчәләрдә һәм үзәкләрдә, диспансерларда, күп профильле хастаханәләрдә);
- өченче буын – медицина оешмаларында (бүлекчәләрендә) махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карарлары нигезендә авыруларның тәгаен юнәлешләрдә медицина ярдәме алуга ихтыяҗларын һәм махсуслаштырылган медицина оешмаларының нинди ераклыкта урнашкан булуын исәпкә алып, авырулар өчен һәр юнәлеш буенча маршрут расланды.

Республикада 124 сәламәтлек саклау учреждениесе бар (шулардан 26 – республикакүләм), шул исәптән, 71 хастаханә медицина учреждениесе, 36 амбулатория-поликлиникасы, тәүлек әйләнәсе эшли торган стационарлары булган 5 диспансер, бары тик амбулатория-поликлиника ярдәме генә күрсәтелә торган 2 диспансер, аерым типтагы 10 медицина оешмасы (санаторийлар, медицина профилактика үзәкләре һ.б.).

21 җәрәхәтләр алган кешеләргә ярдәм күрсәтү үзәге, 4 кардиохирургия ярдәме үзәге, 20 баш миендә кан әйләнеше кискен зарарланган авырулар өчен кан тамыры үзәге һәм 7 кискен коронар синдромлы авырулар өчен ашыгыч медицина ярдәме

күрсәтү буенча беренчел коронар ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү үзәге.

Медицина оешмаларыннан яисә аларның структур бүлекчәләреннән еракта урнашкан (6 км дан ераграк) 100 дән кимрәк кеше яши торган торак пунктларда бәхетсезлек очраклары килеп чыкканда, җәрәхәтләр алу, агулану очракларында, кеше сәламәтлегенә һәм гомеренә куркыныч янаган башка очракларда медицина хезмәткәре килеп җиткәнче беренчел медицина ярдәме күрсәтү пункты – биналарның берсен файдаланып беренчел ярдәм күрсәтелә. Әлеге биналар һәр торак пунктка кимендә бер исәбеннән төзелә. Бина элемтә чаралары белән җиһазландырылган, интернетка тоташтырылган, беренчел медицина ярдәме күрсәтү өчен кирәк булган барлык җайланмалар белән тәэмин ителгән. Әлеге территорияләрдә яшәүче кешеләр беренче ярдәм күрсәтү буенча шундый биналар барлыгы турында хәбәрдар була. Әлеге биналарда эшләүче җаваплы затлар беренчел ярдәм күрсәтү күнекмәләренә өйрәтелгән була.

Авыл халкы өчен шулай ук үз структурасында махсуслаштырылган муниципальара (районара) бүлекчәләре һәм үзәкләре булган медицина оешмаларында, шулай ук диспансерларда һәм күп профильле хастаханәләрдә махсуслаштырылган медицина ярдәме алу мөмкинлеге бирелә.

Медицина ярдәме алуга күрсәтмәләре булган авыл кешеләре беренчел медицина-санитария һәм махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме алу өчен республика һәм федераль дәрәҗәдәге медицина оешмаларына җибәрелә.

Татарстанда беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү буенча 91 күчмә (мобиль) медицина бригадасы эшләп килә, алар торак пунктларга барып, ярдәм күрсәтә. 2024 елда күчмә (мобиль) медицина бригадалары тарафыннан 3 539 торак пунктка барып, 4 250 күчмә медицина ярдәме күрсәтелде, 104 915 авыру тикшеренү узды, шулардан 62,2% ы (65 237 кеше) – 60 яшьлекләр һәм аннан өлкәнрәкләр.

Медицина оешмаларында, шул исәптән үзәк район хастаханәләрендә беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү мөмкинлекләрен арттыру максатларында өйдә медицина ярдәме күрсәтү буенча күчмә фельдшерлык бригадалары булган ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү кабинетлары ачылды. Әлеге кабинетлар базасында 106 ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү күчмә бригадасы эшли. 2024 елда ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү күчмә бригадасы тарафыннан өйдә 428,8 мең кешегә ярдәм күрсәтелде.

«Татарстан Республикасында беренче медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты кысаларында 2019 елда республика бюджеты акчалары хисабыннан «Мобиль поликлиника» 4 мобиль медицина комплексы сатып алынды. Ел саен мобиль комплексларның табиб-белгечләргә ихтыяҗ аеруча зур булган Татарстан Республикасы муниципаль районнарына чыгу план-графиклары раслана. Бригадалар эшендә акушер-гинеколог, невролог, офтальмолог, кардиолог, кан тамырлары хирургы, уролог, эндокринолог, УЗИ-диагностикасы табибы, функциональ диагностика (ЭКГ) табибы катнаша. Мобиль пунктка шулай ук лаборатория комплексы кертелгән.

«Өлкән яшьтәге гражданнарга системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру (Татарстан

Республикасы (Татарстан)» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2019 елның сентябреннән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре автотранспорты белән медицина оешмаларына китерелгән 65 яшьтән өлкәнрәк затларга медицина ярдәме күрсәтү эшен оештырылды.

2024 елда мобиль комплексларында 50 047 кеше медицина тикшеренүе узды, шулардан диспансеризация узуның икенче этабы барышында – 17 914 кеше (35,8%).

**22. Сәламәтлек саклау өлкәсендә кадрларга кытлыкны бетерү чаралары турында.**

Табибларга ихтыяҗ мәсьәләсе мөһим булып кала бирә. 2024 елның 1 гыйнварына дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә табибларга булган ихтыяҗ 1 694 кеше тәшкил итте.

Татарстан Республикасында кадрларга кытлыкны бетерү максатларында «Сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» төбәк проекты эшләнде һәм расланды. Аны гамәлгә ашыру кысаларында медицина оешмаларын, шул исәптән беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын кадрлар белән тәэмин итү һәм кадрларга кытлыкны бетерү буенча берничә этапка бүленгән эш алып барыла.

Кадрларга кытлык мәсьәләсен хәл итүнең бер юлы булып югары белем бирү мәгариф оешмаларында укуга максатчан кабул итү квоталары буенча белгечләрне максатчан укыту тора. 2024 елда югары медицина белеме бирү мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасының максатчан кабул итү квотасы буенча укып чыккан белгечләр саны 379 кеше тәшкил итте, шулардан 130 кеше белгечлек программасы буенча, ординатура программасы буенча – 249 кеше тәмамлады.

Урта медицина персоналын әзерләү кысаларында 10 дәүләт автоном һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларында 2024 елда белгечләрне максатчан билгеләнеш буенча һәм укуларын тәмамлаганнан соң эш белән тәэмин итү турында 1 470 шартнамә төзелде. 1 292 кеше укуларын тәмамлап чыкты, шулардан 1 054 кеше дәүләт медицина оешмаларына эшкә урнашты (укуларын тәмамлаучыларның 81,6 проценты).

Барлык ведомство карамагындагы медицина оешмаларында яшь белгечләрне (табиблар, шәфкать туташлары) эшләү чорының беренче 2 елында медицина этикасына һәм деонтология нормаларына, үз-үзен тоту кагыйдәләренә өйрәтергә, аларны җәмгыять тормышында катнашуга җәлеп итү максатында «Медицина өлкәсендә остазлык» дип аталган программа гамәлгә кертелде.

Өзлексез медицина белеме бирү кысаларында медицина хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү эше дәвам иттерелә. Өзлексез медицина белеме бирү системасында барлыгы 52 670 белгеч теркәлгән.

2024 ел йомгаклары буенча 10 482 табиб һәм гомуми камилләштерү курсларында 12 607 урта медицина хезмәткәре белем алды, һөнәри яктан яңадан әзерләү циклларында 436 табиб һәм 1 337 урта медицина хезмәткәре укып чыкты.

2024 елда түбәндәге проектлар гамәлгә ашырылды:

1. Татарстан Республикасының алты югары технологияле үзәгендә симуляция җиһазларында эшләргә өйрәтү сыйныфлары ачылды (Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Чаллы шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Түбән Кама үзәк район күп профильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Әлмәт районара күп профильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе).

Белгечләр симуляция-тренинг һөнәри медицина белеме бирү программалары буенча түбәндәге медицина симуляторларында: эндоскопия симуляторы, йөрәк-үпкә реанимациясе комплексы өчен симулятор, ангиографик симуляция җиһазлары, лапароскопия симуляторы, ультратавыш диагностикасы симуляторы өйрәнә;

2. «Фельдшер ярдәмчесе» проектының максаты булып авыл халкына медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен хәл итү тора. Проект буенча республиканың 44 муниципаль берәмлегеннән 1 033 кеше укып чыкты.

3. «Һөнәри осталык. 2024» һөнәри осталык чемпионаты. Чемпионат йомгаклары буенча «Медицина технологияләре» блогында Татарстан Республикасы 11 медаль яулады, шулардан түбәндәге компетенцияләрдә:

- «Медицина һәм социаль хезмәт күрсәтү» – 2 алтын медаль, 1 көмеш медаль, 1 бронза медаль;
- «Лабораториядә медицина анализы» – 2 алтын медаль;
- «Дәвалау эшчәнлеге» – 1 көмеш медаль, 1 бронза медаль;
- «Фармацевтика» – 1 алтын медаль, 1 көмеш медаль;
- «Акушерлык эше» – 1 көмеш медаль.

«Абилимпикс» инвалидлар һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында һөнәри осталык буенча илкүләм чемпионаты финалы йомгаклары буенча «Медицина һәм социаль хезмәт күрсәтү» компетенциясендә Татарстан Республикасы вәкилләре 2 медаль (көмеш һәм бронза медальләр) яулады.

Социаль ярдәм чаралары буларак түбәндәге чаралар финанслана:

табибларга – яшь белгечләргә социаль ярдәм чаралары – хуҗалык кирәк-яраклары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү һәм өзлексез эшләү чорының беренче өч елында түләнә торган айлык өстәмә. Республиканың дәүләт (автоном) сәламәтлек саклау учреждениесенә эшкә кабул ителгән 411 яшь белгечкә (табибка) дәүләт ярдәме күрсәтелде, шулардан 141 белгечкә 21 534 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелде һәм беренче тапкыр 2 510 сум күләмендә айлык өстәмә билгеләнде. Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан 2024 елда 14,4 млн сум бүлеп бирелде;

Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларына ия булган табиб-белгечләргә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына дәүләт ярдәме чараларын финанслар белән тәэмин итү. Бер белгечкә грантның суммасы 800,0 мең сум тәшкил итә. 2024 елда гомуми суммасы 100,0 млн сумга 125 грант бирелде. Әлеге

максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан 2025 елга 120,0 млн сум каралган.

Өстәмә рәвештә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре буенча программа («Авыл докторы»/«Авыл фельдшеры») эшләп килә. Бер табибка бер тапкыр бирелә торган түләүнең күләме 1 млн сумнан 1,5 млн сумга кадәр, фельдшерга – 500,0 мең сумнан 750,0 мең сумга кадәр. 2024 елда бер тапкыр бирелә торган компенсация 100 табибка һәм урта медицина персоналыннан булган 30 хезмәткәрне кертеп, түләнде. Татарстан Республикасы бюджетында 2024 елда әлеге максатларда 142,0 млн сум бүлеп бирелде, шул исәптән федераль бюджеттан – 85,2 млн сум (60 процент), Татарстан Республикасы бюджетыннан – 56,8 млн сум (40 процент). Татарстан Республикасы бюджетында 2025 елга әлеге максатларда гомуми суммада 143,75 млн сум каралган, шул исәптән федераль бюджеттан – 83,375 млн сум (58 процент), Татарстан Республикасы бюджетыннан – 60,375 млн сум (42 процент).

2020 елдан Татарстан Республикасы Сәламәтлек министрлыгы тарафыннан республиканың дәүләт медицина оешмаларында эшләүче медицина хезмәткәрләре өчен «Социаль ипотека» программасы буенча чираттан тыш торак алуга квота бирелә. 2024 елда медицина хезмәткәрләренә фатир сатып алуга 180 квота бирелде (2023 елда – 142 квота).

**23. Сәламәтлек саклау тармагына ясалма фәһем кертү өчен, шул исәптән дәвалау учреждениеләрендә гражданнарны беренчел кабул итүне камилләштерү максатларында республикада кабул ителә торган чаралар турында.**

2024 елның гыйнварыннан республиканың медицина оешмаларыннан «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчерлык үзәге» дәүләт автоном учреждениесе базасындагы медицина сурәтләре үзәк архивына килә торган медицина сурәтләрен анализлау буенча ясалма фәһемнең өч сервисы (магнит-резонанс томографиядән медицина сурәтләрен автомат рәвештә анализлау, активлаштырылды.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды» дәүләт учреждениесе ярдәме белән 2024 елның 1 сентябреннән «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе белгечләре белән берлектә район хастаханәләре белгечләре тарафыннан өлкән яшьтәге кешеләрнең билгеле бер төркеменә диспансеризация уздыру кысаларында ясалма фәһем технологияләрен кулланып, маммография тикшеренүләрен икеләтә уку буенча сынау проекты эшли башлады.

2024 елның III кварталыннан республиканың медицина оешмаларында уздырылган диагностика тикшеренүләрен алу һәм аларны ясалма фәһем сервисларына юллау һәм эшкәртү буенча бердәм цифрлы мәйданчык булдыру кысаларында Мәскәү шәһәре Сәламәтлек саклау департаменты белән хезмәттәшлек оештырылды.

«Сбер» эшләп чыгарган ТОП-3 – ясалма фәһем базасында табибка цифрлы

ярдәмче гамәлгә кертелә, ул табибларга авыру зарлары нигезендә беренчел диагноз куярга ярдәм итә.

**24. Республиканың зур шәһәрләрендәге яңа микрорайоннар территорияләрендә яңа сәламәтлек саклау учреждениеләре төзү (ачу) барышы турында, Казан шәһәренең 1 номерлы балалар күп профильле хастаханәсенең яңа бинасын төзү перспективалары хакында.**

2025 елда Татарстан территориясендә 2024 елда төзелә башлаган түбәндәгеләр объектларда эшләр дәвам иттерелә:

- «Стационарларның кабул итү һәм диагностика бүлекчәләрен төзү» республика программасы кысаларында Казан шәһәренең «Профессор К.Ш. Зыятдинов исемендәге 18 нче үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУнең кабул итү һәм диагностика бүлеге (Казан шәһәре, Хөсәен Мәүлетов урамы, 3 нче йорт);

- «Стационар сәламәтлек саклау объектларын капиталь төзекләндерү» дәүләт программасы кысаларында Саба муниципаль районының «Саба үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кан тамырлары үзәге;

«Сәламәтлек саклауның беренчел буынын яңартып кору» федераль программасы кысаларында 2025 елда түбәндәгеләрне төзү планлаштырыла:

- 47 фельдшерлык-акушерлык пункты, шулардан Татарстан Республикасы халкына беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне камилләштерүгә юнәлтелгән чаралар кысаларында 13 фельдшерлык-акушерлык пункты;

- «Әлмәтнең 3 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гомуми практика табибы һәм педиатр үзәге, 100 кешене кабул итүгә исәпләнгән (Әлмәт шәһәренең Урсалы микрорайоны);

- Казан шәһәренең «20 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гомуми практика табибы һәм педиатр үзәге, 100 кешене кабул итүгә исәпләнгән (Вишневка торак массивы, Казан шәһәре);

- Казан шәһәренең «20 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы, 400 кешене кабул итүгә исәпләнгән («Весна» торак комплексы, Умырзая урамы);

- Казан шәһәренең «11 номерлы балалар шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы, 200 кешене кабул итүгә исәпләнгән («Идел киңлекләре» торак комплексы).

«Казан шәһәренең 1 номерлы балалар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында балалар күп профильле хастаханәсе төзү планлаштырыла, 6,2 га мәйданда җир кишәрлеге бүлеп бирелде. «Казан шәһәренең 1 номерлы балалар күп профильле хастаханәсе төзелеше» объекты буенча хәзерге вакытта технологик тоташтырулар һәм инженерлык челтәрләрен чыгаруга чыгымнарны оптимальләштерү эше алып барыла.

**25. Онкология чире булган гражданнар өчен республиканың санаторий-курорт учреждениеләрендә дәвалануларын дәвам итүне (тернәкләндерүне) оештыру турында.**

Татарстан Республикасында авырулар Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау

министрлыгының «Олы яшьтәге гражданнарның медицина тернәкләндерүе узуын оештыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 788н номерлы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы медицина оешмаларында өлкән яшьтәге кешеләргә медицина тернәкләндерүе узуны оештыру турында» 2021 елның 1 февралендәге 107 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Стационарда дәваланганнан соң санаторий-курорт учреждениеләрендә (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре) дәвалануларын дәвам иттерүне (тернәкләндерүне) оештыру турында» 2011 елның 28 мартындагы 233 номерлы карарлары нигезендә медицина тернәкләндерүе уза.

Өлкән яшьтәге кешеләр түбәндәге шартларда медицина тернәкләндерүе уза:

- 10 медицина оешмасы базасында 14 медицина тернәкләндерүе стационар бүлекчәсендә;

- 14 медицина оешмасының көндезге стационарлары шартларында медицина тернәкләндерүе бүлекчәләрендә;

- республиканың 17 медицина оешмасы базасында амбулатория шартларында.

Үзәк нерв системасындагы яман шешне (алга таба – яман шеш) алу буенча операция кичергән затлар медицина тернәкләндерүен үзәк нерв системасы авырулары булган авырулар өчен медицина тернәкләндерүе бүлекчәләрендә уза: сөяк-мускул системасында яман шеш булганнар – сөяк-мускул системасы һәм периферия нерв системасы медицина тернәкләндерүе узу бүлекчәләрендә; эчке органнарында яман шеш булганнар – соматик авырулары булган өлкән кешеләр өчен медицина тернәкләндерүе узу бүлекчәләрендә.

2024 елда «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында соматик авырулары булган кешеләр өчен 18 урынга исәпләнгән медицина тернәкләндерүе узу бүлекчәсе ачылды, аның төп юнәлеше – күкрәк читлеге органнарындагы һәм оча сөягендәге, күкрәк бизләрендәге яман шешне алдыру буенча операция кичергән кешеләр тернәкләндерү уздыру.

Өлкән яшьтәге авыруларга медицина тернәкләндерүе узу мәҗбүри медицина иминиятләштерүе акчалары хисабыннан, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан да (дәвалануларын дәвам итү) башкарыла.

Санаторий-курорт учреждениесе (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) шартларында стационарда дәваланганнан соң дәвалануларын дәвам итә (тернәкләндерелә) торган эшләүче гражданнарның авырулар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшләүче гражданнарның стационарда дәваланганнан соң шифаханә-курорт учреждениесе (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) шартларында дәвалануларын дәвам итүен (тернәкләндерүне) оештыру турында» 2011 елның 28 мартындагы 233 номерлы карары белән расланды. Кискен миокард инфаркты булган, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына операция ясалган, тотрыксыз стенокардия белән авырган, баш мие кан әйләнеше кискен бозылганнан соң, умыртка сөяге үсешендә кимчелекләр һәм җитешсезлекләр булганда ортопедик, травматологик операция, буыннарга пластик операцияләр ясалганнан соң, эндопротезлау һәм реэндопротезлаудан соң, очлыклар

реплантациясеннән соң авырулар, шикәр авыруы белән авыручылар, сәламәтлегенә куркыныч янау төркемендәге йөкле хатын-кызлар тернәкләндерүгә җибәреләләр. 2025 елга әлеге чараларны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 191,3 млн сум акча каралган, бу исә 5,6 мең эшләүче гражданның дәвалануын дәвам итүен (тернәкләндерүне) оештырырга мөмкинлек бирәчәк.

Санаторий-курорт дәвалануына юлламалар дәүләт социаль ярдәме алуга хокуклары булган, медицина күрсәтмәләре булган һәм санаторий-курорт дәвалануы алуга каршылыклар булмау өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасын сакланган затларның федераль регистрына кертелгән ташламага ия гражданнарга, шул исәптән онкология чире белән авыруларга «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 6.1 статьясы нигезендә бирелә.

Санаторий-курорт дәвалануына юллама алуга һәм дәвалау урынына тотылган юл чыгымнарын каплауга гариза Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының территориаль органына бирелә.

**26. Баланың әнисе һәм (яисә) әтисе инвалид булган очракта, баланы табибка телефон аша яздыруны оештыру кирәклеге турында.**

Бүгенге көндә авыруларны электрон рәвештә табибка яздыру каналлары булып дәүләт хезмәте күрсәтү федераль һәм төбәк порталлары, инфоматлар, электрон язылу терминаллары тора. Начар күрүчеләр өчен «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең контакт-үзәге, медицина оешмалары һәм 112 хезмәтләре аша телефоннан мөрәҗәгать итеп табибка чиратка язылырга мөмкин. Шулай итеп, республикада барлык гражданнарга, шул исәптән инвалидларга электрон рәвештә табибка язылу өчен техник мөмкинлекләр булдырылды. Өйдән чыкмыйча гына, табибка язылырга мөмкин.

Статистика мәгълүматларны табибка электрон рәвештә язылучылар санының артуын күрсәтә. 2024 елда электрон рәвештә табибка язылучыларның саны 17 млннан артып китте (2023 елда – 14,4 млн). Электрон рәвештә табибка язылу республикада иң киң таралган һәм ихтыяҗ зур булган электрон хезмәт булып санала.

2024 елның икенче яртыеллыгыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының бердәм колл-үзәгенә шалтырату өчен мобиль телефоннан 03-16 номерын, стационар телефоннардан 8 800 200 03 16 номерын җыярга кирәк. Шалтырату бушлай, колл-үзәкләр тәүлек әйләнәсе эшли.

## Мәгариф һәм мәдәният

**27. Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларының кадрлар белән тәэмин ителеше мәсьәләсен хәл итү буенча чаралар турында.**

Республика мәгариф системасында 76 меңнән артык педагогик хезмәткәр, шул исәптән 32 меңнән артык мәктәп укытучысы эшли. 35 яшькә кадәрге укытучылар өлеше – 20,4 %, 60 яшьтән өлкәнрәк укытучылар өлеше 12,7 % тәшкил итә.

Педагогик кадрлар җитмәү проблемасы актуаль булып кала. 2024/2025 уку

елы башына укытучыларга ихтыяҗ – якынча 2 мең кеше, тәрбиячеләргә 1 меңнән артык кеше тәшкил итте.

Барыннан да бигрәк математика (344), рус теле (334), башлангыч сыйныфлар (310), чит тел (180), физика (124), тарих (94), информатика (86), химия (77) укытучылары таләп ителә.

Муниципаль берәмлекләр яктылыгында Казан шәһәрендә, Чаллы шәһәрендә, Түбән Кама, Биектау, Лаеш һәм Әлмәт муниципаль районнарында укытучыларга аеруча зур ихтыяҗ бар.

Тулаем алганда, гомуми белем бирү оешмаларының педагогик кадрларга ихтыяҗы югары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар хисабына тәэмин ителә. 2024 елда гомуми белем бирү оешмаларына якынча 1 мең яшь белгеч эшкә урнашты.

Педагогик кадрлар җитмәү мәсьәләсе педагогик белгечлекләр буенча белем алучы югары курс студентларын җәлеп итү хисабына өлешчә хәл ителә. Республика мәктәпләрендә һәм балалар бакчаларында 630 студент эшли.

Бүгенге көндә педагогларның 27 проценты диярлек бер ярымнан артык ставка алып бара, шул исәптән укытучыларның 45 процентыннан артыгы ике төп предмет: математика белән рус телен укыта. Шул ук вакытта укытучыларның 8 проценты икедән артык ставка белән эшли.

Республикада яшь белгечләрне беркетү мәсьәләсен хәл итү өчен мәгариф хезмәткәрләренә түбәндәге ярдәм чаралары гамәлгә ашырыла:

- беренче өч ел эшләү дәверендә яшь педагогларга 2 510 сум күләмендә ай саен бирелә торган өстәмә түләү;
- сыйныф җитәкчелеге өчен 5 мең сум күләмендә ай саен бирелә торган түләү, халык саны 100 мең кешедән кимрәк торак пунктларда урнашкан оешмаларда сыйныф җитәкчелеге өчен – 10 мең сум;
- авыл җирлегендә яшәүче һәм эшләүче педагогик хезмәткәрләргә торак урыннар, җылылык һәм ут өчен түләүгә субсидия;
- авыл җирендә эшләгән өчен ай саен бирелә торган түләү, авылда урнашкан балалар бакчаларында һәм рус булмаган телдә укытыла торган мәктәпләрдә балаларга рус телен өйрәткән өчен өстәмә түләү;
- кайбер муниципаль районнар яшь педагогларга җирле бюджет акчасыннан бер тапкыр бирелә торган түләүләр башкара (Лаеш муниципаль районы – 120 мең сум, Азнакай муниципаль районы – 50 мең сум, Сарман муниципаль районы – 25 мең сум, Лениногорск, Түбән Кама муниципаль районнары – 10 мең сум, Әгерҗе муниципаль районы – 8 мең сум);
- «Безнең яңа укытучы» грантында җиңүчеләргә өч ел дәвамында ай саен 10 мең сум күләмендә хезмәт хакына өстәмә түләү билгеләнде;
- «Земский учитель» программасында җиңүчеләр 1 млн сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен алалар;
- индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү;
- бюджет өлкәсе хезмәткәрләре өчен, шул исәптән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ укытучылар өчен дә социаль ипотека программасы.

**28. Татарстан Республикасында мәгариф системасын цифрлаштыру турында.**

2024 елның гыйнварыннан республиканың барлык гомуми белем бирү оешмалары яңартылган «Татарстан Республикасы Электрон мәгарифе» дәүләт мәгълүмат системасында эшли башлады, аның составына «Мәскәү электрон мәктәбе»нең яңа компонентлары һәм сервислары кертелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, Мәскәү шәһәрендә апробация йомгаклары буенча урта һөнәри белем бирү дәрәҗәсендә белем бирү барышын цифрлаштыру өлешендә «Татарстан Республикасы электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасын модернизацияләү мәсьәләсе каралачак.

«Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2024 елда республиканың проектка җәлеп ителгән барлык мәгариф оешмалары җиһазлар белән тәэмин ителеп бетте.

2024 елда һөнәри белем бирү оешмалары укытучыларына 171,2 млн сумлык гомуми суммага 4 286 берәмлек компьютер техникасы (4 262 ноутбук һәм 24 моноблок) тапшырылды.

Татарстанда «Минем мәктәп» федераль дәүләт мәгълүмат системасын һәм «Сферум» мәгълүмат-коммуникация платформасын актив үзләштерү бара. 2024 ел йомгаклары буенча республикада актив кулланучылар саны 291 509 укучы, 36 426 педагогик хезмәткәр тәшкил итте.

2023/2024 уку елында «Киләчәк коды» федераль проекты программалары буенча хәзерге заман программалаштыру телләрен 9 999 укучы, шул исәптән 4 725 укучы – онлайн, 5 274 укучы офлайн режимда өйрәнде.

2024 елда 255 мәктәп укучысы «Яндекс.Лицей» мәгариф проекты кысаларында хәзерге заман программалаштыру телләрен өйрәнү буенча ике еллык курсны тәмамлады. 2017–2024 елларда 855 укучы ике еллык тулы курсны төгәлләде һәм кече уйлап табучы яки стажер буларак эшли башлау өчен җитәрлек күнекмәләр алды.

2018/2019 уку елыннан башлап, Татарстан Республикасының мәгариф оешмалары мәктәп укучыларында цифрлы икътисад компетенцияләрен үстерүгә, шулай ук мәгълүмат технологияләре өлкәсендә аларга алданрак һөнәри юнәлеш бирүгә юнәлдерелгән «Цифра дәресе» бөтенроссия мәгариф акциясендә катнаша.

Ел саен көз көне республика мәгариф оешмаларында интернетта киберкуркынычсызлык дәрәҗәсен арттыруга, ата-аналар белән педагоглар җәмәгатьчелегенең Интернет челтәрендә балалар иминлеге проблемаларына игътибарын җәлеп итүгә һәм мәктәп укучыларында цифрлы грамоталылыкны үстерүгә юнәлдерелгән Бердәм иминлек дәресе уздырыла.

**29. Татарстан Республикасында театр эшен үстерү турында.**

Татарстан Республикасының театр-тамаша учреждениеләре челтәре 19 (15 дәүләт һәм 4 муниципаль) театрдан тора, шулардан иң зурысы – Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт Академия опера һәм балет театры, В.И.Качалов исемендәге Казан Академия рус Зур драма театры, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия

театры.

2024 елда республика дәүләт һәм муниципаль театрларында 4 195 спектакль, шул исәптән 1 384е – балалар һәм яшүсмерләр аудиториясе өчен күрсәтелде. Театр куелышларын 1 561,7 мең тамашачы карады.

100 яңа спектакль, шул исәптән «Кече Ватан мәдәнияте» федераль проекты кысаларында 33 премьера куелды.

Гастрольләр вакытында театр тарафыннан 280 спектакль, шул исәптән Россия Федерациясе төбәкләренә барып 130 спектакль күрсәтелде.

Казан операсының 150 еллыгы үткәрелгән елда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры Кытай Халык Республикасының алдынгы мәйданчыкларында «Лебединое озеро» һәм «Щелкунчик» балет куелышлары белән, зур уңышка ирешеп, чыгыш ясады. Республиканың театр труппалары 67 төбәкара, бөтенроссия конкурсларында катнашты, 54 лауреат премиясе алды.

2024 елның 25 июнендә «Алтын битлек» бөтенроссия премиясен тапшыру тантанасында:

- «Әкият» татар дәүләт курчак театры «Курчак театрының иң яхшы спектакле», «Курчак театры режиссерының иң яхшы эше»; «Курчак театрының иң яхшы актеры» номинацияләрендә 3 бүләк алды;
- Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры «Драма театрының иң яхшы спектакле»; «Драма театры костюмнары буенча рәссамның иң яхшы эше» дигән 2 номинациядә җиңде;
- конкурс жюриеның «Ил язмышына катнашы һәм милли геройны эзләве өчен» дигән махсус премиясе Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрына бирелде.

2025 елның 20 гыйнварында Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының яңа бинасын ачу тантанасы уздырылды.

2025 елда Казан шәһәрендә Халыкара Театр Олимпиадасын, төрки халыкларның «Нәүрүз» XVII Халыкара театр фестивален, «Алтын битлек» милли театр премиясен тапшыру тантанасын уздыру планлаштырыла (Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының яңа бинасында).

2016 елдан «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында һәм сәләтле балаларны ачыклау, аларны иҗади эшчәнлеккә җәлеп итү, телләрне саклау һәм үстерү проблемаларына җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатларында республикада ел саен балалар һәм яшүсмерләр театрларының «Сәйяр» республика фестивале уздырыла. Фестиваль «Салават күпере» балалар журналы һәм «Сәхнә» журналы, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры белән берлектә уздырыла.

2024 елда муниципаль этапта 1 меңнән артык коллектив чыгыш ясады. Республика этабында татар телендә – 309, чуваш телендә – 14, удмурт телендә – 8, мари телендә – 3, мордва телендә 2 чыгыш каралды.

2024/2025 уку елы дәвамында 1 374 мәктәп театры төзелә һәм эшли, 23 247 укучы, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән 554 бала җәлеп ителеп, «Театр эшчәнлеге» юнәлеше буенча 1 276 программа гамәлгә ашырыла. Балалар театр студияләренең эшчәнлеге түбәндәге театр куелышлары аша туган телләрне

һәм туган мәдәниятләрне өйрәнергә ярдәм итә, алар арасында рус телендә – 682, татар телендә – 466, чуваш телендә – 10, удмурт телендә – 3, мари телендә – 2.

Театр студияләре конкурс чараларында, шул исәптән «Беренче театр» һәм «Сәйяр» бөтенроссия театр иҗаты фестивальләрендә; «Бөек Җиңүнең яшь геройлары» республика театр куелышлары конкурсында; «Әйе, исәнме театр!» театр коллективлары фестивалендә һ.б. актив катнаша.

Спектакльләр үз илебез һәм чит ил авторлары әсәрләре буенча куелды. Татар авторларының әсәрләре бик популяр.

2024 елның 24 декабреннән 30 декабренә кадәр «Костер» республика яшьләр үзәге базасында Мәктәптән тыш эшләр буенча республика үзәге тарафыннан «Театр сезоны» республика профильле сменасы үткәрелде, анда Татарстан Республикасының 13 муниципаль берәмлегеннән 7 яшьтән алып 17 яшькә кадәр 140 бала катнашты.

2024 елда Татарстан Республикасында театр эшен үстерү чыгымнары 3 387,5 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән 576,3 млн сум тәшкил итте.

**30. Авылда мәдәният учреждениеләрен (китапханәләрне, клубларны) югары тизлекле интернетка тоташтыру эше турында.**

Татарстан Республикасында хакимият органнары, бюджет учреждениеләре һәм социаль әһәмиятле объектлар Татарстан Республикасы телекоммуникацияләренең дәүләт интеграцияләнгән системасына (алга таба – ТР телекоммуникацияләренең дәүләт интеграцияләнгән системасы) тоташтырыла. Хәзерге вакытта ТР телекоммуникацияләренең дәүләт интеграцияләнгән системасына 9,9 меңнән артык абонент тоташтырылган. 1 970 мәдәният учреждениесе «ВОЛС» һәм «ADSL» технологияләре буенча ТР телекоммуникацияләренең дәүләт интеграцияләнгән системасына тоташтырылды, 304 абонент тоташтыруны көтә.

2024 елда авылда эшли торган 585 мәдәният учреждениесенең интернеттан файдалану мөмкинлеге бар.

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Цифрлы нигездә үстерү, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы адресына 2025–2027 елларда социаль әһәмиятле объектларны, шул исәптән мәдәният-ял итү учреждениеләрен интернетка тоташтыру чараларын гамәлгә ашыруны дәвам итү максатка ярашлы булу турында хат җибәрелде.

**31. Каникуллар чорында коррекцияле гомуми белем бирү мәктәпләре каршында мәктәп лагерьларын оештыру турында.**

«2019–2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2025 елда гомуми белем бирү оешмалары, балалар белем бирү-савыктыру лагерьлары базасында сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән 452 бала һәм инвалидлар өчен ял оештырылды; алар арасында ишетү, күз сәләте, интеллекты бозылган балалар һәм үсешендә күпсанлы авыр бозылышларга ия балалар да булды.

Мәктәп лагерьлары «Лаеш шәһәренең сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә (күрү сәләте бозылган балалар өчен), «Яңа Кенәр авылының сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә (интеллекты бозылган балалар өчен), «Менделеевск шәһәренең сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә (интеллекты бозылган балалар өчен), «Әлмәт шәһәренең сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә (терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен) оештырылачак.

Мәктәп лагерьлары мәктәпләр базасында белем алучыларның законлы вәкилләреннән гаризалар булганда оештырыла.

Кара диңгез яры буенда ишетү сәләте бозылган 35 баланың ялын оештыру өстәмә рәвештә планлаштырыла.

**32. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру турында (шул исәптән спорт заллары төзү, иске биналарда урнашкан шәһәр мәктәпләренең спорт залларын капиталь ремонтлау турында).**

Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру максатларында, мәктәпләрнең спорт залларын капиталь ремонтлау шулай ук Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларын капиталь ремонтлау программасы һәм «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының мәктәп белем бирү системаларын модернизацияләү чаралары кысаларында гамәлгә ашырыла. Объектларның исемлекләре, эш төрләре һәм күләмнәре Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан билгеләнә.

2024 елда «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының ике спорт залын ремонтлау гамәлгә ашырылды (Тукай муниципаль районының «Новый поселогының урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ һәм Ютазы муниципаль районының «3 нче Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ). Әлеге максатларга 3,34 млн сум, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән 2,71 млн сум күләмендә акча җибәрелде.

Моннан тыш, спорт объектлары (шул исәптән мәгариф оешмалары территориясендә) төзү Татарстан Республикасының торак пунктларында универсаль спорт мәйданчыклары һәм аз чыгымлы спорт корылмалары төзү программасы кысаларында гамәлгә ашырыла. Барлыгы 2024 елда 125 спорт корылмасы төзелде.

2013 елдан 2024 елга кадәр универсаль спорт мәйданчыклары төзү буенча республика программасы кысаларында 1 172 спорт корылмасы, шул исәптән 40 хоккей тартмасы, 44 блоклы модульле чаңгы базасы һәм 19 ябык футбол манежы төзелде. Әлеге максатлар өчен бөтен чор дәвамында Татарстан Республикасы бюджетыннан 5 074,24 млн сум күләмендә акча бүлеп бирелде.

Шулай ук 2024 елда 15 универсаль спорт мәйданчыгы (4есе – Саба муниципаль районында, 3ешәр – Казан шәһәрендә һәм Кукмара муниципаль

районында, 1ешәр – Яр Чаллы, Түбән Кама, Алабуга шәһәрләрендә, Биектау һәм Яңа Чишмә муниципаль районнарында); 4 ябык футбол манежы (Аксубай, Кама Тамагы, Лаеш, Сарман муниципаль районнарында) төзелде.

**33. Балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәпләренең тренер-укытучыларына ярдәм чараларының комплекслы системасын оештыру турында. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән спортчылар тренерларының хезмәте өчен түләү дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар турында.**

Югары спорт казанышларына ирешәкән өчен Татарстан Республикасының әйдәүче спортчыларына ай саен бирелә торган стипендияләр күләмнәре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары казанышларга ирешкән өчен спортчыларга һәм тренер-укытучыларга дәүләт ярдәме турында» 2018 ел, 20 февраль, 98 нче карары белән расланды.

Тренерларга ай саен бирелә торган өстәмә түләүләр бер календарь ел дәвамында гамәлгә ашырыла һәм бер спортчы тарафыннан шәхси дисциплиналарда ярышлар программасының бер төре буенча күрсәтелгән иң югары бер нәтиҗә өчен календарь ел йомгаклары буенча билгеләнә. Спортның төркемле дисциплиналарында һәм команда төрләрендә һәр алдагы спортчы (төркем яки команда) өчен билгеләнгән күләмнән 10 % күләмендә өстәмә түләү башкарыла.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Югары спорт казанышлары өчен Татарстан Республикасының әйдәүче спортчыларына ай саен бирелә торган стипендияләр һәм аларның тренерларына ай саен бирелә торган өстәмә түләүләр билгеләү турында» 2025 ел, 31 гыйнвар, 32 нче боерыгы нигезендә 2025 елда 2024 ел өчен халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары спорт нәтиҗәләренә ирешкән 63 тренер ай саен өстәмә тәүләү ала, гомуми суммасы 4,14 млн сум тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә – хезмәткәрләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2019 ел, 31 октябрь, 979 нчы карарында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә дәүләт ярдәме, шул исәптән ай саен бирелә торган стимуллау характерындагы өстәмә түләү – 2 510 сум; хуҗалыкны төзекләндерү өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү 100 мең сум күләмендә акча каралды.

2024 елда ай саен бирелә торган стимуллау характерындагы өстәмә түләүне дәүләт һәм муниципаль спорт мәктәпләрендә эшләүче 79 яшь белгеч, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне 36 яшь белгеч алды. Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан 6,2 млн сум акча җибәрелде.

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетында югарыда күрсәтелгән максатлар өчен чыгымнар һәр елга 6,2 млн сум күләмендә каралды.

а) Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов карары нигезендә спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә (спорт мәктәпләрендә):

- 2023 елның 1 гыйнварыннан инвалидлар һәм физик яки акыл үсешендә

җитешсезлекләр булган затлар белән эшләгән өчен түләү күләме вазыйфаи окладтан 3 проценттан алып 20 процентка кадәр арттырылды;

- 2023 елның 1 сентябреннән квалификация категориясе өчен адаптив физик культура буенча тренер-укытучыларга (1 категория өчен – 6,5 %, югары категория өчен – 8 %), спорт мәктәпләренең тренер-укытучыларына (1 категория өчен – 11 %, югары категория өчен – 13 %) вазыйфаи окладка өстәмә түләүләр күләме арттырылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасының спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының спорт әзерлеге дәүләт үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары нигезендә тренер-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен спортчыларга һәм спортчы-инструкторларга түләүләр билгеләнде. Спортның олимпия төрләре буенча әлеге түләүләр күләме, ярышлар дәрәҗәсенә һәм алынган урынга карап, вазыйфаи окладның 20 процентыннан алып 500 процентына кадәр күләмдә билгеләнде.

2024 елда тренер-укытучыларга түләүләр өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 106,0 млн сум акча тотылды.

## Иҗтимагый иминлек

**34. Гадәттән тыш хәлләр очрагында халыкны яклауга юнәлдерелгән чаралар турында. Татарстан Республикасы халкына үзәктән хәбәр итү буенча төбәк автоматлаштырылган системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралар турында.**

2025 елгы су басуга әзерлек турында.

2025 елгы су басу чорында гадәттән тыш хәлләр булганда халыкны саклауны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең (алга таба – ГТХ һәм ЯКТИ комиссиясе) «2025 елгы су басуга әзерләнү чаралары турында» 2024 елның 11 июнендәге 17-24р боерыгы белән расланды.

Әлеге боерык нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре (алга таба – муниципаль берәмлекләрнең ГТХ һәм ЯКТИ комиссиясе) тарафыннан 2024 елның җәйге-көзге чорында 754,8 млн сумлык гомуми суммага превентив чаралар комплексы уздырылды, әлеге чараларга 27 гидротехника корылмасына ремонт ясау, елгалар үзәннәрен чистарту һәм турайту, төпне тирәнәйтү, ярны ныгыту һәм башка чаралар (110,508 км гомуми озынлыктагы 135 участокта) керә, 10 862 су үткәрү торбасы урнаштырылды, ремонтланды, чистартылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 август, б-1625 нче боерыгы белән расланган ташкын чорында су басу (җир асты сулары күтәрелеп су басу) зонасына эләгә торган Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлегенә үзгәрешләр кертелде (218 торак пункт расланды).

Югарыда күрсәтелгән боерыкның үтәлешен контрольдә тоту максатларында,

2024 елның 1 ноябреннән 14 ноябренә кадәр муниципаль берәмлекләрнең ГТХ һәм ЯКТИ комиссияләре рәисләренең 2025 елгы су басуга әзерләнү һәм гидротехник корылмаларга су агызып төшерү нәтиҗәләре турында чыгышлары тыңланды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елның су басу куркынычы булган чорында Татарстан Республикасы территориясендә ташкын суларының тискәре йогынтысын һәм зыяннарын булдырмау чаралары турында» 2025 ел, 31 гыйнвар, 47 нче карары кабул ителде, анда контроль, гамәли һәм оештыру чаралары комплексын үз эченә алган План расланды.

Татарстан Республикасы ГТХ һәм ЯКТИ комиссиясенең «Татарстан Республикасы территориясендә ташкынга каршы өстәмә чаралар уздыру турында» 2024 елның 26 декабрендәге 33-24р номерлы боерыгы расланды, аның кысаларында муниципаль берәмлекләрдә территорияләрне кардан чистарту, дренаж системаларын, су үткәрү торбаларын, яңгыр сулары агу урыннарын, каналларны, яңгыр канализациясе корылмаларын һәм кар сулары агызыла торган башка инженерлык системаларын төзекләндерү һәм чистарту, түбәләрне кардан һәм бозлардан чистарту; вакытлыча урнаштыру пунктларының әзерлеген тикшерү, сулары агызылмаган гидротехника корылмаларын контрольдә тоту чараларын һәм башка чараларны үткәрү оештырылды.

Татарстан Республикасы ГТХ һәм ЯКТИ комиссиясенең «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең 2025 елгы язгы ташуны уздыруга әзерлеге турында» 2025 елның 11 февралендәге 02-25р номерлы боерыгы расланды, аның кысаларында 2025 елның 25 февраленнән 7 мартына кадәр муниципаль берәмлекләрнең ГТХ һәм ЯКТИ комиссияләре рәисләренең 2025 елгы язгы ташуны уздыруга әзерләнү һәм муниципаль берәмлекләр тарафыннан ташкынга каршы превентив чаралар (су объектларында боз каралту һәм кисү, су үткәрү торбаларын һәм күпер асты урыннарын чистарту, елгалар үзәннәрен чистарту, вакытлыча гидрочелтәр эшләвен оештыру һәм башка чаралар) уздыру мәсьәләсе буенча чыгышлар тыңлау каралды.

Татарстан Республикасында соңгы 10 ел эчендә, җир асты сулары күтәрелеп, су басуга бәйле гадәттән тыш хәлләр теркәлмәде. Тулаем алганда, 2025 елгы ташкын һәм язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләр булган очракта халыкны саклауга юнәлдерелгән чаралар План нигезендә билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Гидротехника корылмаларында иминлек турында.

Гидротехника корылмаларында иминлек Татарстан Республикасы ГТХ һәм ЯКТИ комиссиясенең «2025 елгы ташкынга әзерләнү нәтиҗәләре, гидротехника корылмаларында су агызу һәм 2024 елда суда кешеләрнең иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2024 елның 29 августындагы 22-24р номерлы боерыгы кысаларында уздырылган чаралар нигезендә тәэмин ителде. Әлеге боерык нигезендә муниципаль берәмлекләр тарафыннан, гидротехника корылмалары милекчеләре белән берлектә, 2024 елның көзге чорында Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территорияләрендә урнашкан гидротехника корылмаларында суны куркынычсыз дәрәҗәгә кадәр агызып төшерү тәэмин ителде. Кышкы куркынычсыз дәрәҗәгә кадәр суы агызып төшерелмәгән 16 гидротехника корылмасы республика җирле үзидарә органнары тарафыннан махсус контрольгә алынды. Шулай ук

гидротехника корылмалары мәгълүматлары буенча су чыгару каналлары аша авария хәлендә су агызып төшерүне тәэмин итү буенча чаралар күрү турында тәкъдимнәр бирелде.

Татарстан Республикасы ГТХ һәм ЯКТИ комиссиясенең «2025 елгы ташкынга әзерләнү чаралары турында» 2024 елның 11 июнендәге 17-24р боерыгы кысаларында 2024 елның җәйге-көзге чорында республикада 339,8 млн сумлык гомуми суммага 27 гидротехника корылмасына ремонт ясалды.

Татарстан Республикасы ГТХ һәм ЯКТИ комиссиясенең «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гидротехника корылмаларын тикшерүне оештыру турында» боерыгы проекты әзерләнде һәм аңа тәкъдимнәр кертү өчен кызыксынучы ведомстволарга җибәрелде, аның нигезендә 2025 елның 7 апреленнән 30 апреленә кадәр ремонт ясау таләп ителә торган гидротехника корылмаларын һәм хуҗалары булмаган гидротехника корылмаларын тикшерү планлаштырыла.

Гидротехника корылмаларында куркынычсызлыкны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы аларда аварияләр булуга бәйле гадәттән тыш хәлләрне булдырмаска мөмкинлек бирә.

2024/2025 елгы ягу чорына әзерлек һәм аны уздыру турында.

2024/2025 елның ягу чорына әзерлек Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024/2025 елның ягу чорына Татарстан Республикасының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларын әзерләү мәсьәләләре турында» 2024 ел, 14 июнь, 425 нче карары нигезендә оештырылды.

2024/2025 елның ягу чорына әзерләнү максатларында Республика штабының 10 утырышы уздырылды.

Әлеге карар нигезендә Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән берлектә, 2024 елның 1 октябренә кадәр түбәндәге чаралар уздырылды:

- узган елларның ягулык чорларына ясалган йомгакларны исәпкә алып, ягу чорында Татарстан Республикасының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларында аварияләр булу итхтималына бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча оператив эш итүләр планына («Стужа») төзәтмәләр кертү;
- һәлакәттән торгызу формированиеләренең Татарстан Республикасының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларында гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә әзерлеген тикшерүләрдә катнашу.

2024/2025 елның көзге-кышкы ягу чорында мөмкин булган һәлакәтләргә һәм гадәттән тыш хәлләргә үз вакытында чара күрү максатларында Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмалар, министрлыклар һәм ведомстволар белән мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру турында 163 килешү төзелде.

Ягу чорында төрле аварияләрне һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә һәм бетерүгә бәйле 22 уку һәм күнегү үткәрелде.

Ведомство буйсынуындагы объектлар гадәттән тыш хәлләр шартларында нормаль эшләсен өчен аларны резерв электр энергиясе чыганаклары белән тәэмин

итүне һәм аларны әзерләүне контрольдә тоту тәэмин ителде.

2024 елда Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә караган күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсе тарафыннан 4 планнан тыш һәм 1 план буенча контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрелде. 2 юридик зат, 5 вазыйфаи зат административ җаваплылыкка тартылды.

«Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» ДБУ мәгълүматлары буенча, түбәндәге ягулык-энергетика ресурсларының запаслары булдырылды:

- күмер – 59,916 мең тонна (билгеләнгән запастан 1 067 %);
- мазут – 165,076 мең тонна (228 %);
- дизель ягулыгы – 0,545 мең тонна (21 %);
- иярчен нефть газы – 238 мең куб.м (100 %);
- утын – 0,15 мең куб.м (11 %);
- пеллетлар – 0,13 мең тонна (40 %);
- мич ягулыгы – 0,602 мең тонна (47 %);
- судно ягулыгы – 3,408 мең тонна (121 %).

2024/2025 елның ягу чорында торак-коммуналь хуҗалык объектлары эшчәнлегенә бәйле гадәттән тыш хәлләр теркәлмәде. Тулаем алганда, 2024/2025 елның ягу чоры узу чорында эш билгеләнгән срокларда план нигезендә алып барыла.

Татарстан Республикасы су объектларында кешеләр үлеме рискларын киметү буенча превентив чаралар турында.

Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы һәм Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча координация киңәшмәсенең бергәләп уздырылган утырышының 2018 елның 4 апрелендәге беркетмәсенең 7.3 пункты (Татарстан Республикасы Рәисенең 2018 елның 19 апрелендәге ПР-95 номерлы йөкләмәләре исемлеге) нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан су объектларында кешеләр үлеме рискларын киметү буенча превентив чаралар оештыру максатларында 2024 елда ГХК һәм ЯКТИ комиссиясенең «2024 елда Татарстан Республикасының су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү буенча превентив чаралар үткәрүне оештыру турында» 2024 елның 18 маендагы 02-24р номерлы боерыгы кабул ителде. Тулаем алганда, муниципаль берәмлекләр тарафыннан 2024 елга су объектларында кешеләр үлеме рискларын киметү планнарында методик тәкъдимнамәләрнең 4 пунктындагы якынча исемлегеннән барлык 19 чара исәпкә алынды. Планнар чараларын гамәлгә ашыру турында хисап мәгълүматына караганда, муниципаль районнар тарафыннан кайбер чаралар үткәрелмәгән һәм 2024 елда Татарстан Республикасында суда кешеләр үлеме рискларын киметү буенча башкарылган превентив чараларның гомуми күләме 92 % тәшкил иткән булуы билгеләнде.

Югарыда күрсәтелгән искәрмәләр муниципаль берәмлекләрнең ГТХ һәм ЯКТИ комиссияләре рәисләренең көзге чыгышларын тыңлаганда карап тикшерелде, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелгән 2024 елның мәгълүмати-аналитик хисабына кертелде, җитешсезлекләрне бетерү өчен муниципаль берәмлекләргә җибәрелгән ГТХ һәм ЯКТИ комиссияләре рәисләре

чыгышларын тыңлау беркетмәләрендә исәпкә алынды.

Тулаем алганда, соңгы 10 елда суда кешеләрнең үлеме кимүе күзәтелә (2015 елда – 136 кеше, 2024 елда – 82 кеше). Эшләнгән превентив чаралар комплексы гадәттән тыш хәлләрне һәм суда кешеләр үлеме артуны булдырмаска мөмкинлек бирә.

Татарстан Республикасының Янгыннан саклау хезмәте.

Татарстанда «Татарстан Республикасының Янгыннан саклау хезмәте» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – ТР Янгыннан саклау хезмәте) төзелде, аның төп бурычлары – янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару.

ТР Янгыннан саклау хезмәте 26 хезмәткәрдән һәм Татарстан Республикасының янгынга каршы хезмәтенең 7 отрядыннан гыйбарәт идарә аппараты булып тора (отрядлар эшчәнлеге «ТР Янгыннан саклау хезмәте» ДКУнең «Татарстан Республикасының Янгыннан саклау хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең янгынга каршы хезмәте отрядлары нигезләмәләрен раслау турында» 2016 елның 27 июлендәге 780-п номерлы боерыгы белән регламентлана), аларның һәрберсенә 13 тән алып 18 гә кадәр янгыннан саклау бүлекчәләре (аерым постлар) керә.

Ике бүлекчәдән – 23ешәр берәмлектән торган Биектау муниципаль районы, Шигали авылының аерым каравыл постыннан һәм Питрәч муниципаль районы, «Усадьба Царево» торак комплексы территориясендәге аерым посттан, шулай ук шәхси составы 8 берәмлектән торган Чирмешән муниципаль районы, Лашман авылының аерым каравыл постыннан кала, бүлекчәләрнең саны 11шәр берәмлек тәшкил итә.

2024 елда ТР Янгыннан саклау хезмәтенең бүлекчәләре тарафыннан тревога буенча 1 758 тапкыр барылды. Янгын бүлекчәләре дислокациясе хәзерге вакытта республиканың янгынга каршы хезмәт бүлекчәләренең норматив килү вакыты зонасында 1 237 авыл торак пункты урнашкан булуын күрсәтә, бу республикада 400 меңнән артык кеше яшәгән торак пунктларның гомуми санынннан 39 процентын (авыл җирлегендә яшәүче халыкның гомуми санынннан 45 процентын) тәшкил итә. Норматив барып җитү вакыты зонасында кешеләр күпләп була торган 3 443 объект, 191 531 шәхси йорт биләмәсе бар.

Янгынга каршы хезмәтне финанслау Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән гамәлгә ашырыла. 2024 елда факттагы чыгымнар 1 млрд сум (2023 ел дәрәҗәсенә карата 110 %) тәшкил итте.

Татарстан Республикасының Эзләү-коткару хезмәте.

Гадәттән тыш хәлләргә һәм һәлакәтләргә оператив чара күрүне оештыру өчен «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының Эзләү-коткару хезмәте» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Эзләү-коткару хезмәте) төзелде, аның гомуми саны 270 берәмлек тәшкил итә.

Эзләү-коткару хезмәте үз эшчәнлеген территориаль принцип буенча гамәлгә ашыра, моның өчен аның составында 7 зона отряды төзелде. Хезмәтнең матди-техник тәэмин ителеше куелган бурычларны билгеләнеше буенча тулы күләмдә

башкарырга мөмкинлек бирә.

2024 елда Эзләү-коткару хезмәте коткаручылары муниципаль характердагы 3 гадәттән тыш хәлне бетерүдә катнашты. 2024 елда коткаручылар тарафыннан эзләү-коткару эшләрен уздыру өчен 1 429 бару очрагы гамәлгә ашырылды, алар барышында 1 081 кеше коткарылды.

Поисково-коткару хезмәтен тотуга финансларның гомуми күләме 2024 елда 247 млн сумнан артык тәшкил иткән.

Татарстан Республикасы халкына үзәктән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасын камилләштерү.

Үзәктән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасын булдыру турында киңәшмә йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 12 сентябрендәге ПР-192 номерлы йөкләмәләре исемлеген, 2024 елның 22 апрелендәге Татарстан Республикасы халкына хәбәр итү системасын булдыру (реконструкцияләү) чаралары планын гамәлгә ашыру кысаларында 2024 елдан хәбәр итүнең яңа төбәк системасын проектлау эше алып барыла. Хәзерге вакытта «МАРС ТЕХНОЛОГИИ» ЖЧҖ һәм «Сенсор» фәнни-җитештерү берләшмәсе АҖ тарафыннан эшләнгән ике хәбәр итү системасы проекты карала. Казан шәһәре территориясендә хәбәр итү системасын төзү һәм файдалануга тапшыру 2025 елның ахырына кадәр, ә калган территориядә 2028 елдан да соңга калмыйча төгәлләргә планлаштырыла.

Халыкка хәбәр итү системаларын кулланырга даими әзер хәлдә булу түбәндәгеләр ярдәмендә тәэмин ителә:

- көн саен техник тикшерүләр үткәрү;
- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкка хәбәр итү системаларын эшләү, реконструкцияләү һәм аларны кулланырга даими әзер хәлдә тоту тәртибе турында» 2023 елның 17 маендагы 769 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын үзәктән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 26 июль, 655 нче карары нигезендә халыкка хәбәр итүнең төбәк системасы әзерлегенә комплекслы тикшерүләр үткәрү (елга 2 тапкыр);
- Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән Россия Федерациясе Цифрлы нигездә үстерү, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Халыкка хәбәр итү системаларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтүне оештыру нигезләмәсен раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 579/366 номерлы боерыгы нигезендә хәбәр итүнең техник чараларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтүне оештыру.

**35. Үз хезмәткәрләрен яшерену урыны белән тәэмин итүче предприятиеләрдә гражданнар оборонасы саклану корылмаларының (убежищеларның) хәзерге торышы турында.**

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы җитәкчесе – Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 30 июлендәге 7 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы халкын яшерену планлаштыру максатларында республика территориясендә гражданнар оборонасы саклану корылмаларына (алга таба – саклану корылмалары) инвентаризация ясау оештырылды һәм ясалды. Әлеге боерык белән республика территориясендә халык яшерену өчен билгеләнгән саклану

корылмаларына инвентаризация үткәрү буенча республика комиссиясе составы расланды.

Саклану корылмаларына инвентаризация Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министры урынбасары тарафыннан 2024 елның 19 июнендәге 43-3750-11 номеры белән расланган Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнарына саклану корылмаларын инвентаризацияләү буенча тәкъдимнамәләре таләпләре һәм Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгыннан кергән саклану корылмаларына инвентаризация үткәрү тәртибе нигезендә оештырылды һәм үткәрелде.

Республика муниципаль берәмлекләре башлыклары боерыклары белән ярдәмче комиссияләр төзелде, муниципаль берәмлекләр территориясендә саклану корылмаларына инвентаризация үткәрү өчен аларның составы билгеләнде, алар тарафыннан инвентаризация нәтиҗәләре Республика комиссиясенә тапшырылды.

Республика комиссиясе тарафыннан инвентаризация нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, шулай ук Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе аша Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына кертелде.

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы җитәкчесе – Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы халкы яшеренү өчен билгеләнгән саклану корылмаларына инвентаризация үткәрү нәтиҗәләре турында» боерыгы проекты әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә кертелде. Әлеге документта республика муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына оешмаларда әзер булмаган һәм чикле әзер булган гражданнар оборонасы саклану корылмаларын тиешле муниципаль берәмлек халкы яшеренү өчен кулланырга әзер хәлгә китерү буенча перспектив планнар эшләүне оештыру, шулай ук яраксыз хәлгә килгән гражданнар оборонасы саклану корылмаларын исәптән төшерү өчен кирәкле документлар әзерләү, «убежище» һәм «радиациягә каршы яшеренү урыны» типларын «яшеренү урыны» тибына үзгәртү буенча документлар әзерләүне оештыру бурычлары билгеләнде.

**36. Гражданнар күпләп була торган урыннарда һәм күпфатирлы йортларда, шул исәптән газлаштырылган йортларда иҗтимагый иминлекне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.**

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (алга таба – ТР буенча ЭЭМ), республиканың башка министрлыклары һәм ведомстволары белән хезмәттәшлек итеп, объектлар һәм территорияләрнең иминлеген тәэмин итү буенча эш алып бара, аларның террорчылыктан саклануына карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр күпләп була торган урыннарны һәм объектларны (территорияләрне) террорчылыктан саклауга карата таләпләрне, мондый урыннар һәм объектлар (территорияләр) иминлеге паспортлары формаларын раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары белән регламентлаштырыла.

Әлеге карар таләпләре нигезендә территориаль эчке эшләр органнары хезмәткәрләре объектлар һәм территорияләр иминлеге паспортларын категориягә бүлү, тикшерү һәм килештерү буенча ведомствоара комиссияләр составларына кертелә.

Муниципаль берәмлекләрнең терророрчылыкка каршы комиссияләре рәисләре тарафыннан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеге төзелде.

Үткәрелә торган комиссия тикшерүләре барышында кешеләр күпләп була торган урыннарның террорчылыктан сакланышында кайбер аеруча үзенчәлекле түбәндәгеләр кебек җитешсезлекләр булуы ачыклана: аларда физик саклау хезмәте булмау; гадәттән тыш хәл барлыкка килгәндә телдән хәбәр итү системасы булмау; видеокүзәтү камералары саны җитәрлек булмау, «күренми торган» зоналар булу.

Террорчылыктан саклану буенча ачыкланган җитешсезлекләр турында мәгълүмат аларның милекчеләре тарафыннан билгеләнгән срокларда җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрү өчен объектларны тикшерү актларында да, шулай ук аларның иминлек паспортларында да чагылдырыла.

Карарның таләпләре нигезендә кешеләр күпләп була торган урыннарның террорчылыктан сакланышын тәэмин итү, шул исәптән саклау хезмәтен инженерлык-техник чаралар белән тәэмин итү чараларын тәгәлләү срогы комиссия тарафыннан террорчылык актларының потенциаль куркынычы һәм аларны кылу куркынычы дәрәҗәсеннән, тиешле бюджет акчасы һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән тиешле чараларны башкару чыгымнарының фараз күләмнәрен исәпкә алып билгеләнә, шул ук вакытта әлеге срок кешеләр күпләп булу урынын тикшерү актына кул куйган һәм аны категорияләргә бүлгән көннән алып ике елдан да артмаска тиеш.

Гражданнар күпләп була торган урыннарда һәм күпфатирлы йортларда җәмәгатьчелек иминлеген арттыру максатларында, ТР буенча ЭЭМ, кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар белән берлектә, «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексының (алга таба – «Имин шәһәр» АПК) хокук саклау сегментын алга таба да үстерү буенча, беренче чиратта, аларны видеокүзәтү системалары белән җиһазлау өлешендә эш дәвам итә.

2025 елның 20 февраленә карата республикада 102 126 видеокамера урнаштырылды һәм эшли, шул исәптән:

- 41 641 видеокамера – күпфатирлы торак йортларда;
- 8 710 видеокамера – җәмәгать урыннарында һәм урамнарда;
- 51 775 видеокамера – чит оешмалар объектларында.

ТР буенча ЭЭМ хезмәткәрләре 6 455 видеокүзәтү камерасыннан файдалану мөмкинлеге тәэмин ителде (җәмәгать урыннары – 2 313, күпфатирлы йортлар – 3 716). Йорт янындагы территорияләрендәге камераларның архив видеоязмаларын карау интернет аша территориаль эчке эшләр органнарының барлык кизү частьләрендә оештырылды.

Урамнарда һәм җәмәгать урыннарында урнаштырылган видеокүзәтү камераларын онлайн карауны һәм видеоархивларны файдалану мөмкинлеге республика эчке эшләр органнарының 45 кизү частендә Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы һәм элемтә операторы операторы арасында ел саен төзелә торган

сервис контрактлары кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән оештырыла.

2024 елда ТР буенча ЭЭМ тарафыннан, элемтә операторлары белән хезмәттәшлек итеп, «Имин шәһәр» АПКның 1 мең видеокүзәтү камерасын, шулардан 593 камера Казан шәһәрендә һәм 407 камера республиканың башка зур шәһәрләрендә (Чаллы шәһәре – 154, Түбән Кама шәһәре – 116, Бөгелмә шәһәре – 37, Алабуга шәһәре – 32, Чистай шәһәре – 27, Зеленодольск шәһәре – 25, Лениногорск шәһәре – 16) урнаштыру оештырлды.

2024 елда, «Имин шәһәр» АПКның һәм башка оешмаларның видеокүзәтү системаларын файдаланып, 158 җинаять ачылды, 445 административ хокук бозу туктатылды.

**37. Татарстан Республикасында миграция сәясәте өлкәсендә, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын яклау өлешендә күрелә торган чаралар турында.**

2024 елда ТР буенча ЭЭМнең миграция мәсьәләләре бүлекчәләре тарафыннан чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны миграция исәбенә кую турында 438 914 хәбәрнамә (2023 елда – 408 482) хәбәрнамә кабул ителде.

2024 елда төп миграция агымнары түбәндәге гражданнар тарафыннан булдырылды:

- Үзбәкстан (159 195 кеше, яки 37,3 %);
- Таҗикстан (61 629 кеше, ягъни 14,5 %);
- Төрекмәнстан (45 402 кеше, яки 10,6 %);
- Казахстан (26 392 кеше, яки 6,2 %);
- Кытай (24 536 кеше, яки 5,8 %);
- Кыргызстан (18 932 кеше, яки 4,4 %).

2025 елның 1 гыйнварына карата республика территориясендә 103 339 чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган затлар фактта булды, шул исәптән килү урыны буенча гамәлдәге миграция исәбенә алынган 81 538 кеше, яшәү төре нигезендә яшәүче 16 570 кеше, вакытлыча яшәү өчен рөхсәтнамә нигезендә 5 231 кеше.

Чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның легаль булмаган миграциясенә һәм законсыз хезмәт эшчәнлегенә каршы тору максаты белән ТР буенча ЭЭМ хезмәткәрләре тарафыннан миграция законнарын бозу фактларын ачыклау һәм кисәтү буенча эш оештырылды. Чит ил гражданнарының 10 248 яшәү (тору) урыны, 548 төзелеш объекты, 551 сәүдә объекты, 145 авыл хуҗалыгы предприятиесе, 103 көнкүреш хезмәте күрсәтү объекты, 25 сәнәгать предприятиесе, 427 башка объект тикшерелде.

Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 18 бүлеге («Россия Федерациясенең дәүләт чикләрен саклау һәм Россия Федерациясе территориясендә чит ил гражданнарының яки гражданлыгы булмаган затларның булу режимын тәэмин итү өлкәсендә административ хокук бозулар») буенча 22 277 миграция законнарын бозулар ачыкланды. 114,4 млн сумлык гомуми суммага штраф салынды.

Булу режимын һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә катнашу шартларын катгый бозган өчен 4 146 чит ил гражданына карата Россия Федерациясеннән административ тәртиптә чыгарып җибәрү турында суд карарлары кабул ителде, шулардан 788е – Россия Федерациясеннән үз-үзен контрольдә тотып чыгып китү, 3 358е – Чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәгенә урнаштыру формасында. 2025 елның 1 гыйнварына карата чыгарып җибәрү турында 3 594 карар үтәлде, шулардан 604 карар – үз-үзен контрольдә тотып чыгып китү формасында; Чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәгенә мәҗбүри урнаштырылган 2 990 чит ил гражданы чыгып китте.

Россия Федерациясенә чит ил гражданнарына керүне ябу турында 5 370 гариза җибәрелде. Чит ил гражданнарын депортацияләү турында 89 карар кабул ителде.

Вакытлыча яшәү өчен 182 рөхсәт, 416 яшәү төренә, эшләү өчен 15 рөхсәт, 2 005 патент юкка чыгарылды. 2024 елда Россия Федерациясе территориясендә чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның булу вакытын кыскарту турында 1 746 карар кабул ителде.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр даирәсендәге вәзгыять тотрыклы булуы белән характерлана. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан кылынган җинаятьләр Татарстан Республикасы территориясендә оператив хәлнең торышына сизелерлек йогынты ясамый. 2024 елда әлеге затлар тарафыннан кылынган 660 җинаять тикшерелде, шул исәптән: 198 урлау, наркотикларның законсыз әйләнешенә бәйле 122 җинаять, 61 ялган документ ясау факты, 49 караклык, 26 ришвәтчелек факты, миграция өлкәсендә 35 җинаять, җенси кагылгысызлыкка каршы 12 җинаять, сәламәтлеккә аңлы рәвештә уртача авырлыкта һәм җиңелчә зыян салу буенча 20 җинаять, сәламәтлеккә аңлы рәвештә авыр зыян салу буенча 8 җинаять, 6 үтерү, 7 талау, 1ешәр кеше талау һәм урлау факты буенча җинаять.

Чит ил гражданнарына карата 435 җинаять, шул исәптән 160 караклык, 167 урлау, 6 талау, 5 талау кылынды.

ТР буенча ЭЭМ тарафыннан үткәрелгән профилактик чаралар белән көнкүреш низагларның милләтара яссылык өлкәсенә күчүен һәм хәлнең катлауланмавын будырмаска ярдәм итте. Чит ил гражданнары катнашында кылынган барлык вакыйгалар буенча анда катнашучыларны билгеләү, хокук бозган затларны җаваплылыкка тарту буенча үз вакытында чаралар күрелә.

Татарстан Республикасы территориясендә этносара һәм милләтара низагларны булдырмау буенча превентив чаралар күрү кысаларында ТР буенча ЭЭМ тарафыннан республика башкарма хакимият органнары, иҗтимагый һәм дини оешмалар, мәгариф һәм фәнни учреждениеләр белән хезмәттәшлек оештырылды. Татарстан халыклары ассамблеясе белән берлектә, милли диаспораларның агымдагы һәм проблемалы мәсьәләләрен карап тикшерү буенча түгәрәк өстәлләр даими рәвештә уздырыла, анда Татарстан Республикасы прокуратурасы, Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, милли иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре һәм Татарстан халыклары ассамблеясенең яшь активистлары катнаша.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән үзара хезмәттәшлек итеп, республиканың югары белем бирү мәгариф оешмаларында

профилактик чаралар даими нигездә гамәлгә ашырыла, чит ил студентлары белән очрашулар оештырыла, алар кысаларында белем алучыларга Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезләмәләре җиткерелә. Террорчылык эшчәнлегенә булышлык иткән һәм анда катнашкан, социаль, раса, милли һәм дини ызгыш уяткан, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләрен дискредитацияләүгә, Россия Федерациясенең конституцион төзелешенә зыян китерүгә юнәлдерелгән гамәлләр өчен җаваплылык аңлатыла.

Татарстан Республикасының хезмәт базарын җайга салу максатларында, «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 18.1 статьясындагы 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Рәисенең «2025 елда Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектлары тарафыннан икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре буенча патент нигезендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы чит ил гражданнарын җәлеп итүгә тыю билгеләү турында» 2025 елның 29 гыйнварындагы 57 номерлы Указы кабул ителде (2025 елда куркыныч йөкләр ташу, таксида, саклау хезмәтләрендә эшләү, финанс хезмәтләре, иминият, бухгалтерлык исәбе, ветеринария, компьютерларны ремонтлау һ.б.ш. өлкәләрдә чит ил гражданнарын җәлеп итүгә тыю билгеләнде).

Бүген килүчеләрне социаль-мәдәни җайлаштыру мәсьәләләре аеруча актуаль. Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы билгеләгән алымнарны исәпкә алып, 2024 елдан түбәндәгеләр өчен шартлар тудыру буенча эш оештырылды:

- чит ил гражданнарының Россия җәмгыятендә яңа тормыш шартларына һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләргә конструктив җайлашуы;
- кабул итүче халык белән низаг чыгу куркынычын киметү.

2024 ел йомгаклары буенча социомәдәни юнәлештәге чараларга 30 652 кеше җәлеп ителде, шул исәптән түбәндәге категорияләр буенча:

- хезмәт мигрантлары – 9 709 кеше;
- чит ил студентлары – 17 227 кеше;
- балигъ булмаган чит ил гражданнары – 3166 кеше;
- чит ил гражданнарының башка категорияләре – 550 кеше.

Хәзерге вакытта Милләтләр эшләре федераль агентлыгы белән берлектә гамәлгә ашырыла торган пилот проекты кысаларында чит ил гражданнарының социаль һәм мәдәни адаптациясе үзәген булдыру эше алып барыла.

Татарстан Республикасында дәүләт миграция сәясәтен гамәлгә ашыруга бәйле Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын бозу очраклары теркәлмәде. Республика җитәкчелеге, шулай ук Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 2024 елда мөрәҗәгатьләр кермәде.

Шул ук вакытта бүгенге көндә өстенлекле бурыч булып Россия Федерациясе гражданнарын эш белән тәэмин итүгә җәлеп итү тора. Республика предприятиеләре бу юнәлештә актив эшлиләр.

2024 елда оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләрендә генә дә 29,8 мең вакансия биләнде. Республика предприятиеләре шулай ук Россиянең башка төбәкләреннән хезмәт ресурсларын җәлеп итү инструментларын актив кулланалар.

Оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре өчен «Мобильность 2.0» субсидияләнгән яллау программасы нигезендә эшкә урнаштырылган һәр граждан өчен эш бирүчегә федераль бюджет акчасы исәбеннән 300 мең сумга кадәр акча

каралды. Шушы программа буенча гына да 57 гаилә, республикага күченеп, эшкә урнаштырылды.

Өлкән халыкны әзерләү һәм яңадан укыту программалары актив тормышка ашырыла. Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы ярдәмендә 2024 елда илкүләм проектлар кысаларында Татарстан Республикасының 5,0 меңнән артык гражданы яңа һөнәрләр буенча белем алды, бу план күрсәткечләреннән бер ярым тапкырга диярлек артты, белем алучыларның 85 проценттан артыгы эшкә урнаштырылды.

**38. Татарстан Республикасында мәгариф оешмаларында балаларның иминлеген тәэмин итү һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозулар санын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.**

Хәзерге вакытта Татарстан территориясендә 3 515 мәгариф оешмасы эшли, шулардан 1 660 – мәктәпкәчә белем бирү, 1 569 – гомуми белем бирү, 132 – һөнәри белем бирү, 154 – югары белем бирү оешмасы.

3 515 белем бирү оешмасыннан Росгвардиянең үзәктән саклау пунктына тоташтырылган тревога сигнализациясе кнопкалары белән 3 373 гомуми белем бирү (1 631 – мәктәпкәчә, 1 554 – гомуми белем бирү, 122 – һөнәри, 66 – югары белем бирү) оешмасы җиһазландырылган, хосусый саклау оешмаларының үзәктән саклау пунктына тоташтырылган тревога сигнализациясе кнопкалары 84 белем бирү оешмасында (барлык югары белем бирү мәгариф оешмалары) бар. Металл эзләү җайланмалары белән 2 829 мәгариф (1 267 – мәктәпкәчә, 1 316 – гомуми белем бирү, 121 – һөнәри, 125 – югары белем бирү) оешмалары җиһазланган, каравыл хезмәте белән 3 370 мәгариф (1 660 – мәктәпкәчә, 1 569 – гомуми белем бирү, 132 – һөнәри, 9 – югары белем бирү) оешмасы тәэмин ителгән, хосусый саклау оешмалары хезмәткәрләре белән 1 867 мәгариф (903 – мәктәпкәчә, 724 – гомуми белем бирү, 103 – һөнәри, 137 – югары белем бирү) оешмасы саклана.

2024 елда республикада балигъ булмаганнар тарафыннан яисә алар катнашында кылынган 784 җинаять тикшерелде. Җинаятьләр кылуда барлыгы 501 балигъ булмаган зат катнашты, шулардан 49ы – исерек хәлдә булды, 30ы – элек хөкем ителгәннәр, 233е – мәктәп укучылары. Әлеге категория затлары тарафыннан наркотик исерек хәлендә җинаятьләр кылу фактлары теркәлмәде.

2024 елда яшүсмерләр катнашында хокук бозуларны кисәтү һәм булдырмау буенча гомуми һәм шәхси характердагы профилактик чаралар кысаларында 248 иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган 307 балигъ булмаган бала ачыкланды. Балигъ булмаган хокук бозучылар өчен вакытлыча тоту үзәгенә ТР ЭЭМ тарафыннан 196 хокук бозучы яшүсмер урнаштырылды, ябык типтагы махсус уку йортларына 20 балигъ булмаган бала җибәрелде.

3 042 балигъ булмаган хокук бозучы һәм 2 733 имин булмаган гаилә профилактик исәпкә куелды. 2025 елның 20 февраленә карата республика эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләрендә 2 283 балигъ булмаган хокук бозучы һәм 3 531 имин булмаган гаилә исәпкә алынды.

2024 елда административ хокук бозулар кылган өчен – 1 105, шул исәптән алкоголь эчемлекләр һәм сыра эчкән, җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган өчен – 788, наркотикларны законсыз әйләнештә йөртү өлкәсендә хокук бозган өчен

108 балигъ булмаган бала җаваплылыкка тартылды.

Яшүсмерләр мохитендә алкоголизмны таратуны киметү максатларында полиция хезмәткәрләре тарафыннан балигъ булмаганнарга спиртлы эчемлекләр сатуны гамәлгә ашыручы сатучыны җаваплылыкка тарту буенча эш алып бара.

Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 14.16 статьясындагы 2.1 өлешендә («Балигъ булмаган балага алкогольле продукцияне ваклап сату») каралган 154 административ хокук бозу кисәтелде. РФ Җинаять кодексының 151.1 статьясы («Балигъ булмаган балага алкогольле продукцияне ваклап сату») буенча квалификациягә бүленгән 10 җинаять тикшерелде.

Республиканың гомуми белем бирү, югары һәм урта-махсус уку йортлары укучылары арасында террорчылык һәм экстремистик идеология таралуны булдырмау буенча хезмәттәшлекне оештыру максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән үзара хезмәттәшлек җайга салынды. Террорчылык һәм экстремистик идеология йогынтысына дучар булган укучылар һәм аларның ата-аналары турында мәгълүмат алмашу мәсьәләләре җентекләп тикшерелде.

Ведомстволар арасында деструктив тәртипкә тартылган балигъ булмаганнар турында мәгълүмат алышканда оператив эш итү өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы арасында мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды.

**39. Татарстан Республикасында юл-транспорт һәлакәтләрен һәм юлларда үлүчеләр санын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.**

2024 елда Татарстан Республикасы территориясендә 3 258 юл-транспорт һәлакәте (алга таба – юл-транспорт һәлакәте) теркәлгән, аларда 3 991 кеше яраланган һәм 320 кеше һәлак булган.

Гомуми файдаланудагы федераль автомобиль юлларында, торак пунктлар территориясе аша узучы участокларны да кертеп, 487 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, аларда 124 кеше үлгән һәм 646 кеше җәрәхәтләнгән; төбәк һәм муниципальара юлларда 538 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, аларда 118 кеше үлгән һәм 757 кеше җәрәхәтләнгән; җирле әһәмияттәге юлларда – 2 233 юл-транспорт һәлакәте, аларда 78 кеше һәлак булган һәм 2 588 кеше яраланган.

Шәһәр һәм торак пунктлар территориясендә 2 656 юл-транспорт һәлакәте кылынган, аларда 121 кеше һәлак булды һәм 3 178 кеше яраланган; шәһәр һәм торак пунктлардан читтә – 602 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 199 кеше һәлак булган һәм 813 кеше җәрәхәтләнгән.

Хисап чорында авария хәленә йогынты ясаучылар, элеккеге кебек үк, транспорт чараларын йөртүчеләр, алар гаебе белән 2 983 юл-транспорт һәлакәте булган (гомуми саннан 91,6 %) аларда 296 кеше үлгән һәм 3 736 кеше яраланган. Юл-транспорт һәлакәте анализы күрсәтте:

- юл чатларын үтү кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә 587 юл-транспорт һәлакәте (19,7%) булды;
- билгеләнгән тизлек режимын бозу яисә, юл һәм метеорология шартларын исәпкә алып, хәрәкәтнең хәвефсез тизлеген дөрес сайламау нәтиҗәсендә – 535 юл-транспорт һәлакәте (17,9 %);
- җәяүлеләр кичүе кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә – 386 юл-транспорт һәлакәте (12,9 %);

- урап узу һәм каршы хәрәкәт полосасына чыгу кагыйдәләрен бозу сәбәпле – 305 юл-транспорт һәлакәте (10,2 %);

- исерек хәлдә автотранспорт белән идарә иткән транспорт чаралары йөртүчеләр гаебе белән – 222 юл-транспорт һәлакәте (7,4 %);

- транспорт чарасы белән идарә итү хокукына ия булмаганнар гаебе белән – 182 юл-транспорт һәлакәте (6,1 %);

- автобус йөртүчеләр гаебе белән – 97 юл-транспорт һәлакәте (3,3 %);

- Россия Федерациясенең башка субъектларында яшәүчеләр булган машина йөртүчеләр гаебе белән – 188 юл-транспорт һәлакәте (6,3 %).

Җәяүлеләр кичүендә 408 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 14 җәяүле һәлак булган һәм 420 җәяүле төрле тән җәрәхәтләре алган; тимер юл аша чыгу урыннарында – 5 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 2 кеше үлгән һәм 7 кеше җәрәхәтләнгән. Җәяүлеләр гаебе белән 317 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 44 җәяүле үлгән һәм 286 кеше җәрәхәтләнгән.

Балигъ булмаган затлар катнашында 432 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, шуларда 11 бала үлгән һәм 463 бала төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган, шул ук вакытта 162 юл-транспорт һәлакәтендә (37,5%) балалар автотранспорт чаралары пассажирлары булган, аларның 3 һәлак булган, 184 – җәрәхәтләр алган.

2024 елда Татарстанда юл хәрәкәте өлкәсендә нормаларны һәм кагыйдәләрне бозуның 9,1 млн очрагы ачыкланган, аларның күбесе (8,8 млн бозу яки 93,8%) автоматик фото һәм видеофиксация комплекслары белән теркәлгән.

Юл-транспорт һәлакәте һәм юлларда үлүчеләр санын киметү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссиясенең максатчан эше нәтиҗәле чараларның берсе булып тора. Аның утырышларында министрлыклар һәм ведомстволар тарафыннан алдагы чорга профилактик чаралар, шулай ук хәлнең катлаулануына җавап бирү буенча тиешле чаралар күрелә.

Киләсе мөһим чара – Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотовидеофиксацияләү системаларын алга таба үстерү, транспорт агымнарын аеру, юл-транспорт һәлакәтләре концентрацияләнгән урыннарны, юлларның потенциаль куркыныч участокларын бетерү һәм аерым юл-транспорт һәлакәтләре булган участокларны эшкәртү.

Хәзерге вакытта юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокук бозуларны автоматлаштырылган теркәүнең республика системасы автомат режимда эшләүче 925 фото- һәм видеофиксация комплексыннан тора (737 стационар, 171 күчмә һәм 17 мобиль), шулардан:

- федераль әһәмияттәге автомобиль юлларында 166 участокта стационар комплекслар урнаштырылган, 78 участокта күчмә комплекслар эшли;

- төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында 170 участокта стационар комплекслар урнаштырылган, 230 участокта күчмә комплекслар эшли;

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында 402 участокта стационар комплекслар урнаштырылган, 56 участокта күчмә комплекслар эшли.

2024 елда тизлек режимын бозу очракларын гына түгел, башка төрләрне дә (каршы хәрәкәт полосасына чыгу, хәвефсезлек каешын куллану кагыйдәләрен бозу һ.б.) ачыклау техник мөмкинлеге булган 62 стационар фото- һәм видеофиксация

комплексы файдалануга тапшырылды.

Юл-транспорт травматизмы дәрәҗәсен киметү, авария куркынычы булган участокларның санын кыскарту максатларында республикада юл-транспорт һәлакәтләре тупланган урыннарында гына түгел, ә тулаем алганда аларның барлыкка килүен профилактикалау өчен урам-юл челтәрендә инженерлык чараларын үтәүне үз эченә алган чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.

2024 елда республиканың автомобиль юлларында 137 авария куркынычы булган участок ачыкланган, шул исәптән:

- юл-транспорт һәлакәте тупланунын 49 урыны;
- 26 потенциаль куркыныч участок;
- 26 «авария зоналары»;
- авыр нәтиҗәләр белән юл-транспорт һәлакәтләре булган 36 участок.

Мондый авария участокларының һәркайсына тиешле инженерлык чаралары эшләнде һәм гамәлгә ашырылган: светофор объектлары, куркынычсызлык киртәләре, электр уты, юл билгеләре куелган, юл тамгалары ясалган, ясалма тигезсезлекләр урнаштырылган һ.б.

**40. Татарстан Республикасында, шул исәптән Казан шәһәрендә гражданнарны, шулай ук аларның берләшмәләрен җәмәгать тәртибен саклауда катнашуга җәлеп итү буенча күрелә торган чаралар турында.**

ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы республика муниципаль берәмлекләренең ирекле халык дружиналары штаблары (алга таба – ИХД) белән үзара хезмәттәшлектә җәмәгать тәртибен саклауга һәм халыкның киң катламнарының иҗтимагый иминлеген тәэмин итүгә җәлеп итү буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.

2025 елның 1 гыйнварына федераль һәм республика законнары таләпләре нигезендә гомуми саны 19 764 кешедән торган 1 433 ИХД эшли һәм республика реестрына кертелгән. Казан шәһәрендә гомуми саны 1 692 кеше булган 267 отряд төзелгән һәм эшли.

Халык дружиначыларының барысы да аларның иҗтимагый тәртипне саклау чараларында катнашу чорына иминиятләштерелгән.

Җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыруда актив катнашкан өчен дружиначыларны матди кызыксындыру буенча оештыру чаралары күрелә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» республика премияләре турында» 2015 ел, 17 август, 603 нче карары белән «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» республика премияләре турында нигезләмә расланды (3 категория каралды: 30 премия – 5ешәр мең сум, 10 премия – 20шәр мең сум, 3 премия – 50шәр мең сум).

Өстәмә матди кызыксындыру чараларын кабул итү максатларында, республика муниципаль берәмлекләрендә шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен халык дружиначыларына премия бирү турында нигезләмәләр эшләнгән, алар муниципаль берәмлекләр башлыклары карарлары белән расланды. Әлеге эшчәнлекне финанслау чаралары хокук бозуларны профилактикалауның муниципаль программаларына кертелде.

Халык дружиналары әгъзаларын җәлеп итү эше офицерлар патрульләре составындагы участок вәкаләтле полицияләре һәм тышкы хезмәтләр нарядлары белән бергә тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары базасында оештырылды.

Халык дружиначылары вәкилләре гавами, иҗтимагый-сәяси, дини, мәдәни-тамаша һәм спорт чараларын үткәргәндә хокук тәртибен тәэмин итүдә катнаша.

Муниципаль берәмлекләр башлыклары тарафыннан квартал саен дружиначыларның чыгу графиклары раслана, алар территориаль эчке эшләр органнары башлыклары белән килештерелә, дружиначыларның хокук тәртибен саклауга чыгуларын исәпкә алу буенча тиешле журналлар алып барыла, халык дружиначыларын әзерләү, шул исәптән физик көч куллануга бәйле шартларда гамәлләр кылуга әзерләү һәм беренче ярдәм күрсәтү буенча инструктажлар оештырылды.

2024 елда халык дружиначылары катнашында 152 җинаять ачыкланган, 1 502 административ хокук бозу кисәтелгән.

## Авыл хуҗалыгы, экология

**41. Авыл җирлегендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларга дәүләт ярдәмен киңәйтү турында.**

«Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә республикада шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары гамәлгә ашырыла.

2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан 43 857 шәхси ярдәмче хуҗалыкка 446,9 млн сумлык ярдәм күрсәтелгән, шул исәптән:

- 1 яшьтән зуррак сыерлар, ана кәҗәләр һәм кәҗәләр асрауга – 33 517 шәхси ярдәмче хуҗалыкка 302,4 млн сумлык;
- сөтчелек юнәлешендә кече фермалар төзүгә – 77 шәхси ярдәмче хуҗалыкка 35,7 млн сумлык;
- 3 яшьтән өлкәнрәк бияләрне тотуга – 1 823 шәхси ярдәмче хуҗалыкка 26 млн сумлык;
- товар өчен һәм нәселле таналар һәм беренче бозаулаган сыерлар сатып алуга – 35 шәхси ярдәмче хуҗалыкка 5,8 млн сумлык;
- яшь кош-корт сатып алуга – 8 405 шәхси ярдәмче хуҗалыкка 77 млн сумлык.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов тарафыннан 2025 елда шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында карар кабул ителде. Шулай итеп, савым сыерлары көтүен тотуга ставкалар 2,3 мең сумнан 4,3 мең сумга кадәр арттырылган, бер сыерга бердәм ставка 6,3 мең сумга кадәр арттырылган, 1 яшьтән зуррак булган ана кәҗәләр һәм кәҗәләр тотуга субсидия 0,5 меңнән 1,0 мең сумга кадәр арттырылган. 2025 елда савым сыерларын тотуга субсидиянең гомуми суммасы 534,5 млн сумга кадәр артты (элек Татарстан Республикасы бюджетында 350 млн сум каралган иде).

2025 елдан сөтчелек юнәлешендә кече фермалар төзүгә субсидияләр 8 сыердан башлап кече фермага 600 мең сумнан 1 млн сумга кадәр, 5 сыердан башлап кече фермага 300 мең сумнан 500 мең сумга кадәр (2024 елга карата) арта.

Товар өчен һәм нәселле таналар һәм беренче бозаулаган сыерлар сатып алуга субсидия ставкалары 20 мең сумга, димәк, 80 – 90 мең сумга кадәр (2024 елга

карата) арттырылган. Шулай ук бер мәртәбә сыерлар сатып алуга чикләүләр бетерелде, сатып алына торган таналарның һәм беренче бозаулаган сыерларның чик күләме 5 баштан 15 башка кадәр артты.

**42. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү буенча республикада башкарыла торган эш турында.**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карарыбелән расланган «Әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасының (алга таба – Программа) «Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2021-2024 елларда Татарстан Республикасының 43 муниципаль районында су җыю скважиналарын ревизияләү эшләре башкарылды:

- 2021 елда – Апас һәм Кайбыч муниципаль районнарында;
- 2022 елда – Арча, Әтнә, Балтач, Югары Ослан, Биектау, Зеленодольск, Кукмара, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Теләче муниципаль районнарында;
- 2023 елда – Менделеевск, Минзәлә, Түбән Кама, Алабуга, Тукай, Сарман, Актаныш, Мөслим, Мамадыш, Ютазы, Әгерже, Баулы, Азнакай, Бөгелмә, Лениногорск муниципаль районнарында;
- 2024 елда – Аксубай, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Буа, Чүпрәле, Зәй, Кама Тамагы, Яңа Чишмә, Нурлат, Спас, Тәтеш, Чирмешән, Чистай муниципаль районнарында.

Ревизия кысаларында 4 033 су пункты (3 546 скважина һәм 487 чишмә) тикшерелде, 2 803 су пробасы алынды. Эшләр авыл торак пунктларының эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганаклары белән тәэмин ителешен бәяләүдән, су җыю җайланмаларының техник торышын бәяләүдән, санитар яклау зоналарының беренче поясы чикләрендә санитар хәлне билгеләүдән, уртача тәүлеклек су сайлап алудан һәм суга ихтыяждан, су җыю җайланмаларының гамәлдәге техник документациясен туплаудан гыйбарәт. Ревизия эшләре тәмамланды.

Шулай ук Программаны гамәлгә ашыру кысаларында 2024 елда торак пунктларны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларын нигезләү өчен җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатында җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләре башкарылды:

- Биектау муниципаль районының Каймар торак пункты (Каймар чыганагындагы эчә торган җир асты суларының баланс запаслары С1 категориясе буенча 470 куб.м/тәүл.);
- Биектау муниципаль районының Ключище, Никольский торак пункты (Көнбатыш Ключище чыганагындагы эчә торган җир асты суларының баланс запаслары С1 категориясе буенча 100 куб.м/тәүл.);
- Биектау муниципаль районының «Белая Аллея» торак массивы (Көнбатыш Чабакса һәм Чабакса Акы чыганакларының җир асты сулары запаслары эчәргә яраклы, хуҗалык-көнкүреш һәм техник су белән тәэмин итү өчен гомумән алганда С1 категориясе буенча 3 мең куб.м/тәүл. расланган).

Су җыю җайланмаларының ревизия бәяләмәсе һәм җир асты суларын эзләү эшләре 2024 елда «Татарстан Республикасының геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан үтәлде.

Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатларында Программа кысаларында 2024 елда 159,44 км суүткәргеч челтәр төзелгән һәм реконструкцияләнгән, 22 артезиан скважинасы бораулангaн, 1 217,3 млн сумлык 26 су җыю башнясы урнаштырылган.

**43. Эре сәнәгать шәһәрләрендә атмосфера һавасының сыйфатын яхшыртуга һәм кеше сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны булдырмауга юнәлдерелгән чаралар турында.**

2024 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында атмосфера һавасының сыйфатын яхшырту һәм кеше сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны булдырмау чараларына 38,9 млн сум юнәлтелгән, 2025 елга план – 95,0 млн сум.

Казан шәһәренең Авиатөзелеш, Киров, Мәскәү районнары һәм Зеленодольск муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан атмосфера һавасының пычрануын контрольдә тотуның өч автоматлаштырылган станциясе һәм ике күчмә экологик лаборатория ярдәмендә атмосфера һавасының сыйфатын мониторинглау һәм тикшереп тору оештырылды.

2023 елдан 2024 елга кадәр әлеге станцияләрдә күкерт водороды, формальдегид, азот диоксиды, углерод оксиды һәм PM10 үлчәнгән кисәкчекләренең рөхсәт ителгән концентрациясенең артуы теркәлгән. Артулар турында мәгълүмат Казан шәһәрендә атмосфера һавасының сыйфатын тәэмин итү мәсьәләләре буенча төзелгән ведомствоара эш төркеме кысаларында сәбәпләрен ачыклау һәм чаралар күрү өчен Ростабигатькүзәтчелегенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә һәм Ростабигатькүзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

Гражданнарның күп тапкыр мөрәҗәгате уңаеннан һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы инициативасы белән, шул исәптән калдыкларны урнаштыру лимитлары юкка чыгу сәбәпле, 2024 елның 26 декабрендә Химик урамы буенча полигон ябылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә һәм Татарстан Республикасы Лаеш, Питрәч, Биектау һәм Зеленодольск муниципаль районнарының «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләреннән 3 км ераклыкта урнашкан территорияләрендә атмосфера һавасына антропоген йөкләнешне киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2024 ел, 9 декабрь, 1116 нчы карары белән проектлана торган объектның атмосфера һавасына йогынтысын тулысынча анализлаганнан соң гына әлеге территориядә башка объектлар белән берлектә яңа производстволар төзү яисә гамәлдәге производстволарны киңәйтү мөмкин булачак чаралар билгеләнде.

Россиянең иң эре сәнәгать төене буларак, Түбән Кама сәнәгать үзәгенә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү мәсьәләләренә, беренче чиратта, атмосфера һавасын саклау мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 16 март, 344-б номерлы боерыгы белән Түбән Кама сәнәгать төенен үстергәндә экологик

иминлекне тәэмин итү буенча ведомствоара эшче төркем төзелде;

- Россия Федерациясе Баш санитар табибының 2019 елның 19 сентябрендәге 193-РСЗЗ номерлы карары белән Түбән Кама сәнәгать төене өчен Бердәм санитар-яклау зонасы билгеләнде. Түбән Кама шәһәре һәм аңа якын территорияләр өчен атмосфера һавасын пычратуның җыелма исәпләүләре системасы булдырылган.

Түбән Кама шәһәре һәм «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләреннән 3 км ераклыкта урнашкан Түбән Кама һәм Тукай муниципаль районнары территорияләрендә яңа производстволар булдыруның яисә гамәлдәге производстволарны киңәйтүнең мөмкин булуына анализ Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территорияләрендә атмосфера һавасына антропоген йөкләнешне киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2024 ел, 07 август, 126 нчы карары белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны киметү буенча зур эш сәнәгать предприятиеләре тарафыннан башкарыла. Табигатьне саклау чаралары планнарын үтәү кысаларында предприятиеләр производстволарны модернизацияләүне, искергән җиһазларны алыштыруны, тузан газ чистарту системаларын урнаштыруны һәм башка һава саклау чараларын гамәлгә ашыра.

«СИБУР» ҖЧҖ Түбән Кама шәһәрендә юк итәргә яки яңадан эшләргә мөмкин булмаган сәнәгать калдыкларын күмәргә каралган сәнәгать полигонын масштаблы реконструкцияләү тәмамланды. Проектның төп максаты - әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны киметү һәм полигонны файдалы эксплуатацияләү вакытын арттыру.

«Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ территориясендә 285 бина һәм корылма демонтажланган, 74 мең тонна металл һәм 400 мең куб.метр бетон чыгарылган. Ике ел эчендә предприятие территориясендә яңа заводлар төзү өчен мәйданнар бушатылды, предприятиенең экологик булуы, иминлеге һәм эстетик рәвеше яхшыртылды.

«Казаноргсинтез» ГАҖ:

- югары тыгызлыктагы полиэтилен җитештерү буенча өч линиянең берсен (реактор В) модернизацияләү тәмамланды. Инвестицияләр күләме 8 млрд сумнан артык булган проект, елына 8 мең тонна чамасы күләмдә углеводород газларын рекуперацияләү системасы исәбенә факель җайланмасына чыгарып ташлауларны киметү юлы белән, предприятиенең экологик нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк;

- продукциянең сыйфатын һәм предприятиенең экологик сыйфатын контрольдә тоту тизлеген арттырырга мөмкинлек бирә торган сыйфатны контрольдә тотуның бердәм үзәге булдырылды, шулай ук һава сыйфатын мониторинглау өчен SMP Robotics компаниясенең үзебезнең технологияләр базасында 9 критерий буенча һаваның торышын күзәтеп торучы экобот кертелде;

- пиролиз, полиэтилен һәм энергия җитештерү заводларында планлы тукталыш ремонтының икенче этабы тәмамланды. Цифрлы тукталыш ремонты ремонтның критик этапларында интеллектуаль видеоконтроль кертү һәм авыр үтеп керә торган участокларда җиһаз кимчелекләрен ачыклау исәбенә җиһазларның ышанычлылыгын һәм җитештерүнең экологик булуын арттырды.

«Аммоний» АҖ AUS-32 дизель ягулыгына өстәмә базасындагы AUS-40 яңа

продукт эшләп чыгарды һәм сертификацияләнде, ул диңгез судноларының дизель двигательләре, электр станцияләре, котель җайланмалары, цемент һәм пыяла заводлары, калдыкларны яндыру җайланмалары һәм башка җиһазларның чыгарып ташлауларын киметергә мөмкинлек бирә.

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ:

- Алабуга шәһәрендә сыгылмалы композит торбалар җитештерү заводын эшләтеп җибәрде (продукт шулай ук катлаулы климат һәм ландшафт шартларында актуаль булачак), шулай ук сорбцион-фильтр җайланмасы кулланып, чыгарыла торган суны чистарту технологиясен гамәлгә кертте;

- Түбән Кама шәһәрендә Түбән Кама ТЭЦында энергия җайланмасы һәм «ТАНЕКО» АҖендә метилдиэтаноламин регенерациясе җайланмасы эшләтеп җибәрелде, ул сероводород алу күләмен арттырырга гына түгел, «ТАНЕКО» АҖнең комплекстагы технологик процессларны күчерү исәбенә, шул исәптән планлы ремонт барышында өзлексез эшләвен тәэмин итәргә дә мөмкинлек бирә.

Уртак тырышлык нәтиҗәсендә статистика атмосферага чыгарып ташлауларның гомуми күләменең тотрыклы кимүен күрсәтә. 30 ел эчендә тулаем төбәк продукты чагыштырма бәяләрдә өч тапкыр артканда чыгарылмаларның кимүе 24,1 % тәшкил итә.

**44. Чүп-чар күләмен киметүгә юнәлдерелгән чаралар турында.**

Татарстан Республикасында 2024 елда 1 562,9 мең тонна каты коммуналь калдыклар барлыкка килгән, шулардан 412,1 мең тонна – эшкәртүгә, 183,7 мең тонна – утильләштерүгә; 1 268,9 мең тонна – җиргә күмүгә җибәрелгән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 19 декабрь, 1166 нчы карары белән Татарстан Республикасы калдыклары белән эш итү өлкәсендә актуальләштерелгән территориаль схема расланды, ул каты коммуналь калдыклар белән эш итү инфраструктурасының перспектив объектларын төзүне күз алдында тота: Лениногорск, Тукай, Питрәч, Югары Ослан муниципаль районнарында калдыкларны эшкәртү комплекслары, аларда эшкәртү, компостлау, күмү объектлары каралган.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү инфраструктурасы объектларын төзү Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы белән билгеләнгән «Экологик иминлек» илкүләм максаты күрсәткечләрен үтәүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- йомык цикл икътисадын формалаштырырга;

- ел саен барлыкка килә торган каты коммуналь калдыкларның бөтен күләмен 100% эшкәртүне тәэмин итәргә;

- каты коммуналь калдыкларны күмүне кимендә 50% киметергә;

- җитештерү һәм куллану калдыкларының кимендә 25 % икенчел ресурслар һәм чимал сыйфатында хуҗалык әйләнешенә кертергә.

б) Татарстанда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслар министрлыгы һәм Табигатьтән рациональ файдалану фонды арасында төзелгән электрон һәм электр җиһазлары калдыкларын аерып туплауны, җыюны һәм утильләштерүне оештырганда циркуляр икътисад принципларын кертүгә

юнәлдерелгән экология программаларын гамәлгә ашыруда үзара бәйләнеш турында килешү тормышка ашырыла. Килешү дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, ведомство буйсынуындагы оешмаларның электрон һәм электр җиһазлары калдыкларын түләүсез утильләштерү исәбенә бюджет акчаларын сизелерлек экономияләүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. Бүгенге көнгә бушлай утильләштерүгә оешмалардан 2 123 гариза теркәлгән, фактта 787 гариза гамәлгә ашырылган.

в) Татарстан Республикасында «Утильләштерү мәктәбе: электроника» программасын гамәлгә ашыру барышында физик затлардан электр ломын утильләштерүгә кабул итү гаризасы формасы булдырылды. 34 торак пункт территориясеннән 366 тоннадан артык электрон һәм электр җиһазлары калдыкларны утильләштерүгә чыгарылган. Халыктан электроника кабул итү эше дәвам итә.

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ чүп-чар күләмнәрен киметүгә юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыра:

- «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» ҖЧҖ каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы белән хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә Казан шәһәрендә ике шин монтажлау пунктында эшкәртелгән автомобиль шиннарын аерым туплау өчен контейнерлар урнаштырылган;
- 32 автоягулык салу станциясендә (Әлмәт, Зәй, Баулы, Лениногорск, Бөгелмә, Түбән Кама, Чаллы һәм Казан шәһәрләрендә) эшкәртелгән шиннарны халыктан кабул итү өчен стеллажлар һәм контейнерлар урнаштырылган;
- 2024 елда 24 200 тонна эшкәртелгән шин җыелган, чипска һәм резина валчыгына 22 134 тонна эшкәртелгән.

2024 елның 31 декабренә торышына I һәм II класстагы куркыныч калдыклар белән эш итүне исәпкә алу һәм контрольдә тоту федераль дәүләт системасында 2 015 кулланучы теркәлгән. Системадан файдаланучылар саны арту I һәм II класстагы куркыныч калдыкларны, шул исәптән каты коммуналь калдыклар составында физик затлар тарафыннан булдырыла торган калдыкларны икенчел әйләнешенә җәлеп итүгә ярдәм итә.

«Татарстан Республикасының экологик картасы» геомәгълүмат системасының мәгълүматлар базасына кертү өчен халык тарафыннан чыгарыла торган куллану калдыкларын аерым туплау һәм җыю пунктларының адреслы исемлеге төзелде (токның эшкәртелгән химик чыганаклары, терекөмеш булган лампалар һәм градусниклар, автомобиль шиннары һәм покрышкалар, кәгазь макулатура һәм катыргы, полимерлы төргәк, алюминий төргәк, яраклылык срогы узган дару препаратлары, электрон һәм электр җиһазлары калдыклары, куллануның текстиль калдыклары).

**45. Хайваннар белән җаваплы эш итү турындагы законнарны хуҗасыз агрессив хайваннар проблемасын хәл итү өлешендә үтәү барышы турында.**

Хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү өлкәсендәге мәсьәләләрне хокукый җайга салу «Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив

хокукый актлары, шулай ук алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары нигезендә башкарыла (алга таба – Тәртип).

Тәртипнең 5.1 пункты нигезендә элекке яшәү урынына, хайваннар приютында хуҗалары булмаган хайваннарга карата карантинда тоту, дәвалау, вакцинация, стерилизация (кастрация) ясау, тамга салу чаралары тәмамланганнан соң, әлеге мотивлаштырылмаган агрессивлыгын күрсәтми торган хайваннар кире кайтарылырга тиеш.

Хуҗалары булмаган хайваннарның мотивлаштырылмаган агрессивлыгы булуы йә булмавы турында карар (алга таба – карар) хайваннар приюты җитәкчесеннән һәм аның ике хезмәткәреннән торган комиссия тарафыннан кабул ителә. Комиссия карары ирекле формада язылган ветеринария бәяләмәсен төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

Республика территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар санын киметү максатларында 2024 елның 26 декабрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 11 август, 971 нче карары белән расланган йорт хайваннарын карап тотуга, шул исәптән аларны һавада йөртүгә өстәмә таләпләргә үзгәрешләр кертелде.

Кертелгән үзгәрешләр нигезендә 2025 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы территориясендә барлык этләр хуҗалары аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе карамагындагы дәүләт ветеринария учреждениеләрендә теркәргә тиеш.

Этләрне теркәү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- аларның тәненә уникаль цифрлы яисә хәрефле-цифрлы идентификация номерын үз эченә алган маркирлауның электрон чарасын кертү юлы белән маркирлау (эт хуҗасы хисабына башкарыла);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә буйсынучы дәүләт ветеринария учреждениеләре тарафыннан эт һәм аның хуҗасы турындагы белешмәләрне Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертү (түләүсез гамәлгә ашырыла).

2025 елның 28 мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан «Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителде, анда түбәндәгеләр каралган:

- Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексының 3 бүлегенә Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын карап тотуга өстәмә таләпләрне бозган өчен административ җаваплылык билгели торган 3.18 статья өстәргә;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария

идарәсенә Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексының 3.18 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүне һәм эшләр карауны беркетергә.

Административ җаваплылык гражданнарга, йорт хайваннары хуҗаларына, түбәндәге таләпләрне бозган өчен кисәтү яки 2-4 мең сум күләмендә административ штраф рәвешендә билгеләнә:

- күпфатирлы йортларның гомуми файдаланудагы урыннарында һәм аларның йорт яны территорияләрендә йорт хайваннарын асрау;

- эт хуҗасы тарафыннан этне мәҗбүри теркәүне гамәлгә ашырмау.

Закон кабул итү хайваннар белән эш итү өлкәсендә гамәлдәге хокукый җайга салуның нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк, бу хайваннарны яклау максатларына ирешүгә, хайваннар белән эш иткәндә гражданнарның хокукларын яклауга ярдәм итәчәк.

Шулай ук билгеләп үтәбез, «Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 8.52 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 ноябрендәге 440-ФЗ номерлы Федераль закон белән йорт хайваннарын тоту таләпләрен үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләнгән.

Күрсәтелгән таләпләр «Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 13 статьясында беркетелгән, алар шул исәптән, йорт хайванын һавада йөрткәндән хайваннарны йөртү өчен җирле үзидарә органы карары белән рөхсәт ителгән урыннардан читтә хайванның ирекле, контрольсез йөрү мөмкинлеген юкка чыгарырга кирәк. Шул ук вакытта потенциаль куркыныч этне йөртү урынына бәйсез рәвештә борынчыктан һәм бәйләүдән башка йөртү тыела, моңа әлеге эт милек хокукында яки башка законлы нигездәге потенциаль куркыныч эт хуҗасыныкы булган территориядә урнашкан киртәләнгән территориядә йөргән очраклар керми.

**46. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнешен камилләштерү, алардан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау, авыл хуҗалыгы җирләрен саклап калу, эрозия процессларын киметү һәм мелиорация комплексын үстерү буенча башкарыла торган эш турында.**

Татарстан Республикасы куркыныч игенчелек зонасында тора, шул сәбәпле, мелиорация комплексын үстерүгә зур игътибар бирелә. Соңгы елларда федераль һәм төбәк программалары кысаларында 471 гидротехник корылма ремонтланды, 37,2 мең гектардан артык сугарулы җир реконструкцияләнде, 250 км суүткәргеч сузылды, 230 данәдән артык сугару техникасы сатып алынды.

Республикада мелиорацияне үстерү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 14 маендагы 731 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне нәтиҗәле әйләнешкә кертү һәм мелиорация комплексын үстерү буенча дәүләт программасының ярдәмче программалары гамәлгә ашырыла:

- Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм «Приволжскмелиоводхоз» идарәсе» ФДБУ балансындагы федераль милектәге мелиорация объектларын реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау дәүләт программасы кысаларында федераль акчалар хисабына гамәлгә ашырыла. Әлеге

юнәлештә 2024 елда 2 048 гектар җир тапшырылган, шул исәптән Түбән Кама сугару системасының Сухарево участогын, Мамадыш муниципаль районының «Бишьеллык» сугару системасын, Азнакай муниципаль районының Тумутук сугару системасын реконструкцияләү исәбенә – 1 418 гектар, капиталь ремонт хисабына – 1 010 гектар. Финанслау суммасы 529,6 млн сум тәшкил итте, проект-тикшерү эшләрен дә кертеп;

- 2019 елдан 2024 елга кадәр республика территориясендә «Халыкара кооперация һәм экспорт» илкүләм проекты составында «АСК продукциясе экспорты» федераль проекты гамәлгә ашырылды. Алты ел эчендә 8 736 гектар мелиорация җирләре файдалануга тапшырылган, шул исәптән 5 618 гектар сугарулы җирләр, 1 709 гектар әйләнешкә кертелгән, шулай ук 1 408 гектар мәйданда сазлы кишәрлекләрне киптерү чаралары уздырылган. Инвестицияләр 1,9 млрд сум тәшкил итте, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 794 млн сум дәүләт ярдәме бирелде;

- «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне әйләнешкә кертү һәм комплекслы мелиорацияләү» федераль проекты буенча гидромелиоратив, культуртехник, агроурманмелиоратив чаралар һәм химик мелиорация (әче туфракны известьлау, фосфор кертү, гипс кертү) уздыруга чыгымнар кайтарыла.

2024 елда күрсәтелгән проект кысаларында Чүпрәле муниципаль районының Бикчуров Р.А. крестьян (фермер) хуҗалыгында 14,8 гектар мәйданда культуртехник чаралар үткәрелде (субсидияләр күләме 1,2 млн сум тәшкил итте), Азнакай муниципаль районының «Союз-Агро» ҖЧҖ 954 гектар мәйданында гидромелиоратив чаралар узды. Дәүләт ярдәме суммасы 37,9 млн сум тәшкил иткән, шул исәптән федераль бюджеттан – 22,7 млн сум, Җиһазлар белән төзелеш-монтаж эшләренең смета бәясе 76,6 млн сумнан артык тәшкил иткән.

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең химия мелиорациясе уздыруга киткән чыгымнарын финанслау (чәчүлекләрдә әче туфракны известьлау, туфракка фосфор кертү) 50 процент күләмендә ике программа буенча гамәлгә ашырыла:

- «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне әйләнешкә кертү һәм комплекслы мелиорацияләү» федераль проекты буенча. 2024 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бюджет акчаларының 259,7 млн сумы җиткерелгән, шул исәптән 60,2 мең гектарга известь кертү өчен федераль бюджеттан 155,8 млн сум;

- «Үсемлекчелек ярдәмче тармагын үстерү, үсемлекчелек продукциясен эшкәртү һәм сату» төбәк проекты буенча мелиорантлар (известьле һәм фосфор ашламалар) кертүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан. 2024 елда 1,8 мең гектар мәйданда мелиорантлар кертүгә 10,1 млн сум акча җиткерелгән.

Мелиорацияне үстерү өчен федераль программалардан тыш, республика программалары гамәлгә ашырыла, шул исәптән:

- муниципаль җирләрдә урнашкан гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау (Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән гамәлгә ашырыла). 2024 елда программаны гамәлгә ашыруга 830 гектар сугарулы җирләрне су белән тәэмин итү өчен алты объектта 102,4 млн сумлык эшләр башкарылган, шул исәптән бер объектта эшләр 2025 елга күчә;

- авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре җирләрендә урнашкан гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау. Субсидияләр, өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча, чыгымнарның 95 % финанс белән тәэмин

итү рәвешендә бирелә;

- мелиорация техникасын сатып алуга бәйле чыгымнарның 70%ын финанс белән тәэмин итү. 2024 елда 325,3 млн сумлык 48 сугару техникасы сатып алынган, шуларның 227,7 млн сумы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидия рәвешендә җиткерелгән;

- үсемлекчелек һәм терлекчелек объектларын су белән тәэмин итүгә тотылган чыгымнарның 70% каплау, скважиналар бораулауны һәм су җыю башняларын урнаштыруны да кертеп. 2024 елда 12 скважина төзелгән, 8 су җыю башнясы урнаштырылган, 30,0 млн сум дәүләт ярдәме күрсәтелгән;

- су бирү чараларына, авыл хуҗалыгы культураларын электр насослары белән сугару өчен күтәрүнең ике баскычлы схемасында су бирү өчен электр энергиясенә чыгымнарны да кертеп. Субсидия, өстәлгән бәягә салымны исәпләп, башкарылган чыгымнарның 60% кайтару рәвешендә бирелә. 2024 елда 2 730 гектар мәйданда авыл хуҗалыгы культураларын сугаруга су бирү өчен чыгымнарны финанслау 7,3 млн сум тәшкил иткән.

Еш кабатлана торган корылыкларның, атмосфера һәм туфрак корылыкларының тискәре йогынтысын киметү, шулай ук эрозия процессларын киметү максатларында Татарстан Республикасында эрозиягә каршы һәм кырларны яклау өчен урман утыртмаларын булдыру һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрендә файдаланудагы җирләрдә, шулай ук башка юридик затларга файдалануга тапшырылмаган муниципаль милектәге җирләрдә кыр саклагыч урман утыртмаларын торгызу чаралары гамәлгә ашырыла. Ел саен әлеге максатларга 150 млн сум (муниципаль җирләрдә урман мелиорациясе утыртмаларына – 130 млн сум, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренеке булган җирләрдә – 20 млн сум) бүлеп бирелә.

2024 елда урман мелиорациясе эшләре (шул исәптән кыр яклау, чокырларны томалау, эрозиягә каршы) 1 363 гектар мәйданда башкарылды. Әлеге эшләр 16 муниципаль районда гамәлгә ашырылды, Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау күләме 152,5 млн сум тәшкил итте.

Татарстан территориясендә шулай ук игенчелекнең агроландшафт туфракны саклаучы системалары проектлары гамәлгә ашырыла, алар югары һәм тотрыклы уңыш алуда, җирдән нәтиҗәле файдалануда һәм туфракның уңдырышлылыгын арттыруда һәм җитештерелә торган продукциянең экологик иминлеген торгызуда үрнәк булып тора. 2022 елдан башлап, Тукай, Әлмәт, Биектау, Әтнә, Кукмара, Тәтеш, Нурлат, Аксубай, Арча, Балтач, Мамадыш, Спас, Теләче муниципаль районнары хуҗалыкларында 37 проект (шул исәптән 2024 елда – 10 проект) эшләнде, 350 мең гектарга якын авыл хуҗалыгы җирләре колачланды.

Игенчелектә агроландшафт туфракны саклаучы системалар проектларын гамәлгә кертү авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен шактый җитди өстенлекләргә ия:

- авыл хуҗалыгы предприятиесенең экологик-географик һәм агроклимат шартларын анализларга мөмкинлек бирә;

- авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең торышын һәм перспективаларын, сугаруны үстерүнең перспективаларын билгеләргә мөмкинлек бирә;

- туфракны агроэкологик төркемләүне үткәрергә була.

Шулай ук игенчелекнең агроландшафт туфракны саклаучы системалары проекты туфракны эрозиядән саклау чараларын, чәчү мәйданнарының структурасын һәм чәчү әйләнеше, туфракны эшкәртү, орлыкчылык системасын, туфракның уңдырышлылыгын саклау һәм арттыру чараларын үз эченә ала.

## Җирле үзидарә мәсьәләләре

**47. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен финанс белән тәэмин итү.**

2025 – 2027 елларга республика муниципаль берәмлекләре бюджетлары, тәкъдим ителгән федераль индекс-дефляторларны исәпкә алып, республиканың берләштерелгән бюджетын төзүнең бердәм сценар шартларыннан чыгып формалаштырылды.

Бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда 2025 елга җирле бюджетлар, 2024 ел дәрәҗәсенә караганда 11,6 млрд сумга (яки 24,6 %) үсеш белән 58,9 млрд сум күләмендә законда беркетелгән салым һәм салымнан алынмаган керемнәр буенча фаразланган.

Җирле бюджетларның чыгымнары сценария шартлары нигезендә 2024 елга карата 18,7 млрд сумга (яки 19,8 %) үсеш белән 2025 елга үз вәкаләтләре буенча 112,9 млрд сум күләмендә билгеләнгән.

Шулай итеп, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларының чыгым вәкаләтләренең 2025 елга беркетелгән керемнәр белән тәэмин ителеше уртача 52,2 % тәшкил итте.

Бюджетара җайга салу нәтиҗәсендә физик затлар керемнәренә салым муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең бер өлешен алмаштыручы өстәмә нормативлар буенча җирле бюджетларга 27,9 млрд сум күләмендә күчерелергә тиеш.

Шулай ук җирле бюджетларның баланслылыгын тәэмин итү өчен 2025 елга Татарстан Республикасы бюджетында җирле бюджетларга 25,8 млрд сум күләмендә дотацияләр һәм субсидияләр каралган. Моннан тыш, җирле бюджетларга 3,7 млрд сум күләмендә максатчан субсидияләр бирелә.

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү максатларында 2025 елга Татарстан Республикасы бюджетында 47,5 млрд сум күләмендә субвенцияләр каралган.

Финанс ярдәмен исәпкә алып, республиканың җирле бюджетлары керемнәренең гомуми күләме 2025 елга 163,8 млрд сум тәшкил итте, «тискәре трансфертлар» түләү йөкләмәләрен исәпкә алып, чыгымнар күләме шулай ук 163,8 млрд сум.

Шул рәвешле, 2025 елга бюджетлар формалашуның сценарий шартларында җирле бюджетлар дефицитсыз булып тора.

**48. Гражданнарның үзара салым программасын 2024 елда гамәлгә ашыру һәм 2025 елга фаразлар турында.**

2013 елдан Татарстан Республикасында гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү программасы тормышка ашырыла.

Гражданнар үзара салым кертү мәсьәләләре буенча җыеннарда шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә туры килә торган чаралар кысаларында акчаларны тоту юнәлешләрен үзләре билгели.

Муниципаль берәмлекләрне социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсен һәм халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә кызыксындыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар тапшыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән (алга таба - Тәртип) Татарстан Республикасы бюджетыннан гражданнарның үзара салымы уздырыла торган муниципаль берәмлекләр бюджетларына өстәмә акчалар бүлеп бирү каралган.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 декабрь, 1397 нче карары нигезендә Тәртипкә башка бюджетара трансфертлар акчалары юнәлдерелергә мөмкин булган эшләр төрләрен билгели торган үзгәрешләр кертелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 ноябрь, 1532 нче карары белән Тәртипкә үзгәрешләр кертелде, алар нигезендә 2024 елда башка бюджетара трансфертлар трансфертларның норматив күләме чикләрендә бары тик авыл һәм шәһәр җирлекләре составына керә торган торак пунктларга гына бирелде, моңа республика муниципаль районнарының административ үзәкләре булган торак пунктлар керми. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 25 ноябрь, 1049 нчы карары югарыда күрсәтелгән таләпләрне куллануны 2025 елда һәм аннан соңгы елларда ныгытты.

Югарыда күрсәтелгән норматив хокукый актлар нигезендә гражданнарның үзара салымы кертелгән муниципаль берәмлекләр бюджетларына гражданнар җыйган һәр сумга республика дүрт сум бүлеп бирә («Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге өчен өч сум).

2014 елдан 2024 елга кадәр үзара салым тәртибендә татарстанлылар үз территорияләрен үстерүгә барлыгы 2 710,4 млн сум акча җыйганнар һәм гамәлгә керткәннән. Шул ук чорда Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашуның гомуми суммасы 10 409,9 млн сум тәшкил итте.

Гражданнарның үзара салым акчаларын уртак финанслау программасы агымдагы елда һәм 2026 - 2027 еллардагы план чорында дәвам итәчәк. Татарстан Республикасы бюджетында бу максатларга ел саен 1 352,1 млн сум акча каралган.

Үзара салым акчасына торак пунктлар эчендәге юллар, күперләр төзелә һәм ремонтлана, су белән тәэмин итү, авыл торак пунктларын яктырту эшләре башкарыла, ял итү урыннарын, спорт һәм балалар мәйданчыкларын, чишмәләрне, табигый һәм ясалма сулыкларны төзекләндерү эшләре алып барыла, һәйкәлләр һәм обелисклар урнаштырыла һәм реконструкцияләнә.

2024 елда үзара салым кертү җыеннарына әзерлек кысаларында «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе Татарстан Республикасы прокуратурасы һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән берлектә торак пунктларда үзара салым буенча гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәнең бертип проектын әзерләде һәм муниципаль берәмлекләргә җибәрде.

**49. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында.**

Татарстан Республикасында территориаль иҗтимагый үзидарә (алга таба – ТИҮ) актив үсүен дәвам итә.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы территориясендә 484 гамәлдәге ТИҮ исәпләнә (шул исәптән 29 ТИҮ юридик затлар буларак эшли), алар 28 муниципаль районда һәм 2 шәһәр округында эшчәнлек алып бара.

Муниципаль берәмлекләр территорияләрендә ТИҮ эшчәнлегенең төп юнәлешләре: халык белән оештыру эшләре; территорияләрне төзекләндерү һәм гражданнарга яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру; җәмәгатьчелек юнәлешендәге массакүләм мәдәни чаралар оештыру һәм үткәрү; физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрү; гражданнарның социаль яктан зәгыйфь категорияләренә ярдәм күрсәтү; иҗтимагый тәртипне саклау; махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү; идарә итүче оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү.

Татарстан Республикасында ТИҮ дәүләт ярдәме чараларыннан файдалана.

ТИҮ үстерүгә төп ярдәм чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче, «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче, «Татарстан Республикасы территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыруга, территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 31 октябрь, 988 нче Татарстан Республикасы карарларында китерелгән.

2015 елдан башлап, республика бюджеты турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә ТИҮ җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә ТИҮгә ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасының муниципаль районнарына (шәһәр округларына) субсидияләр бирү каралды.

Бүгенге көндә субсидияләрнең гомуми күләме 116,8 млн сум тәшкил итә.

2024 елның 1 гыйнварыннан ТИҮ җитәкчеләренә айлык түләүләр түбәндәгечә бүленә:

- юридик зат булган ТИҮ җитәкчесенә, шәһәр (авыл) җирлеге өчен – 20 502,7 сум, шәһәр округы өчен – 27 012,7 сум;
- юридик зат булмаган ТИҮ җитәкчесенә, шәһәр (авыл) җирлеге өчен – 15 747,1 сум, шәһәр округы өчен – 20 747,1 сум.

Ел саен үткәрелә торган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын (алга таба – Конкурс) уздыру йомгаклары буенча территориаль иҗтимагый үзидарәләр эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыру һәм гражданнарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү өчен грантлар бирә.

2023 елның 1 гыйнварыннан Республика конкурсының грант фонды 50 дән 73 млн сумга кадәр артты.

Ггрант фонды гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, спорт һәм массакүләм

мәдәни чаралар үткәрү, гражданнарның, махсус хәрби операциядә катнашучы затларның, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының социаль яктан зәгыйфь категорияләренә ярдәм итү, ТИҮ эшчәнлеге территорияләрен төзекләндерү һәм аларның иминлеген тәэмин итү, аларның эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту, муниципаль хакимият органнары, идарәче оешмалар белән хезмәттәшлек итү кебек критерийлар буенча аларның эш нәтиҗәләрен бәяләү нигезендә 120 ТИҮ арасында бүленәчәк.

2024 елдан башлап, грант акчасы түбәндәгечә бүленә:

- Конкурста җиңүчеләргә – иң күбе 1 млн.сум, шул исәптән ТИҮ рәисен бүләкләүгә иң күбе 28,5 мең сум, ТИҮ активын бүләкләүгә иң күбе 28,5 мең сум;
- Конкурс призерларына – иң күбе 477,77 мең сум, шул исәптән ТИҮ рәисен бүләкләүгә иң күбе 22,5 мең сум, ТИҮ активын бүләкләүгә иң күбе 22,5 мең сум.

Грантлар территорияне, паркларны, скверларны төзекләндерүгә, кече архитектура формаларын урнаштыруга һ.б., социаль-мәдәни чаралар үткәрүгә, бәйрәм декорацияләре, бүләкләр сатып алуга һәм иминлекне арттыруга юнәлдерелгән чараларга тотыла.

Татарстан Республикасында ТИҮ финанс ярдәме күрсәтү системасыннан тыш, аларга оештыру һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү системалары булдырылды һәм эшли.

ТИҮ эшли торган һәр муниципаль районда һәм шәһәр округында җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре арасыннан кураторлар билгеләнде, алар территориаль иҗтимагый үзидарәгә муниципаль хакимият белән үзара хезмәттәшлек иткәндә барлыкка килгән агымдагы мәсьәләләрне хәл иткәндә ярдәм итәләр.

ТИҮ мәгълүмати-методик ярдәм «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советы» ассоциациясе ТИҮ төзү һәм аның эшләве өчен кирәкле документларның бертип формаларын, аеруча еш бирелә торган сорауларга җавапларны рәсми сайтта (http://sovmo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән, шулай ук ТИҮ вәкилләренә телефоннан, электрон почта аша һәм шәхси очрашкан вакытта консультацияләр бирү юлы белән башкарыла.

2016 елдан башлап, Ассоциация ел саен республика министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре һәм ТИҮ җитәкчеләре катнашында ТИҮ эшчәнлегенең актуаль мәсьәләләре буенча күчмә конференцияләр уздырыла.

Конференцияләр кысаларында ТИҮнең үткән елга эш йомгаклары һәм киләсе елларга бурычлар турында, республикада ТИҮ эше тәҗрибәсен тарату турында мәсьәләләр каралды.

2024 елның июнендә Әлмәт шәһәрендә ТИҮ рәисләре өчен эшчәнлекнең актуаль мәсьәләләре буенча күчмә конференция үткәрелде.

Әлеге конференциядә катнашучылар түбәндәге докладларны тыңладылар: Татарстан Республикасында ТИҮ эшчәнлеге һәм аларга дәүләт ярдәме чаралары турында, җирле хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлек хакында.

Татарстан Республикасында ТИҮ органнары һәм җирле үзидарә органнары гамәлләрен координацияләү, ТИҮ системасын үстерү шартларын тәэмин итү, халыкның социаль әһәмиятле иҗтимагый инициативаларына ярдәм итү һәм аларны үстерү максатларында «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе президиумының 2016 елның 29 апрелендәге ПР-12-7 номерлы карары белән ТИҮ Координация советы төзелде.

ТИҮ Координация советы составына территориясендә ТИҮ төзелгән һәм

эшли торган һәр муниципаль районнан һәм Татарстан Республикасының шәһәр округындагы һәр районынан 1 җитәкче (рәис) керә.

Татарстан Республикасында ТИҮ җитәкчеләре өчен Казан федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе базасында «Территориаль иҗтимагый үзидарәнең заманча җитәкчесе» квалификация күтәрү программасы гамәлгә ашырыла. 2017 елдан башлап аның буенча 760 кеше укулар узган, шул исәптән 2024 елда – 101 кеше.

**50. Җирле үзидарә хезмәткәрләре хезмәтенә түләүне камилләштерү чаралары турында.**

Татарстан Республикасында сайланулы вазыйфаи затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән билгеләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының әлеге карары белән федераль һәм республика дәрәҗәсендә каралган муниципаль хезмәткәргә айлык акчалата түләү структурасы сакланып калды.

Муниципаль вазыйфалар һәм хезмәткәрләр буенча хезмәт хакын индексацияләү бер үк вакытта Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары һәм дәүләт хезмәткәрләре өчен кабул ителгән шундый ук карарлар буенча гамәлгә ашырыла.

2024 елның 1 июленнән хезмәт хакы уртача 20 процентка арткан. Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәдәге үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлау органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның айлык акчалата бүләкләү һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре 5 процентка үскән.

Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның акчалата түләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру белән бер үк вакытта муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар өчен һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру өлешендә хезмәткә түләүнең аерым шартлары 18 проценттан 41 процентка кадәр үзгәртелде.

2025 елның 1 гыйнварыннан акчалата түләү күләме 5 процентка арткан.

Моннан тыш, «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә дәүләт вазыйфалары, дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен дә, шулай ук Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен дә 2026 елның 1 гыйнварыннан һәм 2027 елның 1 гыйнварыннан вазыйфаи окладларны ел саен 5 процентка индексацияләү каралган.